Ризаэддин Фәхреддин

# АСАР

Беренче том

RUHIAT

Казан
«Рухият» нәшрияты
2006

ББК 63.3(2Рос=Тат)
Ф97

*Китап «Татнефть» ААҖнең Фәрит Вафин
җитәкчелегендәге «Чулпан» иминият компаниясе
матди ярдәме белән нәшер ителде*

Фәнни мөхәррир
*Миркасыйм Госманов,*
тарих фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Төзүчеләр
Татарча текст: *Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин*
Русча текст: *Сөләйман Рәхимов*

RUHIAT

Бизәлеш рәссамы
*Шамил Насыйров*

**Фәхреддин Ризаэддин**
Ф97 Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – 360 б.
ISBN 5-89706-100-9

ISBN 5-89706-100-9 © «Рухият» нәшрияты, 2006

## *Төзүчеләрдән*

Сезнең игътибарга мәшһүр татар галиме, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» дип аталган дүрт томлы биобиблиографик хезмәтенең беренче җилде-томы тәкъдим ителә. «Асар»ның бу томы 1900–1904 еллар дәвамында сигез аерым җөзьэ-кисәк рәвешендә Казан һәм Оренбург басмаханәләрендә нәшер ителгән.

«Асар» хәзерге татар теленә тәрҗемә ителеп, хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраклаштырылып, шул ук вакытта авторның стиль үзенчәлекләре сакланган хәлдә бирелә.

Әсәрнең төп нөсхәсендәге бит саннары ике сызыкчадан соң квадрат җәяләр эчендә күрсәтелде.

Китапта тәрҗемәи хәлләре тасвирланган шәхесләр һәм текстта очраган географик атамалар хезмәтнең ахырында аерым күрсәткечләр рәвешендә туплап бирелде.

Ризаэддин Фәхреддин, «Асар»ның икенче басмасын эшләү ниятендә булып, 1929 елда шуңа махсус «Сүз башы» да язган. Халкыбызның тәмам бетүенә ачынып язылган әлеге кереш сүзне бу китапка кертү мәгъкуль күрелде.

«Асар»ның өйрәнү даирәсен киңәйтү максатыннан төп текст рус теленә тәрҗемә ителде.

Китапны басмага әзерләү дәвамында ярдәм иткән галимнәр Марсель Әхмәтҗановка, Алсу Арслановага, Ильяс Мөстәкыймовка, Сиринә Баһавиевага, Лилия Байбулатовага, Илшат Гыймадиевкә рәхмәтләребезне җиткерәбез.

RUHIAT

## Мәдәни тормышыбыз тарихында «Асар»ның урыны

Халкыбыз кичергән гасырларның олы һәм каршылыклы вакыйгаларга бай булганлыгы бәхәссез, әлбәттә. Ләкин шул үзенчәлекле узганыбызның катлаулы һәм гыйбрәтле, вакыт-вакыт фаҗигале сәхифәләрен тулырак яктырта торган язма истәлекләр – үз телебездә иҗат ителгән махсус әсәрләр юк дәрәҗәсендә аз сакланган. Дөресрәге, андыйларның иң борынгылары безгә бөтенләй диярлек килеп җитмәгән. Төрле бәла-казаларда, ягъни объектив һәм субъектив сәбәпләр (әйтик, ихтыяҗ кимүдән күчермәләр эшләнмәү, вакыт узудан кәгазь таушалу, сугыш гарасатлары, янгын афәтләре) аркасында алар харап булып беткән.

Соңрак чорларда исә, дәүләтчелек бетерелү, ягъни халыкның этник-административ оешканлыгы, икътисади һәм мәдәни бердәмлеге җимерелү, шул рәвешчә авыр иҗтимагый һәм сәяси, рухи вә идеологик кысуларга тару нәтиҗәсендә, андый әсәрләр тудырылуга зарур булган шартлар – ихтыяҗ һәм мөмкинлек бөтенләй диярлек калмаган иде. Кешеләрнең үз тарихларына карата булган, була торган мөнәсәбәте шуңа күрә риваятьләр, мификлаша язган хатирәләр, нәсел-нәсәп истәлекләре, ягъни шәҗәрәләр, ниһаять, җыр-дастаннар нигезенә салынган аерым-өзек сюжетлар рәвешендә гәүдәләнергә мәҗбүр ителгән иде.

Бары соңгы дәверләрдә генә, яңа социаль катламнар үсеп чыгу (эшлекле буржуазия сыйныфы барлыкка килү, милли капитал туплану), беркадәре дини-рухи яңарыш омтылышлары барлыкка килү, шулар тәэсирендә милли аң – бер милләт, бер халык аңы формалашу нәтиҗәсендә татарча тарихи фикер яңадан җанланып, махсус «жанр» рәвешендә мәйданга чыга башлаган иде.

Мәдәни хәятыбыздагы бәхәссез олы шәхесләрнең берсе – бөек фикер иясе, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, әдип вә педагог, журналист һәм мөхәррир, гаҗәп киң колачлы тарихчы галим Ризаэддин Фәхреддиннең (1859–1936) «Асар» исемле фундаменталь биобиблиографик хезмәте менә шул яңа дәвер тарихи фикеребезнең иң күренекле истәлекләреннән берседер.

«Асар»ның гыйльми хезмәт буларак кыйммәтен, тарихи чыганак буларак әһәмиятен, андагы күпкырлы материалларның бирелү үзенчәлеген төрле яклап аңлар һәм алардан нәтиҗәле рәвештә файдаланыр өчен аның жанр сыйфатына һәм, гомумән, Шәрекъ дөньясында туган, күп гасырлар хөкем сөргән мондый биобиблиографик тарихи жанрның «елга башына» мөрәҗәгать итү, аның бездәге традициясенә дә кыскача тукталып узу зарур булса кирәк.

Мәгълүм булганча, IX–X гасырларда, ягъни Якын һәм Урта Шәрекътә ислам дине киң таралып, Гарәп хәлифәлеге колач җәйгән чорларда, гарәпчә язма традиция, җөмләдән тарих һәм география белемнәре буенча булган әдәбият та, тәмам формалашып, үз йөзен таба. Соңрак гасырларда исә бу традиция гомумән һәм бу төр әдәбият бигрәк тә зур казанышларга ирешә. Гарәпчә тарих белеменең бер мөһим тармагын персоналии – күренекле шәхесләрнең (дин вә дәүләт әһелләренең, галим-голәма һәм әдипләрнең) тормыш юлларын, эшчәнлекләре белән мирасларын яктырта торган махсус әсәрләр, ягъни тәрҗемәи хәлләр тәшкил итә.

Әле генә күрсәтелгән гасырларда һәм алардан соңгы чорларда иҗат иткән галимнәрне, гарәп телендә язылган андый хезмәтләрне дистәләп-дистәләп санарга мөмкин. Шулар арасында иң характерлы һәм атаклыларының берсе сыйфатында, гадәттә, Әбү Фазыл Шиһабеддин Әхмәд бине Гали Ибне Хәҗҗәр әл-Гаска-

ланиның (1372–1449) хезмәтен күрсәтәләр. Аның «Әд-дөррел-кяминә фи агъян әл-къәрн әс-сәминә» (ягъни «Сигезенче гасырның күренекле кешеләре турында яшерен энҗеләр») дип аталган зур күләмле әсәрен һиҗри белән VIII гасырда (1300–1397) мөселман илләрендә яшәгән, үлгән күренекле шәхесләргә багышланган биобиблиографик энциклопедия дип атарга мөмкин.

Шуны да әйтергә кирәк, Ибне Хәҗҗәрнең бу фундаменталь хезмәтендә һәм аның «Зәйл...» дигән, «Әд-дөррел-кяминә...»не дәвам иткән «Өстәмә»сендә без гарәпчә биографик әдәбият жанрының тәмам оешып җиткән төп сыйфатларыннан берсен – мәгълүматларны тәрҗемәи хәл иясенең вафат вакыты буенча урнаштырылу алымын күрәбез. Ягъни биографияләрнең урыннарын билгеләүдә исем һәм фамилияләрне (бу очракта дөресрәге: тәхәллүс, нисбә яки ләкабләрне) алфавит тәртибендә түгел, бәлки кеше гомеренең соңгы чиге (эшчәнлекнең тәмамлануы) буенча тәртипкә салуны, димәк, иң эзлекле хронология принцибы кулланылуын күрәбез. Мондый алым исә тарихи эзлеклелекне төгәлрәк күзалларга ярдәм иткән.

Гарәпчә биографик әдәбиятта барлыкка килгән мондый ысул мөселман халыклары, җөмләдән татарлар тарафыннан да кагыйдә рәвешендә кабул ителгән иде. Бездә, мәсәлән, мондый кагыйдәдән үзенең «Вафийәт әл-әслаф вә тәхийәт әл-әхлаф» исемле фундаменталь хезмәтендә Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләре (1818–1889) актив файдаланган. Икенче зур мисал сыйфатында Ризаэддин Фәхреддин каләменнән чыккан «Асар»ны атарга мөмкин.

Дөрес, әле аталган татар галимнәренең хезмәтләре һәм гарәпчә классик биографик әсәрләр арасындагы уртаклык бер хронология алымының охшашлыгы белән генә чикләнми, әлбәттә. Төп уртаклык биография объектының туганнан алып үлгәнгә кадәрге тормыш юлын, эшчәнлеген, аның үз шәхесен генә тасвирлау белән чикләнмичә, ул яшәгән, гамәл иткән шартлар һәм даирәне дә мөмкин кадәр тулы һәм әтрафлы итеп яктыртуда чагыла. Тулы биографиядә тәрҗемәи хәл иясенең нәсел-нәсәбе, ата-анасы, гаиләсе, барлык балалары, алар аркылы кемнәр белән туганлашуы, белем алган чактагы остазлары, укыган мәдрәсәләре, өйрәнгән китаплары, үз шәкертләре, тоткан дәрәҗә һәм кылган эшләре, шулай ук иярчен яки фикердәшләре, сафташлары, шәхси дошманнары белән көндәшләре, эшчәнлек һәм холкының өстенлекләре белән кимчелекләре хакындагы, ниһаять, вафат булгач, кемнәр җеназа укып, кайда күмүләренә кадәрге мәгълүматлар китерелгән була.

Табигый ки, биографиянең үзәгендә мәрхүмнең иң әһәмиятле эшләре күрсәтелеп, әгәр ул каләм әһеле булган булса, язган әсәрләренең исемлеге, кайберләреннән өзекләр китерелә һәм ул язган яки аңар күндерелгән хатларның вә башка документларның текстлары да урнаштырыла.

Дөрес, язылган тәрҗемәи хәлнең тулылык, объективлык һәм аныклылык сыйфаты җыелган мәгълүматларның байлыгы белән генә чикләнмәгән. Аны язучы авторның белем һәм эрудициясе, материалларны җыю һәм эшкәртү осталыгы, документ төрләренең әһәмият вә кыйммәтләрен аңлый алу, бәяли белүе, ниһаять, шуларның иң мөһимнәрен сайлаудагы маһирлыгы да зур роль уйнаган.

Шуны да искәртү зарур: тарих өлкәсендәге бөтен эшчәнлегеннән күренгәнчә, Ризаэддин хәзрәт Шәрекъ дөньясындагы мәгълүм галимнәрне яхшы белгән һәм аларның хезмәтләрен җентекләп өйрәнгән икән. Үз оппонентлары белән бәхәсләшкәндә, ул, бер Ибне Хәҗҗәр белән генә чикләнмичә, әт-Табари, әз-Зәһәби, Ибне әл-Асир, Ибне Хәлдун, әл-Фәраби, Бируни фикерләренә дә таянып хөкем чыгара.

RUHIAT

Шәрекъ дөньясында барлыкка килгән, күп гасырлар дәвамында эшкәртелгән, үстерелгән, бәхәссез дәрәҗәдә камиллеккә ирешкән биография жанрының казанышларын, барлык нечкәлекләрен үзләштерә алган Риза казый Фәхреддин, теге яки бу тәрҗемәи хәлне өйрәнгән, тасвирлаган чакта, әле күрсәтелгән таләпләрнең һәммәсен дә күз уңында тотарга тырышкан. Бер урында ул үзенең биография язу принципларын, образлы итеп, болайрак аңлата. Мин, ди, ялгыз «агачны» тасвирлау белән чикләнмичә, аның тирәсендәге башка «агачларны» да исәпкә алырга, ягъни объектны бөтен әйләнә-тирәсе, даирәсе белән күрсәтергә тырыштым, ди. Димәк, Р.Фәхреддиннең мондый эш алымында аның методологик принциплары да чагылыш тапкан. Галимнең аерым шәхесләр биографиясенә багышланган зур күләмле әсәрләреннән Ибне Рөшед, әл-Гарәби, Имам Газзали, Әхмәд бай һәм Ибне Тәймиягә багышланган китапларында, «Шура» журналында басылган зур күләмле мәкаләләрендә, ниһаять, «Асар»да урын алган биографияләрнең күпчелегендә дә аның шушы принципларга тугрылыклы булып калырга тырышуы күзәтелә.

Әлбәттә, «Асар»да яктыртылган тәрҗемәи хәлләрнең һәммәсе дә тулылык һәм төгәллек җәһәтеннән бер дәрәҗәдә түгелләр. Тәфсилле мәкалә-очерклар белән янәшәдә кыскача белешмәләр дә җитәрлек. Бары исемнәр белән үлгән ел тарихы гына теркәлгән очраклар да аз түгел. Һәм бу аңлаешлы: теге яки бу биографиягә караган материалларның автор кулына килеп керү микъдарлары да төрлечә булып, бер дәрәҗәдә, бер күләмдә саклана алмаганлыгы да табигый. Ягъни бу тәрҗемәи хәлләрнең теләсә ничек әвәләргә мөмкин автор хыялы җимешләре түгел, бәлки аңа ирешелгән реаль мәгълүматларның чагылышы икәнлеге дә бәхәссез. Димәк, югарыда куелган «таләпләрдә» сүз мөмкинлек хакында гына түгел, бәлки «шулай кирәк»лелек – идеал турында барды.

«Асар» өстендә эшләгән чакта Риза казый ихтыярында булган мөмкинлек мәсьәләсе, минемчә, кыскача булса да махсус яктыртуны сорый.

Мәгълүм булганча, 1890 елда Диния Нәзарәтенә казый итеп билгеләнгән, 1891 елдан алып Уфада яши башлаган Риза Фәхреддин тормышында зур борылыш барлыкка килә. Нәзарәттәге казыйлык эше аңар өлкән дәрәҗә, чагыштырмача мулрак тормыш шартларын гына түгел, бәлки гыйльми юнәлештә дә киң мөмкинлекләр тудырган иде. Чөнки еллар буена анда җыела килгән, тәртипсез рәвештә өелеп ята биргән басма һәм язма китапларны карый-карый, укый-укый тәртипкә салу, авыл шартларында төшкә дә керми торган төрле телләрдәге газит-журналлар белән иркенләп танышу күктән өмет иткәнне җирдән табу белән тиң иде.

Риза казыйга шулай ук Нәзарәттә йөз ел дәвамында барлыкка килгән бай архивны җентекләп өйрәнү, тәртипкә салу эше дә насыйп була. Очраган һәр кызыклы документтан үзенә күчермәләр ала бара ул. Ә Нәзарәт архивы гаҗәп бай булып чыга. Халыклар төрмәсе булган Русия шартларында бернинди дөньяви оешмалары, идарәләре булмаган, була алмаган мөселманнар өчен Диния Нәзарәте социаль-иҗтимагый тормышны да, мәктәп-мәгариф эшләрен дә әзме-күпме дәрәҗәдә тәртипкә салуга өлеш керткән, алар белән хәл кадәри идарә итү буенча да эш күрсәткән идарә иде. Шуңа күрә йөз ел дәвамында анда җыелган бихисап кәгазьләр арасында тормышыбызның төрле якларын яктырткан беренче кул документлар – асыл чыганаклар гаҗәп күп булган.

Бай китапханә хәзинәлегендә актарыну, төрле документлардан күчермәләр алу иртә-кичен дә, ял һәм бәйрәм көннәрендә дә дәвам итә. Эшчәнлеген дини публицист, иске мәдрәсә педагогы сыйфатында башлап җибәргән Риза казый әлеге китаплар, әлеге бихисап оригинал документлар тәэсирендә тарихчылык

RUHIAT

ягына борыла. Дини иманына дөньяви ышанычлары да кушылу аны үзе өчен махсус тарихи мәүзугъ – тема сайлауга китерә. Яшьли алган тәгълим-тәрбиясе, тырышып җыйган аң-белеме аңар теманы да ачыкларга ярдәм итә. Тарихи юнәлеш буенча аны ул болайрак билгели (телен гадиләштереп бирәм): «Үз мәмләкәтебездә булган ислам галимнәренең тәрҗемәи хәлләре, туу вә вафат тарихлары һәм башка әхвальләре...» Китап исеме астына аңлатма рәвешендә язылган бу сүзләргә соңрак, «галимнәрдән» соң, «вә мәшһүр кемсәләр» дигән өстәмә дә кертелгән.

Күп томлы китап булыр дип уйланылган бу яңа хезмәтенә Р.Фәхреддин «Асар» дигән тирән мәгънәле исем бирә.

Гәрчә бу сүз безгә яхшы таныш «әсәр» белән бер тамырдан булып, аның күплек саны формасына беркадәре охшап китсә дә, Р.Фәхреддиндә, ягъни нәкъ бу очракта, ул сүз «Эзләр, билгеләр, истәлекләр, калдыклар» дигән мәгънәдә кулланылган. (Асаре гатика – археологик, археографик истәлекләр, калдыклар һ.б.) Шуңа күрә аны татарча һәм башкортчада «әсәр» яки «әсәрләр» дип аңлау һич тә дөрес түгел.

Хезмәт, Риза казый уйлавынча, җилдләрдән – томнардан, томнар исә үз нәүбәтендә аерым басыла торган җөзьэләрдән – өлеш яки кисәкләрдән торырга тиеш була. Беренче томның беренче өлеше 1900 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә. Бу томга караган башка җиде кисәге 1901–1904 еллар арасында Оренбургта нәшер ителә. Җиде кисәктән торган икенче җилд исә 1904–1909 еллар арасында шулай ук Оренбургтагы татар нәшриятларында дөньяга чыга.

Югарыда бер әйтелгәнчә, шәхесләр хакындагы биографик материаллар «Асар»да хронологик тәртип буенча урнаштырылган. Беренче җилднең беренче кисәгенең шактый өлешендә Әхмәд Ибне Фазланнан башлап Болгар дәүләте, Җучи Олысы (Алтын Урда) һәм Казан ханлыгы дәверләреннән исемнәре сакланып калган кешеләр хакындагы кыска-кыска мәгълүматлар бирелгән.

Борынгы чорга караган материалларның болай шактый «сыек» булуы, мәкаләбез башында махсус күрсәтелгәнчә, шул заманнарга мөнәсәбәтле чыганакларның гаять аз саклануына бәйле. Хезмәтнең бу өлешендәге кыскача белешмәләрнең күпчелеге Шиһабеддин Мәрҗани һәм башкаларның мәгълүм китапларыннан алынганлыгы ап-ачык. Бары икенче кисәкнең урталарыннан биографик материаллар «куерак» һәм саллырак була башлый. Ягъни XVIII гасырның ахырларында һәм аннан соң үлгән кешеләрнең тормыш юллары һәм эшчәнлекләре хакындагы мәгълүматлар җитди төс алалар. Димәк, Диния Нәзарәте архивының сыйфаты үзен сиздерә башлый. Һәрхәлдә, беренче җилднең икенче җөзьэсе уртасыннан XVIII гасырның ахырында вафат булган кешеләр хакында сүз башланса, томны йомгаклый торган сигезенче кисәктә сүз 1843 елда үлгән кешеләр белән тәмамлана. Беренче томның гомум күләме 483 бит һәм анда озынлы-кыскалы 222 биография буенча мәгълүмат тупланган.

Гомум күләме (күрсәткечтән башка) 564 биттән гыйбарәт икенче томда 1843–1874 еллар арасында үлгән тагын 243 кешенең биографиясе яктыртылган. Шулай итеп, ике томда барлыгы 465 тәрҗемәи хәл яки шулар өчен кирәкле белешмә һәм материаллар тупланган икән.

Материалның сан ягына игътибар итү белән бергә аның сыйфат мәсьәләсен дә истән чыгармаска кирәк. Ике томда бирелгән биографияләрнең зур өлеше руханиларга – шул чор татар җәмгыятенең «каймагына» багышланган. Моның хакта алда да махсус сүз булыр әле.

RUHIAT

Икенче томның ахырында бирелгән «Соңгы сүз»дән күренгәнчә, автор өченче томны, кисәкләргә бүлеп тормыйча, бер китап рәвешендә бастырырга әзерләгән икән. Хәтта «Шәрекъ» китапханәсе белән аны бастыру хакында килешенү дә булган. Тик эшләнеп беткән, 1874 елдан башлап «ошбу көнемезгә кадәр» (1909 елга) килеп җитәчәк материалларны эченә алган том «Шәрекъ» вәгъдәсеннән соң да дөньяга чыкмыйча кала.

Болай килеп чыгуга берничә фактор сәбәп булганга охшый. Беренчедән, автор үзе махсус күрсәткәнчә, сирәк кешеләр, нигездә галим-голәмалар гына файдалана торган, димәк, азрак сатылачагы алдан ук билгеле булган китапны бастыру эшенә атлыгып торучы нашир табылмый. Икенчедән, бурычка акча табыла дип торганда гына, галим башына көтелмәгән бәла-каза ишелеп төшә: 1911 елның 12 февраленә каршы төндә Риза казыйның өендә полиция һәм жандармерия тарафыннан тентү булып, аның бөтен кулъязмалары, җөмләдән «Асар»ның өченче томы да кулга алына – бер олау китап-кәгазь йөге элек Сарапулга, аннары Казанга озатыла. Шул рәвешчә, туздырылган, өлешчә югалган шәхси архив бары бер елдан соң (1912 елның 17 февралендә генә) галимгә кайтарыла. Тагын акча мәсьәләсе алга килеп баса. Авторның 1912–1913 елларда «Шура» журналы аркылы наширләргә мөрәҗәгать итүе нәтиҗә бирми. Галимҗан Ибраһимовның «Аң» журналындагы махсус мәкалә-өндәмәсе дә (җәмәгатьчелекне бераз оялтырга тырышуы да) файда китерми. Шул рәвешчә, эзләнеп-соранып йөргән арада ике-өч ел узып, беренче бөтендөнья сугышы башланып китә.

Ләкин, нәшрият юлында уңышсызлыкларга очрауга карамастан, Ризаэддин Фәхреддин «Асар» өстендә эшләвен дәвам итә. «Шура» журналы битләрендә, материаллар сорап, киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итүен кабатлап тора. Мәгълүматлар туплавын, җыелган материалларны эшкәртүен хәтта совет чорында да – гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән, мөфти килеш тә «йорт әсире» хәлендә калган рәвештә дә туктаусыз дәвам итә. Әллә кайчан язылып беткән өченче томны, хәреф җыючыларга җайлылык өчен, аерым кәгазьләрнең бер ягына гына теркәлгән текстларны, кат-кат эшкәртеп, бер төпләмгә яңадан күчереп чыга. Аңа сыймаган яңа материаллар нигезендә дүртенче томны да оештыра башлый. Нормаль кәгазь җитешмәү сәбәпле, текстларны галим амбар кенәгәләренең файдаланылмый калган ак битләренә күчереп яза. Дөрес, патша заманының амбар кенәгәләре, 20–30 нчы еллардагы совет кәгазьләренә караганда, күпкә сыйфатлырак булган икән!

Бу материаллар белән мин 1966 ел башында, Р.Фәхреддин архивы әле Диния Нәзарәтендә саклаган чакта, беренчеләрдән булып танышкан идем. Галимнең кырык томлы кулъязма архивының зур өлеше белән бергә.

Шул ук елда Ленинградтагы ориенталистлар архивында «Асар» өчен җыелган документларның төп нөсхәләре белән дә беренче булып танышырга туры килгән иде. Аларны карт галим 1935 елда академик А.Н.Самойловичка җибәргән булган. Ышанычлырак җирдә саклансын өчен. Тик алар 1966 елга кадәр ачылмаган хәлдә яткан икән. Болар хакында беренче хәбәр шул елда ук басылып чыккан иде (Казан утлары, 1966, 7 сан).

Инде килеп, «Асар»ның барлыкка килү тарихы, аның жанр үзенчәлеге, соңгы томнарының аяныч язмышы белән кыскача булса да танышкан укучыда шундый сорауларның тууы ихтимал:

Китапның язылу тарихы, соңгы язмышы гыйбрәтле генә булса да, андагы материалларның бүгенге көн өчен әһәмияте бармы, булса – нәрсәдә?

Тәрҗемәи хәл ияләренең зур күпчелеген руханилар тәшкил иткән биографик җыелманы яңадан бастырып чыгарудан фәнгә нинди файда?

RUHIAT

Ниһаять, бер мәртәбә басылган китапларны икенче кат чыгарганчы, «Асар»ның өченче-дүртенче томнарын нәшер итү турында уйлау дөресрәк булмасмы?

Мондый сорауларның вариантлары (хәтта күпкә «усалраклары») элек тә яңгыраган кебек, аларның кайберләрен бүген дә ишетергә туры килгәли. Шуңа күрә аларга кыскача булса да җавап бирергә кирәктер.

Беренчедән, «Асар»ның төп кыйммәте, югарыда махсус күрсәтелгәнчә, аның документаль мәгълүматлардан, хәтта шул документларның үзләреннән, ягъни текстлардан гыйбарәт булуында. Авторның хәбәрләре, гәрчә алар иркле хикәяләү сыманрак тоелсалар да, асылда төрле рухтагы документларның сөземтәсеннән тора. Алар исә элегрәк материал җыйган авторларның хезмәтләреннән (мәсәлән, Мәрҗанидән), Диния Нәзарәте архивыннан (әйтик, рәсми белешмәләр белән метрик язмалар, гариза һәм шикаятьләрдән) чүпләнгән, шулай ук төрле кешеләр җибәргән хәбәрләр һәм хатлардагы фактлардан гыйбарәт. Ниһаять, элекке каләм ияләренең әсәрләре аталуы, алардан үрнәкләр, өзекләр бирелүе дә биографияләрнең документаль нигезен көчәйткән. Бу уңайдан бер генә фактны атау да җитә. Мәсәлән, моңа кадәр без Шәмседдин Зәки исемле олы шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты хакында бары «Асар»дагы хәбәрләрдән генә белеп килдек.

Риза Фәхреддиннең бик теләп, яратып файдаланган документларының бер төре сыйфатында хосусый хатларны атарга кирәк. Чөнки галим аерым кешеләрнең бер-берсенә язган мәктүпләре ише нигездә субъектив рухлы язмаларның шул шәхесләрнең үз йөзләрен, кешелек сыйфатларын, интеллектуаль дәрәҗәләрен ачу, бәяләү өчен иң ышанычлы, димәк, бу очракта объективлыкка күбрәк якын чыганак икәнлеген яхшы аңлап гамәл кылган.

RUHIAT

«Асар»ның документаль нигезләре хакында болай тәфсилләп сөйләү һич тә очраклы түгел: галим үзе кат-кат күрсәткәнчә, бу хезмәт төгәл тәмамланган тарих китабы түгел әле. Бәлки киләчәктә язылачак тарихи әсәрләргә нигез булачак материаллар – фактлар җыелмасы ул. Шулай булгач, «Асар»га мөрәҗәгать итү һәр буын саен яңарып, кабатланып торачак. Файдаланучылар арасында татар тарихчылары белән бергә гомумән ориенталистлар да булачак. (Моңарчы да гарәп язулы төрки кулъязма истәлекләрне өйрәнгән, тасвирлаган чакта, ленинградлы совет галимнәренең һәм аурупалы ориенталистларның «Асар»дагы материаллардан файдаланулары мәгълүм факт.)

Димәк, җыеп әйткәндә, тарихыбыз өчен «Асар»ның гыйбрәтле язмышыннан бигрәк, аның документаль мәгълүматлары мөһимрәк һәм кыйммәтрәк икән. Чөнки узганыбызны азмы-күпме дәрәҗәдә үзебез үк төгәлрәк белергә, башкаларга да беркадәре белдерергә, шул рәвешчә, киләчәгебезне дә дөресрәк күзалларга теләсәк, тарихи фактлардан торган мәгълүматларны сакларга, өйрәнергә, алардан нәтиҗәле рәвештә файдаланырга тиешбез. Ә мондый ихтыяҗ исә аларның әледән-әле тулыландырылуын, мөмкин кадәр киңрәк җәмәгатьчелеккә ирешүен, ягъни басылып чыгуын таләп итә.

Гыйльми белемнең, әгәр ул чын белем булса, гомум кагыйдәсе, хәтта какшамас кануны шундый.

Икенчедән «Асар»дагы мәкаләләрнең күпчелеге руханилар, дин әһелләре биографияләренә караган булуы кайберәүләрдә икеләнүле сораулар тудыруы ихтимал. Чөнки безнең күпчелегебез вульгар һәм субъектив атеизм рухында тәрбияләнгән кешеләр: диннең тормыштагы урынын күрмәмешкә салынудан мәгънә, мәнфәгать эзләүгә күнеккән мәнсез халык. Моңарчы дини узганыбызга күз йому, руханиларга карата «мулла-монтагай» дип кенә аларны түбәнсетергә тырышулар шуның галәмәте.

Чынбарлык исә күпкә катлаулы, каршылыклы һәм шунысы белән бай эчтәлекле булган. Халык, ил тормышындагы шул каршылык һәм байлыкның аерылгысыз бер өлеше, һичшиксез, югары катламны тәшкил иткән руханилардан, аларның эшчәнлегеннән гыйбарәт булган. Чөнки XVI–XVII гасырларда баштан кичкән гарасатлы вакыйгалар, ягъни яулап алыну, талану, төрле чаралар ярдәмендә югары катламнарның, ягъни татар аксөякләренең юк ителүе нәтиҗәсендә кавемне оештырып торучы катламсыз («изүче» сыйныфларсыз) калган җәмгыятьтә үзенчәлекле социаль вакуум барлыкка килгән иде. Шул бушлыкны, моңарчы (Хөсәен Фәезхановка багышланган китапта) бер әйткәнемчә, руханилар «тутырып» торган иде. Икенчерәк итеп әйткәндә, колониаль изү нәтиҗәсендә икътисади һәм сәяси зәгыйфьләнеп, таркалып (өлешчә чукындырылып, өлешчә сөрелеп), ахыр чиктә бөтенләй диярлек туздырылып юкка чыккан татар феодалларының – элекке оештыручы көчләрнең урынын дин әһелләре алган, алырга мәҗбүр булган иде. Әгәр 1552 елдан соң бернинди дөньяви-иҗтимагый институтлары, идарә һәм оешмалары калмаган татарларның 400 елга якын сузылган аяусыз изү, эзлекле чукындыру аркылы да, – халыкның зур күпчелеге бер кавем буларак, – үз йөзен саклап чыга алган икән, монда да иң элек ислам диненең һәм мәктәп-мәдрәсә тоткан мөселман руханиларының роле, әһәмияте бәхәссездер.

Ачыграк итеп әйткәндә, дүрт гасырга якын хөкем сөргән туктаусыз тапалудан соң да халкыбызның иҗтимагый аренага Мәрҗани һәм Фәхреддиннәрне, Исхакый һәм Тукайларны чыгара алуында, милли китабын үстереп, яңаруга сәләтле әдәбиятын саклауда, вакытлы матбугатын, хәрәкәтчән театрын тудыруда, ниһаять, милли рухның эчке җегәрләреннән килә торган олы омтылышның – мәгърифәтчелек һәм җәдитчелекнең киң җәелә алуында, ягъни татарның милләт буларак саклануында, яшәп үсүендә, гел алга, гел киләчәккә каравында әлеге күпсанлы руханиларыбыз өлеше, һичшиксез, зур иде. Дөрес, руханилар эшчәнлегендә консерваторлык, кинәт калкып чыккан, актив гамәл иткән яңалыкларга каршы булу, аларның юлларына аркылы яту сыйфаты да характерлы иде. Ләкин шундый яңалыкларның тудырылып, үстерелеп торулары да шул ук руханилар тоткан юлның, тәгълиматның асыл табигатенә хас иде. Мондый диалектик эчке бердәмлекне күрмәү һәм аңламау примитив сукырлык вә мәнсезлек галәмәте булса, аны күрергә һәм аңларга теләмәү исә аңлы намуссызлыкка кайтып калыр иде. Бездә, кызганычка каршы, боларның икесе дә булды, мәгәр соңгысы күбрәк һәм оештырылган рәвештә хөкем сөреп торды. (Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтик: әле генә билгеләп узылган консерваторлык ул бары татар тормышында гына йөз биргән күренеш түгел, бәлки җәмгыятьне оештырып, билгеле бер дәрәҗәдә тәртип саклап торырга тиеш булган һәм була торган барлык хаким катламнар өчен дә теге яки бу күләмдә хас, уртак, шуның белән котылгысыз күренеш.)

Ислам диненең, мөселман руханиларының бездәге тарихи әһәмиятләрен бары соңгы заманнарга гына хас күренешләр белән дә чикләп куярга ярамастыр. Монгол яулап алулары фаҗигасен кичергән мөселман болгар халыкның Җучи Олысы (Алтын Урда) чорында «яңадан туып», кан яңартып аякка нык басуын, Казан ханлыгы оешуга этник нигез булуын, аннан соңгы афәте өч-дүрт гасыр дәвамында болгар чоры цивилизациясенең мирасы булган болгарчылык аңын буыннан буынга әманәт итеп бирә килүен исәпкә алсак та, югарыда әйтелгән фикерләр көчәйгәннән-көчәя төшә. Бу әйтелгәннәрнең хаклылыгын аңлар өчен әйләнә-тирәбезгә күз салу да җитә. Әйтик, XIII–XVI гасырлардагы Чулман-Идел-Ука елгаларының урта агымы бассейнында масса, ягъни гомум җан исәбе ягыннан шунда яшәгән мөселман төркиләрдән әллә ничәгә күбрәк булган мәҗүси, димәк, рухи һәм иҗтимагый оешмаган фин-угор халыкларының язмышларына, бүгенге

RUHIAT

менталитет һәм мөмкинлекләренә күз салыйк. Аңлы кешегә артык аңлатма кирәкмәстер, шәт!

Димәк, элекке руханиларыбыз иҗтимагый аң, милли тел, укый-яза белү, җыеп әйткәндә, милләт саклануга да билгеле өлеш керткән икән. Ризаэддин Фәхреддин әйткәнчә, теле сакланмаган, иҗтимагый аңы (җөмләдән тарихи белеме) булмаган кавем аерым халык, милләт буларак яши алмый.

Шул ук вакытта халыкта иман һәм рух, этник кавем аңы һәм гамәли культура элементлары саклануга объектив рәвештә зур өлеш керткән руханиларыбызның шул халыкның түбән катламнарын социаль изүгә дә шактый көч куюларына күз йомып булмый. Икенчерәк итеп әйткәндә, татар мөселман руханиларының, гадәти иҗтимагый-интеллектуаль катлам хәлендә генә калмыйча, социаль категория – югары сыйныф дәрәҗәсенә дә күтәрелүе, берьюлы дөньяви функцияләрне үтәүләре дә бәхәссез. Мәсьәләнең шушы мөһим ягын да безгә әтрафлап аңларга вакыт инде.

Кыскасы, «Асар»да тәрҗемәи хәлләре тасвирланган шәхесләр узган тормышыбызның аерылгысыз өлешен – зарури социаль катламын тәшкил итүчеләр иде. Һәм Риза Фәхреддин язган биографияләр, кем әйтмешли, «мулла-монтагайларга» дан җырлау түгел, бәлки узгандагы җәмгыятебезнең өстен катлаулары-на – «каймагы һәм сөт өстләренә», аларның табигатен, рухын вә гамәлләрен, шулай ук «гамәлсезлекләрен» дә ачып бирә торган характеристикалар. Моның шулай икәнлеген Риза казый хөкемнәренең объективлыгында, хәтта кырыслыгында да күрергә мөмкин. Биография ияләренең берсен дә ул күпертеп мактамаган, ягъни идеаллаштырмаган, эшчәнлекләренең уңай, халык өчен файдалы якларын күрсәтү белән бергә, үз геройларының фикер һәм гамәлдәге ялгышларын, шәхси кимчелекләрен дә ачыктан-ачык билгеләп барган. Әлбәттә, мөмкин булган дәрәҗәдә. Элекке татар руханиларының күпчелеге урта кул белемле булуларын, еш кына юк-бар белән мәш килүләрен, фанатизмга бирелүләрен, кайбер очракта динлелек урынына динчелек белән шөгыльләнүләрен дә яшереп тормаган галим. Шушы туры сүзлелеге өчен аңар шелтәләр ишетергә дә туры килгән. Ләкин үз фикереннән, үз иманыннан Риза казый чигенмәгән. «Асар», ди галим, «мактау китабы» түгел, бәлки чорның, чынбарлыкның «көзгесе» булырга тиеш мәгълүматлар, документлар җыелмасы ул.

Шулай итеп, җыеп әйткәндә, «Асар»да тупланган материаллар, бездә элек бозып аңлатылганча, «чикләнгән, консерватив, файдасыз» нәрсәләр түгел, бәлки халык, ил тарихының реаль чынбарлыгын яктыртуга сәләтле, шуңа күрә өйрәнелүе зарур мәгълүматлардан гыйбарәт икән.

Өченче мәсьәлә яңа басмаларны «Асар»ның кайсы томыннан башлауга карый. Сүз дә юк, кулъязма килеш калган өченче-дүртенче җилдләр дә дөньяга чыгарга тиешләр. Һичшиксез. Чөнки алардагы мәгълүматлар һаман гыйльми хәрәкәттән читтә кала киләләр (кайбер хезмәтләрдә алардан аерым өзекләр генә бастырылу мәсьәләне хәл кылмый). Ләкин XX гасырның башында ук аерым-аерым, таркау кисәкләр (җөзьәләр) рәвешендә нәшер ителгән, вакыт узу белән сирәк китаплар хәленә төшкән, язу һәм тел-стиль үзгәрү сәбәпле бүгенге укучыга аз аңлаешлы булып калган, ниһаять, идеологик басым аркасында әһәмиятләре инкяр ителүгә, оныттырылуга дучар ителгән беренче-икенче томнары да гыйльми хәрәкәттә сакланган, дип авыз тутырып әйтеп булмый. Шуңа күрә «Асар»ның барлык өлешләре дә яңадан бастырылып, киңрәк гыйльми җәмәгатьчелеккә ирештерелүе ул актуаль бурычларның берсе. Димәк, эшнең беренче томнан ук башлануы табигый һәм зарури да икән.

RUHIAT

***

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, бу басманы әзерләүчеләр «Асар»ның элек чыккан ике томын яңадан бастыруны, кулъязма хәлендә сакланган өченче-дүртенче җилдләрен дә нәшер итүне, ниһаять, бу олы хезмәтнең бераз кыскартылган рәвештә русча тәрҗемәсен дә дөньяга чыгаруны максат итеп куялар.

«Асар» теленең, бигрәк тә аның баштагы өлешләренең лексикасы, имлясы хәзерге заман укучылары өчен шактый авыр (нык архаиклашкан) булуын исәпкә алып, ул яңа язуга күчерелгән чакта беркадәре адаптацияләнеп бирелер. Ягъни текст, аның тел-стиле, лексикасы һәм имлясы җиңеләйтелгән хәлдә күчерелер. Димәк, безнең алда текстның бер язудан икенчесенә механик рәвештә «аударылган» күчермәсе дә яисә фонетик төгәллеккә, эзлеклелеккә омтылган гыйльми транскрипциясе дә түгел икән. (Бу хакта тулырак мәгълүматны төзүчеләр тарафыннан бирелгән махсус белешмәдән дә карарга мөмкин.)

«Асар»ның беренче җөзьэсе 1900 елда басылган чакта, хезмәткә Р.Фәхреддин тарафыннан язылган күләмле мөкаддимәнең – керешнең – шактый өлеше һәм мәгънәле урыннары цензор (В.Д.Смирнов) тарафыннан идеологик максаттан чыгып сызылган була. Шул беренче җөзьэнең цензор тарафыннан таланган кулъязма нөсхәсе сакланган булуыннан файдаланып, мөкаддимәнең текстын элекке хәленә, ягъни автор ихтыярына муафыйк булган тулы рәвешенә кайтару кирәк табылды. Кулъязмада кызыл кара белән аркылы-торкылы сызылган шундый урыннар бу басмадагы керештә үз урыннарына куелды. Патша цензорының нинди фикерләрне өнәмәве, алып ташлавы бүгенге укучыларга да ачык күренсен өчен, текстның андый кире кайтарылган өлешләре курсив хәрефләр белән басылды.

Дөрес, «Асар» текстын хәзерге язуга күчерелгән вариантында төзүчеләр тарафыннан да артык әһәмиятле булмаган, бары стилистик максаттан башкарылган кайбер кыскартулар кертелүен махсус билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, биография иясенең эшчәнлеген күрсәтүдә артык бернәрсә дә бирми торган, мәгънәләре буенча бүгенге укучыларга аңлаешсыз һәм, иң мөһиме, эчтәлеге белән «Асар»да ук элек китерелгән, ачыграк мәгънәле истәлекләрне кабатлаган кайбер хатларның «транскрипциядән» төшерелүе кулайрак табылды. Мондый алым шулай ук кайбер кабатланган цитаталарга да, шигъри парчаларга да карый. (Шушы характердагы кыскартулар хезмәтнең русча вариантында да бар.)

Әлбәттә, бу басманың элекке иске язулы китапларның репринтлы нәшерләреннән беренче үрнәк булуын истә тотсак, анда кайбер җитешсезлекләрнең, төгәлсезлекләрнең урын алуы гаҗәп булмас. Әгәр укучы андый кимчелекләр хакында вакытында хәбәр итсә, киләчәктә дөнья күрүе өмет ителә торган башка томнарның сыйфатларын күтәрүгә лаеклы өлеш булыр иде, дип, сүзне йомгакларга кала.

*Миркасыйм Госманов.*
*Июнь, 2001*

## Сүз башы[1]

Бу көннән утыз ел элек бервакытта «Асар»ны язарга керешкән сәгатемдә булган максатыма туры китереп, шушы 1348 ел, 1 мөхәррәмдә (9 июнь, 1929) югарыда әйтелгән әсәрне икенче мәртәбә язарга башладым. Ләкин беренче мәртәбәдә язарга керешкән вакытымда булган хәлем белән бу көндәге хәлем арасында булган аерымлык мәшрикъ белән мәгъриб арасында булган аерымлыктан да ерак.

Беренче мәртәбәдәге хәлем: «Милләтебез гафләт йокысыннан уяныр, аякка басар, гыйлем вә мәгърифәткә, һөнәр вә сәнәгатькә, кәсеп вә сәүдәгә, дөнья көтүгә, гомумән, игенчелеккә сәләтлелеген мәйданга куячак, моның өстенә дә яхшы холыклы вә намуслы, диндар бер кавем, затлы бер милләт икәнлеген дөнья халкына күрсәтәчәк, яңа мәдәният нигезен салуда киң күңелле галия сахибларының хезмәтләренә катнашачак», – дип, ләззәтле өметләр белән рәхәтләнүдән гыйбарәт иде.

Шул вакытта: «Бер кисәк кенә булса да минем дә хезмәтем кушылсын. Кырмыскаларның чикерткә ботын Сөләйман галәйһиссәламгә бүләк итүләренә охшаса охшасын, һәрхәлдә, бу бөек фидакярлекләр арасында үзем кебек зәгыйфь бер хезмәтем дә катнашсын», – дигән ләззәтле, рухлы хыяллар һәм фаразлар белән мәшгуль булган идем.

Әмма бу көндәге хәлне бәян итүгә мөмкинлегем юк. Әүвәлдәге фаразларымның бөтенләй киресе вә капма-каршысы килеп чыкканлыкны күзләрем белән күрдем. Газиз милләтем җан биреп ятканлыгы күз алдымда.

Ни кайгы! Ни үкенеч! Ни хурлык һәм түбәнлек!

Бу милләт хакында: «Идел, Урал сахраларында төрки кавеме һәм ислам динендә булган олуг бер милләт мең елдан артык вакытлар гомер сөргән, мәчетләре һәм мәдрәсәләре дәвам иткән, мәшһүр галимнәре вә киң күңелле кешеләре, зур дәүләт әһелләре булган», – дип сөйләүчеләр генә булыр дип тә өметләнмим. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә күктән бер билге җибәреп кисәтмәсә яки берәр яңартуны күндереп, рәсүлуллаһ юлын яңартмаса, безнең газиз милләтебез һәлак булачак, хәтта тарих китапларына да бер дә булмаган кебек керә алмый калачак һәм тәмам онытылачак булачак. Өч йөз еллардан артык вакытлар вәхши урысларга, җәберләүче императорларга каршы торып килгән, диннәрен һәм миллиятләрен, гореф һәм гадәтләрен саклауга батырлыклары вә дәртләре җиткән бу газиз кавем үз араларыннан җитешкән имансыз малайларга һәм һәртөрле исемнәр белән билгеле булган тинтәк ерткычларга каршы җавап кайтарудан гаҗиз калдылар, шулай ук инкыйраз дәһшәтеннән үзләрен коткарырга көчләре җитмәде. Тыштан һөҗүм итүче дошманга күрә эчтән һөҗүм итүче дошман зарарлырак. Шул сәбәптән Аллаһы Тәгаләнең казасына юлыгудан башка чаралары юк. Буласы эш булды.

«Без барыбыз да Аллаһныкы һәм аңа кайтачакбыз. Берни дә мәңгелек түгел, бөеклек һәм хөрмәт иясе – Раббың гына мәңгелек».

---

[1] Автор тарафыннан китапның икенче басмасына дип язылган әлеге «Сүз башы»н тарих фәннәре кандидаты Лилия Байбулатова әзерләде.



RUHIAT

Бу язуларны кешеләр укысыннар өчен язмыйм. «Асар»ны яңадан язсам, бездән соңгылар файдалансыннар иде дигән фикер белән язмыйм. Мондый максатларның вә фикерләрнең күңелебездә хәтта бөртеге дә калмады. Эшләрнең кайсы тарафларга барачагы инде мәгълүм булды. Безнең максатлар тәмам җимерелде, кирпеч өстендә кирпеч калмады. Өмет тәмам өзелде.

«Сүгадка ничек ирешергә? Алдында – таулар, артында – үлем. Яланаяклы кешемен, атланырга атым юк. Куллар буш һәм көчсез, юл коточкыч». Дөрес, имам Шәфигыйнең бу шигырьләре бер эшнең авырлыгын бәян кылудан гына гыйбарәт булса дә вә икенче бер шагыйрь да шушы шигыре берлә бер кадәр юатырга тырышса да: «Әгәр эшләр буталса, төенләнсә, Аллаһы теләге белән аларның чишелеше шаять, шаять, төеннәрне төйнәүче аларны чишәр», – дисә дә, эш бу дәрәҗәләрдән үтте, гырылдау заманалары килеп җитте. «Үзебезгә һәм халкыбызга зарар килде. Раббым, мин – зарар күрүче, ә син – рәхимлеләрнең рәхимлесе».

Беренче мәртәбәдә «Асар»ны зур теләк вә зәвык белән язган булсам, бу юлы инде үземнең сынган күңелемә һәм янган йөрәгемә юаныч табу, хәсрәт ялкыннарына су бөркү өчен язам. Әүвәлге мәртәбә тәртип каләмемне карага манчып язган булсам, бу дәфгасында инде күземнән аккан яшь тамчыларына манчып язам...

Ризаэддин Фәхреддин.

*Россия Фәннәр академиясенең Уфа гыйльми үзәге.*
*7 фонд, 1 тасв., 4 сакл. бер (н/а)*
*Уфа. 1 мөхәррәм, 1348 (9 июнь, 1929)*

RUHIAT

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

# « آثار »

اوز مملكتمزده اولغان اسلام عالملرينڭ ترجمه وطبقه‌لری، تاريخ ولادت
ووفاتلری وباشقه احواللری حقنده يازلمش بر كتابدر.

برنچی جزؤ

صاحبی
رضاء الدين بن فخر الدين

RUHIAT

дозволено цензурою. С.-Петербургъ, 20 сентября 1899 г.

КАЗАНЬ
Типо-Литографія Императорскаго Университета.
1900 г.



*Үз мәмләкәтебездә булган мөселман галимнәренең*
*тәрҗемәи хәлләре һәм дәрәҗәләре, туган һәм үлгән вакытлары*
*вә башка хәлләре хакында язылган бер китап*

Максатка кергәнче, беркадәр җөмләләрне ошбу урында язу кирәкле дип күрелде. Бу җөмләләр исә максатыбызның нигезе.

I

Мәшһүр кешеләрнең яки халык вә мәмләкәтләрнең гомер итүләрен, тереклек итү рәвешләрен сөйләгән гыйлемгә «тарих гыйлеме» диләр. Тарих вә аның бер өлеше булган тәрҗемәи хәлләр һәм нәсел-нәсәп гыйлемнәренең файдасы чиксез икәнлеген игътибарлы һәм үткен күзле булган галимнәрнең һичберсе инкяр итмәс.

Мәккәи мөкәррәмә, Мәдинәи мөнәүвәрә, Мәрв, Исбаһан, Хәләб, Каһирә шәһәрләре хакында аерым-аерым тарихлар язылуы вә Бәгъдад илә Димәшкъ шәһәрләренең һәрберсе хакында алтмыш һәм җитмешләп җилд [том] тарих китаплары язылуы, изге сахабаларның вә сахабаларны күрүчеләр, башка галим һәм укымышлыларның тормышлары буенча хисапсыз күп әсәрләр иҗат ителгәнлеге мөселманнарда бу фәннең никадәр могтәбәр булганлыгына дәлил.

RUHIAT

Мөселманнар өстенә килгән мәшәкать вә мәгълүм вакыйгалар сәбәпле, сансыз әсәрләр, һәм бу җөмләдән күп тарих китаплары юк ителсә дә, бүген дә һаман йөзләр вә меңнәр илә мондый газиз нөсхәләр дөнья йөзендә исән булуы хәйран калырлык.

Дәүләт вә милләтләр хакында булган маҗараларны бәйан итеп мөселман галимнәре тарафыннан гомуми тарихлар тупланган кебек, биографик һәм югары катлауларга бәйле булган мәгълүматлар, гомуми тарихлардан аерып, үзенә башка җыелган. Сахабалар, сахабаларны күрүчеләр, хәлифәләр, изгеләр, әдипләр, хәдис һәм фикъһ галимнәре, тәфсирчеләр, карыйлар, тарихчылар, // [3] шагыйрьләр, хәкимнәр, вәзирләр, солтаннар, әмирләр – барчасының туган һәм үлгән урын вә елларын, остаз вә шәкертләрен, тормышларын, һөнәр вә эшләрен, берсен дә калдырмыйча, ачык һәм дөрес итеп саклаганнар.

Төрле заман вә гасырларда булган вакыйгаларның тарихларын, шулай ук һәрбер мәшһүр затларның тәрҗемәи хәлләрен, гаять тә озын һәм тәфсыйльле итеп бер урында язу вә җыю мөмкин эш түгел. Ошбу сәбәп өчен тарихларны дәвер һәм гасырларга яки шәһәр вә кавемнәргә, мәмләкәт һәм милләтләргә бүлеп өйрәнү – тарихчылар арасында гадәткә кергән. Шулай ук тәрҗемәи хәлләрне гыйлем вә фәннәргә аерып, мәсәлән, мантыйк, кәлям, хәдис, тәфсир, нәхү, фикъһ, игътикад (иман), әдәб, шигырь галимнәрен аерым-аерым язган кебек, күп вакытта мәмләкәт вә шәһәрләргә хас тарих китаплары языла. Хәтта ки бу соң заманнарда мәшһүрә хатыннарга махсус язылган гарәп һәм төрки телләрдәге әсәрләр күрелде.

## II

Бу мәмләкәттә булган халыкларның иң искесе безнең бабаларыбыз – борынгы төрки вә болгарлар булган хәлдә, үзләренә багышланган тарихлары бездә булмаганы кебек, галимнәре хакында да әсәрләр булмавы – аянычлы бер хәл.

Гәрчә 559 һиҗри/1164 милади елда вафат булган Ягъкуб бине Ногман әл-Болгарый дигән бер галим безнең Болгар шәһәре вә халыклары хакында зур бер тарих язганлыгы билгеле булса да, бу тарихтан безгә һичбер хәбәр вә исем беленмәде. Шулай ук аннан элек, ягъни һиҗри 310 елда, Бәгъдадтан Болгарга илче булып килгән җәмәгать эчендә булган гарәп галимнәреннән Әбүл-Габбас Әхмәд бине Фәзлан исемле мәшһүр затның ошбу Болгар сәфәре хакында язган сәяхәтнамәсе булуы билгеле. Хәтта ки «Иктифаэл-конуг» авторы Ибне Фәзланның ошбу әсәре хакында «алман теленә булган тәрҗемәсе белән бәрабәр, Фрайн исемле бер галимнең тырышлыгы нәтиҗәсендә 1823 елда Петербург шәһәрендә басылды» дип язылса да, бу әсәр хакында мәгълүмат алырга ирешә алмадык. Петербург вә Кронштадт шәһәрләрендә булган дусларга кат-кат // [4] мөрәҗәгать итүебез, хәтта ки кайбер шәркыять галимнәренә язган хатларыбыз – барысы да нәтиҗәсез калды.

Кыскасы, ошбу урында мәмләкәт төзеп, шәһәрләр корып, сәүдәләр йөртеп, мәдәният таратып, дөньяга олуг хезмәтләр иткән бабаларыбызның (борынгы төркиләрнең) хәлләре безләргә караңгы булып калган кебек, араларында булган мәшһүр адәмнәре вә танылган галимнәре дә билгесез калган. Шөкерләр булсын ки, рус язучылары, үзләренең нәсел вә кабиләләренә тиешле тарихларны язганда, читләтеп һәм кыскалык илә булса да, безнең ата вә бабаларыбыз булган болгар, хәзәр, кыпчак халыкларын да телгә алып үткән булганнар. Булдырырдай кешеләрнең ошбу рус әсәрләреннән файдаланып бер тарих китабы язулары безнең өчен беренче дәрәҗәдә тиешле эш булса кирәк.

Ерак бабаларыбыз хәлләре хакында милли әсәрләр булмаган кебек, бабаларыбыз өстенә килгән татарлар (татарлар да безнең бабаларыбыз кеби төрки халык) әхваленнән вә алардан чыккан галимнәр хакында кулыбызда ачык мәгълүматыбыз юк.

Казан шәһәре Русия дәүләте тарафыннан алынган көндә (Басма китапта: якшәмбе көн, 13 зөлкагдә, 909 һиҗри / 2 октябрь, 1552 милади елда) Казан ханлыгы дөньяда бөтенләй булмаган мисалында калган, *Казан шәһәрендә бер мөселман калдырмый кылычтан үткәрелгән*[2]. Бу вакытта мөселманнан әсәр калмаган кеби, гыйлем җәһәтенчә булган әсәрләреннән дә хәбәр калмаган. Моннан соң Казанда да вә тирә-як авылларда булган зур янгыннар, бүгенге көндә Оренбург һәм Уфа вилайәтләреннән булган урыннарда берникадәр вакыт дәвам иткән Сәед Җәгъфәр[3] һәм Алдар[4] вакыйгалары, шулай ук Килмәк абыз (хафиз), Акай, Йосыф вакыйгалары[5], мулла Габдулла бине Мәезкилде илә Батыршаһ Гали угылының[6] яулары, Идел буенда булган мәмләкәтләрдә мәшһүр Пугачев вакыйгалары мөселман // [5] әсәрләренең вә нәфис китапларының юкка чыгуына сәбәп булган.

---

[2] Цензор тарафыннан сызылган. – *Төз.*

[3] Сәед Җәгъфәр башкорт старшинасы булып, 1662 елда ихтилал чыгарып, егерме елдан артык вакыт дәвам иткән.

[4] Алдар да башкорт башлыгы булган.

[5] Килмәк абыз, Акай, Йосыф та башкорт халкы арасында зур ихтилал чыгарганнар. Ахырында, 1737 елда әсир алынып, Петербург шәһәренә җибәрелгәннәр.

[6] Бу кешеләр Орски тирәсендә 1755 елда сугыш чыгарганнар. Батыршаһ мишәр таифәсеннән булган. Петербургка җибәрелгән.

Юкса Казан ханлыгы җимерелүеннән соң да, аз булса да, берникадәр гыйлем әһелләре булырга тиеш иде.

Мәгәр Пугачев вакыйгасыннан соң, бер гасырдан артык вакыт булыр, әһле ислам гадәттән тыш бер тынычлык вә рәхәтлектә гомер уздырдылар. Бераз нәрсәләргә игътибар итмәгәндә, бу гасырны Гомәр бине Габделгазиз (аңа Аллаһының ризалыгы булсын) заманасы белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Инде бу тыныч вә рәхәт бер заманда безнең галимнәребез ошбу *олуг*[7] милләт өчен нинди хезмәтләр иттеләр?! Халкыбыз өчен тарих яздылармы? Яки үзебезнең ана телебезне әдәби тел итәр өчен тырышып, нәхү һәм сарыфларны төзеделәрме? Яки яхшы әхлак хакында гүзәл әсәрләр нәшер кылдылармы? Яисә башка рәвеш илә гыйлем вә мәгърифәт сәбәпләрен җиңел итү өчен тырыштылармы?!

Без исә, бабаларыбызның хезмәт вә гыйлемдә булган мәртәбәләрен инкяр итүчеләр булмыйча, мөмкин кадәр камиллекләрен танытучылардандыбыз. Хәтта ки, төн рәхәтләрен вә төн йокыларын фида итеп, бу юлларны язып мәшгуль булуыбыз ошбу сәбәп өчен. Инде безнең югарыдагы сорауларыбызга җавап бирүче булса, хәзер мәйданга чыксын да, сораган әсәрләрне безгә күрсәтеп, гыйлем исеменә, һич тә булмаса инсанлык исеменә аңлатып бирсен!.. Моның өчен исә барчабыздан олуг рәхмәтләргә ирешер.

«Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез; мәшһүр кешеләрне оныткан халык сакланмас; әдәбияты булмаган халык рухсыз» диелгән сүз хәтерләрдә.

Шуңа күрә үз халкыбызның мәшһүр шәхесләрен җыеп таныту өчен ошбу китапны язарга ният иттем. Болардан башка, кайбер чит мәмләкәтләрдән булып та, бу мәмләкәткә килеп йөргән адәмнәрне дә телгә алырга булдым. Язылачак затлар исә үзем белгән кадәр булачак. Юкса, Аллаһы Тәгаләнең дөньясы киң булган кебек, ирләре дә күптер. Ялгыз бер вилайәт яки бер гасырның мәшһүр затларын җыяр өчен безнең кодрәтебез җитешмәс. Хәбәрләрне белмәвебез аркасында кайбер затлар хакында, әлбәттә, хәлләрен яза алмыйбыз. // [6]

## III

Тарих, тәрҗемәи хәлләр язудан асыл максат исә укучылар өчен дөрес бер хакыйкатьне белдерү яисә дөрес бер хакыйкать белдерергә гайрәт сарыф итү. Шуның өчен иң элек боларга бәйләнешле булган китаплардан вә могтәбәр әсәрләрдән мөмкин кадәр җыеп өйрәнү, һәм аннан соң күңелдән озын һәм әтрафлы тикшерү кирәклеге мәгълүм. Бу исә, мөмкин булган тәкъдирдә, бер нөсхә илә генә канәгать итмичә, бәлки икенчеләренә күз салу белән була торган хәл. Юкса, тарих язмак булып, бер ишеткәнне вә колакларга килеп җитешкәнне хөкем йөртмичә һәм тикшермичә кабул итү бөтенләй дөрес булмас.

Һич әһәмияте булмаган нәрсәләргә зур әһәмият биреп яки әһәмияте булган нәрсәләргә илтифат итмичә, алтынны бакыр итәргә вә бакырны алтын дип күрсәтергә тырышкан кеше гомерен фәкать хыял илә уздырган булыр.

Хәлбуки бу китапны язып шөгыльләнгән вакытымда йөз төрле каршылыклы фикерләр илә күңелем тәшвишле вә тынычсыз иде. Әгәр дә икенче том «Мөстәфадел-әхбар...» китабын, шулай ук «Вафийәтел-әсляф...»ның кайбер кисәкләрен искә алмасак, күзем уңында китап исеменә лаек булган һичбер нәрсә булмас иде.

[7] Цензор тарафыннан сызылган. – *Төз.*

Тарих китаплары язганда булган асыл мөшкеллек заманалар вә мәмләкәтләрнең ераклыгы булмыйча, бәлки мөрәҗәгать итәрлек китап һәм чыганакларның юклыгы. Бу исә тәҗрибә итүчеләр өчен мәгълүм бер мәсьәлә.

Бу юнәлештә ничә еллардан бирле җыеп килгән мәгълүматларымның күбесе төрле кәгазьләргә язылган хатлар иде. Безнең арабызда хатлар тәртипсез язылуы бер гадәт булганлыктан, бу хатларның берсе – бер тарафтан вә икенчесе икенче тарафтан башланып, язылачак кәгазе мәйдан булган хәлдә дә читләренә чыгарып һәм дә астын өскә китереп тә язылган булыр иде. Шулай ук максатка бәйле булмаган гыйбарәләр, кыш көннәренең кичәләреннән дә озын язылганга, максат булган бер юлны укыр өчен тәмам зиһен ватуга хаҗәтле булыр иде.

Мин исә, нигездә, югарыда исемнәрен атаган китапларга игътибар иттем. // [7] Ләкин асыл игътибар итүемнән тулаем күчерү илә канәгатьләнүем аңлашылмасын! Бәлки аларда язылган шәхесләр хакында мәгълүмат алынуы өмет ителгән затларның барысына булмаса да, күпчелегенә мөрәҗәгать итеп хатлар яздым. Бәлки, дөрес бер сүз ишетелер дип уйлаган затлардан яңадан тулырак аңлатуларын сорадым. Кыскасы, тәкатем җиткән кадәр гайрәт итүдән бервакытта ялыкмадым. Кулыма алган каләмемне максатыма ирешмичә куймас өчен, тиешле эшләрен җиренә җиткерүгә каршы тормадым. Ләкин нәтиҗә хасил итү – Аллаһ бәрәкәте. Кайвакытта ахмак вә ялкаулар яткан урыннарында хәзинә табып, төнкөн тырышучылар ачлыктан җан бирәләр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең һичкемгә бирәчәге вә бурычы юк!..

Фикерләгәч, тикшергәч, үз карашымча, ышанычлы булган дәлилләргә нигезләнеп, күп вакытта «Мөстәфадел-әхбар...», ягъни шәех Мәрҗанинең ихтыяр иткән сүзләренә дә хилафлык иттем. Моннан исә Мәрҗани хәзрәтләренә кылган хөрмәтләребезгә вә саклаган әдәпләребезгә зарар килмәс. Тәнкыйть һәм хөкемфикер йөртү ысулын исә без аның әсәрләрен һәм хезмәтләрен укып өйрәндек.

RUHIAT

IV

Кеше никадәр зирәк вә хәтерле булса да, һәрбер укыган һәм күргән нәрсәсен хәтерендә тулаем саклап тота алмас. Күп вакыт булыр, бер сүзне китапта күргәнлеген хәтерләгән хәлдә, урынын яки китабын онытыр. Хәтта ки, үзе язганнарны да күп чагында зиһененнән югалтыр.

Бу хикмәт өчен, кирәк булган исемнәрнең тизлек вә җиңеллек белән табылуына кулай булыр дип, күп галимнәр үзләренең китапларында могтәбәр затларны әлифба тәртибе илә язалар. Мәшһүр мөхтәрәм Шәмседдин Сами бәкнең әйтүенә караганда, бу кагыйдә иң әүвәл гарәп галимнәре тарафыннан иҗат ителеп, аннары һәрбер мәдәни вә гыйлемле халык боларга ияргәннәр. Чынлыкта бу рәвештә, әлифба тәртибенчә язылган әсәрләрдән күреп, оныткан исемнәрне генә түгел, һич укылмаган вә күрелмәгән затларның да тәрҗемәи хәлләрен исемнәре буенча эзләп табарга мөмкин. Шулай булса да мин, бу китапны гасырлар вә еллар үтүенә муафыйк тәртиптә һәм әүвәл // [8] заманнарда булганнарны алдан сөйләп, акрын-акрын соңгыларга таба килдем. Мәгәр дә китапның бер тарафына әлифба тәртибе илә бер эчтәлек өстәдем. Эчтәлек булгач, кирәкле исемне укучы һичбер кыенлык кичермәс.

Тәрҗемәи хәлләрне еллар тәртибе белән язучыларның ысуллары, гыйлемлек елдан-ел түбәнлек тарафына бара. Соңгырак заман галимнәренең мәртәбәләре, элеккегеләргә чагыштырылып, ким дәрәҗәдә була. Шуның өчен укымышлылар арасындагы муафыйк тәртип, шулай ук һәркемне үзенең лаек дәрәҗәсенә кую, еллар буенча урнаштырудан башка сурәттә булмас диюдән гыйбарәт.

Ләкин еллар тәртибенчә бирүдән минем максатым бу түгел. Чөнки югарыда әйтелгән дәгъваны бу мәмләкәт галимнәре хакында кылырга, үткәндәгеләргә вә элек заманнарда булганнарга ачык хөрмәт итүдән башка дәлил юклыгы һичкемгә сер түгел. Хәлбуки ачык хөрмәт ысулы илә тормыш юлын язу бу фәннең кагыйдәсенә тәмам каршы бер эш. Бәлки еллар тәртибенчә бирүдән минем ниятем вә ысулым, электә килгәннәр гыйлемдә камил булсалар да, булмасалар да, соңгыларга остазлык нисбәтләре бар. Бу остазлык вә шәкертлек нисбәтләрен саклау вә хөрмәт итү, гыйлем дәвамлылыгы кемнәрдән кемнәргә калуын белү, ата-бабалар хәлләрен өйрәнеп, балалар вә угылларга күчү, элекке чорларда гизеп, нәүбәте белән хәзерге заманнарга килеп тоташу, гасырлар арасында үлчәү вә чагыштырулар йөртеп, зиһеннәрне кузгату, фәһемнәрне уяту, минем күңелемдә булганча, еллар үтүенә муафыйк тәртипне ихтыяр иттем.

Юкса Бохарый, Мөслим, Тахауый, Җәүһәри, Сафани, Фәйрүз Абади, Исбаһани, Ибне әл-Әсир, Ибне Хәлдун, Зәһәби, Мәкъризи, Ибне Гасакир, Сәмгани кеби мәшһүр мөселман галимнәре әсәрләреннән кулларында гына түгел, бөтен төбәкләрендә бер кәгазе булмаган заман галимнәрен, ачык хөрмәт илә исемнәрен күтәрү өчен тырышу урынсыз булса кирәк. Ләкин бу сүзне мин үз хәзинәмә күрә яздым. Әгәр дә аларның гыйлемдә камил икәнлекләрен дәлил илә исбат итүче булса, инкяр итү түгел, җирдән күккә кадәр хупларга, мактарга хәзербез. Моның илә бәрабәр, бер-ике затны исәпкә алмаганда, соңгы заманда гыйлем мөнбәренә утыручыларны да «гыйлемдә камил иделәр» дип дәгъва итәргә кыюлыгыбыз // [9] җитми. Олуг галимнәрнең әсәрләреннән мәхрүм булган бер гасыр укымышлыларының, зур дәрәҗәдә булулары шөбһәле һәм икеле булган кебек, кулларында китаплар, аеруча ышанычлы галимнәрнең әсәрләре күп булу – бер гасыр укымышлыларының зур мәртәбәдә икәнлекләренә дәлил булмас. Асыл галимнәр вә камил гыйлемлеләр исә гыйлем вә фәннән кагыйдә илә файдаланучылар була. Мәсәлән, «Тәфсире Кәшшаф» гыйлем һәм мәгърифәттә нихәтле тирән гыйлемле бер зат әсәре булган хәлдә, бәхетсез кешеләрдән күпләр бу тәфсирдән үзләренең наданлыкларына дәлил китерүләре һәр көн күрелә килә. Мондый нәрсәләргә гайрәте килеп, бөек галим вә мәшһүр фәйләсүф Ибне Рөшед әл-Әндәлеси хәзрәтләре «гыйлеме камил булмаганнар Имам Газзалиның гыйлемгә багышланган хезмәтләрен кулланмасыннар» дигән.

Үткән заман галимнәре үзләренең көннәрен уздырып киткәннәр, киләчәкләре исә нинди сыйфатта һәм нинди хәлдә булачаклары мәгълүм түгел. Шуның өчен бу ике өлешкә саф караш ташлап, үзебезнең гасырыбызда һәм үз мәмләкәтебездә булган галимнәребез хакында фикеребезне түбәндәгечә бәйан итәбез.

Бу заманыбызда хисапсыз җаннар данлык хасталыгына вә фәкыйрьлек бәласенә дучар булды, гыйлем эстәү өчен төрле каршылыклар көннән-көн көчәйде. Башыбызга мең төрле әһәмиятле дини вазыйфалар төште. Кыскасы, дини һәм дөньяви хаҗәтләребез чиксез вә карарсыз бер рәвешкә керде. Инде безнең хөрмәтле галимнәребез, ошбу ихтыяҗларыбызны фикер итүчеләр, көне-төне шуның чарасында гамәл күрүчеләр булачак. Юкса, үзләренең кайсы заманда икәнлекләрен белмичә, дөньяның да кай өлешендә яшәүләренә игътибар итмичә, «бер тиенлек куян, ун тиенлек зыян» мәкалендәге кебек, файдасыз бәхәсләр белән көнетөне гаугалашып гомер уздырган, хәтта ки галимнәргә лаек булмаган гыйбарәләр илә бер-берен сүгеп һәм хурлауны үзләренә зиннәтле бер гадәт итүчеләрне галим дип санау – тауларны урыныннан күчерү кебек кыен бер эш.

Бүген дә Казан матбагаларында басылып чыккан хурлаулы һәм буш сүзле язмаларны яшь вакытларында тәрбиясез хатыннардан тәрбия алганнарның барчасы яза, моның өчен гыйлем хаҗәт булмыйча, фәкать беркадәр холыксыз булу җитә. // [10]

RUHIAT

## V

Бу китапны язуда булган авырлыкның сәбәбе ни җәһәттән икәнен сөйләдем. Шуның өчен минем әсәрем яки «Асар»ым тулы түгел бер сурәттә булганын инкяр итәргә хакым юк. Хәлбуки камил әсәрләр иҗат итү минем кебек бер гаҗизгә генә түгел, бәлки дөньяның танылган әдипләре өчен дә зур тырышлыклар сарыф кылуны таләп итә. Үзебезне юату өчен бер-ике сүзне бу урында искә алсак, зарар булмас. Мәсәлән, 200 һиҗри / 816 милади елдан соң вафат булган Әбү Габдулла Касыйм бине Сәлям (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) үзенең бер китабын кырык ел вакыт уздырып язганлыгын икърар иткән. 356/967 елда вафат булган Әбелфәраҗ Гали бине әл-Хөсәен әл-Исбаһани (Аллаһ аны ярлыкасын), илле ел гомер сарыф итеп, бер китап язган. 927/1521 елда вафат булган Габдулла Һатифи «Зафәрнамә»сенә кырык ел исраф иткән, мондыйлар гаять күп. Ләкин мисал өчен болар да җитәр. Шулай ук Европа галимнәреннән гадәттән тыш зирәклеге белән танылган булган Ньютон, Монтескье кебекләр кыска гына хезмәтләр язу өчен еллар сарыф иткәннәр. Һәркемнең әсәрен үзенә чагыштыру хәтергә алынса, бу сүзләрне язуым тиешсез булмас.

## VI

Наданлыкка дучар булмаган, тәрҗемәи хәлләр язучы өчен нинди затларны язу вә кайсыларын язмау яки нинди сыйфатлар белән мактау, нинди хәлләргә игътибар бирү хакында иң элек күңелендә бер үлчәү хәзерләп, аннан язачак һәрбер нәрсәләрне әлеге үлчәвенә салып карау зарур була. Юкса бер-беренә мөнәсәбәтсез затларны яки үзенә туры килмәгән хәлләрне бер урынга тезеп куюдан бер файда да күрелми. Мәсәлән, фәкыйһләрне [фикъһ галимнәрен] язачак бер зат фәкыйһләр арасында Әбү Тәммам, Җөрәйр кебек шагыйрьләрне искә алуы яки тарихчыларны язган урынга Хәсән әл-Басрый кебек суфыйны, Җөббәи кебек кәлям галимен куюы көлке булыр. Шулай ук бер сыйфат илә берсен мактаганда, нәкъ шундый сыйфат белән икенчесен тәнкыйть итү зур бер хаксызлык һәм гафу ителмәслек дәрәҗәдә ачык золым булыр. // [10] Мәмләкәтебездә булган галимнәрне туплап китап язуыбызны белгән вә ишеткән затлардан күпләр хатлар илә һәм шулай ук йөзебезгә дә: «Безнең мәмләкәтебездә (бер-ике затны исәпкә алмаганда) исемнәрен кәгазьгә язарлык галимнәр булганмы? Һәрбер имам вә мөдәррис яки шәех һәм ишан исеме илә мәшһүр булганнарны мактауда асыл вә хакыйкый галимнәргә золым булмасмы?» – дип белдергәннәр иде.

Бу китапны язу максатыбыз һәм зиһенебездә булган үлчәвебез үз милләтебезгә укыту һәм гыйлем өйрәтү илә, шулай ук әсәр яки вәгазь һәм нәсыйхәт белән хезмәт иткән шәхесләрне теркәү, хәлләрен тасвирлаганда, мактаганда яисә тәнкыйть иткәндә, гаделлектән аерылмыйча, белгәнебез кадәренчә дөрес һәм тугрысын бәйан итүдән гыйбарәт.

Әсәрләре булса, аларны санау, туган вә вафат булган елларын, остаз һәм шәкертләрен һ.б. мондый хәлләрен язып китү безнең максатыбыз. Кыскасы, без язачак нәрсәләр рәсми хәлләргә бәйле. Әмма документаль ышанырлык булмаган яки гыйлеме безгә тапшырылмаган нәрсәләргә катышудан бар куәтебез белән саклandык. Мәсәлән, бер кеше турында язган вакытыбызда «бу зат Аллаһы Тәгаләнең дусты, Аллаһы Тәгалә каршында кадере зур, бу кеше үлекләрне тергезде, тәкъдирләр белән идарә итте, күрәзәлек итте» дигән кебек хикәятләр язу вазыйфабызга кермәде.

RUHIAT

Әлхәмде лилләһи, балигъ булган көнемнән бирле барлык зур ихтыяҗларымны Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең фәкать үзеннән үтенгән һәм ялварган кебек, рәсүле әкрам әфәндебез (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) тарафыннан хәбәр ителмәгән затларга вәли (Аллаһы Тәгаләнең дусты) дигән кебек бер батырлык кылмадым.

Инде ошбу сүзләрнең барчасын җыеп әйткәннең соңында боларны язуда булган максатыбыз, шулай ук «Безнең мәмләкәтебездә галимнәр булганмы?» дип сораучыларга әйтеләчәк җавабыбыз да беркадәр мәгълүм булыр. Ягъни бу китапны язудан асыл максатыбыз үз халкыбызга азмы-күпме гыйлем өйрәткән, кайгы һәм хәсрәтләрен тараткан шәхесләрне бәйан итү. Моннан исә хезмәт һәм мәшәкатьләре бәрабәренә, аз булса да, бер бүләк, хезмәт итәчәкләренә кызыксындыру булыр. // [12] Юкса галим дип язачак кешеләребезне Әбелвәлид Ибне Рөшед, Ибне Ризван, Хәлил, Сәйбәйвийә, Зәмәхшәри кебек мөселман галәменнән бөек галимлек исеме илә макталган затлар илә тиңләштерү максатыбыз түгел. Бәлки, һәрникадәр түбән дәрәҗәдә булсалар да, онытырга ярамаган исемнәрне язып калдырырга тиеш дип инандым. Кулымнан каләмем төшкән көнгә кадәр ошбу максатта торуымны Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән өмет итәм.

## VII

Мәдәни халыкларның мәктәп вә уку йортлары түбән, урта, югары дигән өч өлешкә бүленә. Галимнәре дә түбән, югары дигән икегә аерыла. Түбән (башлангыч) мәктәпләр сабыйлар өчен булганга, галим исемен алуга аларда уку гына җитми. Галим исемен алыр өчен, һич югында, урта мәктәпләрдә укытылуы тиеш булган фәннәрне (дөнья тормышы өчен зарур, шәригатьтә фарыз ителгән нәрсәләрне) яхшы аңлаганнан соң насыйп була.

Урта мәктәпләрдә яхшы укып та, соңыннан университет кебек югары уку йортларында дәвам итү белән белгән нәрсәләрне гамәлләр илә тәҗрибә кылып, һәрнәрсәнең асыл һәм дәлилләрен, хикмәтләрен, сәбәп вә серләрен аңлап, осталыкка ирешүчеләр олуг галимнәр гөруһына керәләр.

Адәм баласы өчен һәр гамәлне тәмам асылына ирешеп белү вә барлык фәннәр илә кирәкле дәрәҗәдә мәгълүматлы булу мөмкин түгел. Мөмкин булган тәкъдирдә дә моның өчен гомерләр җитми. Берәүнең һәр гамәлдә камиллеккә ирешүе башкаларга йомышсыз торачагын белдергәнгә, бу эш исә тормыш мәслихәтенә каршы вә табигать таләпләренә дә хилаф була. Иң бай булган бер кеше беренче дәрәҗәдә фәкыйрьгә йомышы төшүе һәм камил бер табибның гади тегүчегә мохтаҗ булуы һәрвакытта булып тора.

Ошбу сәбәп өчен бөек галимнәр катлавына керергә теләүчеләр, гади гыйлемнәрне өйрәнеп тәмам иткәч, үзләренең табигатьләренә муафыйк вә сәләтләренә лаек дип уйланган бер яки төрле фәнне сайлап алып, шуның илә мәшгуль булалар. Бу юлда җиләк кебек газиз гомерләр, // [13] юкә балыннан татлырак вакытлар вә иң ләззәтле йокылар, мең төрле рәхәт чак һәм теләкләр фида вә корбан ителәләр. Бу дәрәҗәдә булган нәфесне тыюлар вә рәхмәтләр соңында теләгән гыйлеменнән өлеш алса, ул зур бәхет санала. Шул дәрәҗәдә ки, өстендә гади чикмән булган хәлдә, дөнья байлыгына күзе төшмәс, үзенең хәленә монасыйб бирелгән доктор, профессор, хәким, фәйләсүф, бөек галим исемнәрен алмаштырырга риза булмас.

Адәм балаларының тереклек итүләренә сәбәп булган файдалы ачышларны, кирәкле булган һөнәр вә сәнгатьләрне Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре тырыш затлар ярдәме белән дөньяга чыгарыр.

RUHIAT

Боларга комачауларга түбән галимнәрнең тузан кадәр дә хаклары юк. Мәхкәмә вә хакимнәр өчен берәр төрле фәтва кирәк булганда, аларга мөрәҗәгать ителми. Биргән фикерләре ишетелмәс һәм тотылмас. Бәлки мондый зарур фәтвалар хакында ялгыз олуг галимнәр сүзе белән генә гамәл ителер. Ләкин бу урында тагын бер нәрсә бар ки, аны бераз бәйан итүдән зарар булмас. Ул мәхкәмә вә хакимнәр өчен яки, гомумән, тормыш итүгә бәйле нәрсәләр хакында фәтва алырга кирәк булуында, шул гамәлнең үзенә мөнәсәбәтле булган кешеләренә мөрәҗәгать ителер. Ул кешеләрнең дә үзләре кирәк дип тапкан гыйлемнәре хакында булган сүзе генә тотылыр. Мәсәлән, математика гыйлеменә мөнәсәбәте булган бер олуг галим үзенә ят булган тыйб-медицина гыйлеме хакында һичбер мәхкәмә хозурына чыгып фикер бәйан итә алмас. Шулай ук бер оста табиб, үзе шөгыльләнмәгән хәлдә, географиядән яки педагогикадан мәгълүмат сатмас, сатса – үзенең бер кимчелеген мәйданга куйган саналыр. Чөнки һәрникадәр бу гыйлемнәр урта уку йортларында кыскача күрелсә дә, аның белән генә ул гыйлем хакында сүз сөйләргә хокук бирелми. Моннан аңлашылганча, мәдәни халыкларда һәрнәрсә үзенең әһелләренә тапшырылган яки һәрнәрсәнең үзенә хас әһелләре булыр.

Изгеләр дәверендә, габбаси хәлифәләр вә Әндәлес дәүләтләре дәверендә, мөселманнар гадәттән тыш бай булган кебек, гыйлем һәм мәгърифәттә дә иң зур мәртәбәдә булганнар. Чөнки милләтләргә нисбәт илә байлык белән гыйлем берберенннән һич аерылмас. // [14] Болар исә бер кошның ике канаты яки бер көймәнең ике ишкәге кебек булырлар. Гыйлемнән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас. Ягъни гыйлемсез милләт баемас вә алга китмәс, баемаган милләт гыйлем өйрәнә алмас.

Элекке заман мөселманнары дөньяның беренче байлары булган кебек, һөнәр вә сәнгать өлкәләрендә булган гайрәт һәм тырышлыклары бик тә гаҗәеп булган. Харап булып яткан туфракларны бакча итү, тап-такыр булган кырларны игенлеккә әверелдерү, арыклар белән теләгән урыннарына сулар йөртү – мөселманнарның гади эшләреннән булган. Юллар ясау, кирәк урыннарга чишмәләр казып су чыгару, кәрвансарайлар төзү гомуми гадәт булган.

Мөселман тауарлары җиһан йөзенә таралыр, кәрваннары илә иң ерак урыннарга йөрер, гарәп сәяхәтчеләре, дөньяның бер читеннән икенче читенә йөреп, һәрбер халыкның гореф вә гадәтләрен, дин һәм тормышларын, мәмләкәтләренең географияләрен язып китерер булганнар.

Һәр мәхәлләдә сабыйлар өчен мәктәп, һәр шәһәрдә урта мәктәпләр, Бәгъдад, Куртуба, Гарната, Каһирә, Нисабур, Һират шәһәрләрендә дарелфөнүннәр (университетлар) нигезләнгән. Басра, Бәгъдад шәһәрләрендә булган гыйльми мәҗлесләрдә (академияләрдә), олуг галимнәр вә бөек әдипләр җыелып, гыйльми әңгәмәләр корганнар һәм оста чыгышлар вә нотыклар тотканнар. Гарната, Басра, Бәгъдад көтепханәләренә җыелган китапларның хисабы булмаган.

Ахирәт вә дөнья өчен кирәк булган фәннәрнең зур галимнәре мөселманнарның үз араларында йөзләр вә меңнәр белән саналган. Бу галимнәрнең үзләре мөнәсәбәтле булган гыйлемнәренә нисбәтле ләкаб-титуллары да булып, мөфәссир [тәфсир галиме], мөхәддис [хәдис галиме], лөгави [тел галиме], сарфый [морфология галиме], нәхүви [синтаксис галиме], фәкыйһ [фикъһ галиме], мөтәкәллим [кәлям галиме], табиб, фәйләсүф, тарихчы, мантыйкый, мөһәндис [инженер] кебек хөрмәтле исемнәр белән бер-береннән аерылып торганнар.

Болар алдында гыйлем шул дәрәҗәдә хөрмәтле булган ки, бер сүзне үзенең белгеченнән ишетер өчен, айлар буе сәфәр мәшәкатьләрен һәм мөсафирлыкны ихтыяр иткәннәр. Гыйлем вә мәгърифәте камил булганнарны, бөтенләй башка

RUHIAT

һәм чит халыктан булса да, һаман могтәбәр тотканнар. Бәгъдад шәһәрендә мәҗүси, саиби, // [15] яһүди, христиан галимнәренең бөек мөселман укымышлылары белән янәшә утырып гыйльми әңгәмәләр коруларының сәбәбе шул.

Бүген дә мәдәни халыкларның югары сыйныфтан булган галимнәре һәрбер гыйлемне тупларга кодрәте җитмәгән кебек, элекке мөселман галимнәренең дә олуг галимнәре хакында «һәр фәнне камил белгән» дип дәгъва ителмәсә, «һәрнәрсәне белү дәгъвасындагы кеше надан» диелгән кебек, камилләре хакында да «һәрнәрсәне белгән» дип арттырып сөйләнмәс.

Бөек галимнәрнең шөһрәтләре вә камиллекләре исә бары тик үзләре шөгыльләнгән гыйлемнәрендә вә гомерләрен фида иткән фәннәренә нисбәт белән булган. Үзләре шөгыльләнмәгән гыйлемнәр турында гади галимнәр дәрәҗәсеннән үтмәгәннәр.

Гади һөнәр һәм сәнгатьләрдән башлап иң югарыларына барганчы үз өлкәсенең осталары «әһле зикер» дип хисапланган. Һәрбер гыйлемнең зур белгече һәм «әһле зикер»е – бөек галимнәре була. Инде кайсы гыйлемдә булса да хаҗәт һәм мөшкеллек чыкканда, «Фәәсъәлү әһлиз-зикран күнтум лә тәгъләмун» аяте кәримәсе, шулай ук «Әстәгыйнү галә күлли сангати бисалихи әһлиһа» мәгънәсендә булган әсәр кебек һәр гыйлемнең үзенең олуг галимнәреннән сорау вә бәйан иткән фикерләрен һәм үрнәк тоту тиешле.

Оешкан көненнән башлап Бәгъдад хәлифәлегенең вә Әндәлес дәүләтенең көчсезләнү көненә кадәр булган вакыйгаларны тарих гыйлеме белән өйрәнгән һәм мөселман әсәрләрен тикшергән затлар алдында борынгыларыбыз вә, гомумән, мөселманнарның хәлләре ошбу нигезгә корылганлыгы ачык мәгълүм. «Бу зат ошбу дәрәҗәдә булган бөеклеге вә гыйлеме белән, әлбәттә, белми калмас» дип, үзләре шөгыльләнмәгән гыйлемнәр хакында фәтва сорамаганнар һәм мәсьәлә хәл иттермәгәннәр. Хәтта ки, хәл итәрлек булсалар да, җентекләп тикшермичә торып кабул итмәгәннәр. Хәдис мәсьәләләре хакында Имам Сәйбәвийәдән, һәйәт-астрономиядә Ибне Габделбәрдән, тел гыйлемендә Бохарыйдан һәм Бине Бәйтардан, нәхүдә Имам Кәрхидән, фәлсәфәдә Әхмәд бине Хәнбәлдән, тәфсирдә Ибне әл-Һәйсәмнән, шигырьдә Әбү Каләбадән бик тәфсилле тикшерenүләрнең мөселман китапларында күчерелмәвенең баш сәбәбе шулдыр. // [16]

Бөек галимнәрнең олуг хезмәтләренең безнең өчен зур ярдәмнәре барлыгы шөбһәсез. Моны инкяр итү Аллаһ нигъмәтләреннән баш тарту булыр. Рухларны хәер-дога илә шатландыру вә мөмкин кадәр тугры сыйфатларны телгә алып мактау – бурычыбыз. Ләкин һәрнәрсәдә үзенә муафыйк үлчәве булган кебек, яхшы фикердә, хөрмәттә булуның да мәгълүм бер карары була. Карарыннан читкә чыккан мактаулар хурлауга әйләнеп киткән кебек, үлчәвеннән үткән ихтирам да мәгънәле булмас. Хөрмәт итү нияте илә пәйгамбәрләргә гыйбадәт итү хәрам булган кебек, ихтирам итәмен, дип, һәрникадәр тәкъва вә галим булса да, бер галимне гөнаһлардан азат дәрәҗәсендә тоту һичвакытта дөрес булмас.

Катгый яки зарури дәлилләр белән расланмаган хәлдә, билгеле бер галимнең сүзен дөп-дөрес вә рас дип ышану белән әлеге шәхесне гөнаһсыз дип инану арасында никадәрле аерма бар?!

Кеше никадәр сакланып һәм никадәр игътибарлы вә дикъкатьле бер галим булса да, белеп яки белмичә бер хата сүз әйтүе һәм тискәре гамәл кылуы мөмкин. Ләкин моннан бөек галимнәребезнең һәр сүзләре хата дигән кебек бер дәгъва аңлашылмый һәм аңлашылмасын. Максат исә югары дәрәҗәдә булган галимнәрдән бер төрле караш яисә сүз ишетелеп тә, дәлилләр көтмичә, сукырларча иярү вә ышану, әлеге карашны нигезле дип карау муафыйк түгел.

RUHIAT

Бүгенге ислам галәменең борынгы мөселман мәдәниятенең дәвамы булуын яки хәзерге мөселманнарны әүвәлге мөселманнарның варислары, оныклары икәнлеген исбат итәрлек дәлил булуы иң мөшкел мәсьәләдер. Чөнки гайрәт һәм тырышлык, шулай ук гыйлем вә мәгърифәт өлкәсендә бу ике гөруһ арасында кечкенә генә дә охшашлык калмаган: әүвәлге мөселманнар иртәгә дә яшәячәк кеше мисалында ахирәт өчен вә мең ел торачак кебек дөнья өчен тырышкан да булсалар, бу замана мөселманнары ялкаулык һәм ваемсызлык йокысына шулкадәр чумганнар ки, уяну ихтималы да бик ерак калган.

Әһле ислам бәхет дәрәҗәләренең беренчесенә ирешкәннән соң ни хикмәт өчен җәһәннәм төбенә төштеләр?! Моңа ишарәт итүнең дә вакыты җитте. Бу юнәлештә киң вә тирән тикшерүчеләрнең мәгълүматларына күрә, // [17] мөселманнарның түбән төшүенә ошбулар сәбәп булган:

1) Аерымлык. Аллаһы Тәгалә хәзрәте: «Аллаһы Тәгаләнең бавына җыелышып ябышыгыз да аерылышмагыз!» – дип фәрман итеп торган хәлдә, мөселманнар, үз араларында булган бердәмлек бауларын өзеп һәм кисеп, нәфрәтләнеп, бер-берсеннән аерылганнар. Бу фирка теге фиркане бидгатькә нисбәт иткән, теге фирка исә монысын азгыннар дип санаган. Бәланең зурысы шул ки, мондый яман уйларны дин вә шәригать исеменнән йөрткәннәр. Рәсүле әкрам әфәндебез (саллаллаһу галәйһи вәссәллам) үзенең өммәтен үз юлына һәм изге сахабалар (Аллаһ алардан разый булсын) юлына чакырып, шуннан аерылудан кисәткән вә тыйган хәлдә, мөселманнар бу изге әмерне җиренә җиткерү өчен үзләренең гамәл һәм инанулары сахабалар юлына төшү зарур вә бер карыш аерылудан саклanyрга фарыз булган хәлдә, мөселманнар рәсүле әкрамның өммәтен фиркаләргә бүлү вә вак-төяк сәбәпләр белән күпләрне бер читкә аерып чыгарганнар.

2) Милләт киләчәгеннән вә милләткә бәйле файда һәм зарарлардан хәбәрләр исә аять вә хәдисләрне ялгыш аңлатып, халыкны байлыктан нәфрәтләндергәннәр. Моның нәтиҗәсе буларак әһле ислам кәсеп вә һөнәр, сәүдә һәм сәнгатьтән туктаганнар. Кулларыннан байлык киткән, башкалар ярдәменә мохтаҗ булып калганнар. Табигый, караклык вә талашу арткан. Юллар киселгән, кәрваннар тукталган. Байлык беткәч, гыйлемлек, үз-үзеннән сүнеп, мөселманнар белән хушлашкан.

3) Түбән җанлылар вә ялганчылар пәйда булу. Болар аркасында мәүзугълы (проблемалы) хәдисләр күбәйде, тәфсир китаплары Бәни Исраил кыйссалары белән тулды.

4) Мөнәсәбәте булмаган кешеләрнең гыйлемнән мәгълүмат бирүләре. Болар тарафыннан аять һәм хәдисләр ялгыш һәм хата тәфсир кылынганнар. Һөнәр вә сәнгатьләр шәригатькә хилаф дип аңлатылганнар.

5) Арасту вә Әфләтун фәлсәфәләренең пакь шәригатькә кушылып китүе. Моның аркасында ысуле игътикадат [инану ысуллары, ислам нигезләре] юнан-грек философлары терминнары белән өйрәтелә башлаган.

6) Гыйлемнәр өйрәтү һәм укыту өлкәсендә гадәттән тыш башлангыч өлешләре белән генә шөгыльләнү. Шәкертләр исә ун-унбиш еллар үзләренең уку вакытларын башлангыч мәйданында әйләнеп үткәрергә мәҗбүр булганнар. Вә бу сәбәптән максатларын күрүдән һәм осталыкка ирешүдән мәхрүм калганнар. Исламның артта калуына моннан башка сәбәпләр дә күп булган. // [18] Куәтле язучыларга без бу урында ишарә иткән маддәләрнең һәрберсе хакында томнар тулы китаплар язарлык.

RUHIAT

VIII

Бездә беркадәр дәрес китапларын күргән биш-ун том микъдарындагы китапларга ия булучылардан кайбер адәмнәр үзләрен галим вә мөселман шәригатенә хезмәт итүче дип ышаналар. Мондый ышануның тиешсез нәрсә икәнлеген аз булса да белдерү өчен үткән бүлекне яздык.

Кайбер дәрес китапларының өстәмә һәм кушымталарыннан, остазларыннан ишеткән ысул белән укыту галим булу өчен җитмәгән кебек, кайбер шәхесләрнең әсәрләрен үзеңдә булдыру да шәригать хадиме исемен алырга җитәрлек булмас. Бәлки хадим булу өчен иң газиз гомер вә вакытларны корбан итү һәм иң ләззәтле теләкләрне фида кылу, ишеткән авыр сүзләргә сабырлы булу, көне-төне элгәреләрнең әсәрләрен тикшереп, һаман укуда булып, киләсе буыннарга йә телдән, йә язып гыйлем өйрәтү юлында булу кирәк.

Үзебезнең мөселман гыйлемнәренә булган хезмәтләребезнең дәрәҗәсен ачык белү өчен, Европа галимнәренең тырышлыклары илә чагыштыру җитәр. Европа галимнәренең дөньяви гыйлемнәргә булган хезмәтләре белән түгел, бәлки безнең шәргый гыйлемнәребезгә булган хезмәтләре бик тә гаҗәеп. Мәсәлән, мөселманнарның иң кыйммәтле нөсхәләрен кулларыннан чыгарган хәлдә, европалылар, дөнья малларын сарыф итеп, мөселман әсәрләрен җыйганнар. Европаның мәшһүр китапханәләрендә хисапсыз мөселман китаплары саклануның сәбәбе шушы. Коръәни Шәрифне иң элек Европа галимнәре бастырганнары кебек, сирәк очрый торган тәфсир вә хәдис китаплары да алар тарафыннан дөньяга таратылган. Бу җөмләдән «Тәфсире Кәшшаф»ны Ли исемендә бер галим 1276/1860 елда Калькуттада, «Тәфсире казый Бәйзави»не Фляйшер исемендә бер алман Лейпциг шәһәрендә бастырды. Алман галимнәреннән Фел исемендә бер зат Лейпцигта басылган тәфсир өчен камил сурәттә бер эчтәлек-каталог та төзегән. «Сахихел-Бохарый» өч том булып, 1868 елда Лейден шәһәрендә басылган. Шәмседдин әз-Зәһәбинең «Мөштәбә»се Де Юнж исемле галимнең төзәтүе илә 1881 елда Лейден // [19] шәһәрендә басылды. Сийәр, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең гадәт һәм әхлагын, тормышын яктырткан китаплардан «Сийәрәте Ибне Һошшам» ике томлы булып, 1857 елда Гуттенгенда алман галимнәреннән Востенфельд тырышлыгы белән, Имам Вакыйди тарихы «Фөтухе ислам» алман галимнәреннән Фон Крамер гайрәте илә 1856 елда Калькуттада, Биләзаринең «Фәтхел-әмсар» исемле китабы өч томлы булып, Диэ Жуйе һәм Эһельварт тарафыннан 1864 елда Лейденда басылганнар. Әбү Хәнифә әд-Дәйнүринең «Әл-әхбар әт-тауваль» исемле әсәре Җәрҗис исемле галим тарафыннан 1888 елда Лейденда нәшер ителде. Ибне Катибәнең «Китабел-мәгариф» исемле әсәре 1850 елда Востенфельд тарафыннан Гуттенгенда, «Тарихе Табарри»ның күп урыннары Диэ Жуйе, Барис, Нольдки, Лос исемле галимнәрнең әһәмият бирүләре белән 23 кисәктә Лейден шәһәрендә 1879 елда басылды. Имам Мәсгудинең «Мәһүәҗеззәһб» исемле әсәре 1861 елда Де Майнард исемле француз галиме тарафыннан Парижда 14 томлы итеп басылган. Ибне әл-Әсир хәзрәтләренең «Камилет-тәварих» исемле әсәре 14 томлы булып, Лейден шәһәрендә Турнберг исемле галимнең төзәтмәләре белән 1851 елда басылган. Бу әйтелгән әсәрләр фәкать үзебезнең мөселман шәригатебезгә бәйле нәрсәләр. Хәлбуки бу хакта сөйләмичә калганнарыбыз болардан да күбрәк. Әмма дингә бәйле булмыйча, мөселман әдәбиятына караган нәрсәләр дә (мәсәлән, шигырь, фикерләр, бәйан, риторика, сарыф, нәхү, тарих кебек) Европа галимнәренең күрсәткән һөнәрләрен бәйан итеп язу безнең көчебездән килми. Шулай ук бу хакта языласак бәхәснең ахыры һәм очы да чыкмас. Без исә, үз мәмләкәтебездә булган мөселман галимнәре илә Европа галимнәре арасында булган гайрәт вә тырышлыкларын үлчәүчеләргә, бәлки, ярдәм булыр, дип, әлеге мәгълүматны яздык. Һәркем, үзенең вөҗдан вә инсафына кайтып, бер төрле хөкем йөртер. // [20]

**1. Әхмәд бине Фәзлан бине әл-Габбас бине Рәшид бине Хәммад әл-Бәгъдади**

Бәгъдад галимнәреннән иде. Дүртенче (милади унынчы) гасырның башында исән-сау булганлыгы мәгълүм. Габбаси хәлифәләрдән Әбелфазыл Җәгъфәр әл-Мокътәдир Билләһи тарафыннан безнең Болгар шәһәренә җибәрелгән илчелектә кятиб [секретарь, язып баручы] итеп билгеләнгән булган. Шуның сәбәбеннән Болгарга озын бер сәяхәт итте. Болгар хакында китап язган галимнәрнең (безнең уйлавыбызча) әүвәлгесе – ошбу зат. Рус халкы хакында булган мәгълүматның күбесен тарих галимнәре Ибне Фәзланның бу әсәреннән алганнары кебек, башкорт халкының исеме дөньяга чыгуына да ул сәбәпче булган. Ибне Фәзлан Болгар мәмләкәте хакында күп мәгълүмат биргән. Үзе күреп белгән нәрсәләрне дикъкать вә дөреслек белән язса да, кешедән ишетеп, риваятьләргә нигезләнеп язган кайбер вакыйгаларында арттырулар да булган икән. Андый хәлләр һәрбер сәяхәтчеләрдә булганга, Ибне Фәзлан да чыгарма түгел. Әлеге илчеләр, 309 һиҗри/921 милади елның 11 сәфәрендә/21 июньдә Бәгъдадтан аерылып, Хорасан, Хәрәзем мәмләкәтләрен үтеп, Оренбург вә Самара вилайәтләре урыныннан кичеп, Болгарга килеп җиткәннәр. Бу вакытта Болгар ханы Алмас бине Силги исемле зат иде. Илчеләр хозурында үзе исемен мөселманча Җәгъфәр исеме белән алмаштырган[8]. Ошбу илчеләр төркемендә олуг галимнәр, мәшһүр әдипләр, танылган укымышлы затлар, хәтта ки астроном һәм мөһәндис тә [инженерлар] булган. Болгар шәһәре мәчетенең нигезе дә болар хозурында нигезләнгән. Әлеге илчеләр илә килгән халыкның Болгарда калганнарыннан башкалары, Бәгъдадка кире сәфәр итеп, 310 һиҗри/922 милади елда изге мөхәррәмнең 12 сендә/12 майда Бәгъдадка ирешкәннәр. Гәрчә «Иктифаэль-конугъ» авторы Ибне Фәзланны 309/921 елда вафат булды дип язса да, Аллаһы әгъләм [белүче], ялгыш язылса кирәк. Чөнки һиҗри 310/милади 922 елда // [21] Бәгъдадка кайтып кергәнлеген үзе анык язган.

RUHIAT

**2. Хамид бине Идрис әл-Болгарый (казый)**

Һиҗри 500/милади 1107 елларда исән булган. Сөләйман бине Дауд исемле зат «Зөһрәтер-рияз» китабында ошбу кешедән хәдисләр китергән.

**3. Әбү Хәмид әл-Әндәлеси**

Әндәлес галимнәреннән булып, 529/1135 елда Болгарга килгән. Ошбу вакытта Болгарның мәшһүр галиме һәм казые Ягъкуб бине Ногман илә күрешеп, әңгәмәләр корганнар.

**4. Ягъкуб бине Ногман әл-Болгарый**

Бу зат Болгарда казый булып, Болгар хакында махсус тарих китабы да язган. Остазы Әбүл-Мәгалә Габделмөлек бине Габдулла әл-Җүвәйни[9]. 559/1164 елда вафат булган. Кабере Болгарда булса кирәк.

---

[8] Бөтен Болгар вилайәтендә хакимлек иткән бер хан, гарәп галимнәре хозурында үз исемен мөселман исеменә алмаштырган хәлдә, безнең имамнарыбыз саф грек исемнәре булган Әфләтун (Платон) кеби исемнәрне балаларга кушып киләләр.

[9] Бу зат Нисабурга (Нишапур) буйсынган Җүвәйн авылыннан булып, берникадәр Бәгъдадта торган. Аннан Мәккә илә Мәдинә шәһәрләрендә яшәгән вә бу мөнәсәбәт илә «Имам әл-хәрәмәйн» исеме белән танылган. Ахырында Нисабурга кайтып, «Низамия» мәдрәсәсендә (бүгенге университет мәдрәсәләре исемендә) дәрес әйткән һәм 59 яшендә 478/1085 елда Нисабурда вафат булган. Боларны игътибарга алганда, Ягъкуб казый, бик яшь вакытында ошбу шәһәрләрнең берәрсенә барып, бу заттан гыйлем өйрәнгән булган.

### 5. Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Габдеррәхим бине Сөләйман (Гарнати)

560/1165 елдан соң вафат булган. Әндәлес галимнәреннән булып, 530/1136 елда Болгарга килеп, казый Ягъкуб бине Ногман илә күрешеп, мәҗлесендә булган. Башкортлар арасында да сәяхәт иткән. «Төхфәтел-әхбаб вә нәхбәтел-әгъҗаб» исемле китабында Болгар вә башкорт мәмләкәтләре хакында беркадәр хәбәрләр язган. Ләкин беркадәр хаталы булганлыктан, ышанырга бик кыендыр. Гадь кавемнәренең тешләрен башкортта күрдем, дип, зурлыкларын белдергән. Мәгәр дә бу тешләр гадь кавеменең тешләре булмыйча, бәлки шул гасырларда чуд (фин) халкы тарафыннан җыелып, сәүдәдә булган су сыерлары (морж) тешләре булганлыгы бик ихтималга якын. Элекке заманнардан калган хорафатларга ышанып, бу тешләрне башкортлар гадь кавеме тешләре дип уйлап хәбәр биргән булырлар. Бу кеше дә аларның хәбәрләрен инкяр итми язган булыр. Чөнки гадь кавемнәренең урыннары билгеле булып, башкорт сахраларында булмаганы кебек, Болгар // [22] тирәсендә дә түгел. Хәлбуки тарихчылар гадь кавемен, риваятьләрдә күрелгәнчә, манаралар кадәр озын бәдәнле вә гаҗәеп куәтле кешеләр булмыйча, гади инсаннар иде дип дәгъва итәләр. Болар сүзенә караганда, әүвәл заман хикәятчеләре, һичбер зарурлык булмый торып, Гауҗ бине Гаукъ кеби олуг бәдәнле вә озын гомерле, дөньяга тудырылмаган бер заттан хәбәр биреп, ничә төрле вакыйгалар булдырган хәлдә, гадь кавеменең дә гадәттән тыш куәтле вә гаҗәеп эшләрен күргәннән соң, боларның буй һәм куәтләре хакында тел белән күңелгә килгән кадәр хорафатны сөйләгәндә, бер-береннән арттырганнар. Боларның фикерләренчә, зур биналар төзү өчен, һичшиксез, зур бәдәнле вә куәтле булу кирәк, имеш. Хәлбуки гаҗәеп олы һәм зур эшләр тудыру, бәдән зурлыгына бәйле булмыйча, мәдәнияткә бәйледер. Гадь кавемнәре дә бик мәдәни халыклардан булганнар.

RUHIAT

### 6. Мохтар Әбүр-Риҗа Нәҗмеддин бине Мәхмүд бине Мөхәммәд (Заһиди)

688/1289 елда вә бер риваятьтә 658/1260 елда вафат булган. Бәркә[10] хан гасырында Сарай шәһәренә килеп, Бәркә хан исеменә атап «Әр-рисаләтен-насыйрийә» исемле китабын язган. Асылы Хәрәзем вилайәтендә Газмин исемле шәһәрчектән. Мәзһәбләрне белүдә, бәхәскә осталыкта беренче дәрәҗәдә мәшһүр булган. Гыйлемдә камиллеккә ирешкәч, Бәгъдад шәһәренә барып, галимнәре илә әңгәмәләр корган. Язган әсәрләре күп. Мәгәр дә бу дәрәҗәдә олуг бер кеше булган хәлдә, сүз күчерүдә игътибарсызлыгы күп булыр иде, диләр.

### 7. Хәсән бине Гомәр әл-Болгарый

Туксан яшеннән узып, 699/1300 елларда вафат булган. Вафат вакыты турында башка төрле сүзләр дә бар. Болгарга килеп, берничә еллар торган. Дошманнары тарафыннан зур бер бәла килү ихтималы булганга, Болгарны калдырып, Бохара шәһәренә киткән. Бохарада Гобәйдулла Садрешшәрига хәзрәтләре үзенә мөрид булган.

---

[10] Җучи хан угылы булып, асыл исеме Бүркә иде. Татар ханнарыннан иң элек исламга күчеп, исемен Бәркәгә алмаштырганнар. Әбүл-Мәгалә Насреддин дип тә йөртелгән. Татар ханнарының мәшһүр һәм танылганнарыннан булган.

## 8. Хөсәен бәк бине Измир бәк

Кабер ташына язылганга караганда, җитмеш алты яшендә, 744/1343 елда мөхәррәмнең җидесендә вафат булган. Кабере Уфадан Самарага // [23] барганда икенче тукталыш, «Чишмә» исемле вокзалга якын мәшрикъ тарафында. Өстендә тәрәзә вә ишекле таш бинасы бар. Әлеге бина кабер өстенә корылганмы, югыйсә бина үзе мәнфәгатьтән чыккач, ерткычлардан саклансын өчен җеназаны башта булган әзер бина эченә җирләнгәнме – монысы мәгълүм булмады. Нәкъ ошбу бина кебек үк, шул урынга якын җирдә тагын бер башка бина бар. Монысында исә кабер-фәлән юк. Бер риваять буенча, Аксак Тимер, Туктамыш хан илә сугышып йөрүендәме яки башка бер сәфәрендәме, ошбу урында берникадәр вакыт калып, әлеге биналарны үзенә торыр өчен төзеттергән, имеш. Ошбу вакытта аның алты бие вафат булып, бу бинаның янына җирләнгәннәр. Гәрчә боларның өсләрендә ташлар булса да, аларда язулар юк. Кайберәүләр фикеренә күрә, бу корылма, кабер өстенә төзелмичә, нугай ханнарының җәйге тору урыннары булып, алар өчен бина кылынганнар, имеш. Хөсәен бәк каберенең өстенә зур таш куелып, исеме һәм яшәгән еллары уелып язылган.

Бабур мирза Заһиреддин Мөхәммәд бине Мирза Гомәр хан («Бабурнамә» китабының авторы) тарафыннан, иң беренче мәртәбә буларак, Хөсәен хаҗи исемле бер кеше Русия дәүләтенә илче булып килгәч яки илчелек хезмәтен тәмам итеп кайтып барганда Иделнең мәшрикъ тарафында бер урында вафат булып калганга, әлеге илченең үзедер дип фикер йөртүчеләр бар. Ләкин еллары моңа туры килми. Бу тарафта булган башкортларның ата вә бабаларыннан ишетелеп калган риваятьләренә караганда, бу зат (Хөсәен бәк) Төркестан шәһәреннән, имеш. Төркестан тарафында мәшһүр булган Хуҗа Әхмәд Ясәви исемле шәехнең мөридләреннән булып, гүя остазы вә шәехе тарафыннан бу вилайәттә булган башкортларга ислам дине һәм шәригать өйрәтү өчен җибәрелгән, имеш. Монда килеп башкортларга гыйлем өйрәтү илә мәшгуль булган вә бер заманда хаҗ кылып та килгән, имеш. Тәне һәм акылы бик сәламәт булган хәлдә вафат иткән. Кабер ташы әллә ничә дөя белән Сәмәркандтан вә бер риваятьтә унике үгез белән Бохарадан китерелгән. Башкортлар гүя моның каберендә нур күрәләр яки күргәннәр. Шуның өчен һәр тарафтан килеп каберен зиярәт итәләр, корбаннар да суеп китәләр. Ошбу әтрафта булган күп мәҗүсиләрне күркәм вәгазе илә мөселман иткән. Башкортлар риваяте монда тәмам булды. Ләкин бу хикәяттә күп күпертүләр булса кирәк. Әгәр дә тарихларында // [24] бер хаталык булмаса, Хөсәен бәк Хуҗа Әхмәд Ясәви тарафыннан җибәрелергә заманнары туры килми. Бәлки бу кеше туган көндә Хуҗа хәзрәтләре күптән, ягъни 562/1167 елда вафат булган. Шулай ук, ул заман мөридләрендә «бәк» кебек ләкабләр булмаган. Бәлки бу ләкаб түрәләр вә мирзаларга махсус бер титул булган. Моннан өстен, һиҗри җиденче гасырда, Идел буенда вә Урал вилайәтләрендә ислам дине җәелеп, камил дәрәҗәдә ныгыган иде. Араларында галимнәр һәм мөхтәрәм затлар күп булган, мөселман мәмләкәтләренең кәрваннары өзлексез йөргән. Шуның өчен башкортларга ислам өйрәтергә килде дигән сүзне кабул итү бераз кыен. Сарайда булган ханнар тарафыннан ошбу якларны идарә итәр өчен җибәрелгән бәкләрнең берәрсе булыр дип уйлаучылар да бар. Бу да бик ихтимал. Милади 1891 елда май аеның 24 ендә яки 25 ендә ошбу урыннарны йөреп, күргән идем. Гаять тә хуш урыннар. Яныбызда булган башкорт дөнья күргән бер мәгълүматлы зат иде. «Боларны сахабалар кабере дип әйтәләр», – дип, тагын беркадәр зират күрсәтсә дә, язуларын укыгач, һиҗри XII (XVII) гасырның башында вафат булган башкортлар зираты булып чыкты. Ошбу заттан күп нәрсәләр сорашып сөйләтсәм дә, күбесе хорафат һәм нәзер ашаучылар тарафыннан сеңдерелгән нәрсәләр дип хөкем йөрттем.



RUHIAT

**9. Ибраһим Борһанеддин бине Хәзир әл-Болгарый**

751/1350 елда исән булган. Бу зат «Фосулен-Нәсәфи фи гыйльмил-җәдәл» исемле китапка шәрех (комментарий) язган Ибраһим Борһанеддин бине Йосыф идеме, түгелме – мәгълүм булмады.

**10. Әхмәд бине Мәхмүд әл-Җәнди**

«Гаҗаибел-мәкъдур» китабында әл-Хөҗәнди рәвешендә язылган. Сарай шәһәрендә торганлыгын Ибне Гарәбшаһ язган. Имам Матразиның «Әл-мисбах» исемле китабына 751/1350 елда «Әл-мәкалид» исемендә бер шәрех тә язган. Вафаты соңрак булса кирәк.

**11. Садир Әбү Мөхәммәд бине Галәведдин әл-Болгарый**

Таҗеддин Ибраһим бине Мөхәммәд атлы шәкертенә 766/1365 елда иҗазәтнамә (ишанлык шәһадәтнамәсе) язган.

**12. Мөхәммәд Котбеддин бине Мөхәммәд әр-Рази әш-Шафигый әт-Тәхтани**

Үзбәк, шулай ук Җанибик ханнар заманасында Сарай шәһәрендә торган. Безнең мәмләкәтебездә гамәлдә булган «Шәмсийә шәрхе» китабы ошбу зат // [25] әсәре. 766/1365 елда вафат булган.

**13. Мөхәммәд шәйх Болгарый**

«Кәшфез-зөннун» китабында Кятиб Чәләби әйтүенчә, «Хәзинәтел-голәма вә зиннәтел-фөкара» исемендә бер хезмәт язган. Башка әхвале билгесез.

**14. Ибраһим Минһаҗеддин бине Сөләйман әс-Сарайи**

Сарай галимнәреннән булган. «Һидайә» китабы авторының «Әл-фәраизел-Госмани» исемле китабына язылган «Мәфатихел-әкъфаль» исемле шәрех ошбу затныкы.

**15. Әхмәд бине Шәмседдин**

Сарай галимнәреннән мәшһүр шәхес. Гарәп, фарсы, төрки телләрен камил дәрәҗәдә белгән. Моны Аксак Тимер Сәмәрканд шәһәренә алдырды, диләр.

**16. Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Габдулла бине Мөхәммәд бине Ибраһим (Ибне Батутта) әт-Тәнҗи. Ләкабе** [кушаматы] **исә Шәмседдин**

Гарәп галимнәреннән бик мәшһүр бер зат. 703/1304 елда мәгърибтә Тәнҗә шәһәрендә дөньяга килеп, 77 яшендә 780/1378 елда вафат булган. 23 яшендә башлаган сәяхәтендә дөньяның һәр тарафына барган. Гыйрак, Мисыр, Шам (Сүрия), Йәмән, Һинд өлкәләрен гизгән. Шулай ук Синоп шәһәреннән Кара диңгез аркылы Кырымга чыккан. Мөхәммәд Үзбәк хан заманасында Сарайга килеп, беркадәр сәяхәт кылды. Аннан Төркестан, Кытай мәмләкәтләренә киткән. Аннары Африка эчләрендә сәяхәт итеп, Әндәлескә барган. Шунда сәяхәтнамәсен тә-

RUHIAT

мамлап, «Төхфәтен-нәзар фи гараибел-әмсар вә гаҗаибел-әсфар» дип исем куйган. Бу китапны исә Европа галимнәре, җаннарыннан кадерле күреп, Европаның барлык телләренә тәрҗемә иткәннәр, кабат-кабат бастырып, нәшер иттеләр. Шулай ук французча тәрҗемәсе илә асыл нөсхәсен француз галимнәре, дүрт том итеп 1874 елда Париж шәһәрендә бастырганнар. Шулай ук 1288/1871 елда Каһирәдә дә 2 томлы итеп бастырылган. Бу сәяхәтнамәнең кыскачасы да бар. Кыскачасы исә 79 кәгазьдә 1287/1870 елда Каһирәдә басылган. Сарайга килүендә Үзбәк хан хозурына кабул ителгән вә, шул заманның гадәтенчә, ханның хатыннары хозурына да кергән. Ордуҗа, Биләмүн, Тайтагълы, Кәбәк исемле хатыннарыннан, Иткөчек исемле кызыннан зур илтифатлар вә олуг хөрмәтләргә ирешкән. Хәтта ки ханның хатыннары кулыннан савыт белән кымыз алып эчү сирәк затларга насыйп булган зур бер илтифат булган, Тайтагълы ханәш (ханбикә) // [26] үз кулы илә бу затка кымыз да биргән. Үзеннән исә күп нәрсәләр сорашып, бик хөрмәт иткәннәр. Иткөчек солтан, Гайсә исемле бер түрә никахында булып, ханнан бер читтә торган, имеш. Бу кешене кабул иткән вакытында мәҗлескә сәед Шәриф ибне Габделхәмид исемле затны, шулай ук казый вә галимнәрне, шәкертләрне дә бергә чакырган.

### 17. Мәсгудь Кәмаледдин Хөҗәнди

Төп чыгышы Хөҗәнд шәһәреннән булып, хаҗ сәфәренә юнәлгән. Кайтканда Тәбриздә туктап, яшәр өчен калган. Дәшти Кыпчакның Туктамыш хан гаскәре белән Тәбризне яулап алгач, Мәсгудь Хөҗәнди Сарай шәһәренә җибәрелгән. Дүрт ел Сарайда калып, аннан Тәбризгә киткән. 792/1390 елда вафат булган. Кабере Тәбриздә. Шәех һәм шагыйрь булган. Ләкин югары катлауларны мактап шигырь сөйләмәгән, диләр. Хуҗа Хафиз Ширази илә дә замандаш һәм дус булган. Сакалы бик озын булган, имеш.

RUHIAT

### 18. Мәсгудь Сәгъдеддин бине Гомәр әт-Тәфтазани әш-Шәфигый

792/1390 елда Сәмәрканд шәһәрендә Аксак Тимер хозурында кинәттән вафат булган. Җеназасы Сәрхәскә күчерелеп җирләнгән. Сарай шәһәренә килеп, Үзбәк хан һәм Җанибик хан заманнарында беркадәр яшәгән. «Мөхтәсар шәрхе тәлхыйс» китабының кереш өлешендә әлеге Җанибик хан исемен телгә алган.

### 19. Йосыф Җәмаледдин бине әл-Хәсән бине Мәхмүд

Сарай шәһәреннән булган. Соңрак Тәбриздә дә торган. Имам Нәвоинең «Әрбәгыйн» китабына бер шәрех [комментарий] язган. 884/1479 елда вафат булган.

### 20. Мөхәммәд бине Хафизеддин бине Мөхәммәд Шиһабеддин бине Йосыф. Ибне Бәззаз исеме белән мәшһүр булган

Чыгышы белән Хәрәземнән булып, Сарай шәһәрендә торган. Аннан Кырым мәмләкәтенә барган. Соңрак Хаҗитархан (Әстерхан) шәһәренә килеп, галимнәре белән аралашкан. Бу шәһәрдә күп еллар гомер кичергән. Аннан Хәрәземгә кайтып киткән. Шуннан соң, икенче мәртәбә килеп, Рум мәмләкәтенә сәфәр иткән. Анда исә Шәмседдин әл-Фәнари илә күрешкән. «Әл-важиз» исемендә булган фәтваларны (бездә «Фәтави Бәззазийә» буларак мәгълүм) безнең бу мәмләкәтебездә туплаган. Сиксән яшеннән узып, 827/1424 елда вафат булган.

**21. Гыйсамеддин бине Габделмөлек әл-Мәргыйнани** // [27]

«Һидайә» китабы авторы нәселеннән булган. Сарай шәһәрендә яшәгән. Хаҗдан кайткач, 814/1411 елда Әстерхан шәһәрендә дә берникадәр гомер кичергән. 840/1437 елда Сәмәрканд шәһәрендә булган. Вафаты соңрак булса кирәк. Абруйлы вә шагыйрь бер зат булган.

**22. Әхмәд Шиһабеддин бине Мөхәммәд бине Габдулла (Ибне Гарәбшаһ)**

Димәшкъ шәһәрендә дөньяга килгән. Аксак Тимер, Димәшкъ әтрафын яулаганда, Ибне Гарәбшаһны, барлык кавем һәм кабиләсе илә әсир итеп, Сәмәркандка җибәргән. Сәмәркандта төрки телен өйрәнеп, гарәп һәм төрки телләрендә оста булган. Аннан Идел буйларына, Урал тарафларында сәяхәт иткән. Болгарга килеп, озак еллар Сарай вә Әстерхан шәһәрләрендә торган. Әстерханда вакытында 813/1410 елда Габделваһаб исемле угылы дөньяга килгән. Соңрак Кырымга вә аннан диңгез илә Әдернәгә киткән Солтан Мөхәммәд бине Госман тарафыннан угылы Морад өчен китаплар тәрҗемә итү хезмәтенә билгеләнгән. Ошбу хезмәтендә азмы-күпме булып, ахырында туган урыны Димәшкъкә кайткан. 854/1450 елда Димәшкътә вафат булган. Яше 63тә булган. Гарәп галимнәренең мәшһүрләреннән, фикъһ галиме, әдип, шагыйрь, тарих гыйлеменә маһир бер зат булган. Аксак Тимер хакында язган «Гаҗаибел-мәкъдур фи нәуаиби Тимур» исемле китабы мәшһүр. Бу китап тел җәһәтеннән бик матур һәм аңлаешлы, шигъри һәм ләззәтле булса да, тезмә әсәр дип каралырга мәҗбүр булуы сәбәпле, күп файда алыначак урыннары караңгылыкта калган. Телен зиннәтләүдән бигрәк, мәгънәсенә игътибар биргән булса, файдасы тагын да күбрәк булыр иде. Әлеге китапны исә Голбус исемле бер европалы галим 448 кәгазьдә 1636 елда Лейден шәһәрендә бастырган. Шулай ук 1812 һәм 1818 елларда Калькуттада вә соңрак 1285/1868 һәм 1305/1888 елларда Каһирәдә нәшер ителгән.

**23. Касыйм бине Ибраһим әл-Казаный**

Казан халкы һәм Казан әтрафында Касыйм шәех дип мәшһүр булган бер зат. 998/1590 елда Кәрминәдә вафат булган. Бу шәхес турында мөхтәрәм Мәрҗани «Казан халкында Касыйм шәехнең Казан кешесе булуы мәгълүм, хәтта ки кайберләре, Казанда җирләнгән, диләр. Мәвараэннәһер тарафында да аны Казанга нисбәт итүчеләр бар, ләкин кабере билгеле. Казан шәһәрендә Беренче мәчет мәхәлләсендә // [28] бер йортны «Касыйм шәех йорты» дип, нәзер вә садакалар китерәләр.

Ошбу йортның күбрәк өлеше хәзер Гали бине Максуд атлы кеше милкендә, ләкин ул исә садака вә нәзерләрдән файда күрми. Әмма бер өлеше Габделвәли бине Йосыф балалары – Әхмәд, Салих, Гайшә милкендә. Болар садакалардан файда итәләр. Ләкин бу урында Касыйм шәех үзе булмыйча, бер мөриде генә булган дигән сүз дә бар. «Тәварихы Болгария» китабында бу кешене «Казан халкыннан иде, вафаты да Казанда булды. Яңа Чаллы авылында Юныс бине Зөлмөхәммәд исемле кешенең мөриде иде, дип әйтелгән» дип язган. Казан шәһәре Русия тарафыннан басып алынган вакытта чыгып китеп, Мәвараэннәһергә барган дип уйлаучылар да бар.

## 24. Хисамеддин бине Шәрәфеддин

Үзе язуына караганда, Казан вилайәтендә Ташбилге авылы халкыннан вә Мөслим баба исемле затның нәселеннән. Һиҗри (милади XVI) гасыр ахырында исән булган. «Тәварихы Болгария» исемле әсәре халкыбыз арасында билгеле. Кырык битле булып, Казанда берничә мәртәбә басылып таралган. Кульязма нөсхәләреннән күпләрен вә гаять тә оста язылганнарын күрдек. Фәкать язганнары беркадәр озынрак. Бу әсәрне күчереп язып, бу кадәр таратуларыннан халкыбызның тарих гыйлемен бик яратканлыгы һәм сәләтле икәнлеген, вә язган нәрсәләргә аз гына булса да хөкем йөртеп карамыйча ышануларын, иярүчән булуларын әйтергә мөмкин. Әлеге тарихны Сәгъдеддин әт-Тәфтазани хозурында укып кайтканның соңында, 34 ел эчендә язганлыгын вә 992/1584 елда Ташбилге авылында мөхәррәмнең 15 көнендә/28 гыйнварда тәмам булды дип күрсәткән. Бу тәкъдирдә әлеге китабын Тәфтазани вафатыннан (аның вафаты исә 792/1390 елда) ике йөз ел соңрак тәмам иткән була. Болай булган хәлдә Тәфтазаниның шәкерте булганлыгына ничек ышанырга? Моннан башка вакыйгаларны сөйләгән вакытында күрсәткән руми вә гарәпчә һәм фарсыча айларның һичбере бер-беренә туры килми. Хәтта ки китабы тәмам булган вакытны бәйан иткән чагында булган мөхәррәм җивәзгә түгел, дәлү, ягъни гыйнварга туры килә. Инде шулкадәре язуны дөресләмәгән кешенең башка сүзләренә ничек ышанырга кирәк? Адәм угылы ялган сөйләргә мәҗбүр булган вакытында гарәпчә һәм руми айларны күрсәтү кирәк дип белсә, мөмкин кадәр туры китерергә тиеш. Шуның өчен, фикеребезчә, бу китап тагын беркадәр // [29] еллар соңрак язылган булса кирәк. Илле яки йөз ел үткәннән соң руми илә гарәпчә айларның туры килгән көннәрен тикшермичә, уйламыйча язган булып чыга. Безнең фикеребез шулай. Китабында гадәттән тыш күп нәрсәләр җыеп язуына гаҗәпләндек вә хөкем йөртмичә язганлыгы өчен дә борчылдык. Бичараның газиз гомерләре вә кыйммәтле вакытлары урынсызга һәм файдасызга әрәм булган. Китабында унберенче (милади унҗиденче) гасыр галимнәреннән мәгълүмат бирелгән хәлдә, Казанда булган Шәрифкол кеби олуг затлардан, шулай ук Казан шәһәренең русиялеләр тарафыннан яулануы кебек дөньяның беренче дәрәҗәдә зур вакыйгасыннан аз булса да хәбәр вә ишарә булмаганлыгына да һичбер сәбәп таба алмадык. Хәлбуки үзе «Русиялеләрнең Покрау бәйрәме Казан алынган өчен һәр елда, октябрь башында билгеләп үтелүче шатлык көннәре» дип язган. Моның китабы турында хөкем йөртү һич ниятебездә булмаса да, бу кадәресен яздык. Уебызча, бер мавыгучан адәм булып, гомерләрен зиратларда йөреп, һәрбер нәзер вә садака ашаучылар тарафыннан чыккан хәбәрләргә ышанып язып йөргән булса кирәк. Рәтен[11] бабайның 600/1204 елдан соң рәсүле әкрам әфәндебезгә (салаллаһу галәйһи вәссәллам) әңгәмәдәшчелек дәгъвасын белдергән хәлдә, Хисамеддин бабайның 200 елдан соң Тәфтазанига шәкертлек дәгъвасын белдерүе бик гаҗәп булмас. Күп могтәбәр шәхесләрнең каберләрен безнең мәмләкәтебездә итеп

[11] Әберриза Рәтен бине Кәрбаль бине Рәтен. Һиндстанның Битрәндә шәһәреннән булган. Сахабалыкны һәм хәзрәти Фатыйманың никахында булганлыгын дәгъва иткән. «Камус» китабы авторы «Сахабалардан түгел иде» вә «Камус шәрхе» авторы булган Сәед Мортаза да «бер ялганчы иде» дигән. Ләкин Хафиз Зәһәби, бу кешенең дөньяга килүен кире кагып, бер уйдырма адәм булганлыгын белдергән. Мөхтәрәм Мәрҗани милкендә булган «Камус» нөсхәсендә бу урында «Сахабалардан түгел иде» җөмләсе төшеп калган булса кирәк. «Мокаддимәи вафийәтел-әсляф...»ка мөрәҗәгать ителде.

күрсәтсә дә, рәсүле әкрам әфәндебез (саллаллаһу галәйһи вәссәллам), шулай ук аның хәлифәләренең (Аллаһы Тәгалә алардан разый булсын) каберләрен Болгар мәмләкәтендә итеп күрсәтергә батырчылыгы җитмәгән. Монысына да күп шөкер!..

### 25. Янсарый бине Хафиз бине Байсарый бине Килдеш бине Килуаз

Казан ягында Оры авылыннан. 1099/1687 елның мөхәррәмендә/ноябрендә вафат булган. Оры зиратында кабере мәгълүм. Балалары һәм нәселе шул якларда таралганнар. Йүчәнәһал исемле кызы Юныс бине Иванай никахында булган. Бу кешенең вафаты белән Казан шәһәренең русиялеләр тарафыннан // [30] яулануы арасында 130 елдан артык вакыт үткән. «Хафиз» дип хәдис әһелләрендә эчтәлек һәм дәлилләре илә йөз мең хәдисне күңеленә алучы ятлаучыга әйтелсә дә, Бәгъдад мөселманнары тарафыннан үзенең лаеклы кешеләрен атый торган бу исемтитулны безнең халкыбыз алып, үзләренең һәрбер олылаган, бөек дип саналган кешеләренә мактаулы исем буларак кулланган. Хәтта ки укый-яза белмәгән кешеләргә дә әйтә башлаганнар. «Абзый», «абыз тутай», «абыстай» сүзләре «хафиз» сүзеннән үзгәртелгәннәр, диючеләр дә бар. Ләкин Сибириядә булган христиан татарлар бу исем белән үзләренең попларын да атауларын кайбер сәяхәтчеләр сөйләделәр. Бу очракта «хафиз»дан үзгәртелмичә, төркичә сүз булганлыгы да бик ихтимал.

RUHIAT

### 26. Иванай бине Усай

Казан төбәгендә Кәче авылында имам вә мөдәррис булып, 1100/1689 елларда вафат иткән. Казан якларында нәселе күп. Мәшһүр Юныс әфәнде бу затның угылы булган. Язуга оста булган. Мөхтәрәм Мәрҗани «Иванай хафизның бүген булган нәсәпләре үзләренең нәсел шәҗәрәләрен Иванай бине Габделхаликъ бине Шаһнәсәб бине Габделкадыйр бине Габделкәрим бине Габдеррәхим бине Габделмәннан бине Габдулла бине Мәсгудь бине Әбүзәр дип йөриләр. Ерак бабалары гүя изге сахабалардан булган. Әбүзәр әл-Гаффари булган. Бабалары Габдеррәхим бине Габделмәннан Шамда (Димәшкъ, Сүрия) вә ике угылы Габделкәрим һәм Габделҗәлил. Габделҗәлил исә «Әмалый касыйдәсе»нә шәрех язган, имеш. Ләкин Әбүзәр әл-Гаффариның ялгыз бер угылы булып, атасы исән вакытта өйләнмичә вафат булган, кыз балаларыннан башка баласы калмады» дип язган. Бу тәкъдирдә Әбүзәр әл-Гаффари (аңа Аллаһның ризалыгы булсын) нәселеннән булулары дөрес түгел. Хәлбуки Иванай илә Әбүзәр арасында бабалар да бик аз. Алар гөман иткәнчә булса, шәҗәрәдә күп кешеләр булыр иде.

### 27. Хуҗашөкүр бине Гаузбай

Сибирия галимнәреннән үзенең остазы тарафыннан язылган бер иҗазәтнамәсендә (ишанлык шәһадәтнамәсе) «тарикать әһеле мулла Хуҗамшөкүргә рөхсәт ви иҗазәт бирелде. Моны яздым фәкыйрь Дәүләтшаһ ибне Шаһ Габделваһаб әл-Хөсәени. 1106/1694 елның рабигыль-ахир аеның 14 көнендә/2 ноябрендә» диел-

гән. Вә үзенең таб[12] халкына язган бер нәсыйхәтнамәсен дә күрдек. // [31] Башында «олуг вә кече таб халкы җәмәгатьләренә» һәм ахырында «бу нәсыйхәтнамәне фәкыйрь Хуҗашөкүр бине Гаузбай, татар башлыгы яздым, тарих 1114/1703 елкы елында дәлүнең 18 ендә, рамазан аеның тугызы/27 гыйнвар, шимбә көн язылды» дип язылган. Вафат елы беленмәде. Мөхтәрәм галимнәрдән Тобол шәһәрендә булган Хуҗашөкүр бине Йосыф исемле зат башка кеше – Нигъмәтулла әфәнде Карамшак бәйан итүенә караганда, элеккерәк елларда Сибириядә мондый тарихлары мәгълүм вә билгесез иҗазәтнамәләр һәм башка гыйльми әсәрләр күп табылса да, аларны җыйнаучы булмаганлыктан, күбесе таралып, чәчелгән. Шуның белән берлектә бүген дә күп әсәр-истәлекләр бар икән. Моңа караганда, гыйльми язмаларны, ата вә баба ядкәрләрен саклауда, безнең Идел буе мөселманнары белән чагыштырганда, Себер мөселманнары гайрәтлерәк булганлыклары күренә.

### 28. Мөхәммәд бине Муса әл-Каддәкый әш-Ширвани

Каспий диңгезенең көнбатыш тарафында булган Ширван мәмләкәтеннән. 1139/1727 елда үз кулы белән язган хатын күрдем. Вафат елы исә соңрак булса кирәк. Фикъһ, ысул, бәйан, нәхү, сарыф һ.б. фәннәрдән осталыгы камил булган. Заманасында мәшһүр вә могтәбәр галимнәрнең берсе булган. Безнең Болгар һәм Казан ишаннарының гыйлем силсиләсе бу затка тоташа. Хаҗга да барып, гыйлем эстәү нияте илә күп рәхәтләр чиккән. Йәмән вилайәтендә кайбер галимнәрнең хезмәтендә булган.

Остазы: Дауд әд-Дагыстани һ.б.

Шәкертләре: Әхмәд әд-Дагыстани һ.б.

Әсәрләре: «Әлгауамилел-мийә шәрхе», «Әлфауаидез-Зыяийә» өчен булган «Гыйсам хашийәсе» һ.б. китап һәм хезмәтләре күп.

### 29. Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети

Мортаза әфәнде, Мортаза хафиз, Мортаза хаҗи исемнәре белән билгеле шәхес. Дагыстан тарафында гыйлем алып, хаҗга барган. 1136/1724 елда исән-сау булган. Вафаты исә соңрак булган. Кабере Мамадыш төбәгендәге ике Симет авыллары арасында. Әсәрләреннән кайбер иске китап читләрендә күрелгән фәтвалар, шулай ук намаз хөкемнәре хакында гарәп телендә бер китапчыгы бар. Бу әсәренең кереш өлешендә үз исемен // [32] дә Хаҗи Мортаза әл-Казаный дип билдергән.

Шәкертләре: Мансур бине Габдеррахман әл-Борындыкый, әл-Мөхәммәд бине Сүкәй әш-Шәмәки, Әгъзам бине Габдеррахман әт-Тенеки, Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабауый, Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый һ.б.

[12] Тобол елгасының уң тарафындагы билгеле бер җәмәгать һәм кабилә.

**30. Мансур бине Габдеррахман бине Әнәс әл-Борындыкый**

Тау ягында Зөя төбәгендә Борындык авылыннан. Мөхәммәдҗан мөфтинең әтисе ягыннан бабасы, имеш. Башта Мортаза әфәнде хозурында укып, аннары Бохарага барып кайткач, үзен, Мортаза әфәндедән гыйлемлерәк санап, һәр мәсьәләдә аңа каршы булган. Зур мәдрәсәләр тотып, күп шәкертләр җыйган. Риваятьләргә караганда, бу мәмләкәт мөдәррисләре башлангыч сыйныфларга сарыф буенча «Зәнҗани» һәм нәхүдән «Мисбах» вә «Ифтитах» китаплары укыткан. Мансур әл-Борындыкый, Бохарадан кайткач, яңа ысул (?) белән, ягъни сарыфтан «Бидан» вә «Шәрхе Габдулла» һәм шулай ук нәхүдән «Кавагыйд» вә «Гауамил» әсәрләреннән дәрес бирү кагыйдәсен уйлап тапкан һәм «Гауамил» өчен фарсы телендә сүзтезмәләр дә язган, имеш. Вафат елы һәм кабере кайда икәнлеге билгесез.

Әсәрләре: башлангыч сыйныфларда укучылар арасында бүгенгә кадәр гамәлдә булган «Әлгауамилел-мийә» исемле китапка шәрех [аңлатма] рәвешендәге «Тәракибе мәнсурийә» әсәре. Китабының башлам өлешендә әйтелүенә караганда, бу китапны 1139/1727 елда язган. Фәкать үз исемен язмыйча, Габдулла әл-Болгарый дию белән канәгатьләнгән. // [33]

RUHIAT

# ИКЕНЧЕ КИСӘК

ایکنچی جزء　　　　　　　　　　　　　　　　　　برنچی جلد

## « آثـــار »

مملکتمزده اولان اسلام عالملرینک ومشهورکیمسه‌لرینک ترجمه وطبقه‌لری، تاریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش برکتابدر .

RUHIAT

## ایکنچی جزئی

صاحبی
رضاء الدین بن فخر الدین

لَيْسَ الْفَتَى بِفَتًى لاَ يُسْتَضَاءُ بِهِ　　وَلاَ يَكُونُ لَهُ فِي الأَرْضِ آثَار

Дозволено цензурою С.-Петербургъ 20 апрѣля 1901 г.

Оренбургъ.
Типографія Г. И. Каримова.
1901.

## 29. Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети

Мортаза әфәнде, Мортаза хафиз, Мортаза хаҗи дип танылган кеше. Дагыстан тарафында укыган вә хаҗ сәфәрендә булып кайткан. 1136/1724 елда исән булып, вафаты соңрак булган. Кабере Мамадыш төбәгендә ике Симет авылы арасында. Бибисолтан исемле кыз карендәшенең кызы Нәзым исемле булып, аның угылы Госман вә аның угылы Әмир вә аның угылы Ногман. Ошбу Ногман, Уфа янындагы Сәмән исемле авылдан булып, Әбеннасыйр әл-Курсавыйның якын шәкертләреннән булган.

Шәкертләре: Мансур бине Габдеррахман әл-Борындыкый, әл-Мөхәммәд бине Сүкәй әш-Шәмәки, Әгъзам бине Габдеррахман әт-Тенеки, Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабавый, Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый, Габдессәлам бине Уразмөхәммәд, Максуд бине Афак әл-Уфавый һәм башкалар.

Элекке заманда яшәгән мөселман сәяхәтчеләре яки заманыбызның Европа мөсафирләренең әсәрләре кебек үк бай мәгълүматлы булмаса да, бу галимебезнең моннан бер гасыр элек язылган // [34] әсәре булуы җәһәте белән бер сәяхәтнамәсе бирергә күрсәтелде. Сөйләм вә хәрефләренә булдырган кадәр игътибар ителсә дә, файдалану өчен бер нәрсә дә таба алмадык. Киресенчә, бәхәс вә тәнкыйть өчен күп нәрсәләр күренә. Сәяхәтнамәсе шушы:

«Бу сәфәребездә юлыбыз мактаулы Бохара шәһәре аша узып, анда беркадәр тукталып, голәма вә дәрәҗәле кешеләре белән аралашудан хөрмәт вә бик күп файда күреп, хаҗ кылу теләге белән Хәрәмәен тарафына юнәлдек. Юлыбыз Хорасан вилайәте аша узды вә Гыйрак вилайәтенә иреште. Бу вилайәтләрдә күргән шәһәрләрдән кайберләре: Мәрвишаһҗиһан – Фарсы вилайәтендә, Мишһәд, Тус, Нишабур, Сәбезвар, Бөстам, Дамган, Сәмнан, Кәшан, Исфаһан, Һәмдан, Керманшаһ, Бәгъдад, Мәусыйль, Нәсыйбин – болар Гарәбстанда. Болар шулай ук Гарәбстанда: Диярбәкер, Көрдестан, Гарәфә, Хәлеб, Хөма, Хамас, Шамшәриф, Мәзриб, Мәдинәи мөнәүвәрә, Мәккәи мөкәррәмә, Мисыр, Рәшид, Искәндәрия. Соңгы өч шәһәр мөбарәк Нил елгасы буенда.

Моннан соң Урта диңгез аша Рум иленә юлланып, Родус шәһәренә килдек. Аннан Сакызга, Кәлибулигә, Истанбулга килдек, аннан Кара диңгез белән Кырым вилайәтенә чыктык. Азау диңгезе илә Тайганга, аннан Хаҗитарханга, аннан үз вилайәтебезгә вә ватаныбызга сау вә сәламәт кайтып кердек. Дүрт елгадан өчесен, ягъни Җәйхун, Дижлә, Форатны кичтек, мөбарәк Нилдән үттем. Гарәфат, Мөздәлифә, Мина, Сафа, Мәрвә, Мәсҗидел-харам, Мөлтәзим, Хәҗәрел-әсвад, // [35] Бабе Шәриф, Мизабе Рәхмәт, Мәкаме Ибраһим – боларның һәммәсендә догалар кылдык. Без каберләрен зиярәт иткән изге пәйгамбәрләр һәм бөек шәехләрнең кайберләре болар: Хивада Пәһлеван Мәхмүд хәзрәт, шәех Нәҗмеддин әл-Көбра, шәех Мохтар хәзрәт, Баба хәзрәт, Хөсәен Газизан; Бохарада хәзрәти Әюб галәйһиссәлам, Әбү Хәфас хәзрәт әл-Кәбир, Казыйхан, Садреш-шәрига, Суфиян Сәүри, Хуҗа Баһаведдин Нәкышбәнд, Әбү Йосыф Габделхаликъ Гыйҗдивани, Сәед Әмеркилял хәзрәт вә гайреләр. Мишһәдтә имам Риза (Аллаһының ризалыгы булсын) белән күрештек. Нишабурда шәех Гаттар вә Әбү Зәед Бөстами, Сәмнанда шәех Галәэд-Дәүлә, Бөстамда вә Бәгъдадта имам Әгъзам, Бәшәр Хафи, шәех Шәмбәли, мәшһүр Кәрхи, Мансур Хәллаҗ, Зөннун әл-Мисрый, Бәһлул Дивани, Җөнәйд, Йаушигъ бине Нун галәйһиссәлам, Дауд Таи, Муса әл-Кязыйм вә Локман Хәким хәзрәт; Гәркүктә Даниал хәзрәт галәйһиссәлам, Газир галәйһиссәлам, Хинин хәзрәт; Мәусыйльдә Җәрҗис хәзрәт илә Юныс хәзрәт галәйһиссәлам; Нәсыйбиндә имам Зәйнелгабидин; Диарбәкердә Халид бине Вәлид; Гарәфәдә Мәүлед Ибраһим вә Мәнҗаникъ Нәмруд; Хәлебтә Зәкә-

рия галәйһиссәлам; Шамшәрифтә Яхъя галәйһиссәлам, Билал Хәбәши, Могавия, Мәдинәи мөнәүвәрәдә Рәсүл әс-Сәкыйлин (саллаллаһу галәйһи вәссәллам) хәзрәтләре, Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, Гомәр хәзрәт, Фатыйма вә Гайшә хәзрәтләре, Мотаһира вә Рәсүлулла кызларының ирләре; Бәкыйгъда Госман хәзрәт, имам Хәсән, имам Гали әл-Бакыр, имам Җәгъфәр әс-Садыйк, Габбас хәзрәт, имам Җәгъфәр әт-Таййар, Әбү Һөрәйрә, Габдулла бине Габбас, Әнис бине Малик, Хәлимә, Әхәд һәм Хәмзә. Язылды рәҗәб аеның 29 нчы көнендә, 1110 елда/1699 елның 31 гыйнварында, ахун Максуд Афак угылының Мортаза Гали әфәндедә укып чыккан заманында тәмам булды».

Бу сәяхәтнамәдә күрсәтелгән кешеләрнең күмелгән урыннары күбесе хата күрсәтелгән һәм асыл язма бозык каләм илә игътибарсыз язылып, «моны фәкыйрь, мохтаҗ Мортаза Гали бине Котлыгыш суфый язды» дигәне Мортаза әфәнденең үз язуы, аннан соңгысы – шәкерте булган ахун Максуд әфәнде язуы. // [36]

### 30. Мансур бине Габдеррахман бине Әнәс әл-Борындыкый

Тау ягында Зөя өязендә Борындык авылыннан. Мөхәммәдҗан мөфтинең атасы булган Хөсәен мулланың атасы. Вә бер риваять буенча Хөсәен мулланың атасы булмый, бәлки бер туганы. Башта Мортаза (кара: 29) әфәндедән укып, соңрак Бохарага барып белем алган, бу мәмләкәткә кайткач, үзен Мортаза әфәндедән галимрәк белеп, һәр мәсьәләдә аның каршы тарафын ала торган булган. Мортаза әфәнденең «Тәкбире ифтитах»та һәмзәне сузып әйтүенә ризасызлык белдереп, Мортаза әфәнде моңа җавап сурәтендә гарәби бер рисалә язган.

Зур мәдрәсәләр тотып, күп шәкерт җыйган. Сөйләгәннәргә караганда, бу мәмләкәт мөдәррисләре гади халыкка сарыф [морфология] гыйлеменнән «Зәнҗани» һәм нәхүдә [синтаксиста] 1538 елда вафат булган Насыйр бине Габдессәед Әбелмәкярим бине Гали Әбелмозаффар Әбелфәтех әл-Мотаразыйның[13] «Әлмисбах» һәм аңа аңлатма булган «Ифтитах» укытканнар. Мансур бине Габдеррахман, Бохарадан кайткач, җәдид ысулы белән, ягъни сарыфтан «Бидан» вә «Шәрхе Габдулла», нәхүдән «Кавагыйд» вә «Гавамил» нөсхәләреннән дәрес бирү кагыйдәләрен эшләгән. «Гавамил»дә фарсый теленнән кушымта да биргән. Үлгән елы вә кабере кайда икәне беленмәде.

Әсәре: халык арасында бу көнгә кадәр кулланылышта булган «Әл-гавамилелми йә» исемле рисаләгә аңлатма рәвешендә «Тәрякибе мансурия»се. Бу китабын 1139/1727 елда язып, үз исемен күрсәтми, бары «Гобәйдулла әл-Болгарый» дип кенә канәгатьләнгән. // [37] Бу әсәре арабызда шулкадәр күп күренә ки, мондый зур күләмле бер китапның каләм илә язылып, бу кадәр күп таралуыннан әлеге шәхеснең шәкертләре күп вә шөһрәте дә аеруча зур булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин. Мансур ахунның үз каләме илә күчереп, бу гыйбарәләр язылган: «Бу бәетләрне Мансур бине Габдеррахман мөбарәк шәүвәл аенда гарәфә көнендә 1118 елда/1707 елның гыйнвар аенда язды». Аның кайбер маҗаралары булганы да сөйләнә.

RUHIAT

[13] Бу кеше, кайберәүләр уйлаганча, Зәмәхшәри шәкерте түгел, бәлки игътизальдә хәлифәсе мәкамендә булган. Чөнки Зәмәхшәри вафат булган елны дөньяга килгән. Болай булганда шәкертлеге күздә тотылмас.

### 31. Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд (Тәмәк) бине Нияки бине Төнләч бине Сабырхуҗа бине Йәмаш бине Бәраш бине Байтөгәл бине Габдерраззак бине Сардак бине Йәмин

Тукмөхәммәд, Болгар шәһәреннән чыккан биләрдән булып, Дагыстан тарафына барып укыган. Һәм Тукмөхәммәд хафиз, Тукмөхәммәд шәех дип танылган. Ишмөхәммәд Малмыж өязендә Адай авылында һиҗри белән XII йөз башларында/милади белән XVII гасыр ахырларында аеруча шөһрәт казанган бер зат, Шәех баба дип танылган. Саба авылында имам булган Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай моның шәкертләреннән.

Уфа вилайәтендә Көбәк авылында имам булган хаҗи Ишмөхәммәд бине Мөхәммәдзаһид каләме белән үзенең «Фәтави Һиндия» нөсхәсенә язганнан бер өзеге, бу урынга мөнәсәбәтле булганга, биредә китерелә: «Адай авылының Тәмәт Хафиз угылы Шәех баба булып, исеме Ишмөхәммәд. Аның угылы Балтай, Балтай кызы Ниязбикә исемле. Ниязбикә кызы Сәгадәт булып, Сәгадәтнең ике кызы булды. Берсенең исеме Хәдичә вә икенчесенең исеме Хәҗәр. Хәҗәрнең кызы Фатыйма бинте Гомәр булып, әл-хаҗ Мөхәммәд хатыны. Сәгадәт илә Хәсән икесе бертуган вә Ниязбикә бинте Балтай балалары булып, аталары да Габдулла исемле зат иде». Ишмөхәммәд хаҗи бине Мөхәммәдзаһиднең // [38] «әл-хаҗ Мөхәммәд» дигән кешесе үзедер.

Бу затның үлгән елы мәгълүм булмады. Кабере Адай авылында.

### 32. Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый

RUHIAT

Казан өязендә Курса авылында имам вә мөдәррис булган.

Остазы Мортаза әфәнде (кара: 29) булып, шәкертләре: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Вәлид бине Сәгыйдь әс-Сәгыйди һәм башкалар. Габделгазиз исемле улы булган. Кыска төннәрдә Болгар халкына ястү намазы уку кирәклеге хакында бер рисаләсе бар икән.

### 33. Юныс бине Иванай (кара: 26) бине Усай

Казан өязендә Оры авылында имам вә мөдәррис булып, гыйлем биргән. «Юныс әфәнде», «Юныс ахун» дип шөһрәт булган бер зат. 1046/1639 елда дөньяга килеп, сөйләгәннәргә караганда, икенче тапкыр хаҗ сәфәре вакытында вафат булган.

Хатыны Йүчәнәһал бинте Йансарый хафиз (кара: 25) иде.

Балалары Нәзар, Сәфәр, Максуд булып, нәселе күп вә Казан тирәләрендә таралган. Бу көндә булган нәсел-нәсәбенең фикеренчә, Казан мөселман дәүләте [Казан ханлыгы] җимерелгәннән соң, беренче тапкыр буларак Урта Азиягә сәфәр итеп, укып кайткан зат Юныс әфәнде булган. Бу сәфәрендә казакъ ханнарыннан Җингиз хан исемле зат (мәшһүр Әбелхәер Мөхәммәд бине Ачаның угылы булса кирәк) тарафыннан кабул ителеп, асыл ватанына кайткач, Мөһлибикәсолтан исемле кызга өйләнгән. Монда кайтып азмы-күпме торгач, Юныс әфәнде никахында булган хәлдә, вафат булган. Оры зиратында күмелгән.

Юныс әфәнде һиммәтле вә заманына күрә төпле гыйлемле бер зат булган. Болгар мәмләкәтендә булган ислам әһелләренә гошернең мәҗбүри булуы турында язган фәтвасы, дөрес яки хата булуына игътибар итмәстән, мөһим вә ха-

лык өчен кирәк булган бер зур мәсьәлә илә шөгыльләнүенә // [39] дәлил булыр[14].

Сарыф гыйлеме буенча булган «Бидан» рисаләсе бу затныкы дип исәпләнсә дә, хакыйкате мәгълүм булмады. Шушы «Бидан» китабына язылган хашияләр [аңлатмалар] вә «Шәрхе Габдулла» исемле фарсы әсәрләренең авторлары хакында булган эзләнүләребез нәтиҗәсез калып, боларны белү вә хакыйкатьне ачу хезмәте әдәбиятка киләчәк гайрәтле вә яңа буынга әманәт ителгән. «Ахун» сүзенә килгәндә, үзебезнең асыл сүзебез булып та онытылганмы яки башка халыктан алындымы – анык булмады. «Чнд» калыбында буларак, сахиб, малик, әфәнде мәгънәсендә булган «хунд» сүзеннән алынган булуы да ихтимал. Асылында фарсы буларак, бу сүз җиденче, сигезенче, // [40] тугызынчы гасырларда Мисыр вә Шам (Сүрия) мәмләкәтләрендә шаһлар хозурында булган якыннарының һәм башка дәрәҗәле кешеләрнең аталып йөрүе тарихта расланган. «Мулла» сүзе гарәп телендә булган «мәүля»дан алынган хәлдә, хәрефләре үзгәртелеп, «мелла» вә «даменла» сурәтендә халык арасында таралып, соңрак гарәпчәсе онытылу белән, гарәпчә кулланылышында да үзгәргән хәлдә таралып, гарәби сүзләр исәбенә кергән. Максаттан чыксак та, «Юныс ахун», «Шәрхе мелла Юныс» сүзләре мөнәсәбәте илә бу сүзләр язылды.

### 34. Әлмөхәммәд бине Сүкәй бине Айтуган бине Шаһйосыф бине Шәмәк

Тау ягында Шәмәк авылында 1155 елда җөмадиел-ахирның 20 се, якшәмбе көн/1742 елның 11 августында вафат булган. Остазы Мортаза әфәнде (кара: 29) үзенә 1110/1698 елда ишанлык шәһадәтнамәсе язган[15].

1136/1724 елда Хәнифә исемле кызы илә Габделвахид исемле угылы, 1138/1726 елда Хафаса исемле кызы дөньяга килгән. Болардан башка тагын Габделҗәлил вә Мөхәммәделәмин исемле угыллары бар. Габделҗәлил угылы Габбас вә аның угылы Сабит булып, Сабит угыллары – Исмәгыйль илә Хәйрулла. Мөхәммәделәминнең Яһүдә исемле угылы 1138/1726 елда дөньяга килгән.

### 35. Ибраһим бине Мөхәммәдтүләк бине Бикмөхәммәд

Котлыгмөхәммәд мирза бине Тәүкил бине Мәмеш 1743 елда Оренбург шәһәренә нигез салдыру хезмәтендә булганда, Ибраһим ахун моның хозурында имамлык вазыйфасын башкарган, кайсы кабиләгә караганлыгы вә вафат елы мәгълүм булмады, ләкин 1155/1742 елда исән булган. Нигъмәтулла исемле угылы ахун Габделмәннан бине Мостафа хозурында укып, // [41] 1187 елның 4 мөхәррәмендә/1773 елның 17 мартында «Фәраизе Шиһабия» язып тәмам иткән. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани «Бетчә ахун» дип танылган иде, мөһере Бохара мөфтие вә казыйлары мөһереннән зур вә шул рәвештә булып, «Ибраһим бине Мөхәммәдтүләк әл-мөфти» дип язылган иде, «Һидая» китабын русчага тәрҗемә итүе халык арасында сөйләнсә дә, әлбәттә, хата сүз булыр. Мәгәр берәр мәсьәләне тәрҗемә иткән булса да, гаҗәп түгел» дигән. Мөфти исеме дәүләт тарафыннан рәсми бирелгәнме яки үзе генә язганмы – безгә мәгълүм булмады. Болгар вә Казан дәүләтләреннән мирас булып калган булса кирәк, элекке заманнарда голәманың олугларына мөфти, казый исемнәре бирелүе китап вә җыентыкларның читләрендә күп күренә.

RUHIAT

[14] Бу фәтва сурәте элекке җыентыкларда, «Мохтәсарел-викайә» аңлатмаларында күп күрелгәнгә, биредә язылмады, «Мөстәфадел-әхбар...»да да искә алына (2 нче кисәк, 188 б.).
[15] «Мөстәфадел-әхбар...»да искә алына (2 нче кисәк, 214 б.).

Биредә телгә алынган Котлыгмөхәммәд мирзаның хатыны Хәдичә бикә Сәгыйдь авылында 1165/1752 елда вафат булган, кабере өстенә таш бина куелган вә Ибраһим ахунд угылы каләме илә вафат тарихы да язылган.

### 36. Ишбулад мелла

Казан шәһәрендә гайрәт вә дини куәте илә шөһрәт казанган бер зат, мөселманнарны яклап вә фетнәләрдән саклап, гүзәл исеме таралып, «Ишбулад заманасы» дигән гыйбарә дә булган. Императрица Анна заманында 1253/1837 елда әле исән булган. Габдерраззак // [42] исемле углының кызы Хәбибә Гаид бине Габделбакый бине Хөсәен бине Котлыг бине Биккенә бине Бики бине Нугай бине Турай никахында булып, әлеге иреннән соң 1222/1807 елда вафат булган.

### 37. Габдессәлам бине Уразмөхәммәд (Урай) бине Колмөхәммәд бине Колчура бине Колаб

Асылы Казан өязе Алат юлы буенда Мәңгәр исемле авылдан. Казан ягындагы Ташкичү авылында имам вә мөдәррис иде.

Остазы – Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле. Сарыф вә телгә караган бер китап язып, ахырында бу сүзләре теркәлгән: «Бу нөсхә җөмадиел-әүвәл аенда, җомга көнне, мелла Габдессәлам мәдрәсәсендә тәмамланды. Иясе Габдессәлам бине мелла Уразмөхәммәд бине Колмөхәммәд, 1144/1733 ел».

Балалары: Габденнасыйр, Әбелфәтех, Әбелфәиз вә башкалар.

Әбелмәних исемле шагыйрьнең «Шәһре Каргалыда фәкыйрең мәүлиде... Дәүридә остазы кол Габдессәлам...» дигән юлларында шушы Габдессәламнең исеме атала.

Бер кызы Эстәрлетамак ягында Кырмыскалы авылында ахун Вәли бине Максуд ахун бине Афак бине Дустмөхәммәдтә булган. Императрица Елизаветаның 1744 елдагы фәрманына нигезләнеп, Казан ягындагы Саба авылыннан Сәгыйдь бине Гадәл-Хәйалый исемле батыр һәм һиммәтле сәүдәгәр Сакмар елгасында 1750 елда Сәгыйдь авылына [Оренбург Каргалысы] нигез салу өчен якыннары белән күчеп килгәч, Габдессәлам бине Уразмөхәммәд тә, әлеге авылга барып, имам вә ахун булган. 1155/1742 елда Ташкичүдә булуы мәдрәсәсендә язылган китаплардан мәгълүм. Алла белә, Сәгыйдьнең күчүе дә шул елларда булса кирәк. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Габдессәлам бине Урай мәдрәсәсендә Ташкичү авылында Бәшир бине Габдеррәхим бине Уразмөхәммәд «Шәрхе гавамил»[16] язып тәмам иткән вә Илми бине Үтәш исемле зат фикъһ гыйлемендә Габдулла бине Мәхмүд әл-Мәусыйли төзегән «Мохтар китабы»н язып тәмам иткән», – дигән. // [43]

### 38. Мортаза бине Гали бине Йосыф

Мортаза әфәнде (кара: 29) хозурында укып, заманасының танылган галимнәреннән булган. Сембер вилайәтендә Бизнә авылында имам булып, 1157/1744 елларда вафат булган. «Зәнҗани» китабын язып тәмам иткәч, ахырында ошбу сүзләре язылган: «Җомга көн, 1102 елның шәүвәл ае/1691, июнь. Мортаза бине Гали әл-Болгарый язды».

Мозаффар исемле угылы 1215/1800 елда вафат булып, Габделмәҗид, Зәйнеддин, Бәрхайә, Зәбир исемле угыллары калган.

---

[16] Кызганычка каршы, бу шәрехнең исемен вә язучысы кем икәнен бәйан итмәгән.

**39. Әбелхәер Мөхәммәд бине Айрыш бине Ача бине Айчуак бине Бүләкәй бине Үсәк бине Әбү Сәгыйдь Җанбик хан**

Казакъ ханнарының мәшһүрләреннән. Ерак бабасы Әбү Сәгыйдь Җанбик хан IX гасыр башында/милади XV гасырда Сарай шәһәрендә падишаһлык иткән Борак хан бине Каерчык хан бине Рысхан угылы. Әлеге шәхес, Казакъстанда хан булып, 1142/1730 елда Алдар исемле башкорт старшинасы ярдәме белән Уфа шәһәрендәге Русия гаскәре башлыгы Бутурлин исемле заттан Русия кулы астына керү турында ярдәмен сорап үтенгән. Киләсе елда Русия дәүләте тарафыннан әлеге Алдар вә иптәше Таймас илче сыйфатында Әбелхәер хан хозурына җибәрелгән. Котлыгмөхәммәд мирза бине Тәүкил илчеләргә тәрҗемәче буларак кушылган. Шушы елларда Әбелхәер хан, Оренбург вилайәтендә булган Ор шәһәренә килеп, Коръәни Шәриф тотып ант итеп, Русия дәүләтенең хакимиятен таныды. Соңрак гаскәр вә тарафдарлары белән Үргәнеч мәмләкәтенә һөҗүм итеп, шәһәрне басып алды. Хәрәзем тәхетенә менеп, биш көн хакимлек иткәннән соң, «Шәрекъ Наполеоны» булган Надиршаһ Төрекмәнинең гаскәр башы булган Таһир хан бине Рөстәм хан килүеннән хәбәр алып, тәхетен ташлап качкан. Бу вакыйга 1152/1739 елда булса кирәк. 1161/1748 елда вафат булып, Нургали, Яргали, Әхмәд, Айчуак, Гадел, Җинкиз исемле балалары калган. Бу зат бик зур гыйлем әһле булмаса да, мөселманнар арасында мәшһүр вә эш-гамәлләре телдән телгә сөйләнгәнлектән, бу көндә Русия дәүләтендә күп мәшһүр // [44] фамилияләрнең нәсәпләре моңа тоташканга, тәрҗемәи хәленнән беркадәр булса да хәбәр бирелде.

**40. Ахундхуҗа бине Маһийәмхуҗа**

Төркестанлы Хуҗа Әхмәд Ясәви нәселеннән булып, Хаҗитархан янында Хантүбә исемле җирдә дөнья кичереп, картайган. 1169/1756 елда вафат булып, Каләндәр хуҗа, Габдеррәхим хуҗа дип танылган угыллары калган.

**41. Габделкәрим бине Балтай бине Ишмөхәммәд** (кара: 31) **бине Тукмөхәммәд**

Бу мәмләкәт голәмасы хозурында укыганнан соң, Бохара тарафына сәяхәт итеп, шәех Габделәхәд әс-Сәрһәнди угылы Мөхәммәд әл-Мәгъсүм хәзрәтләренең эшен дәвам иттерүче булган ишан Имляшәех Әбү Габдулла әл-Бәлхигә иптәш булу өчен тарикатьтә рөхсәт алган. Бу җирләргә килгәч, Сәгыйдь авылында имам вә мөдәррис булып, мөридләр җыйган. 1171/1758 елда вафат булып, Сәгыйдь зиратында җирләнгән, кабере мәгълүм вә вафат тарихы ташына язылган. Мин фәкыйрь, 1314 зөлкагдә/1897 елның март аенда Сәгыйдь авылына барып, хәтердә булган бөек затларга вә туфрак астында ялгызлык галәмендә булучыларны зиярәт иткән вакытымда ошбу затның төрбәсендә дә булдым (Аллаһу Тәгалә һәммәсенә рәхмәт әйләсен!). Моның шәехе вә остазы булган Хәбиб әл-Бәлхи 1167/1754 елда Бохарада вафат булган.

**42. Габдерраззак бине Ишмөхәммәд бине Тәйми**

Казан өязендәге Көтернаҗ авылыннан булып, Түнтәрдә кырык еллар имам булып вафат. Мөхәммәд исемле угылы Семипалат шәһәрендә булган Әхмәд ишанның атасы. Габдерраззак бине Ишмөхәммәднең мәдрәсәсендә Габдулла бине Нәзир исемле зат 1176/1763 елда «Зәнҗани» вә «Мисбах» китапларын күчереп язып тәмам иткән. // [45]

## 43. Габдеррахман бине Туймөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Янбулат бине Ягъкуб бине Симән бине Илаз бине Габдулла бине Бикчура хан

Элеккеге китапларның читләренә вә күпсанлы кәгазьләрдә язылганнарга караганда, Бикчура хан Җаек елгасы башындагы Карагай исемле урында булган икән. Әмма кайсы гасырдадыр балалары вә оныклары Минзәлә һәм Зәй елгаларына килгәннәр. Янбулатның бер угылы Кадермәт, аның угылы Уразмәт (Кадермөхәммәд һәм Уразмөхәммәдтән үзгәртелгән булса кирәк). Уразмәт угылы Сөләй, аның угыллары Әмин илә Сөбханкол булып, Әмин Минзәлә өязендәге Мортыштамак авылында, ә Сөбханкол Бөгелмә өязендә Яңа Кәшер авылында торганнар. Кадермәтнең икенче угылы (Уразмөхәммәднең бер туганы) Ураздәүләт булып, аның кызы Сабира. Сабираның угылы Күҗәкәдә Габделҗәлил исемле зат икән. Янбулатның икенче угыллары Теләүмәт илә Әхмәд Абыздан таралган нәсәпләрнең күпчелеге Йөзкәй Тәкермән белән Әхмәт Абыз авылларында. Янбулатның Акмәт (Әхмәд) исемле угылының угылы Тукмәт (Туймөхәммәд), аның угылы Сәгыйдь бистәсендә Иманай булып, Иманай угылы Мөхәммәд. Туймөхәммәд бине Бикмөхәммәднең олы угылы Әлмөхәммәд исемле булып, Минзәлә өязендәге Әлмәт авылында дәрәҗәле вә шөһрәтле бер зат булган. Соңрак Зәй елгасында булган Әлмәт[17] авылына күчкән. (Һәр ике авыл моның исеме белән аталган булуы ихтимал.) Әлмөхәммәднең Рәхмәтулла исемле угылы Зәй Әлмәтендә (бу көндә атнада бер көн базары булып, почта вә телеграф һәм өч җамигъ мәчетле олы бер авыл) имам вә мөхтәсиб булып вафат иткән. Әлмөхәммәднең ошбу угылыннан башка Рахманкол һәм Габдеррәхим исемле угыллары булган. Туймөхәммәднең икенче угылы әлеге Габдеррахман 1102/1691 елда Мортыштамак авылында дөньяга килеп, күп вакытлар гыйлем юлында йөреп, акыл иясе булып җитешкән. Гыйлем илә гакылы бер дәрәҗәдә булганга, заманасында фикъһедән белемле бер зат булган. Бөгелмә өязендә Зәй елгасының сул ягындагы Тайсуган авылында имам вә ахун булып, тирә-яктагы мөселманнарның дәгъваларын ислам шәригате буенча хәл иткән, зур мәдрәсәләр оештырылу белән төрле фәннәрдән күп тырышлык куеп дәрес укыган. Шәкертләре Оренбург илә Казан арасында таралган. 74 яшендә // [46] 1176/1763 елда әле исән булган. Моннан соң никадәр яшәгәндер, мәгълүм булмады.

Балалары: Габделмәннан, Гобәйдулла, Габделхәмид, Габдессәлам, Фәйзулла, Габделҗәббар, Гыйсмәтулла, Мәрфуга, Зөбәйдә. Мәрфуга мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим никахында булып, Зөбәйдә Кинәле елгасы буендагы Солтанкол авылындагы Сәлим исемле бер зат никахында булган. Габделҗәббар – 1166/1753 елда, Гыйсмәтулла 1176/1763 елда дөньяга килгәннәр. Балаларыннан күп затлар бу китапта телгә алына булса кирәк. Чөнки моның йорты бу мәмләкәт мөселманнары арасында мәшһүр вә хөрмәтле бер гыйлем йорты булган. Кабере Тайсуган авылында. Язып тәмам иткән китапларыннан «Мөнният» шәрхе «Хәләби», «Бөстан әл-фәкыйһ», «Ифтитах» нөсхәләрен күрдек. Һәрберсенең ахырында исемен вә тарихын язган. Әүвәлгесен 1139 елның 22 рәҗәбендә /1727 елның 4 мартында, икенчесен 1141 елның рабигыль-ахирында /1728 елның ноябрендә, өченчесен 1159/1746 елда язып тәмам иткән. Язуы гүзәл, дөрес вә игътибарлы, гарәби сүзләре дә зарарсыз. Үзе, тәкъва, диндар бер зат булып, сөннәт илә гамәл иткән. Гаять тә әсәрле рәвештә язган бер васыятьнамәсе дә игътибарга лаек булды. Бу васыятьнамәсе 1140/1728 ел белән билгеләнгәнгә, 38 яшьләрендә язган булырга тиеш. Васыятьнамәсендә иң дикъкать иткән нәрсәләрдән

[17] Хәзерге Әлмәт шәһәре турында сүз бара. – *Төз.*

балалары һәм тарафдарларына, һәммә якыннары һәм сөеклеләренә әһәмиятле дини вә дөньяви мәсьәләләр буенча сөйләгән нәсыйхәтләре, гыйлем илә мәшгуль буларак, наданнар илә аралашудан искәртүләре, туганлык вә карендәшлек хакын хөрмәт илә һәрвакыт хезмәттәшлек вә ярдәмләшү өчен файдалануга кызыктыру вә өндәүләре булган. Әлеге затның шулай ук рәсүлулланы мактап язган шигыре дә билгеле. // [49]

Мөхтәрәмә анам Мәүһубә бинте Рәмколның анасы Фәрхиҗәмал бинте Гыйсмәтулла бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд булганга, ошбу Габдеррахман хәзрәт анам ягыннан бабам була. // [50]

### 44. Габдеррәшид бине Йосыф бине Кадермөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Тәтеш

Чыгышы белән Сәгыйдь авылыннан. Казан шәһәрендә беренче мәчет хозурында имам булып, 1188/1774 елда Казан шәһәрендә вафат булган. 1767 елның 26 маенда Казан шәһәренә императрица Екатерина килеп, таш мәчетләр салу турында мөселманнарга рөхсәт биргәч, беренче таш мәчет салу тугрысында ошбу затның зур тырышлык куюы сөйләнелә. Русия дәүләте Казан шәһәрен басып алганнан соң, иң әүвәл төзелгән таш мәчет ошбу беренче таш мәчет булып, 1184/1770 елда тәмам булган. Мөхәммәдшәриф исемле угылы, Малмыж өязендә Портянур авылында имам вә ахун булып, 1248/1832 елда, туганы Гобәйдулла бине Йосыф, 100 яшенә ирешеп, 1242/1827 елда Казанда вафат булганнар.

### 45. Исмәгыйль бине Бикмөхәммәд

Сәгыйдь авылына бәйле бер зат. 1165/1751 елда Ягъкуб, Габдеррахман, Надир исемле иптәшләре белән озын бер сәяхәт ясаган. Сәгыйдь авылыннан башлаган бу сәфәрендә Хәрәзем, Бохара, Һәрат, Кандаһар, Килат, Басра, Хәйдәрабад, Бинарис, Мәккә, Мәдинә, Шам[18], Коддес[19], Истанбул кеби зур шәһәрләрдән узганнар. 31 биттән гыйбарәт булган ошбу әсәрдә заманасының мәшһүр кешеләре илә очрашып сөйләшү яки фәнни вә әдәби берәр нәрсәдән мәгълүмат бирү кебек, сәяхәтнамә язуда әдәп вә гадәт булган нәрсәләр очрамый. Гади халыктан алынган хәбәрләрдән укучылар өчен файда чыкмас яки укып тору мәшәкатенә бәрабәр тормас // [51] дәрәҗәдә файда гына булыр. Исмәгыйль әфәнденең төркичәдән башка тел белмәве вә 1190/1776 елда исән икәнлеге әлеге әсәреннән аңлашыла.

### 46. Габдессәлам бине Хәсән

Чыгышы Уфа вилайәтеннән булган. Казан өязендә Кариле исемле авылда шөһрәтле бер мөдәррис булган. Заманының сәләтле вә дөрес галимнәрнең берсе булып, Мортаза әфәнденең (кара: 29) якын иптәшләреннән булуы вә Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавыйдан (кара: 32) да файда күрүе сөйләнә. Кайбер кешеләр Кызлар шәһәреннән әсир буларак килгән Габделлатыйф исемле бер фазыйльдән дә гыйлем алуы турында сөйлиләр. Ир баласы булмаганга, соң гомерендә Минзәлә өязендәге Шыгай авылына кияве Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман тәрбия-

[18] Гыйлемияләре Шам сүзен Сүрия мәгънәсендә кулланса да, гади халык Нас (Димәшкъ) шәһәренә махсус куллана.
[19] Яһүдчә исеме Иерусалим яки Оршалайм, ә аннан элеккерәк исеме Илйа булган. Соңрак Бәйтелмөкаддәс дип тә әйтә башлаганнар.

сенә килеп гомер кичергән һәм дәрес бирү белән мәшгуль булган. Аннан соң Мәлем авылында булган кияве Зәйнеддин әл-Мәлеми йортына күчеп, әлеге Мәлем авылында вафат булган. 1190/1776 елда исән булып, вафаты шуннан соң. Кабере Мәлем зиратында икәнлеге мәгълүм булса да, ташы вә тарихы юк. Шәкертләре вә шәкертләренең шәкертләре тирә-якта күп булып, кызлары ягыннан булган балалары вә нәселләре ничә вилайәтләргә таралса да, бу газизнең кабере-нә билге куярлык вә тарихын язып, дога өчен сәбәп булырлык бер һиммәт сарыф ителмәгән.

Шәкертләре: Зәйнеддин әл-Мәлеми, Габделваһаб бине Бикмөхәммәд әл-Чакмагышый, Хәмид бине Мортаза әл-Әлдермеши, Җәгъфәр бине Ягъкуб әл-Әгерҗеви, Салих бине Сәгыйдь әл-Кенәри әл-Кили, Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Вәлид бине Максуд әл-Уфавый, Габделҗәлил бине Габдеррәшид әл-Мөслими, Габдеррәшид бине Мөхәммәд әл-Хәнәфи әш-Шөкри, Нәриман бине Сөләйман әл-Уфавый, Чураш бине Чүкәй әл-Колшәрифи, Габдулла бине Җәгъфәр әл-Әлмәти, Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри һәм башкалар.

Кызлары: Рабига – Мөхәммәтшәриф бине Сөләйман // [52] хатыны; Мөхибә – Зәйнеддин әл-Мәлеми[20] хатыны; Фазыйлә илә Хәбибә, берсе Җәгъфәр бине Ягъкуб әл-Әгерҗеви вә икенчесе Габделваһаб әл-Чакмагышый хатыны булган. Мәдрәсәсендә язылган китаплар һәр урында күрелә. Ләкин «Бидан» вә «Шәрхе Габдулла», «Гавамил», «Әнмүзәҗ» нөсхәләрен бервакытта да очратмадык. 1177/1769 елда язылган бер «Ифтитах» вә 1186/1772 елда язылган бер «Мелла Җами» вә 1187/1773 елда язылган (исемен оныттым) бер нөсхәне күргәнебез булган иде. Габдеррәшид әш-Шөкри моның хозурында 1190/1776 елда бер «Мелла Җами» язып тәмам итүе китабының ахырыннан мәгълүм булды. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «1186/1772 елларда Кариле авылында бер хәят вә мәдрәсәсе булуы мәгълүм. Ишнияз әфәнденең әхвале тәрәккый итүен күрү сәбәпле, шәкертләренең аңа мәхәббәт вә ихтирамнарын күрү өчен бер мәҗлестә җыелып, гыйлем өлкәсендә фикер алышып, Ишнияз әфәнденең гыйлеменең дәрәҗәсен күрсәтү өчен гайрәтләнсә дә, бу хәлгә... Ишнияз әфәнденең бергә җыелудан саклануы халыкта билгеледер», – дигән.

RUHIAT

### 47. Әмир бине Нурмөхәммәд

Уфа ягыннан булган галимнәрнең берсе. Ахун вә мөдәррис булып, тирә-яктагы мөселманнарның дәгъваларын хәл иткән. Бөре өязендә Көндәшле авылында 1193/1779 елда әле исән булган. Бөгелмә өязендә Түбән Шәлчәле авылының Хәсән бине Гаед исемле кеше моның мәдрәсәсендә «Һәдиятес-Сәгълук» китабын // [53] язып тәмам иткән. Туганы Ибраһим ахун бине Нурмөхәммәд вә аның угылы Таҗеддин ахун ошбу авылда бере соңында икенчесе ахун вә мөдәррис булганнар икән. // [54]

### 48. Габделмәннан бине Габдеррахман (кара: 43) бине Туймөхәммәд

Тайсуган авылында имам вә мөдәррис булып, гыйлем вә яхшы мөгамәлә илә имтияз казанган. Фәкать яшьли вафат булуы сөйләнә. 1194/1780 елда әле исән булган. Русия мөселманнары арасында олы бер шөһрәт казанган Вәлид бине Сәгыйдь моның хозурында Коръәнне укып өйрәнгән. Шөгер авылында Габдеррәшид бине Мөхәммәд тә моның тарафдарыннан иде. Остазы Габдессәлам бине

[20] 1810 елда вафат булып, кабере Мәлем авылында.

Хәсән әл-Кариле булса кирәк. Фазлулла исемле угылы да зур галимнәрдән булган. Язып тәмамлаган Ибне Һөшшамның «Кавагыйдел-игъраб»ын күргәнебез булды. Язуы дөрес вә гүзәл.

**49. Сәлимҗан бине Дустмөхәммәд**

Казан тарафында Кавал авылында имам булган. 1146/1733 елда дөньяга килеп, 1194/1780 елларда вафат булган. Китаплары өлкәсендә кайбер әсәрләре булуы билгеле. Рәйхана исемле кызы Фәхреддин бине Габдеррәшид никахында булган.

**50. Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман бине Чикә бине Бимәк суфый**

Кичү елгасы // [55] буендагы Чупай исемле авылдан. Минзәлә өязендәге Шыгай авылында имам вә мөдәррис, 1194/1780 елда вафат булган. Бер «Кыйссаселәнбия» китабы язып, 1110/1698 елда тәмам итүе, үз язуына караганда, бик озын гомер сөрүе аңлашыла. Кабере Шушма елгасы буендагы Иске Иштирәк авылында, кабере мәгълүм, ләкин ташы искергән вә язулары укылмас бер хәлгә килгәннәр. Анам ягыннан булган бабам Рәмкол бине Максуд шул якта җирләнгәнгә күрә, 1305/1888 елда һәр икесенең төрбәләренә зиярәт кылган идем.

Хатыны Рабига бинте Габдессәлам (кара: 46) 1209/1795 елда вафат булган.

Балалары: Шәмседдин, Борһанеддин.

**51. Габделләтыйф бине Габдессәлам** (кара: 37) **бине Уразмөхәммәд**

Сәгыйдь авылында беренче мәчеттә имам булып, яхшы дәресләр укыткан. Остазы атасы Габдессәлам ахун иде. 1194/1780 елларда вафат булган.

RUHIAT

**52. Ибраһим бине Габдулла бине Габделгафур**

Тау ягындагы Барыш авылыннан булып, 1195/1781 елда Урбар авылында вафат булган. 1167/1754 елда Хәсәншәех авылында, 1178/1764 елда Казакларда, 1182/1768 елда Урбарда дәрес әйтүе мәгълүм. Мәдрәсәсендә язылган бер «Каһестани» ахырында гарәпчә болай дип язылган: «Моны Сәйфулла бине Габделкәрим ахун Ибраһим бине Габдулла мәдрәсәсендә, Казаклар авылында 1174/1760 елда язды». Үзе галим, ләкин ялгышучан табигатьле кеше булуы билгеле.

Остазы – Мортаза әфәнде (кара: 29) вә шәкертләре болар: Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Сәйфулла бине Габделкәрим әс-Саснавый вә башкалар. Атасы Габдулла Вятка вилайәтендә Нократ авылында имам булган икән. // [56]

**53. Вәли хан бине Аблай хан**

Казакъ ханнарыннан. 1739 елда атасы Аблай хан Русия хакимлеген кабул итеп, 1781 елда вафат булган. Казакъларның сайлавы вә императрица Екатеринаның раславы белән 1192/1782 елда Уфа шәһәрендә атасы урынына Вәлинең ханлыгы рәсми рәвештә расланган. Бу вакыйга бөек вә солтанатлы булып, Уфа шәһәренә рус чиновниклары вә казакъ түрәләре хисапсыз микъдарда җыелган-

нар иде[21]. Ант мәҗлесендә ахун (бу ахунның кем икәнлеге безгә мәгълүм булмады, ихтимал ки, Ибраһим бине Түләк яки Мөхәммәдҗан мөфти булыр) артыннан Вәли солтан ант кәгазен кычкырып укыган, Коръәни Шәрифне ихтирам йөзеннән үбеп, баш өстенә күтәргән. Кайбер җыентыклардан аңлашылганча, моның ханлыгы озак вакытлы булмый, бәлки яшьлегендә вафат булган.

### 54. Мөхәммәдкол бине Табай

Ык елгасындагы Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1200/1786 елларда вафат булган. Гыйлем әһелләре арасында белемле вә камил дигән исеме таралган.

### 55. Хөсәен бине Габдеррахман бине Әнәс әл-Борындыкый

Уфа вилайәтендә Эстәрлебаш авылында 1132/1720 елларда имам вә мөдәррис булган. Аның дәвамчысы булган Гаделшаһ бине Габдулла 1210/1796 елда Эстәрлебашта мөдәррис булганга, бу гасыр башында вафат булса кирәк. Исеме язылган таягы бу көнгә кадәр мәчеттә саклана вә хатыйблар кулында берсеннән берсенә күчеп йөрүе мәгълүм. Үзе галим, үзе изге, нәсыйхәт итүче[22] бер кеше // [57] булган икән. Бер риваять буенча, әлеге зат Мансур ахун (кара: 30) бине Габдеррахман угылы. Вә, һәрхәлдә, Русиядә беренче мөфти булган Мөхәммәдҗанның атасы.

### 56. Мөхсин бине Сәфәр бине Юныс (кара: 33) бине Иванай

RUHIAT

Казан өязендә Оры авылында имам булып, 1204/1790 елда вафат булган. Остазы Хөсәен бине Габделкәрим. Мөэмин исемле угылы булган.

### 57. Габдессәлам бине Хәсән бине Кадермәт (Кадермөхәммәд) бине Теләнче бине Байгилде бине Туеш

Ерак бабасы булган Туеш Минзәлә ягындагы Бикбау авылында вә Байгилде бине Туеш Азалак авылында күмелгәннәр. Теләнченең Кадермәт илә Сәрмәкәй исемле угыллары Мәллә елгасының башында Кәкре Елга атлы бер авылга нигез салганнар. Кайбер җыентыкларда язылганнарга караганда, авылның нигезләнүе 1709 милади/1121 һиҗри ел ахырында булган. Тирә-ягындагы җир, урман, печәнлекләрне һәм, гомумән, яхшы вә яман җирләрнең барчасын Надир бине Уразмәт (Уразмөхәммәд) атлы кешедән сатып алып, үзләренең милке иткән. Сәрмәкәйнең Әлмәт исемле угылы, бу якларда беренчеләрдән буларак, Русия дәүләтенә сусар тиресеннән ясак биргән. Алтынбай бине Әлмәт бине Сәрмәкәйнең балалары Исмәгыйль, Мәрхәба, Габдеррәшид, Җәгъфәр, Ягъкуб, Яхъя, Тәхаведдин булып, туганы Тимеркәй бине Әлмәт балалары: Миңлекәй һәм башкалар. Кадермәт бине Теләнче угыллары Мостафа вә Хәсән. Габдессәлам бине Хәсән замандашлары арасында бер мөдәррис булып танылып, Кәкре Елга авылында озак вакытлар укыту белән шөгыльләнеп, 1204/1790 елда вафат булган. 1115/1703 елда язып тәмам иткән бер «Шәрхе викайә»се күренгән. Үзенең угылы язып тәмам иткән бер китап (беренче бите югалганга күрә, исемен белә алмадым, ләкин эчтәлегеннән шигый галимнәрнең әсәре икәне ачык аңлашыла) ахы-

[21] Бу вакыйга турында рәсми газеталарда тәфсилле бирелгән иде. 1892 ел саны.
[22] «Эстәрлебаш тарихы», 5 б.

рында шул рәвешле язылган: «Уфа вилайәтендә Кәкре Елга авылы мәдрәсәсендә // [58] атабыз Габдессәлам бине Хәсән һәм мин, фәкыйрь Габделгаффар бине Габдессәлам бине Хәсән тарафыннан 1185/1771 елда язылды».

Балалары: Габделгаффар, Шәмседдин, Зәйнеддин, Габдессаттар һәм башкалар. Оныгы Сәгъдеддин бине Габдессаттар Кәкре Елгада имамлык итеп, 1300/1883 ел ахырында вафат булган. Ир баласы булмаганга күрә нәселе дәвам итмәгән.

Ошбу урында исеме телгә алынган Надир бине Уразмәт[23] Тау ягы мирзаларыннан булып, Казан алынган вакыттамы яки Урал тарафында булган чуалышлар вакытындамы, дәүләт өчен олы бер хезмәт күрсәтеп, Зәй, Кичү, Шушма, Сок елгалары буенда бертоташтан буларак, яхшы хезмәте өчен, Хива мәмләкәте кадәр җир һәм урманнар белән бүләкләнә. Әлеге җирләрдә кырыкка якын мөселман авылы урнашса да, ничек тә җиргә ия булырга теләмәгәннәр, шуңа күрә мондый хуҗасыз мирас һаман да иясез кала биргән. 1770 елда мәшһүр бер дәгъва вәкиле тырышлыгы белән өч-дүрт авыл халкы үз биләмәсендә булган җирләрне үз милекләре буларак хөкүмәт тарафыннан раслаттырсалар да, башкалары бу файданы үз күзләре белән күргән хәлдә, сүз аңламас йорт башлары аңсыз муллаларының: «Монда, әлбәттә, бер хәйлә вә мәкер бар», – дип хәвефләнүләреннән мондый зур вә мәңгелек хәзинә кулдан киткән. Безнең халкыбызның гадәте исә: булса – җирне сату, ә алу түгел. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!

### 58. Хөсәен бине Габделкәрим бине Ярмөхәммәд бине Янсарый (кара: 25) бине Байсарый

Казакларда, Орыда, Ушмыда имамлык итеп, 1205/1791 елда Оры авылында вафат булган. Бу кеше мәшһүр Хәбибулла ишан илә Фәтхулла ахуннарның ата907лары була. Болардан башка Исхак исемендә бер угылы булган. // [59]

### 59. Габделкәрим бине Габдеттәүуаб бине Габделгани бине Габделкоддус әл-Мәрҗани

Йөз яшенә ирешеп, 1205/1791 елда Мәрҗан авылында вафат булган. Садака, гошер җыеп тереклек итәргә риза булмаганга, имамлык хезмәтен кабул итмәгән икән.

Балалары: Рәхмәтулла, Сөбхан, Госман, Габдулла, Габдеррәшид.

### 60. Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд

Асылы Үргәнеч мәмләкәтеннән булып, илебезгә килү белән төрле урыннарда мәдрәсәләр тотып, укыту белән шөгыльләнгән. Ишнияз әфәнде, Ишнияз ахун дип танылып, 1205/1791 елда Сәгыйдь бистәсендә вафат булды. Анасы Хәдичә бинте Шәриф исемле булган.

Шәкертләре: Сәгыйдь бине Ибраһим әл-Барышый, Ибраһим бине Арыслан әл-Киюми [Кимеви – ?], Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Ширвани, Монасиб бине Габдеррәхим әл-Казаный вә башкалар.

---

[23] Надир бине Уразмәт бине Тотыш бине Туйбакты бине Тәүкилде бине Шәехмөхәммәд бине Габдеррахман бине Габдулла бине Хөсәен бине Ослыхуҗа бине Маҗак. Зәй елгасында булган Надир авылы моңа бәйле.



RUHIAT

Әсәре: «Гакаиде Болгария» атлы бер төрки рисалә. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Һәрникадәр дөрес вә сәләтле галим булмаса да, ватаныбызга игътибары зур булган. Җәй көннәрендә кыска кичләрдә, якыннарын вә шәкертләрен биек тау башларына алып барып, шәфәкъ баеганын күрсәтә торган булган. Кыска төннәрдә ястү намазы фарыз, диюне, шушындый үзенчәлекле вә кирәкле мәкаләләрне йортыбызга тараткан зат шушыдыр. Ахыр гомерендә кайбер шәкертләре, бу мәзһәбләрнең хакыйкатьләренә ирешеп, үзен инкяр иткәннәр», – дигән. Элекке җыентыкларда вә китап читләрендә үзеннән беркадәр фәтвалар язылган, нәтиҗәләренә дикъкать ителгәндә, күчерүчеләрнең игътибарсыз икәнлекләренә күңел хөкем итәр. Бу уңайдан берсе шушыдыр: «Ишнияз әфәнде бине Ширнияздан ишеттем. Конут догасына тәкбир әйткән вакытта бармакларын колак йомшакларына тигерсә, намазы бозык булыр, дип». Хәдис китапларында Ифтитах вә Конут тәкбире вакытында колак йомшакларына кул тигерүгә боерып бер өйрәтмә күрелмәсә дә, бу гамәлләрнең намазны бозачагы турында һичбер дәлил беленмәде.

Ошбу Ишнияз әфәндегә // [60] нисбәт ителгән сүз илә моннан утыз ел элек Бөгелмә өязенең олы вә кече голәмасы, шәехләре вә дәрәҗәле кешеләре катнашкан бер мәҗлес Әлмәт авылының Искәндәр бине Хәбибрахман йортында шәех Зәйнулла әл-Халиди Модәзалә хәзрәтләренең гыйлеме имтихан ителгән. Унөченче гасырның ахырында килгән галимнәребезнең бу рәвешле китап читләрендә вә дәлилсез җыентыкларда язылган сүзләргә игътибар итүләре өчен гаҗәпләндек тә, кайгырдык та.

### 61. Нургали хан бине Әбелхәер хан (кара: 39) бине Ага

RUHIAT

1762 елда казакълар тарафыннан, әманәт буларак, Русия дәүләтенә тапшырылган иде. Оренбург вә аннан Уфа шәһәренә китерелеп, Уфада күпме ай торганнан соң азат ителгән. Казакъ кабиләләреннән кайбер таифәләренә хан булган. «Шәрекъ Наполеоны» булган Надиршаһның гаскәр башлыгы Таһир хан бине Рөстәм ханны Үргәнеч мәмләкәтендә үтергән. 1204/1790 елда яңадан Уфага китерелеп, 1205/1791 елда вафат булган. Кабере Иске Уфа исемле урында кирпеч заводлары янында. Бер мәгълүматлы кеше дәлилләре илә каберен эзләп тапкан идем. Өстендә кечкенә бер таш булса да[24], язуы юк. (Кирәк Надиршаһ, кирәк Надиршаһның гаскәр башын үтерәчәк мәртәбәдә баһадир вә югары дәрәҗәгә ия ул, дөньяның карары шулайдыр!..)

Моннан соң угылы Ишем хан вә аның туганы Айчуак бине Нургали хан вә аның улы Җантура бине Айчуак вә аның туганы Ширгази бине Җантура берберсе артыннан ханлык тәхетенә утырганнар. Ләкин боларның ханлыклары исемдә генә булып, чын идарә Русия дәүләтендә булган. Ишем хан 1212/1798 елда вафат, Ширгази хан 1240/1825 елда әле исән булган. Нургали ханның икенче улы Бүкәй хан 1226/1811 елда // [61] Бүкәй иленә хан булып, Русия дәүләте тарафыннан расланган. Вафаты 1238/1823 елда. Моннан соң карендәше Вәли хан ханлык исемен алган.

[24] Бу көндә кенәз Солтан Әхмәд бине Җиһангир хан тарафыннан төрбә өстенә таш бина салынып, тирә-ягына озын итеп чокыр казылды.

### 62. Шәмседдин бине Габдеррәшид бине Гаед

Атасы Габдеррәшид 1183/1769 елда Казан шәһәрендә исән булган. Үзе Казанда имам вә ахун булып, 1207/1793 елда вафат булуы сөйләнә. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Шәмседдин әфәнде дип танылып, заманасында ахун, Казан тирәсендәге дини дәгъваларны хәл итәр иде. Әхмәд бине Сәгыйдь әш-Ширвани сабый вакытында Кишет авылына килеп тикшереп йөрүен күргәләгән, вә рус кавеменнән сәркәтибе дә булган икән.

Шәкертләре: Максуд бине Корбангали әл-Күлбаши һәм башкалар.

### 63. Вәлид бине Максуд бине Афак бине Дустмөхәммәд бине Байгура бине Тукгура бине Чукгура

Эстәрлетамак ягындагы Кырмыскалы авылында имам вә ахун булып, олуг бер шөһрәт иясе булган. Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәте ачылганга кадәр мөселман җәмәгате өчен мөрәҗәгать итәр һәм сиеныр кешесе булып, кирәкле җирләрдә мәчет салуга рөхсәт бирә һәм имамнарны куя торган була. 1179 елның шәгъбан/1766 елның гыйнвар аенда хөкүмәт тарафыннан указ алган, 1207 яки 1208 елда[25] вафат булган. Төрбәсе Кырмыскалы авылында. Угыллары Вилдан ахун илә Суфиян ахун да заманының мәшһүрләреннән булганнар. Атасы Максуд бине Афак, Казан вилайәтендә Яңа Сала исемле авылдан күчеп, // [62] Уфа өязенә Биш Курай авылына килеп гомер иткән, үзе дә голәмадан булып, Мортаза әфәнде (кара: 29) хозурында файда күргән.

### 64. Әбүбәкер бине Ибраһим бине Йосыф бине Ишбулад бине Ишморад

Казан халкыннан вә Казан шәһәрендә имам булып, 1208/1794 елда вафат вә Казан зиратында күмелгән. Остазы Вятка вилайәтендәге Янгул авылыннан Мәсгуд бине Бикмәт исемле кеше булып, аның хозурында «Мисбах шәрхе», «Ифтитах» язып, 1175/1762 елда тәмам иткән. 1204 елның рабигыль-әүвәл аенда/1789 елның ноябрендә Уфа шәһәрендә мөселманнарга махсус идарәханә оештырылганда иң элек әгъза булып барган өч кешенең берсе. Әгъза булуы Мөхәммәдҗан мөфтинең иҗтиһады илә булып, аның теләгенә муафыйк һәм бу хезмәтендә өч нәүбәт тоташтан калган. Диния Нәзарәтенә кагылышлы кәгазьләр таралып вә әрәм-шәрәм ителеп беткәнгә, бу затның шәригать мәсьәләләре хакында язган әсәрләре вә фәтваларына нинди китапларны куллануын белү мөмкин булмады. Бер-ике имзасын санамаганда, һич әсәре очрамады, дию мөмкин булыр. Заманында игътибарлы бер зат булып, Казан вә тирә-ягында булган дини дәгъваларны тыңлап вә низагларны хәл иткән. Озын буйлы, камил әгъзалы, куе сакаллы бер зат булган. Ир баласы булмаганга, бу яктан дәвамы булмыйча, Әбүбәкер бине Йосыф никахында кызы Гафиядән Садреддин бине Әбүбәкер дөньяга килгән, Габдеррәшид бине Исхак бине Юлдаш никахындагы кызыннан оныклары бар икән.

---

[25] Бу зат милади белән 1793 елда вафат булса да, кайсы айда икәнлеге тәгаен булмаганлыктан, бу елда 1207 елның ахыры, 1208 елның башы җыелганга, шул рәвешле күрсәтелде.

## 65. Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд

Казан ягында Сатыш вә Саба авылларында имам булып, мәдрәсә тоткан вә заманының зур мөдәррисләреннән берсе булган. Остазы – Мортаза әфәнде (кара: 29). Моның хозурында шәкертләреннән Габделкәрим бине Ибраһим әл-Болгарый 1175/1762 елда «Каһестани» язып тәмам // [63] иткән; Зәй елгасы буендагы Түбән Мактама авылының Зәйнелгабидин бине Габид 1793 елда «Фәраизе Сираҗия»гә булган «Сәед шәрхе»н язып тәмам иткән; Шушма елгасы буендагы Сары Биккол авылының Әлмөхәммәд бине Думай бине Бимәк суфи 1197/1783 елда «Каһестани» язып тәмам иткән; Чирмешән елгасында Киекле-Бурмәт авылының Йосыф бине Иманколый әл-Болгарый 1197/1783 елда «Әмалый касыйдәсе» өчен Гали әл-Карый (аңа Алланың рәхмәте булсын) тарафыннан язылган шәрехне күчергән. Уса тирәсендәге Балтач авылының Бинейәмин бине Йәһүдә бине Балтач 1208/1794 елда «Каһестани» язып тәмамлаган. Ошбу шәкертләренең язулары дөрес вә гүзәл булганга, үзенең дә җитеш, камил булуы аңлашыла.

## 66. Фазлулла бине Габделмәннан (кара: 48) бине Габдеррахман

Бөтенлек вә камиллек иясе булган зур галимнәрдән. Тайсуган авылында имам вә мөдәррис һәм ахун булып, 1209 елның 23 җөмадиел-ахирында/1795 елның 4 гыйнварында вафат булган. Тайсуган зиратында күмелгән. Дини бер мәсьәләне хәл итү өчен заманының мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен тарафыннан чакырылган бик абруйлылары // [64] арасында бергә булып, фикер алышу вакытында әйткән фикере һәммәсе тарафыннан кабул ителүе һәм яхшы дип табылуы халык арасында сөйләнә.

RUHIAT

Остазы мәгълүм булмады. Бәлки, атасы Габделмәннан булыр.

Балалары: Габдулла, Гобәйдулла, Фәтхулла, Габденнафигъ, Мөфаззал, Мәүһүбә, Сәрвиназ, Фәрхиназ. Сәрвиназ Шәмседдин никахында; Мәүһүбә Борһанеддин никахында булган, һәр икесе Мөхәммәдшәриф (кара: 50) бине Сөләйманның угыллары вә Габдессәлам (кара: 46) бине Хөсәен әл-Кариленең оныклары. Габдулла исемле угылы беренче дәрәҗә гүзәл вә дөрес язучылардан булып, 1260 елның 14 шәүвәлендә/1844 елның 15 октябрендә вафат булган. Моның вафаты белән Габдеррахман (кара: 43) бине Туймөхәммәднең Тайсуганда булган гыйлем йорты сүнгән; мәдрәсә вә шәкертләрне тәрбия итү өчен Габденнасыйр бине Габдеррәхим Каран авылыннан күчеп киткән. Габдулла бине Фазлулланың угылларыннан Шаһиәхмәд 1300/1883 елда, Габделмәннан 1311/1894 елда вафат булдылар.

## 67. Габдулла бине Мөслим бине Гали бине Әлмөхәммәд бине Чуенчал мирза бине Дәвеш мирза

Муса хаҗи бине Фәтхулла сөйләгәннәргә караганда, ерак бабалары Алтын Урдадан чыгып, Дәвеш мирзаның нәсел вә нәсәбе Уфа вә Оренбург вилайәтләренә таралган булган вә кенәз Дашкин фамилиясе илә танылганнар. Күп кешеләрдән ишеткәннәребезгә күрә, Русиядә мәшһүр рус дворяннарыннан Дашковлар ошбу зат тармагыннан икән. Гобәйдулла мирза бине әл-Хөсәен Дашкинның сөйләвенә караганда, Дәвеш мирза, беркадәр үзгәртелеп, Дашка дип танылган булганга, Дәшкә сурәтендә әйтелеп йөргән тармаклары (болар күбесе мөселманнар) Дашкин дип танылганнар; Дәшкаү рәвешендә аталып йөргән тармаклары (болары христианнар) үзләренә Дашков нисбәте биргәннәр. Ике төрле нисбәт-

нең аермалыгы бары шивә (диалект) вә әйтелеш җәһәтенчә булган аермалык сәбәбеннән мәйданга килгән. Гали бине Әлмөхәммәд, хаҗ сәфәрендә йөреп кайтканга, Хаҗи Гали дип танылган иде. Мөслим бине Гали дәүләт тарафыннан бүләкләнеп имтияз алу соңында, Чиләбе ягына килеп, бер авылга нигез салган һәм аны, үз исеменә нисбәт итеп, Мөслим авылы дип атаган.

Ошбу Габдулла Верхний Урал илә Тройски арасындагы киң сахрада бер авылга нигез // [65] салып гомер иткән, үзе мөдәррис вә ахун дәрәҗәсендә булганга, авылы да Ахун авылы дип аталган. Остазы Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаный булып, һәртөрле гыйлемнәрне туплавы белән мөселманнар арасында бигрәк тә дәрәҗәле вә игътибарлы булуы сөйләнә. Дәүләт тарафыннан илчелек сыйфаты белән Бохарага барган вә бу хезмәтенә рәхмәт йөзеннән алтын орден вә күп мөлкәт белән бүләкләнгән. Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәте оешканга кадәр дини мәсьәләләрне хәл итү, имам вә мөәззиннәрне билгеләү, җомга вә гаетләрне уку өчен рөхсәтләр биргән. Заманында Иван бине Емельян исемле кеше Пугачев Өченче Петр бине Федор исеме белән 1185/1773 елда чыкканда, Габдулла ахун башкорт халкын вә, гомумән, ислам милләтен чакырып, каршы алган. 1209/1795 елда вафат булып, васыяте буенча үзе салган мәчет тарафына күмелгән, каберендә таш булып, исеме вә тарихы язылган, диләр.

Балалары: Ибраһим, Габделмөҗиб, Мөхәммәдъяр, Хәнифә. Хәнифә исемле кызы Габделҗәлил бине Фәйзулла хатыны булып, голәмадан Мөхәммәдзариф бине Габделҗәмилнең анасы.

Хатлары[26]: 1. «Типтәрләр старшинасы Сагынбай Солтанай угылы карамагында булган Калкан авылында Үлмәс Хуҗамкол угылын мәхәллә җәмәгатьләре, үзләренә имам вә мөдәррислек өчен лаек күреп, иттифак иткәннәр. Мөселманнарның ризалыклары сәбәпле, гает вә җомга укырга рөхсәт кылып, Калкан авылында шәригать буенча идарә итәргә ихтыярландырдым. Ышанычлык өчен имза иттем: ахун вә депутат Габдулла Мөслим угылы һәм мөһеремне салдым. 1771 ел миләди, июль 17 дә (118 нче номерда)». // [67]

Беренче хатын ахун Муса әфәнде бине Фәтхулла Ахун авылыннан, икенче хатын Гобәйдулла әфәнде бине әш-Шәех Габделхәким Мидиәк авылыннан, Габдулла әфәнденең үз каләме илә язган нөсхәләреннән күчереп җибәргәннәр иде. Беренче хатында әйтелгән Үлмәскол Хуҗамкол угылы Верхний Урал ягында атаклы вә шөһрәтле бер галим булган икән. Икенче хатта бәйан ителгән мәчеттә 1205/1797 елда Әбелләес исемле кеше, рөхсәт алып, имам булган. Беренчесе Сәгыйдь авылында Вәлид ишан тарафдарларыннан, икенчесе Юлык авылында Габделлатыйф шәкертләреннән.

### 68. Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаный (Казакай ахун)

Дагыстан вилайәтендә зур голәмадан булып, каза (хөкем) вазыйфасында булган. Шуның өчен ул тараф халкы үзенә «Казый акай» дигән икән. «Ака» вә «ага» сүзләре безнең төрки телдән булып, гарәпләрнең «мәүля, сәед, рәис» мәгънәсендә кулланыла.

«Казый акай», бераз үзгәртелеп, «Казакай» дип шөһрәт алган. Дагыстан вилайәтендә абруй вә игътибар иясе булган хәлдә, сәбәбе безгә ачык беленмәгән җәһәт белән, Русия эченә куылган. Оренбург ягындагы Сакмар елгасы буенда Кондырау вә бер риваятьтә Кондырау Нугай исемле авылда урнашып, мәктәп вә мәдрәсә оештырып, укыту белән шөгыльләнеп, 1210/1796 елда вафат булып, Ка-

[26] Төп нөсхәдә ике хаты бирелгән.

RUHIAT

закъстанда Сау Каен атлы су буенда күмелгән. Кабере мәгълүм вә ташында исеме һәм тарихы язылган булса да, ташының баш тарафы сынып төшкән икән.

Балалары: Мөхәммәдҗан, Йосыф.

Язма әсәрләреннән бернәрсә дә сакланып калмаган.

Остазы Әхмәд әд-Дагыстаный, аның остазы Мөхәммәд бине Муса әл-Каддәкый, аның остазы Дауд әд-Дагыстаный.

Бу кешенең дагыстанлы булу-булмавы беркадәр каршылыклы. Дагыстаннан куылуы, Дагыстанда казый булуы, Дагыстан халкына гыйлем бирүен дәлил итеп, күп кешеләр аның дагыстанлы булуын дәгъва итәләр. Кайберәүләр асылы казанлы булып, аннан Кабулга барып укып, Дагыстанга кайтып урнашуы һәм ахырда аннан куылуы турында фаразлар әйтәләр. Ничек кенә булса да Мөхәммәд бине Гали, күп мәшәкатьләр чигеп, замана җәфасының һәртөрле фәненнән дәрес алган. Бер риваятькә күрә, кайбер мирзаларда ат тоту (кучерлык) // [67] хезмәтендә булып, ахырында хәле беркадәр тәрәккый итү өчен аларның мәҗлесләренә катышкан вә үзенең сәләте булган музыка уйнау һөнәрен күрсәткән. Бу сәбәпле боларның күңел ачу мәҗлесләрендә газиз гомеренең бер кисәген әрәм иткән. Ләкин шул ук вакытта, «һөнәр ашарга сорамас, ашарга бирер» дигән кебек, бу һөнәр үзенә кимсетелүдән вә гомерлек кол булу хурлыгыннан котылырга сәбәп булган. Скрипка уйнаган бер мәҗлесендә әдәпле вә намуслы кайбер затлар, моның бер галим, бер гыйлем диңгезе икәнен аңлап, иясеннән үтенеп вә ялварып азат иттергәннәр. Ахун хәзрәтләре, әсирлектән котылып, иректә тереклек иткәндә, укыту юлына кереп, тәрбия илә шөгыльләнгән. Шәкертләренә фән ысулларын һәм мәгърифәт нигезләрен укыткан. Ислам җәмәгатьчелеген ныгыту, дини кардәшлекне вә милли бердәмлекне берек тоту өчен бар куәтен сарыф иткән. Җыеп кына әйткәндә, бу кешенең безнең мәмләкәтебездә булган мөселманнар өчен иткән хезмәте вә күрсәткән эше бәһасез. Үз иленнән куылып, безгә җибәрелүе милләтебез өчен зур бәхет булып хисаплана. Хәйрулла бине Габделхәбир әл-Эстәрли хәбәренә күрә, бу кешенең ислам дине гыйлеменең күбесендә тирән белемле булса да, шулардан аеруча өстен күргән гыйлемнәре «Мәган», «Бәйан» кебек гарәп әдәбияты булган икән. Коддури шәрхе булган «Холясатеддәлаил» исемле китапның кереш өлешенә аңлатма бирүе сөйләнә. Бер риваять буенча, Казан шәһәрен Русия басып алганнан соң, әүвәл мәртәбә буларак гарәп теленең сарыф вә нәхүен укыткан зат шушы була. Пугачев фетнәсе вакытында һәммә якыннары вә дуслары илә бергә Казакъстанга күчеп китеп, югарыда әйтелгән Сау Каен исемле җирдә вафат булган. // [69]

RUHIAT

Шәкертләре: Габдессаттар әл-Камывый, Габдулла (кара: 67) бине Мөслим, Мөхәммәдҗан әл-мөфти, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Нигъмәтулла бине Рәхмәтулла әт-Тәүзыйхи, Сөбханкол бине Бикмәт, Мөхәммәдсәлим бине Рәхимкол, Мөхәммәд әл-Богавый, Рәхимкол әл-Калмашый һәм башкалар.

### 69. Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт бине Әлмәт бине Алыш

Чистай ягында Яңа Әлмәт исемле авылда имам булып, 1210/1796 елда вафат булган. Кабере Әлмәттә. Балалары вә оныкларыннан хәтта бу көнебезгә кадәр олуг затлар килеп чыга тора.

Үзе язган бер «Каһестани» ахырында болай ди: «Бу нөсхә Казан вилайәтенең Болгар ягы Нугай юлында Яңа Әлмәт авылында 1178/1764 елда җомга көн Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт Хафиз бине Әлмәт әл-Әфзал бине Алыш

тарафыннан язылды». Милади белән 1744 елда, перепись вакытында[27] «Ибраһим Сәрмәт угылы 54 яшендә, Хөсәен Ибраһим угылы 20 яшендә, Җәгъфәр Ибраһим угылы 15 яшендә, Зәйни 12 яшендә, хәмәл (кучкар) йолдызлыгында» дип язылган икән. Казан шәһәрендә зур сәүдәгәр Бикбау бине Исхак бине Солтангали кызы әлеге затның никахында булуы кайбер җыентыкларда күренде. Кизләү авылындагы шәех Гобәйдулла хәзрәтләре моның угылы иде.

### 70. Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд

Казан ягындагы Кышкар мәдрәсәсендә укып, Казан шәһәренә имам булган вә 1211/1796 елларда вафат. Кадер исемле мөдәррис хозурында «Нигъмәве Алла» дигән китап язып, 1167/1754 елда тәмам иткән. Анасы Бөстан бинте Ярмөхәммәд иде.

Балалары: Шәмседдин, Фәхреддин, Габдессаттар, Габделгаффар һәм башкалар. Чыгышы Зәй елгасы башында Бөгелмә өязенең Каратай авылыннан. // [70] Үзе вә ничә еллар буе угыллары вә оныклары һәртөрле ярдәмнәрне әлеге Каратай авылына китереп вә җибәреп торганнар иде.

### 71. Миңлеакай бине Хаҗиморад бине Дуенкилде

Карагач таифәсеннән Байгынды ыругыннан булып, Әстерхан шәһәрендә имам вә мөдәррис бер зат иде. Шәкертләренә «Гакаиде Нәсәфи» китабын укыткан. Үзе бер «Тәүзыйх» язып, 1206/1792 елда тәмам итүе шул китап ахырында язылган. Мәдрәсәсендә язылган бер «Рамазан» нөсхәсе ахырында булган тарихы шушы «Замана голәмасы арасында мәшһүр Миңлеакай хозурында Хаҗитархан шәһәрендә 1211/1796 елда әл-фәкыйрь Хаҗикол бине Бузылбай язды».

RUHIAT

### 72. Мәсгудь бине Бинейәмин

Хәйрулла ахун әл-Уфавый хәбәренә күрә, Эстәрле ягында укыту илә шөгыльләнгән булган. Идрис бине Ягъкуб бине Халид бине Нөркәй бине Өтекәй исемле кеше моның мәдрәсәсендә 1211/1796 елда китаплар язып тәмамлаган.

### 73. Габдеррәшид бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Мәмәт (Мөхәммәд)[28] бине Нурмөхәммәд бине Бисуфый бине Муса бине Мәмәт бине Хәмадиш бине Үдәмиш бине Хөсәен бине Җәгъфәр

Бу зат үзен 1207/1793 елда 11 гыйнварда сишәмбе көнне Иштирәк авылында шушы рәвешле бабаларын язган. Әмма аннан элегрәк 1185/1771 елда язган бер кәгазендә Исмәгыйль илә Нурмөхәммәд арасында Мәмәт төшереп калдырылган. Өченче бер язуда Мәмәт илә Хәмадиш арасында Хәмаф сурәтендә тагын бер исем күренде. Исмәгыйльнең анасы вә Хәматның хатыны Бики исемле булып, Түмәки кызы. Түмәки бине Янкилде бине Кайбула бине Бәхшәндә бине Кармыш бине Тансар. Риваятьләргә күрә, ата тарафыннан булган ерак бабасы Хөсәен бине Җәгъфәр Болгар шәһәрендә мөселман дәүләте исән вакытта Ус исемле җирдә казый булып // [71] торган икән. Вә аннан соң булган һәммәсе үз заманында гыйлем әһелләре булып килгәнлеге сөйләнә. Бики атасы булган Түмәки бине Янкилде Казан ягында Зөя өязендәге Шырдан авылыннан булган Таҗеддин әл-

[27] Русия дәүләтендә булган икенче ревизия.
[28] Мәмәт илә Нурмөхәммәд бер кешенең исеме булса кирәк.

Иштирәки календареның кырына ошбу сүзләрне язган: «Әткәм тарафыннан булган Янкилде абыз, аның угылы Җанъегет абыз Сембер урынын шәһәр итү өчен биргән. Әүвәлдә үзенең милке булган икән, моның бәрабәренә дәүләт тарафыннан бүләк алган. Җанъегет угылы Сәүкә, Сәүкә угылы Метрәй, Метрәй угылы Шәфи». 1759 милади елда Мортаза бине Исмәгыйль вә хатыны исән булганнар әле. 1172/1173 елларда үлә. Габдеррәшид бине Мортаза, заманасына күрә гыйлем вә мәгърифәт туплап, Казан вилайәте Спас ягындагы Акмәд (Әхмәд) авылында имам вә мөдәррис булган. Мәдрәсәдән кайтып, имам булуы да 1169/1756 елда. Әлеге авылда 30 елга якын яшәгәннән соң, 1198/1783 елның 12 октябрендә дүшәмбе көн бу авылдан күчеп китеп, җиде көннән соң Оренбург вилайәтенә бу көн Самара вилайәтендәге Бөгелмә өязендә Шушма елгасы буендагы Яңа Иштирәк авылына урнашкан. Бу авылда ун еллар гомер кичереп, 1211/1796 елда яки 1212/1797 елда вафат булган. Монда да имамлык вә укыту илә шөгыльләнүе сөйләнә. Хатыны Гөлзәгыйфә бинте Рәҗәб бине Йосыф бине Үркә бине Кырымсарай бине Тунбай бине Бикбулат бине кенәз Бигеш булып, 1221/1806 елда әле исән булган.

Балалары вә туган еллары:

1) Шәмседдин – 1170 ел, 9 мөхәррәм/23 сентябрь, 1756 ел;
2) Хафизә – 1174 ел, 19 җөмадиел-ахир/15 гыйнвар, 1761 ел;
3) Нәҗмеддин – 1176 ел, 26 шәгъбан/1 март, 1763 ел;
4) Таҗеддин – 1184 ел, 15 сәфәр/30 май, 1770 ел;
5) Хисамеддин – 1185 ел, 24 зөлхиҗҗә/18 март, 1772 ел;
6) Сәйфелмөлек – 1187 ел, 17 шәүвәл/21 декабрь 1773 ел;
7) Сәхибҗәмал – 1193 ел, 18 зөлкагдә/16 ноябрь, 1779 ел;
8) Гыйсмәтулла – 1201 ел, 24 рабигыль-ахир/2 февраль, 1787 ел;
9) Фатыйма – 1202 ел // [72] 7 җөмадиел-әүвәл/3 февраль, 1788 ел.

Бер туганы Сәхибҗәмал бинте Мортаза 1173 елның 16 рабигыль-әүвәлендә/27 октябрь, 1759 елда дөньяга килгән. Таҗеддин мәшһүрләрдән булганы өчен, аның турында аеруча сөйләнер. Аннан башка ир балалар тарафыннан бу бөек кабиләнең шөһрәте бу заманнарда югалганнардыр. Гәрчә Иштирәк авылында Бакый бине Гыйсмәтулла бине Шәмседдин бине Габдеррәшид калса да, гыйлем әһеленнән булмаганга, нигездә, билгесез. Хафизә исемле кызы Камы Исмәгыйль авылында Галиәкбәр исемле кешедә никахта булган. Хафизәнең Бәдрелҗәмал исемле кызы Иштирәк авылында имам Мөхәммәдкәрим никахында булган. Моның улы Шәлчәле авылында имам Гыйльман бине Мөхәммәдкәрим бүген дә исән. Сәрвиҗәмал исемле икенче кызы Камы Исмәгыйль авылында имам Гайсә бине Габделмәҗид никахында булган. Габдеррәшид хәзрәт бик яхшы язучы булып, үз гомерендә бик күп Коръәни Шәриф күчереп язган. Язган гарәби вә төрки әсәрләреннән читкә таралганнан калганнары Иштирәк авылында төрле вакытта булган янгыннарда әрәм булуы сөйләнә.

Язган китапларыннан хәзерге вакытта исән булганнары вә тарихлары:

1) «Ифтитах шәрхел-мисбах» – 1166/1753 ел;
2) «Шәрхе Әрҗүзә» – 1127 ел, 19 зөлхиҗҗә/5 декабрь, 1715 ел;
3) «Әхтәри» – җөмадиел-әүвәл, 1172 ел/3 гыйнвар, 1759 ел;
4) «Гөлстан» – 28 җөмадиел-ахир, 1173 ел/5 февраль, 1760 ел;
5) «Холясател-Коддури» – 1185 ел/1771 ел;
6) «Шәрхе Чәгъмәйни» – 29 шәгъбан, 1193 ел/31 август, 1779 ел;
7) «Каһестани» – 1 зөлкагдә, 1195 ел/8 октябрь, 1781 ел;
8) «Әүфак әл-Коръән» – 9 рәҗәб, 1197 ел/30 май, 1783 ел; Акмәт авылында;
10) «Мәҗмугаи фарси вә гарәби» – 1199/1785 ел;

RUHIAT

11) «Шәрхе фәраизе Сираҗия» – 29 рамазан, 1202 ел/22 июль, 1788 ел;

12) «Мәфдихел-җинан» – 8 җөмадиел-ахир, 1208 ел/31 декабрь, 1793 ел; Иштирәктә. // [73]

1786 елда 23 мартта, сишәмбе кичендә, зур янгын булып, йорты януы вә зур каза күрүе үзенең җыентыгында раслана.

Остазы Мансур ахун (кара: 30) дип уйланылса да, хакыйкате мәгълүм булмады. Тәрҗемәсендә [биографиясендә] бирелгәннең күбесе оныгы Габделхак әфәнде бине Зыяддин бине Таҗеддин әл-Иштирәки ярдәме белән үз җыентыкларыннан вә каләме илә язылган элекке кәгазьләрдән алынганга күрә, иң дөрес хәбәрләр булыр дип өметләнәбез.

### 74. Арыслан бине Туйчы бине Тәмә бине Иртуган

Казан ягындагы Бәрәскә авылында имам булып, 1212/1797 елда вафат. Ибраһим исемле улы Кимедә имам булып, 1259 елның рабигыль-ахир аенда/1843 елның май аенда вафат. Бикчәнтәй бине Ибраһим шәкерте иде.

### 75. Сабанчы бине Богай

Сибирия голәмасыннан бер мәшһүр зат. Могтасыйм бине Билал әл-Камәрәви хәбәренә караганда, Тугыз авылында имам булып, 90 яшенә ирешеп, 1215/1800 елда вафат. Укуы Чиләбе ягындагы Әлмән авылында казый Габделкәрим дип мәшһүр бер кеше хозурында булган. Мәккәи мөкәррәмә мөфтие булган Габдулла әс-Сираҗинең «Салимел-әнвәр» дигән рисаләсендә әйтелгән Сабанчы башка кеше. // [74]

RUHIAT

### 76. Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви

Казан ягындагы Бәрәскә авылында имам вә мөдәррис булып, алтмыш яшьләренә ирешеп, 1215 елда 26 шәгъбан/1800 елда дүшәмбе кичендә вафат булган. Диния Нәзарәте оештырылган көндә беренчеләрдән Уфа шәһәренә әгъза булып барган өч затның берсе. Барон Игельстром дигән олуг бер чиновник әлеге мәхкәмәнең идарәсен оештырып, рәсми ачкан вакытта язган дәлилләмәсендә әлеге затның да имзасын күрдек. Бу кәгазь хәзерге көндә идарәханәдә бик тә дикъкать вә абруй өчен саклана. Үзе вафат булганнан соң, Габдеррәхим исемле угылы алмашчысы булды.

Шәкертләре: Ибраһим бине Арыслан әл-Кимеви, Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани, Хәмид бине Солтан әл-Бәрәскәви, Габдессаттар бине Сәгыйдь әш-Ширданый, Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри, Фәиз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Рәхмәтулла бине Сөбхан бине Йосыф бине Арыслан, бине Габделваһаб бине Габдулла бине Нуреддин, Мөхәммәд бине Гали әл-Калмашый һәм башкалар. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Болгар вилайәтендә булган галимнәрнең иң мәшһүрләреннән иде; шәкерте күп булыр вә шөһрәте таралган иде; гыйлем алу нияте белән хозурына ерак җирләрдән килерләр иде; Бәрәскә авылында 28 ел укыту хезмәтендә булды; казый булып, Уфага баруы үзе сайлап түгел, бәлки Мөхәммәдҗан әфәнденең соравына нигезләнә иде», – дигән. Асылы Олуг Саба авылыннан вә, бер риваять буенча, Буклавыч авылыннан булган икән. 60 яшендә вафат булган.

**77. Исхак бине Габделкәрим** (кара: 41) **бине Балтай**

Атасыннан соң күп ел имам вә мөдәррис булып, 1216/1801 елда вафат булган. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, моның хозурында укып, кызын никахлаган. Әбелхәсәнгали исемле угылы, Оренбургта халык җыелган вакытта Меновный базарындагы мәчеттә имамлык итеп, халык таралу белән Сәгыйдь бистәсенә кайтыр иде. Соңыннан бу имтияз үзеннән алынгач, Казан шәһәренә барган, басма Коръәни Шәриф нөсхәләрен // [75] төзәтү белән шөгыльләнгән. 1259/1843 елда вафат булган. Мәдрәсәсендә язылган бер «Ширгател-ислам» китабы ахырында гарәпчә мондый гыйбарә күренде: «Бу нөсхәне Исхак бине Исмәгыйль бине Габдеррахман бине Бикмәт Исхак бине Габделкәрим бине Балтай мәдрәсәсендә язды. 1776 ел».

**78. Габделхаликъ бине Әгъзам бине Габдеррахман әт-Тенеки**

Атасы Әгъзам «Имкә мулла» дип танылган вә 1146/1733 елда әле исән булган. Кыска төннәрдә ястү намазы уку хосусында кайбер әсәрләре бар[29].

Бу зат Мамадыш ягындагы Тенеки Сабасы исемле авылда имам вә мөдәррис булып, 1216/1801 елда вафат булган. Диния Нәзарәте ачылганда, беренчеләрдән әгъза булып барган өч әгъзаның берсе.

Остазы: атасы Әгъзам бине Габдеррахман.

Шәкертләре: Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый, Һибәтулла бине Ислам әс-Салавычый, Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки вә башкалар. Мантыйк (логика) гыйлемендә бәхәс ителгән «4 шәкел» кагыйдәләрен бәйан итеп, бер кагыйдә сөйләгән.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Заманасында мәшһүр мөдәррис вә фазыйльләрдән иде; «Тәүзих» вә «Тәлвих» хашияләрендә үзенең кайбер аңлатмалары бар. Габделгалләм бине Габделкадыйр әс-Сабавый моны төрле фәннәрне бик белгән дип мактар иде. Аннан башкалар хәбәренә күрә, Диния Нәзарәтендә хезмәт итү максаты белән авылыннан киткәч, шәкертләре Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый хозурына барганнар, ләкин аның гыйлемен моның мәртәбәсеннән түбән тапканнар икән,» – дигән. Вафатыннан соң Кәмаледдин исемле угылы дәвамчысы булып калган. // [76]

**79. Сәйфелмөлек бине Мортаза бине Сәлим бине Исмәнән**

Агыйдел елгасының уң ягындагы Коры Алачык авылында имам булып, шәкерт җыеп гыйлем биргән. Сиксән яшенә ирешеп, 1217/1802 елда вафат булган. Биредә аталган ата вә бабаларының һәммәсе гыйлем вә белем әһелләре булган кеби, балалары да голәмадан булганнар.

Угыллары: Габделҗәббар, Габдегаффар, Габделкадыйр, Габдессаттар. Бу кешене Габделкәбир әфәнде: «Дәресе гүзәл, үзе тәкъва вә диндар, сөннәт илә гамәл итү турында зур дан казанган иде», – дип белдерә. Баһадиршаһ бине Сәйяркол әл-Гәйнәви исемле кеше моның мәдрәсәсендә 1185/1771 елда «Дөррәтен-нәсыйхин» китабын язып тәмам иткән.

---

[29] «Мөстәфадел-әхбар...» (1 нче кисәк, 72–73 б.).

## 80. Фәхреддин бине Габдеррәшид бине Гаед

Казан имамнарыннан. Фәхреддин әфәнде дип танылган. Өченче нәүбәттә Уфа шәһәренә Диния Нәзарәте әгъзасы буларак барган. 1802 елның 26 апрелендә имза куйган кайбер кәгазьләрен күргәнебез булды. 1217 елның мөхәррәмендә/1802 елның маенда әле исән була. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Кавал имамы Сәлимҗан (кара: 49) бине Дустмөхәммәднең Рәйхана исемле кызын алып, мөәззин Халид бине Исхак бине Исмәгыйль бине Ибраһим әс-Сагәтигә баҗа иде; әлеге мөәззин имтиханга барганда, Фәхреддин әфәнде Уфа шәһәрендә казый иде», – дигән.

## 81. Вәлид бине Мөхәммәделәмин бине Сөләйман бине Бикмөхәммәд бине Азай

Вәлид ишан дип танылган зат. Чыгышы белән Тәтеш ягындагы Кайбыч исемле авылдан. Мөхәммәд (кара: 68) бине Гали әд-Дагыстаный хозурында укыганнан соң, Бохарага барган. Вә аннан ике мәртәбә Кабул шәһәренә сәфәр иткән. Кабул шәһәрендә 1217 елның беренче мөхәррәмендә/1802 елның 22 апрелендә вафат булган шәех Фәезхан бине Хозырхан хәзрәтләреннән шәһадәтнамә алып, бу илгә кайтты вә Сәгыйдь авылында имам булып, шәехлек итте. // [77]

Бохарада вакытында 1192/1778 елда «Мелла Җами хашиясе»н язып тәмамлаган. 1214/1799 елда хаҗ сәфәре теләге белән Сәгыйдьтән чыгып киткән. Каһирәгә килгәндә Наполеон җитәкчелегендә булган французларны куу өчен хәзерләнеп торган инглиз гаскәренә юлыкканга, Каһирәгә бару өчен юл булмый, беркадәр вакыт туткарланырга мәҗбүр булган. 1216/1801 елда хаҗ кылган вакытта пәйгамбәрләр солтаны саллаллаһу галәйһи вәссәлламның изге каберен зиярәт кылган. 1217/1802 елда Мәдинәи мөнәүвәрәдә вафат, «Җәннәте бакыйгта» күмелгән.

Фикердәшләре: Нигъмәтулла бине Гомәр әл-Утарый, Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви, Җәгъфәр бине Имай әл-Бикмәти, Котлыәхмәд бине Заһид әд-Дустәми, Габделҗәббар бине Габдеррахман әл-Тайсуганый, Әхмәр бине Хәсән әл-Мастакый һәм башкалар. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Бу җиргә кайтып, шәкертләр тәрбия кылды, тәрбияле әхлак вә яхшы әдәп юлында иҗтиһадлы вә Болгар олугларының берсе вә бу мәмләкәт яхшыларының берсе иде», – дигән. // [78]

Мөхәммәд исемле угылы Сәгыйдь авылында 1254/1838 елда вафат булып, Таибә исемле кызы калды.

## 82. Җәгъфәр бине Имай

Бөре өязендә Бикмәт авылында шәехлек итеп, мөридләр тәрбияләгән. Шәехе Вәлид (кара: 81) бине Әмин әс-Сәгыйдинең вафат хәбәрен ишеткәннән соң, 1217/1802 елда вафат булган. Шәмседдин бине Дәванай исемле шәкерте үзенә алмашчы булган. Тәкъва вә диндар булып, үзенең кул кәсебе илә ризыкланып, дөньясын уздырган. // [79] Мөридләре илә бәрабәр мәчеттә зикер әйтү вә аралашу өчен төн уздыра торган булган. Сөйләгәннәргә караганда, Бикмәт халкының надан вә сүз аңламауларыннан шикаять итеп, остазы булган Вәлид ишаннан икенче бер авылга күчеп китәргә рөхсәт таләп иткән, остазы вә шәехе исә: «Аллаһы Тәгалә пәйгамбәр хәзрәтләрен надан халыкларга да җибәрде, аларның кавемнәре бәлки, сезнең мәхәллә әһелегездән күбрәк надан булганнардыр, шуның

RUHIAT

белән бергә алар һәрвакыт тырышлык белән камил илчелек иттеләр. Бер кеше туры юл тапсын өчен никадәр мәшәкать күрергә туры килсә дә түзделәр. Инде син дә, хөрмәтле пәйгамбәрләр юлына иярү теләге белән, торган урыныңда нык булып, олугларына нәсыйхәт, кечеләренә гыйлем бирсәк, шаять, зарар булмас, әгәр дә син алардан китәр булсаң, аларга кем нәсыйхәт бирер? Алар кемнән гыйбрәт алыр? Хәлбуки вәгазь сөйләгән сәгате белән үк нәтиҗәсе күренмәсә дә, күп мәртәбә булыр, соңында нәтиҗәсе булыр; адәм угылы ун ел ишеткән гыйлеме илә бүген килеп гамәл итәр; шуңа күрә күчеп китү турындагы фикерегезне муафыйк күрмәс идем», – дип аңлаткан. Чыннан да гүзәл бер нәсыйхәт вә Җәгъфәр бине Имайның бик тә акыллы булуын раслаучы бер аңлатмадыр.

### 83. Баһадиршаһ бине Сәйяркол бине Габдеррәшид бине Ишбулад

Уса ягындагы Каҗмакты авылының имамы вә Сәйфелмөлек (кара: 79) бине Сәлимнең шәкерте. Үзебезнең төрки телебездә 1219/1804 елда «Һәфтияк шәриф» өчен бер тәфсир язган. Бу тәфсир исә 1275/1858 елда Казан шәһәрендә казна матбагасында басылган. «Әдәбияте мәган» вә «Бәйан»да булган дәрәҗәсен белү өчен, әлеге тәфсирендә язган гарәп телендәге хотбәсен күрү дә җитәр. 1219/1804 елда әле исән булган.

### 84. Габделхәмид бине Үтәгән бине Ярмөхәммәд бине Котлыгмөхәммәд бине Мөхсин

1172/1759 елда Мәчкәрәдә, 1195/1781 елда Адай авылында вә аннан соң Салавычта // [80] вә ахырында үзенең төп ватаны булган Түнтәр авылында имам булып, 1220/1805 елда вафат булган.

Угыллары: Сабит, Габделгаффар, Габделфәттах. Сабит Чутай Завод авылында имам булган, Габделгаффар Яңа Тазлар авылында имам булган хәлдә, 1223 елның 9 мөхәррәмендә/, 1808 елның 24 февралендә Габделгаффар Иске Салавычта имам булган хәлдә 1283/1866 елда вафат булганнар.

### 85. Вәлид бине Сәгыйдь бине Фулад бине Әмин

Минзәлә елгасы башындагы Минзәләбаш исемле авылдан булып, атасы яки бабасы Сәгыйдь бистәсенә барып, сәүдәгәр булып язылган. Бу кеше бу заманыбызга кадәр Вәлид ахун дип мәшһүр булган бер зат. Минзәләбаш авылында имам, мөдәррис вә ахун буларак, 53 яшендә 1221 елның 25 рабигыль-әүвәлендә/1806 елның 31 маенда вафат булган. Кабере әлеге авыл зиратында. Әүвәл берара дәрес илә мәшгуль булып, соңрак 1789 елның 11 февралендә мәхәллә әһеле тарафыннан сайлап куелып, рәсми рәвештә дә имам булган. Диния Нәзарәтенең югалып, әрәм булудан сакланып калган иске кәгазьләре арасында иттифакнамә очрап, ошбу урыны күчереп бирелә: «1789 елның 11 февралендә Уфа наместничествосы Бөгелмә округы Мөслим Бакый сотнясы Минзәләбаш авылының типтәрләр, Сабай Корбанай угылы, Юлдаш Сәед угылы, Мөхәммәд Максуд угылы бирдек ошбу язуны. Оренбург губернасы Сәгыйдь бистәсенең өченче гильдия купец Вәлид Сәгыйдь угылына үз авылыбызда җомга мәчетебездә (моннан 110 ел элек бу авылда җамигъ мәчете булган икән!) имамлык хезмәтен башкарып, угылларыбызга сабак өйрәтү хакында тереклек итүенә риза булып». (Бу урында утыз кеше тамга салган.)

Остазлары: Габдессәлам (кара: 46) бине Хәсән әл-Кариле, Габделмәннан (кара: 48) бине Габдеррахман әт-Тайсуганый һәм башкалар.

Шәкертләре: Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки, Гашир бине Каракай әш-Шөгери, Габделвахид бине Габделмәннан, Габбас // [81] бине Рахманкол әл-Әсәи һәм башкалар.

Балалары: Хәдичә, Шәмседдин, Мөхәммәдшафигъ һәм башкалар. Мөхәммәдшафигъ исемле угылы 1204/1790 елда Уфа шәһәрендә вафат булып, шунда күмелгән. Моның Әхмәделислам исемендә бер угылы булып, 1309 елның рамазан аенда/1892 елның апрелендә Уфа шәһәрендә вафат булган. Хәдичә исемле кызы үзенең шәкерте Габделвахид бине Габделмәннанда кияүдә булган. Мөһере «Әл-мөтәвәккил галә Аллаһы Тәгалә ахун әл-Болгарый Вәлид бине Сәгыйдь» дип язылган иде. Язган китаплары: «Каһестани», 1189/1775 елда Габдессәлам бине Хәсән хозурында тәмам иткән. Тагын исеме хәтеремнән чыккан бер китап, 1194/1780 елда Габделмәннан бине Габдеррахман әт-Тайсуганый хозурында тәмам иткән. «Хөләсател-Коддури»ны, имам вә мөдәррис булган хәлдә, 1195/1781 елда Минзәләбаш авылында тәмам иткән.

Мәдрәсәсендә язылган китаплар: «Мәнар» хашиясе «Җамигыль-әсрар», ахырында мондый сүзләр язылган: «Моны Рәхимкол бине Рәфыйк бине Сөләйман Минзәләбаш авылында заманының гыйлемле әфәндесе Вәлид бине Сәгыйдьтә укыган чагында 1201 елның 2 җөмадиел-әүвәлендә/1787 елның 9 февралендә язды». Әлеге Рәхимкол Уфа шәһәре янындагы бер авылдан[30].

Вафат булгач, шәкерте вә кияве Габделвахид бине Габделмәннан имамлык, ахунлык, мөдәррислек вазыйфаларында үзенә алмашчы булган. Бу Габделвахид ахун чистайлы Габделгафур бине Габделмәннанның бертуганы вә безнең шөһрәтле атабызның кардәше иде. Вәлид ахун гыйлем өлкәсендә галим исемен хаклы рәвештә казанган, үзе кебекләр арасында дәрәҗәсе югары, гарәп вә фарсы телендә гүзәл иншалар язуга сәләтле бер зат булган. Язуы дөрес вә сүзләре урынлы кулланылган. Нәхү, фикъһ, ысуле фикъһ фәннәрен аңлап вә аңлатып укыткан. Борынгы китап читләрендә вә «Каһестани» аңлатмаларында «Вәлиди» имзасы белән күп әсәр күренде. Дусты, шәкерте булган Габдеррафигъ бине Таиш ән-Нөркәвигә 1218/1803 елда // [82] язган фарсыча хаты гыйлем куәтенә бер гадел шаһид[31].

Исеме телгә алынган Габдеррафигъ бине Таиш Минзәлә өязендәге Нөркәй авылында тормыш итеп, сиксән яшеннән узып, 1258/1842 елда вафат булган. Мөхәммәдҗан әфәнде бине Кадермөхәммәд әл-Вәрәши сөйләгәннәргә караганда, вәкарь вә гыйлем иясе, яхшы холыклы бер зат булган икән.

### 86. Габделҗәлил бине Мирсәлим бине Мәкаш бине Чунбай мирза бине Әлмөхәммәд мирза

Ерак бабалары Казан кешеләре булып, Верхний Урал якларына күчеп киткәннәр. Габделҗәлил әфәнде, Казан тарафында гыйлем алып, ватанына кайтып килгәндә, Ахун авылында Габдулла ахун (кара: 67) йортына кунак булып кереп чыккан. Ахун исә, бу кешедә камиллек вә акыл иясе билгеләрен күреп, чын күңелдән ошаткан вә, үзенең кызын биреп, әлеге Ахун авылына мөдәррис итеп билгеләгән. Ахун авылында 50 елга якын укыту белән шөгыльләнгән, хозурында күп затлар файда күреп, камиллеккә ирешкәннәр.

Балалары: Фазлессаттар, Мөхәммәд һәм башкалар.

[30] Бу кешенең каләме илә язылган бер «Шәрхе мисбах» ахырында ошбу сүзләр күренде: «Моны Рәхимкол мулла Таһир бине мулла Уразай мәдрәсәсендә Мусай авылында 1197 елның җөмадиел-ахир/1783 елның май аенда, якшәмбе көн язды».

[31] Ошбу хат «Мөстәфадел-әхбар...»да тулысынча языла (2 нче кисәк, 225–227 б.).

### 87. Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай бине Мәмәт (Мөхәммәд) бине Акман бине Илкәй бине Дулаҗан бине Әюбшәех бине Хуҗашәех бине Юллыкшәех

Казан ягындагы Саба авылыннан. Бу авылның рәсми исеме Мәмәт булганга, беренче нигез салучы Мәмәт бине Акман булмады микән дигән фараз бар. Дулаҗан хафиз бине Әюбшәех заманында Казан шәһәре Русия тарафыннан басып алынган икән. Габделхәмид әфәнденең остазы, кайбер җыентыкларда күрелгәнчә, Ишмөхәммәд (кара: 31) бине Тукмөхәммәд әл-Адайи. Әлеге Саба авылында имам буларак вафат булган.

Балалары: Сәйфулла, Фәйзулла, Нигъмәтулла, Хисамеддин, Габделкәрим, Габделгаффар, Габдессаттар, Әхмәд, Мөхәммәд һәм башкалар. Сәйфулла Салавыч авылында имам вә мөдәррис булган. Фәйзулла Сабада имам вә Әхмәд Сабада мөәззин булганнар. Мөхәммәд исемле угылы, үзе сиксән // [83] яшенә ирешкәннән соң никахлашкан хатыны Шәмгуннан дөньяга килеп, Олыязда имам вә соңыннан вазыйфасыннан китеп, 1277/1861 елда вафат булган.

Оныгы Габделвәли бине Габделкәрим Сабада вә икенче бер оныгы – Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла – Наласада имам булганнар.

### 88. Үтәгән бине Уразмәт

Малмыж өязендә Урбар авылында бай вә гакыллы бер кеше булып, 1221/1806 елда вафат. Беркадәр гыйлем вә дәрәҗәсе булган хәлдә имам вә хатыйблык вазыйфасын сайлаган. Хәнифә исемле кызы Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай никахында булган.

RUHIAT

### 89. Сәлим бине Габдеррәхим

Саба авылыннан булып, Бохарада тереклек иткән вә 1223/1808 ел ахырында вафат булган. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Бохарада вакытында дамелла Сәлим дип танылган... дөрес вә фикъһедән белемле галим булса да, кайвакытта исерткеч эчемлекләрне авыз итүе турында сөйләнә иде», —дигән. Бу мәмләкәттә булган төп исеме Рәхим булган икән.

### 90. Сөбханкол бине Бикмөхәммәд бине Юлдаш бине Ишкәй бине Түмкәй бине Янгилде бине Кайбула бине Кормаш

Бу шәҗәрә якынча моннан илле-алтмыш ел элек язылган, Фәсыйхеддин бине Сөбханкол хатыннан күчереп алдым. Соңрак Габделхак әфәнде бине Зыяддин әс-Саснавыйның Габдеррәшид (кара: 73) бине Мортаза әл-Иштирәкинең элекке җыентыкларында язган әсәрләреннән күчереп җибәрелгән хаты илә танышкач, Габдеррәшид хәзрәт язуында Кайбула илә Кормаш арасында Бәхшәндә дигән бер зат исеме күренде. Һәм дә Кормашның атасы Тансар дип күрсәтелгән. Юлдаш бине Ишкәй Казан губернасындагы Зөя өязе Шырдан авылыннан булып, Кичү елгасы башына күчеп килгән (Бөгелмә өязенә), үзенә нисбәтле рәвештә нигез салган авылы Юлдаш вә елгасына бәйләп Кичүчат дип аталган. Юлдаш бабайның Биккол, Бикмәт, Морад исемле угыллары булуы билгеле. Бикмәт (Бикмөхәммәд) бине Юлдашның Сөбханкол вә Рахманкол исемле угыллары булып, Рахманкол баласыз // [84] вафат булганга, бу көндә дәвамы югалган. Гәрчә моңа нисбәтле Кичүчат авылында кайбер кешеләр булса да, алар асылда Сөбханкол балаларыннан булган хәлдә, фәкать бер сәбәп өчен туганы булган Рахманколга нисбәт ителәләр. Әлеге Сөбханкол, ата-анасыннан рөхсәт вә ризалык алып, шул заманның гадәтенә күрә, елкы көтүеннән яхшы бер ат алып, Кичүчат

авылыннан чыгып киткән. Бәләбәй ягындагы Кыска Елга исемле авылда якын карендәшләре булып[32], аларда тукталган.

Азмы-күпме торганнан соң, Мөхәммәд (кара: 68) бине Гали әд-Дагыстани хозурында калырга теләп, Казакай ахун хозурында тоташтан алты ел торып, әүвәлге гыйлеменә ныклык биреп, зур файда күргән. Асыл ватанына кайтканда Куак елгасындагы Түбән Шәлчәле авылында имам булып, 33 ел гыйлем бирү, дәрес укыту илә шөгыльләнгән. Соңрак Габдрахман авылындагы Габделмәннан бине Аблай исемле кеше белән икәүләп Оренбург губернаторы тарафыннан чакырылганнар. Моның сер вә сәбәбе һич мәгълүм булмаганга, хәвефкә төшеп, һәммә балалары һәм якыннары илә ризалашып вә саубуллашып, Оренбургка юнәлгәннәр. Губернатор исә, боларны дәүләт исеменнән рәсми сурәттә старшина итеп раслап, ватаннарына озаткан. (Бу вакытта исә старшиналык мәртәбәсенең иң әүвәл кертелү заманы булып, мөселманнарның үзләренә хас буларак, дәүләт тарафыннан билгеләнер һәм Төркия нәзарәтендә булган шәехләр кебек иң абруйлы вә галим затлардан билгеләнеп, үзләренә һәртөрле дәгъва вә талашуларны килештерү вазыйфасы бирелә икән. Соңрак, заманалар үтү белән, әкренләп бу мәртәбәләр, беренче халәтеннән чыгып, хәзерге хәлгә килде; фикъһ, хикмәт, хафиз сүзләре кебек, сүзе исән булган хәлдә, эчтәлеге тулысынча үзгәрде. Кичүчат авылында берничә ел исән-имин тереклек итеп, 1223/1808 елда вафат булган. Хатыны Сахибә исемле булып, Шушма елгасы буендагы Шөгер авылында Каракай бине Госман бине Бикмәт кызы булган. Ул, 83 яшенә ирешеп, 1246/1830 елда ваба авыруы белән вафат булган. Кабере // [85] Кичүчат зиратында, Гашир бине Каракай илә бертуган иде.

Балалары: 1) Сәйфеддин (тәрҗемәи хәле бирелер). 2) Фәсыйхеддин – 1193 елның зөлкагдә аенда/1779 елның 8 ноябрендә дөньяга килеп, 1278 елның рамазан аенда/1862 елның февралендә вафат булды. Таҗеддин, Нәҗмеддин, Әхмәди, Шәрәфеддин, Әхмәдҗан исемле угыллары калган. 3) Мәхфүзә 1205 елның рабигыль-ахирында/1790 елның декабрендә дөньяга килеп, Чистай өязендәге Киек Бурмәт авылында имам Габделҗаббар бине Гомәргә никахланып, 1295 елның рабигыль-ахирында/1878 елның апрелендә вафат булды. Вәлиулла, Әхмәдҗан, Гыйссамеддин исемле балалары калды. 4) Фәхреддин (тәрҗемәи хәле бирелер). 5) Габид Кичүчат авылында тормыш итеп, 1271/1855 елда вафат булды. Фәтхия, Миңлебай исемле балалары калган. 6) Фәрхана. Шөгер авылында Габдеррәшид бине Мөхәммәд никахында вафат булды. 7) Сәгыйдә. Сугышлы авылында Мөхәммәдшәриф бине Мансур никахында вафат булып, Мөхәммәдкәрим вә Мөхәммәдзариф исемле балалары калды. Сөбханкол бине Бикмөхәммәднең язуы хуш, рәсеме [каллиграфиясе] дөрес, гарәпчә әсәрләре зарарсыз. Язып тәмамлаган «Мохтасарел-Коддури» китабында ошбу сүзләр күрелде: «Миңа хәер-дога кылсын дип, ошбу китабымны углым Фәсыйхеддингә милек итеп бирдем, мин Сөбханкол Бикмөхәммәд, 1807 ел». Габдулла әл-Кизләви вә Гомәр әл-Киекле илә аралашып, бергә гыйлем туплап яшәгәннәр. Биредә телгә алынган Каракай бине Госман 1773 елда Пугачев гаскәренә каршы сугышта үтерелгән. Кабере Шөгер авылына каршы булган тауның көнбатыш тарафында вә кыйблага каршы агып торган чишмә янында. (Элекке заманда халык үзләренең могтәбәр вә хөрмәтле кешеләрен, билгеле булсын вә чишмә янына килгән-киткәннәр хәер-дога әйтеп // [86] китсеннәр өчен булса кирәк, шул рәвешле чишмә яннарына күмә торган булганнар.)

Ата-бабаларым вә кардәшләрем булганга, бу урында беркадәр тәфсыйльлерәк яздым. Аллаһы Тәгалә хәзрәте һәммәсен гафу итеп, гаепләрен кичерсен!

RUHIAT

[32] Моның Габделлатыйф бине Сөбханкол әл-Корычыйның анасы булуы сөйләнә.

### 91. Хәмид бине Мортаза бине Нурмөхәммәд

Казан өязендәге Әлдермеш авылыннан булып, Казан шәһәрендә имам булган иде. Моннан соң, яки элегрәк заманда, бервакытта Кариледә дәрес бирүе мәгълүм булды. Кариледә вакытта моның хозурында Мөхәммәдгали бине Зәйнелгабидин исемле кеше «Мелла Җами» язып тәмамлаган.

Остазы Габдессәлам (кара: 46) бине Хәсән әл-Кариле һәм башкалар. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Мантыйк гыйлемендә остазлыгы булу белән шөһрәт казанган иде. Казан шәһәрендә башлангыч мәдрәсә тәрбия иткән зат булуы сөйләнә; 1210 ел ахырында/1796 ел уртасында, Диния Нәзарәтенә барып, имтихан бирде», – дигән. 1223 ел ахырында/1809 елның башында әле исән булган.

### 92. Габденнасыйр бине Торымтай

Бәләбәй ягындагы Ирсай [?] авылында имам, 1223 ел ахырында/1809 ел башында вафат булган. Шәкерте күп булу җәһәте илә тиңдәшләре арасыннан өстенрәк булган.

Шәкертләре: Салих бине Габдулла әл-Чокрый, Әхмәд әл-Казанчый, Габделханнан әл-Казанчый, Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Иштирәки, Әмирхан бине Кучкар әл-Үтәки һәм башкалар. Бу кеше Бәләбәй ягындагы Төреш авылында булган Габденнасыйр бине Морадбакый[33] исемле мөдәрристән һәм шулай ук Габденнасыйр әт-Тайсуганыйдан башка кешедер.

### 93. Габделкәрим бине Хәлил

Вятка губернасындагы мәшһүр Бубый авылында 1226/1811 елда вафат. Газизә исемле кызы Нигъмәтулла бине Монасыйб никахында иде. Бу кеше укыту илә мәшгуль вә гыйлем юлында тырышып шөгыльләнүче кешеләрнең берсе булуы сөйләнә. «Шәрхе тәлхыйс» өчен «Ясин хашиясе»н, «Мотауваль» өчен «Чәләби хашиясе»н, «Тәүзыйх» өчен «Тәлвих», вә «Тәлвих» өчен «Хәсән Чәләби» хашиясен, «Тәфсире Бәйзави» өчен «Шәехзадә»не үз каләме белән язган икән. Бу әсәрләрне хосусан мәмләкәтебездә язып туплауның зур иҗтиһад нәтиҗәсе икәнлегендә шөбһә булмас.

### 94. Фазыл бине Сәйфулла бине Хәбибулла

Чистай өязендә Чирмешән елгасы буендагы Кизләү-Курманай авылыннан. Казан шәһәрендә имам булган вакытта – 1227/1812 елда, башка бер чыганак буенча, соңрак вафат булган. Бохарага барып, шәех Ниязколый бине Шаһнияз Төрекмәни хезмәтендә булган. Илебезгә кайткач, Мәмсә авылында имам булып, өйләнгән. Соңрак Курсага вә аннан соң Казанга күчкән.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый һәм башкалар.

Шәкертләре: Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли, Шәрәфеддин бине Зәйнеддин әл-Эстәрли һәм башкалар. Шәрифә атлы кызы Әхмәд бине Сәгыйдь әш-Шырданый никахында вафат булган. Мөхәммәдвафа исемле угылы, Бохарада гыйлем алып, Казанга кайтып, имам була, 1256/1840 елда имамнар тарафыннан сайланып, берара Диния Нәзарәтендә әгъза булып хезмәт иткән һәм 1264/1848 елда вафат булган. Ошбу Мөхәммәдвафаның Гайшә исемле хатыны калган. Оныгы Әхмәдсафа бине Мөхәммәдвафа да Казанда имам булып, 1286/1869 елда вафат булды. Һәммәсенең каберләре Казанда. Әхмәдсафаның остазлары Баймурад бине Мөхәррәм, Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим, Шиһабеддин әл-Мәрҗани һәм башкалар. Бохарага барып, ун елга якын вакытын уздырган. // [89]

---

[33] Бер элекке китап ахырында болай язылган: «Моны Габделгазиз бине Надир бине Ишбулад 1169/1756 елда Төреш авылында мулла Морадбакый бине Нурмөхәммәд мәдрәсәсендә Казан юлында язды». Аз гына мөнәсәбәте булганга, бу гыйбарәне бирегә язу муафыйк күрелде.

# ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

اوچونچی جزء　　　　برنچی جلد

« آثـــار »

ممالکمزده اولان اسلام عالملرینک ومشهور کیمسه‌لرینک ترجمه وطبقه‌لری، تاریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش بر کتابدر.

اوچونچی جزئی

صاحبی
رضاءالدین بن فخرالدین

المرء بعد الموت احدوثة　　یفنی ویبقی منه آثاره
فاحسن الحالات حال امرئ　　تطیب بعد الموت اخباره

« اوفا »

۱۳۲۰ سـنـه

Дозволено цензурою С.-Петербургъ 23 Октября 1902

Оренбургъ.
Типографія М.-Ф. Г. Каримова.
1903.

RUHIAT

## 95. Сөләйман бине Мостафа бине Юныс (Сүнәй) бине Ишали бине Ишанмыш бине Ханмирза бине Хантимер бине Каракай

Уфа шәһәреннән 40 чакрым көнбатыш тарафында булган Каршин Шәриф исемле авылда ахун булган. Бабалары, Нижгород шәһәренә караган бер авылдан күчеп килеп, ошбу авылда яшәгәннәр. Риваятьләргә караганда, Сөләйман ахун шөһрәтле галим, бик гайрәтле һәм вәкарьле булган. Вә үзе зур хөрмәт иясе булган кебек, борынгы галимнәрдән Әбү Мөхәммәд әл-Йәзидидәй угылларының да мәшһүр затлар буларак, хәтта аларның зур гыйлемгә ия булып картаюларын күреп, дөнья куйган. Хатыны 1237/1822 елларда исән булган.

Балалары: Габделкадыйр, Габделкаюм, Габдессаттар, Нәриман, Габделкаһир һ.б.

Габделкаюм исемле угылы Каршин Шәриф авылында укыту илә[34] мәшгуль булган. Хаҗ сәфәренә китеп, шунда вафат булган. Мөхәммәд исемле бер угылы калып, Казан төбәгендәге Үрге авылында имам булып, шунда вафат булган.

Габдессаттар исемле угылы Оренбург шәһәрендә Меновный мәчетенә имам булып, 63 яшендә 1257/1841 елда вафат булган. Мөхтәрәм бер зат булган, диләр. Остазы Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни. Вәлиэддин исемле угылы да үзеннән гыйлем алып, вафатыннан соң шул ук Меновный мәчетенә имам булган. Ун елдан соң, ниндидер сәбәп белән, 1268/1852 елда // [90] вазыйфаларыннан азат ителгән. Габдессаттарның Вәлиэддиннән башка Сәлахеддин, Габдулла исемле угыллары да булган.

Габделкаһир әдип һәм шагыйрь булып, Каршин Шәриф авылында 63 яшендә ваба авыруы илә 1247/1831 ел рабигыль-әүвәл/август аенда вафат булган. Хатыны Шәмсенниса да 63 яшендә 1256/1840 елда дөнья куйган.

Рәхмәтулла исемле угылы Оренбург шәһәрендә мөәззин вә Мөхәммәд исемле угылы Уфа янындагы Акбаш авылында мөхтәсиб булып, болардан башка Әхмәд вә Гобәйдулла исемле угыллары булган. Хәбибә исемле кызы Казарма авылында Мөхәммәдвәли ахунда, Гарифә исемле кызы Сәфәр авылында Юныс исемле имамда, кызы Фатыйма Уфа тарафларында мәшһүр булган Мөхәммәдшаһ ахунда (Солтанай авылында) булган. Габделкаһир әфәнденең туганы Габделкадыйрга язган шигъри бер хаты. [Төп нөсхәдә Р.Фәхреддин 1803 елгы хат текстын китерә.] // [93]

Мондый башка шигъри хатларын да күргән идек. Барчасы да гадәти хатлар рәвешендә язылганнар. Риваятьләргә караганда, иң ашыгыч вакытларында хатларын шулай шигъри итеп язган. // [94]

Бөре төбәгендә Мортаза авылында имам Мөхәммәдшакир әфәнде Сөләйман ахунга кагылышлы ошбу хатны язган иде: «Ишарәгезгә нигезләнеп, Каршин Шәриф авылына бардым. Хәзер бу авылда Сөләйман ахун нәселеннән Шәрәфеддин бине Шәмседдин бине Нәриман исемле зат имам. Авылның көньяк вә Кармасан елгасының көнбатыш тарафында иске каберлектә зур-зур иске ташлар бар. Болардан берсе якынча җирдән өч чирек аршын кадәр биеклектә, юынмаган гади таш булып, көнчыгыш тарафына бераз авышкан. Язуы батырылып язылган булса да, бик ачык укырлык түгел. Дүрт юлда болай дип язылган: 1) һәза мәркадь [бу кабер], 2) Сөләйман бине Мостафа, 3) вә зәүҗәтиһи Мөхиббә вә ибнәһума [хатыны Мөхиббә һәм угыллары], 4) Габделкадыйр.

[34] Бер кульязма китап ахырында мондый язма күрдем: «Моны күчерүче Гыйсмәтулла бине ахун Зөбәер, Уфа вилайәтенең Каршин Шәриф авылында Габделкаюм бине Сөләйман мәдрәсәсендә». 1806 елның 19 октябре.



RUHIAT

Ләкин ташның беренче һәм ахыргы юлларында берәр сүз чамасында таш уалып төшкән һәм өченче юлда хатынының исеме бик ачык укылмый. Мөхиббә булырга язуы да бик үк туры килми. Мөхиббәме яки түгелме – аңлашылып бетмәде. Әмма вафат вакыты язылмаган. Янә бу ташның көнбатыш ягында якын җирдә тагын бер таш бар, алты юл итеп, яхшы вә калкытып болай дип язылган: «Әл-мәрхүм әл-мәгъфүр Габделкаһир бине мулла Сөләйман, 63 яшендә, 1831 елда». Моңа якындагы тагын бер ташка алты юл итеп болай дип язылган: «әл-мәрхүмәтил-мәгъфүрә Бибишәмсеннисә, хәлиләти Габделкаһир [Габделкаһир хатыны], 63 яшендә, 1840 елда». Бу тирәдә тагын бераз зур һәм язулы ташлар булса да, түрәләр һәм кантон башлыкларының каберләре икәнлегеннән хәбәр алгач, язмадым вә язарга да хаҗәт күрмәдем».

Сөләйман ахун гаиләсе бәрәкәтле бер гаилә, аның балалары һәм нәселеннән мәмләкәтебездә һәр вилайәт вә һәр дәвердә олуг затлар чыгып торган. Кайберләре, инша Аллаһ, безнең бу әсәребездә дә телгә алыныр. Югарыда телгә алынган нәсел чылбыры Фәхреддин бине Нәриман кулы белән күчерелгән кулъязма «Тәнбиһел-гафилин» китабыннан күчерелде.

### 96. Әхмәд бине Хәсән бине Колмәмәт (Колмөхәммәд)

Саратов вилайәтендә Хвалынь төбәгендә Иске Мастак авылында имамлык вә ишанлык итеп, 1227/1812 елларда // [95] вафат булган. Сәгыйдь (Каргалы) бистәсенең Вәлид ишаннан ишанлыкка рөхсәт язуы алган.

### 97. Мәхмүд бине Мөхәммәделәмин бине Ярмөхәммәд бине Мамыш

Атасы: Мөхәммәделәмин 1155/1742 елларда исән-сау булып, бер хаҗәте өчен Петербург шәһәренә баргач, дәүләт тарафыннан «Фәтави Казыйхан», «Никайә шәрхе Шәмәни», «Сәххахел-Җәүһәри» китапларына, бүләк буларак, ия булганлыгын сөйлиләр. (Бу вакыйга Бөек Петр кызы Елизавета императрица вакытында булса кирәк.) Ул Казан шәһәрендә дөньяга килеп, атасыннан соң 7 нче җамигъ мәчеттә имам булган. Шәкертләр җыеп, дәрес әйтү белән мәшгуль булган. 1227/1812 елда вафат булган. Казан зиратында җирләнгән.

### 98. Габденнасыйр бине Әбеннасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсавый

Атасы Ибраһим 1205/1791 елда вафат булган. Анасы Миһербан бинте Әмин бине Мансур Максабаш авылыннан. Кыз карендәше Мәрхәбә Ибраһим кызы Мәчкәрәдә Габдулла бине Габдессәлам никахында булып, Гобәйдулла, Муса, Мөхәммәдҗан, Хөснибану исемле балалары дөньяга килгән. 1243/1828 ел ахырында вафат булган дип сөйлиләр[35].

Әбеннасыйр 1190/1776 елда дөньяга килеп, 37 яшендә 1227/1812 елның 10 рамазанда / 17 сентябрьдә вафат иткән. Вә бер хөрмәтле шагыйрьнең «Йәмүтү каумун вә лиәййәси ләһүм әхәд, Вә вахид мәүтиһи һум ли-икуам» шигыренә туры килгән. Моның вафаты илә Казан вә Болгар мөселманнары, бәлки, гомумән, ислам галәме зур бер галимнәрен югалтканнар.

Казанга якын Курса авылында дөньяга килеп, башлангыч гыйлемнәрне Малмыж төбәгендәге Мәчкәрә авылында өйрәнгән. Аннан соң Бохара шәһәренә ба-

[35] «Мәшһүр хатыннар» [Р.Фәхреддин әсәре] исемле әсәрдә дә телгә алына.

рып, олуг укымышлылардан дәресләр алды. Олуг шәехләр белән әңгәмәләшеп, күренеп торган һәм яшерен, шәкли һәм мәгънәви камиллекләргә ирешкән. Ватанына кайткач, җизнәсе Габдулла бине Габдессәлам угылларының ярдәмнәре белән зур мәдрәсәләр нигезләп, күп шәкертләр җыеп, гыйлем өйрәтте. 1222/1807 елда янәдән Бохара шәһәренә сәяхәт иткән вә кайтышлый Хивада тукталып, берникадәр вакыттан Әстерханга, вә аннан асыл ватанына әйләнеп кайтты. 1227/1812 елның шәгъбан/август аенда хаҗ нияте илә дусларыннан бер төркем илә бергә, Казаннан чыгып, Истанбулга баралар, вә анда ваба авыруы илә вафат булып, Искедарда солтан җамигында җирләнгән.

### *Остаз вә шәехләре*

Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Бохарада шәех Ниязкол бине Шаһнияз әт-Төрекмәни. Болардан башка да остаз һәм шәехләре күп булса кирәк.

Шәкертләре: Мөхәммәделәмин бине Сәйфуллаән-Наласавый, Ногман бине Әмир әс-Сәмәни, Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли, Хәбибулла бине Рәфыйк ән-Надири, Фәхреддин бине Хәбибулла әл-Хаҗитархани, Әхмәд бине Сәгыйдь әш-Шырдани, Надир бине Исхак әл-Камышлый, Таиб бине Зәид әл-Верхуралый, Зәйнулла бине Үлмәзкол әл-Калканый, Габдулла бине Әмирхан әл-Верхуралый, Җәмаледдин бине Шәмседдин әс-Сабавый, Габделмөэмин бине Фәез әл-Мишәви, Әхтәм бине Бикмөхәммәд әл-Ярмунчауый, Тимурбәк бине Вилдан әл-Куганакый, Габделгафур бине Габделмәҗид әл-Уфауый[36] һ.б.

Әсәрләре: 1) «Әл-иршад[лил-гыйбад]»; 2) «Китабел-ләуаих»; 3) «Шәрхел-гакаид ән-Нәсәфийәтил-кадим»; 4) «Шәрхел-гакаид ән-Нәсәфийәтил-җәдид»; 5) «Рисаләти исбатис-сыйфат»; 6) «Китабен-нәсаих»; 7) «Шәрхи мөхтәсарел-мәнар»; 8) «Хашийәтил-гакаидел-җәдид»; // [98] 9) төрки телендә «Һәфтияк шәриф тәфсире». Болардан башка кыска-кыска рисалә-әсәрләре бар. Сәгыйдь бистәсендә (Оренбург Каргалысында) замандашларыннан булган мөдәррис Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәнигә язган бер хаты ошбу[37].

Бу хатта Габдеррахман әл-Кирмәнигә махсус язылганлыгын дәлилләрлек нәрсә күрелмәсә дә, 1312/1894 елның 22 мөхәррәмендә / 26 июлендә Сабабаш авылында Тимерпулад бине Акчура өендә шәйхе Зәйнулла әл-Халиди хозурында, // [99] элекке казый Борһанеддин бине Насреддиннән ишеткәнемә таянып яздым. Ихтимал, бу хат Бохарада булган маҗарасыннан соң язылгандыр. Мөхтәрәм Мәрҗани белдерүенчә, «Китабен-нәсаих»та «әййуһа, әш-шәйх!» дип мөрәҗәгать ителгән зат Сәгыйдь бине Ибраһим әл-Барышый яисә Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни булырга тиеш.

### *Шәхси сыйфатлары*

Озын буйлы, киң маңгайлы, зур күзле, үткен сүзле, арык вә төз гәүдәле, табигате зирәк, зиһене камил һәм тугры, фәһеме дөрес, җавабы тиз, татлы телле, вәкарьле, ачык сүзле булган.

[36] Бу затны Бохарада гыйльми бәхәс мәҗлесенә Әбеннасыйрның үзе алып барганлыгын сөйлиләр. Арыслан авылы Хәлил бине Насреддин һ.б. остазы булган.

[37] Гарәп телендә язылган бу хатта Ходай Тәгаләнең куәте һәм кодрәте, аның сыйфатлары турында сүз бара. Дәлилләр итеп Мөхәммәд пәйгамбәр, мөселман фәкыйһләреннән Раббани, Тәфтазани сүзләре китерелгән. – *Төз.*

RUHIAT

*Дошманнарының бәяләмәләре*

Төрле урыннардан җыйганнарымнан ошбулар:

*Беренче*[38]. // [100] Имзалар:

1) Әмир Хәйдәр;
2) Казый Мир Зәйнеддин бине казый ишан Корбан Бәдәл;
3) Хуҗа Гатаулла;
4) Казый Гыйнәят;
5) Мөфти Әбеннасыйр Хуҗа;
6) Казый Мирза Фәзыйль;
7) Казый Мир Габдулла мөфти Җуйбар;
8) Казый Торсынбакый;
9) Казый Мирза Нигъмәтулла мөфти бине мирза Нияз Мөхәммәдгали;
10) Казый мирза Шәмседдин бине Миршаһ әл-Хөсәени;
11) Казый Ниязбирде;
12) Мөфти мирза Габдеррахман Әгъләм;
13) Мир Габдеррәхим Хуҗа мөфти Гаскәр;
14) Мөхәммәд Зыя мөфти;
15) Шәйхелислам Голүви мирза Рәхмәтулла Хуҗа бине Гатаулла Хуҗа Насыйри;
16) Мир Габдулла хуҗа әл-Хөсәени[39].

*Икенче*. Бохара шәһәреннән Болгар галимнәренә булган хат:

«Каргалыда һәм Казан вилайәтендә мәшһүр мөселман галимнәре вә укымышлылары бар иде. 1223/1808 елда нугай [татар] Әбеннасыйр мулла, гыйлемнәр башкаласы – данлыклы Бохара шәһәренә кайтып, бөек галимнәр һәм мөхтәрәм фәкыйһләр каршында үзенең ялгыш иманыннан баш тартты...

Шәйхелислам ахун Гатаулла Хуҗа мөфти, казый мирза Шәмседдин Хуҗа, мөфти мирза Габдеррахман Әгъләм».

*Өченче*. Казый Торсынбакый бине Габдеррәхим әл-Бохарый хаты: «Болгар вилайәтендә мәшһүр галимнәр һәм мөхтәрәм фәкыйһләр бар иде. Габденнасыйр исемле зат 1223/1808 елның сәфәр аенда гыйлемнәр башкаласында, шөһрәтле Бохара шәһәрендә әмир галиҗәнаплары һәм дин галимнәре каршында үзенең ялган, ахмак, динсез инануларыннан баш тартырга әзерләнде, һәм ул үлем җәзасына лаек иде. Ул диннән язганнар рухындагы сүзләр белән сөйләгән. Шуннан соң ул бу шәһәрдән качкан. Хәзер мәгълүм булды: ул яңадан үзенең ялган инануында икән. Ул, динсез, галим һәм фәкыйһләргә каршы килеп, аларны шелтәләгән, ә үзен мактаган. Үзенең җиңелүен ул яшергән. Вакыйгаларны тискәре итеп аңлаткан.

1225 ел, 22 җөмадиел-әүвәл/1880 ел, 14 июнь, дүшәмбе. // [102]

---

[38] Бу урында Курсавиның карашларын шәригатькә хилаф дип бәяләгән фарсы телендәге документ тексты бирелгән. – *Төз.*

[39] Күчерүчеләр сәбәбе беләнме, нидәндер, бу имзалар төрле рәвешләрдә язылганнар. Төрле нөсхәләрне бергә җыеп, мөмкин кадәр дөресләп язсак та, кайберләрендә һаман шөбһәдән азат булмадык. Кулларында ачык вә дөрес нөсхәләре булган затлар бу турыдан безгә аңлатма бирсәләр яхшы булыр иде.

### *Мөляхәзә [фикерләү]*

Әбеннасыйрның Бохарада булган бу маҗарасы безнең өчен караңгы. Чөнки кулыбызда монда язылганнардан вә кайбер риваятьләрдән башка чыганак юк. Хәлбуки, мәсьәләне әтрафлы белү өчен, хөкемнамәнең үзен күрү зарур. Әгәр дә Бохара шәһәрендәге архивтан шул эш алынып нәшер ителсә, мәсьәләне һәркем хәле җиткәнчә тикшереп, нәтиҗә чыгарыр иде.

Зур бер җәмәгать тарафыннан имза куелган хат хөкем мәҗлесенә вә казыйлар дикъкатенә бирелгән фәтванамәме, әллә хөкүмәт исеменнән чыгарылган асыл хөкемнамәме? Бу исә безгә һаман мәгълүм түгел. Әгәр дә бу бер фәтванамә булса, хөкүмәт башында утырган вә мәхкәмәләрнең [суд] гамәлләрен идарә итүче әмир ни өчен моңа имза куйган?.. Бу исә ни канун, ни шәригать буенча яраксыз бер эш. Чөнки патша фәтва (бәяләмә) биргән нәрсәләргә каршы хөкем итәргә берәр мәхкәмәнең кодрәте бармы?.. Һәм дә бу кәгазь анык бер фәтванамә булса, моны берәр мәхкәмә тикшереп хөкем игълан иткәнме? Итсә, нинди хөкем игълан кылган?!

Әгәр дә фәтванамә булмыйча, хөкемнамәнең үзе булса, монда Әбеннасыйр тарафыннан бирелгән җаваплар вә җавапларның хата икәнен күрсәткән дәлилләр һәм аннан соң хөкүмәт тарафыннан шәфкать белән бирелгән нәсыйхәтләр дә язылып; болардан бер нәтиҗә чыгу-чыкмаячагы мәгълүм булса, мәҗбүри бер хөкем игълан ителүе язылу тиеш иде. Хәлбуки бу кәгазьдә андый бер нәрсә дә күренмәде.

Адәм угылының абруе вә хөрмәте шулкадәр бөек ки, бер мөселманны кәферлектә гаепләү түгел, гади бер кешегә шелтә ясар өчен генә дә мәхкәмәләр тарафыннан сарыф ителгән чыгымнарның кайвакыт 20–30 мең сумнарга җитүен сөйлиләр.

Хәтта бер шелтәнең сүзе, урынсыз бирелмәсен өчен, кылны кырыкка ярырлык дәрәҗәдә тикшерелә, гаепле кешедән кат-кат җавап алына. Көн вә сәгате илә хөкем мәҗлесе билгеләнеп, иң зур мәхкәмәләр хозурында булган, университетларда гыйлем алган затлардан // [103] торган иң акыллы вә иң зиһенле бер җәмәгать дикъкать белән күздән кичерә. Моның өстенә күп вакыт хөкүмәт тарафыннан, акчасыз һәм бушка яклаучы адвокатлар куела. Моңа кагылышлы язулар һәм кәгазьләрнең очы-ахыры булмый.

Инде бер мөселманга шелтә түгел, бәлки, Алла сакласын, «кәфер, мөртәд булдың!» дип хөкем итү өчен никадәр дикъкатьле булу вә никадәр тикшерүләр кирәк булганлыгын һәркем үзе инсаф белән нәтиҗә ясасын!

«Кәфер булдың!» дию шәм сүндерү яки кием салу кебек җиңел бер эшмени?.. Болай дип әйтү «Җәнабы Аллаһының рәхмәтеннән мәңгелеккә сөрелдең!» дию булганга, гаять авыр һәм зур эш. Бу сүзне күтәрергә тауларның, ташларның көче җитмәс, җир вә күкләрнең куәтләре булмас.

Үткән заманнардагы изге кешеләр дәверендә кәферлектә гаепләү гаять зур гаеп саналган һәм шәригатьтән гайре каршылыкларга бөтенләй әһәмият бирелмәгән. Күп мөселманнарның каннары түгелүенә сәбәпче вә гайрәтле имам хәзрәти Гали әл-Мортазага (Аллаһ аннан разый булсын!) каршы килгән хәуариҗләләр хакында «Болар кәферләрме?» соравына имам хәзрәтләре «Юк! Дин карендәшләребез!..» дип җавап биргән.

Мөхәддисләр шәйхе Мөхәммәд бине Исмәгыйль (Аллаһ аннан разый булсын!) хәдис сөйләгән хөрмәтле остазлары арасында хәуариҗ, җәбрийә, шыйга, кадрия, могътәзилә мәзһәбләрендәге затлар булганлыгы инкяр ителми. Моннан аңлашылганча, борынгылар (Җәнабы Аллаһ алардан разый булсын!) бер кешенең газиз иманына кагылу түгел, хәтта бидгатькә нисбәт итүдән дә тыелганнар.

RUHIAT

Әбеннасыйрга каршы язылган хатларга бөек затларның катнашлары булуында шөбһә юк. Чынлыкта боларны гади кешеләр язган дип уйласак, бөртек кадәре дә әһәмият бирмәс идек, хәтта китабыбызга да кертмәс идек. Үзебездә булган бу кадәр зәһәрле хатлар вә ачы сүзләргә бер көлемсерәү белән // [104] Әбү Габдеррахман Хәлил бине Әхмәд әл-Фәрһуди әл-Издинең... шигырен укыган кебек, мондый бер каршылык белән канәгатьләнер идек. Бәлки, безнең боларны сөйләп фикерләребезне бәйан итүебез аларны бөек вә газиз затлардан санаганга.

Бу хатларны язучыларга җаваплылык йөкләмәвебез һәм аларга начар мөнәсәбәттә булмавыбыз аларны, кадәри хәл, изгеләрдән санаган хәлдә, әлеге хатларына тугры сүз дип тануыбызда зур шик бар.

Чынлыкта һәрбер бөек остаз дип ышанган затларыбызның дин вә шәригать исеменнән сөйләгән сүзләрен уйламый-тикшерми кабул итсәк, күп мәртәбә ике каршылыкны берләштереп расларга тиеш вә сукырларча иярүгә дучар булыр идек. Хәлбуки гыйлем бәхәс илә артыр, вә тикшерү нәтиҗәсендә бикле ишекләр ачылыр.

Фикеребезчә, бер шикне кире какканда канәгатьләнерлек вә дөрес дәлилләр китерелергә тиеш иде. Хәлбуки бохаралыларның Әбеннасыйрга каршы язмаларында җитди вә ышанычлы бер дәлил // [105] түгел, хәтта уйланырлык та берни күренми.

Берәүнең кәферлеге турында фәтва бирелү өчен, Алла сакласын, аның Мөхәммәд рәсүлулланы инкяр итүе кебек бер хәлдә булуы зарур түгелме? Һәм телгә алынган хатларда әһле сөннәткә нисбәт ителгән нәрсәләр хас мөселман булу өчен кирәкле игътикад-инанулармы? Әһле сөннәткә хас игътикадлар булса, катгый дәлилләр белән исбатланган нәрсәләрме? Болар борынгы инануларны саклый торган махсус мөселман әсәрләренең кайсысында телгә алынган?! Уйлавыбызча, боларны исбат итү җиңел түгел.

Инде ни дин ысулына, ни борынгы изгеләргә мәгълүм булмаган нәрсәләр турында гыйлем каласы һәм мактаулы шәһәр – Бохарадагы мөселман имамнары үзара җыелып, гыйлем сөючеләрне вә элеккеге изгеләрнең юлларын эзләп, «аһваһ» итеп йөрүче бичараларын кәферлектә гаепләп мөһерләр суксалар, мәмләкәтебездәге боларга керүчеләргә ни кала? Һәммәбезне дә Аллаһ яраткан, аның катына кайтабыз. Юкса мөселман имамнарының вазыйфалары туры килгән кешеләрне, сәбәпле-сәбәпсез, кәфер дип атау, шыйга, могтәзилә, бәдмәзһәб, ваһабийә кебек сүзләр белән пычрату һәм сүгүмени?

Җәнабы Мөхәммәд рәсүлуллаһ вә аның сахабалары, вә борынгы изге затлар тугры юлга өммәтләрен иманга яхшылык белән түгел, мондый кәфер дип атау белән чакырганнармы?

Асылсыз вә чыганаксыз, хосусан изге сахабалар һәм борынгы галимнәр әйтмәгән нәрсәләр турында мөселманнар бер-берсен сүгешсәләр, хәтта изге вә иң газиз байлык булган иманга кагылсалар, исламның яхшы һәм өстен сыйфатлары нәрсәдә калыр? Әһле исламның мондый мөгамәләләре Европа галимнәреннән мәшһүр бер затның: «Ислам бөеклек һәм өстенлекләрне туплаган бер дин, ләкин әһеле кыйммәтен тәкъдир итә белерлек // [106] камиллектән мәхрүм булганлыктан, бу газиз динне әрәм иткәннәр. Моны саклау исә европалылар җаваплыгында!..» – дигән сүзен раслау булып тора.

Мөхтәрәм философ шәйхе Җәмаледдин әл-Әфгани (аңа Аллаһның рәхмәте булсын!) хәзрәтләреннән «Ислам шәригатебезне пакьләү вә тазарту өммәт өчен иң беренче бурыч булган хәлдә дә, бу бурыч мөселманнар тарафыннан һаман үтәлми» дип ишеткән сүзләрнең серен, үкенечкә каршы, бик соң аңладым.

RUHIAT

Гакыл әүвәлгерәкме, сөйләмме?.. Мөселман галимнәреннән һәр ике тараф яклылар бар. Сөйләм белән гакыл, бер көймәнең ике ишкәге яки кошларның ике канаты кеби, кешеләр өчен зарур нәрсәләр булып, һәр икесенә ихтыяҗ бар. Сөйләм Җәнабы Аллаһының бер хикмәте булган кебек, гакыл да бер хикмәттер.

// [108] *Дүртенче хат.*

Казан ягындагы Оры авылында ахун Фәтхулла бине әл-Хөсәен тарафыннан мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәен угылының җәнабларына түбәнчелек илә без, Царевококшай округында Казаклар Орысында җамигъ мәчеттә указлы имам, мөдәррис вә мөхтәсиб мулла Фәтхулла Хөсәен угылыннан 1810 ел, 11 ноябрьдә язылды. Шул хакта, Казан округында Югары Курсада Габденнасыйр Ибраһим угылы мөҗтәһидлек [дини китаплар буенча яңа хөкемнәр чыгаручы] дәгъвасын кылып, Гомәр ән-Нәсәфи хезмәтенә шәрех язып, // [109] дүрт йөз елдан бу заманга кадәр килгән мөҗтәһидләрдән һәм изге галимнәрдән булган Тәфтазани, Дәвәни, Сәед Ширази һ.б. шундыйларны түбәнсетә. Мәдрәсәләр салдырып, шәкертләр җыеп, наданлык таратып, дәрес бирәмен, дип, мөселманнар иманын бозып, бидгать юлы вә түбәнлеккә тарта. Чөнки ничә кешеләр, аның мәдрәсәсеннән чыккач, әүвәлдән җомга һәм гаед кылып киленгән авылларга имам булып, мөселманнарны җомга һәм гаедтән мәхрүм иттеләр. Моның белән түбәнчелек илә белдерәбез: ул тугры юлдан адашучыга изге шәригатебезнең хөкемен чыгарып, мөселманнарны юлдан яздырудан тыйсагыз иде. Хезмәтләрегезгә күрә Аллаһның әҗер вә саваплары булыр иде.

### ***Мөляхәзә***

RUHIAT

Ахун хәзрәтләре бу хатларын 1225/1816 ел 25 шәүвәл/23 ноябрь, җомга көн язганлыгыннан, югарыда телгә алынган хатларны күргәч язылган булуы ихтимал. Ничек булса да, безнең уебызча, // [110] бу хат мантыйк кагыйдәсенә тулаем муафыйк язылган.

Ахун хәзрәтләренә хөрмәтебез күп булып, хатының матурлыгын да таныган хәлдә, кайбер шөбһәләребезне язудан каләмебезне тыя алмадык. Чынлыкта шөбһәләр бөек остазларга яки акыллар хәйран калырлык әсәрләргә каршы язылыр. Моннан башкаларга шөбһә белдерү кырмыска оясына таяк тыгып туздыру кебек файдасыз бер эш.

Бу хатны алганнан соң, мөфти әфәнде нинди чара күргәнлеген бик беләсебез килсә дә, Диния Нәзарәтенең мондый иске кәгазьләре, кызганычка каршы, юкка чыкканлыктан, аларны күрү насыйп булмады. Уфа шәһәре тирәсендәге авылларда Мөхәммәдҗан мөфтинең китап һәм җыентыклары булырга мөмкин дип уйланылган җирләрдә дә, өметләнеп йөреп тә, һичбер нәрсәгә тап булмадык.

Ахун хәзрәт әйткән кебек, Әбеннасыйр чынлыкта да мөҗтәһидлек дәгъвасын кылган идеме? Мөҗтәһидлек дәгъвасында булганлыгын үзеннән ишетеп яки берәр китабыннан алса, бу җөмләсенә бер сүз дә юк. Әмма әгәр дә арадашчылар белән килгән хәбәрләргә нигезләнсә, дөрес бер дәлил дип ышанырга ярамый. Фәтхулла ахун заманында булган кешеләр түгел, аннан күпмедер гасырларга элек язылган күп китапларда телләренә түгел, хәтта күңелләргә килмәгән нәрсәләр дошманнар сөйләвенә таянып язылганлыгы тарих белән исбатланган.

Мөселманнар арасында булган каршылыкларның сәбәбе мондый рәвештә, сөйләүләрендә игътибарсыз вә күпертергә яратучы кешеләрнең хәбәрләренә ышану, үзләреннән турыдан-туры ишетелмәгән яки билгеле булган шартлар белән сөйләнмәгән дәлилләрен хак дип белеп китапларга язу, хәтта күпчелек заманнарның хөкемдар вә вәзирләренең сәясәт һәм нәфис максатлары өчен оеш-

тырылган ялган, ялаларга ышану булганлыгы тикшеренүчән, төпченүчән затларга мәгълүм. // [111]

Кайвакытта сөйләнә торган сүзнең башы һәм ахыры дөрес аңланмаганлыктан яки язма нөсхәләренең бозыклыгыннан тиешле сүз тулаем киресенчә сөйләнер. Китабында күрелмәгән, шулай ук урынында бәйан ителгән шартлар илә сөйләнмәгән сүзләргә һәркем ышана алмый.

«Әбеннасыйр, әлбәттә, мөҗтәһидлек дәгъвасын кылгандыр, чөнки Фәтхулла ахун кебек галим вә тугры кеше белмичә әйтмәс һәм игътибарсыз сөйләмәс дисәк, саф фикерләребез илә дошманнар файдасына сөйләгән булырбыз. Хәлбуки мондый чакларда яхшы фикердә булу гына үзен акламый. Чөнки адәм баласы гөнаһсыз булмаган кебек, белмичә сөйләве дә, игътибарсызлыгы да мөмкин. Мөселманнарның иң бөек галим вә иң мәшһүр философларыннан берсе – философларның башлыгы булган Әфләтун, хәзрәти Гайсәнең чакыру-өндәве ирешкәч, «без тәрбияле кешеләр, тәрбия итүчеләргә хаҗәтебез юк дигән» мәгънәсендәге бер сүзне җиткерә.

Һәркем өчен Коръән вә хәдисе шәрифтән дәлилләү фарыз диюеннән дә Әбеннасыйр мөҗтәһидлек дәгъвасында булганлыгы аңлашылмый. Чөнки мондый дәгъва илә мөҗтәһидлек арасында уртаклык юклыгы мәгълүм. // [112]

Әбеннасыйр мөҗтәһидлек дәгъвасын кылган булса да, аның бу дәгъвасы ни җәһәттән гаеп санала соң? Юкса мөҗтәһидләр яңгыр кебек күктән явалармы яки мәрҗән кебек диңгездән чыгалармы? Әгәр дә һәркемгә мәгълүм булган гади кешеләр арасыннан чыксалар, гыйлем өчен көне-төне тырышкан, гарәби гыйлемнәрне дә камил белгән хәлдә, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләреннән башка һичкемнән, хәтта Бохара падишаһының солтанәтле мәҗлесендә курыкмыйча үзенең хаклыгын белдергән бер затның мөҗтәһид булуында яки мөҗтәһидлек дәгъвасы кылуында гаепләнерлек ни бар?!

Мөҗтәһидлек дәрәҗәсе, изге вә бөек вазыйфа булып, һәр заманның вә һәр вилайәтнең иң сирәк затларына насыйп булып килгәнлеген инкяр итмибез. Ләкин ничек кенә булса да әйткәннәребез камиллегенең вә Алла мәрхәмәтенең җир йөзеннән аерылган яки Болгар һәм Казан мөселманнары моннан мәңгелеккә мәхрүм торачакларын ахун хәзрәтләре дә дәгъва итмәгән булса кирәк. // [113]

Тәфтазани, Дәвәни, Сәед Шәриф Ширази үз заманнарына күрә һәрникадәр сирәк галимнәр булсалар да, инануыбызча, гөнаһсыз булмаганнар. Сөйләгән сүзләре дә илаһи вәхи булмаган. Әсәрләре һәм хезмәтләрендә дә, күп булганлыктан, кайбер вакытта кире кагылырлык яки хурларлык сүзләре булуы гаҗәп түгел? Хата һәм ялгыш сөйләүдән азат булу – аз кешеләргә насыйп була. // [115]

Мәдрәсәләр салдырып, белемсез шәкертләрне җыйнауда нинди зыян булуы безгә аңлашылмый. Шәригатебез буенча, белгәнне өйрәтү, белмәгәнне өйрәнү фарыз дип беләбез.

Берәүнең мәдрәсә салдыруы һәм шәкертләр җыеп укытуын ахун хәзрәт кебек галим һәм мәгариф сөюче бер зат, килешле эш дип күрмичә, шикаятькә лаек тапса, башкаларга ни кала?

Әй мөхтәрәм остаз! Мөбарәк авызыгыздан чыккан сүзләрегезне вә каләмегездән түгелгән әсәрләрегезне ишетү вә күңелләренә салып ятлау өчен дәвамчыларыгыз бер-бере белән ярышып йөгерешүләре, һәрбер хәрәкәт вә гамәлләрегезне үрнәк итеп тотарлык изге дип санаулары, бөек исемегезне мактап искә алган хәлдә, каләмегезгә нәрсә булды да, ник мондый зәһәрләргә батырдыгыз? Әхлак төзәтү вә милләт тәрбияләү юлында башкаларга үлчәм һәм үрнәк булырга лаек булган коралыгыз ни өчен болай кимсетү коралы һәм ялган булды?!

RUHIAT

Мәктәп бина итү вә шәкерт җыюны гаепләгән затларны «нишләсеннәр бичаралар, белмиләр!» дип гафу итүчеләр, мондый сүз өчен хәзрәтләрегезне гафу итәрләрме? Итмәсләр дип уйлыйбыз. Чөнки сез беләсез, һәм дә башкаларга караганда бик яхшы беләсез! // [116]

Әй газиз остаз! Боларны язуымнан максат, Алла сакласын, шаныгызны кимсетү түгел. Мактаулар булсын ки, минем гаҗиз каләмем Сезнең кебек бөекләргә түгел, хәтта иң кечеләргә болай кимсетү гамәлендә булганы юк. Бу җәһәттән каләмемнән разый вә канәгатьмен. // [119]

### *Башка әхваль вә әсәрләре*

Мәчкәрә мәдрәсәсендә вакытында атасы Ибраһим вафат итү илә яшьли ятим калган. Укуында гаять оста булып, кайбер мәсьәләләрдә остазының аңлатуына канәгать булмыйча, шул заманда гыйлемнәр мәркәзе һәм мәгърифәт чишмәсе саналган Бохара шәһәренә сәфәр иткән. Андагы гыйлем әһелләре арасында бик тә алга киткән кәлям гыйлеме илә шөгыльләнүдә гадәттән тыш остарган, остазларыннан чакрымнарга алга киткән.

Аннан һәрбер инану вә гамәл хакында җавап бирәчәк бер көн барлыгын хәтеренә китереп, өмет итәргә лаек нәрсәләре булып-булмавын белү өчен үз инануларын тикшергән. Ул вакытта хәзинәсендә булган нәрсәләре нигезле булмаганлыгын күреп бик хәсрәтләнгән һәм, юнан [грек] фәлсәфәсенә[40] бирелеп, Коръән, рәсүлулла сөннәтен тикшерергә керешкән. Иманны боларга ноктага-нокта иярү өчен барлык гайрәтен сарыф иткән, шуның аркасында Коръән вә хәдис гыйлемнәрен тирәнтен өйрәнеп белүгә ирешкән. Изге тәфсирчеләр, олуг хәдис галимнәре һәм суфыйларның әсәрләрен укып, бик күп файда хасил иткәнлеге мәгълүм.

Бохара шәһәрендә могтәбәр шәехләрдән Мөхәммәд Ниязколый әт-Төрекмәнигә кул биреп, аннан дүрт ел гыйлем алып, шәһадәтнамә алып аерылышкан. Асыл ватанына кайтып, укыту, иҗат һәм шәкертләр тәрбияләү белән шөгыльләнгән. 1222/1807 елда Курсадан янә Бохарага барып, андагы галим-голәма белән дини һәм гыйльми бәхәс-әңгәмәләр корган. Аларга дин исеменнән фәлсәфи хезмәтләр ярдәмендә Коръәнгә вә Мөхәммәд рәсүлулла хәдисләренә ябышу мөмкинлеген белдергән. Ләкин бу гамәле үзенең зур бәлаләргә төшүенә сәбәп булган.

Әбеннасыйр үз карашларын көннән-көн куәтләве һәм гыйлем әһелләре булган яшь шәкертләр арасына таратып, һичкемнән хәвефләнмичә, зур кыюлык белән үз максатларын белдергәнлектән, дошманнары тарафыннан иманы төкәнгәнлеге игълан кылынган. Моның нәтиҗәсе исә, әмир хозурында рәсми бәхәс мәҗлесе тәшкил ителеп, шунда тикшерүгә карар бирелүдән гыйбарәт булган.

Әбеннасыйр мәҗлесләрдә саф фикер, буш гайбәтләрдән бер файда чыкмаганын ачык белгән, мондый мәртәбәле бәхәс мәҗлесе корылуына шатланган. Бичара! Мәҗлестә дәгъва һәм җаваплар гаять тыныч бәйан ителер дип уйлаган. Шуңа күрә, иркенләп сулыш алып, солтанәтле бу мәҗлестә максатын камил сабырлык вә вәкарь белән аңлаткан. Ничә еллардан бирле тәртипләп сөйләүдән гаҗиз булган максатын да тирәнтен аңлатып, дошманнарының шөбһәләрен нигездән вәйран иткән.

[40] Хәзерге замандашларыбызның, европалыларда нәрсә ишетсәләр дә, тикшерми-нитми кабул итүләре кебек, габбаси хәлифәләре дәверендә дә юнанлыларда тәрҗемә ителгән нәрсәләрнең барчасын шул заман яшьләре һәм яңалык тарафдарлары кабул иткәннәр, хәтта дин исеменә дә баглаганнар. Кәлям китапларындагы дөнья яратылышы, сыйфатлар, холык-фигыльләр мәсьәләләре һ.б. шундыйлар хәрефкә-хәреф юнаннардан алынган.

RUHIAT

Ләкин кайбер үзсүзле затлар Әбеннасыйрның мондый ыклыгын һәм фикри тотрыклылыгында булган осталыгын кабул итмәгәнлектән, сорау һәм җавабы бер тарафка чыгарылып, мәҗлес тәмамланган. // [121]

Әбү Госман әл-Мазиныйның «Үз мәзһәбемә таянып җавап бирдем, дошманнарым да, үз мәзһәбләренә нигезләнеп, мине хаталануда гаепләделәр» дигәне кебек, Әбеннасыйр тарафыннан хата дип белдерелгән сүзләр белән үз сүзләре үк хата һәм бидгать дип белдерелгән.

Мондый фетнәләр адәм баласына кайвакыт килә. Моннан ун гасыр элек бөтен ислам галәменә остаз булган шәех, хәдис галиме Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохарый (Аллаһ аннан риза булсын!) да мондый бер бәлагә туры килгән.

Сөйләүләренә караганда, элегрәк заманда Әбеннасыйр хакында язылган фәтва кәгазьләре вә башка хатлар безнең мәмләкәтебездә күктән иңгән вәхи яки ләүхелмәхфуздән күчерелгән бер нөсхә кебек ышанычлы хисапланган. Ләкин хәзер мондый кәгазь вә мөһерләрнең бөртек кадәр дә куәте вә үрмәкүч тозагы хәтле дә нигезе юклыгын һәркем аңлый.

Бәхәс маҗарасыннан соң ул, шәехе Мөхәммәд Ниязкол әт-Төрекмәни васыятенчә, Бохарадан киткән.

Бу зат хакында мөхтәрәм Мәрҗани түбәндәгеләрне язган: «Әбеннасыйрның гыйлемен вә камиллеген мактаучылардан Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә күп теләктәшләрен күрдек. Казый Әбессәгыйдь әс-Сәмәрканди (Сәмәркандтә 1265/1849 елда вафат) Әбеннасыйрны мактаганда бик зурлый, Болгар вилайәтеннән баручылардан аның хакында сорашыр иде; казый Рәхмәтулла (Бохарада 1263/1847 елда вафат) бине Габдеррәхим «Әбеннасыйр Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән тәүфыйк алган бер бәндәсе иде, ләкин, ни чара, аның сүзен аңларлык куәт безнең галимнәрдә булмады» ди иде.

Әбеннасыйр саф, борынгыларча иманда иде, ләкин замандашлары көнчелектән һәртөрле ялалар яктылар. Заманасында тиңдәше юк иде димим. Болай дип әйтү аның дәрәҗәсен төшерү булыр иде. Бәлки гакълый гыйлемнәрдә осталыкта, мәзһәбләр һәм төрле агымнарны белүдә, әдәп һәм бәхәстә, хәдис ятлауда, изге хәдисләрнең бүленеш һәм төрләрен аңлап белүдә, көчле тырышлыкта якында да, еракта да аның кебек камил затны бу заман күзе биш йөз елдан бирле күрмәгән иде. Әгәр дә гомере булса, элекке һәм соңгы заман галимнәрен берләштерүчеләрдән берсе булыр иде. Хәлбуки, кырык яшенә ирешмичә вафат булган хәлдә, заманасында булган адәм балалары арасында тиңдәше юк иде. Мондый камиллеккә ирешкән хәлдә күп гыйбадәтле, тәкъва вә диндар, // [123] бидгатьләрдән сакланучан, әүвәлге һәм хәзерге буыннарга тугрылыклы бәндәләрдән иде».

### *Ихласлы дусларының бәяләмәләре*

Ногман бине Әмир әс-Сәмәни: «Гыйлем әһелләреннән күп затлар Әбеннасыйрны Мөхәммәд галәйһиссәлам тарафыннан шатлыклы хәбәр бирелгән мөҗәддидләрдән [яңалык кертүчеләрдән] дип ышаналар иде. Әбеннасыйрның зиһене төгәл, Коръән һәм сөннәт гыйлемнәренә оста, тырышлыгы зур иде», – дигән.

Әхмәдҗан бине Әмирхан әл-Ушмавый, аның вафат хәбәрен ишеткәч, чиктән тыш кайгырган.

Габдеррәшид әфәнде бине Гомәр әс-Себери сөйләвенчә, Тобол вилайәтендә Хуҗамвирде исемле галим кыска төннәрдә ястү намазы фарыз түгел дип ышанып, бу хакта никадәр нәсыйхәт кылсалар да, никадәр китап һәм язмалар китерсәләр дә, һич тә канәгать булмаган. (Бәлки, «Фәтхел-кадыйр» китабы күрсәтелмәгән яки нөсхәсе булмагандыр.) Бервакыт Әбеннасыйр хезмәтен (фикеремчә,

«Әл-иршад...»тыр) китергәч, озак һәм дикъкать белән укып, «инде әүвәлге карашыма тәүбә иттем, калган намазларымны үтәячәкмен, бу китап мине канәгатьләндерде» дигән һәм һәрвакытта Әбеннасыйрны олылаган, мактаган.

Габделхәбир бине Габделваһаб әл-Мөслими: «Әбеннасыйрда булган гыйлем, сәләт чиксез булганга, илаһи бәрәкәт булганлыктан, остазларын уздырган», – дип сөйләгән.

Низамеддин бине Сираҗеддин әс-Сәлими Әбеннасыйрны мактап һәм дәгъвасының да фәкать савап икәнлеген бәйан иткән.

Шәех Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли (Аллаһның рәхмәтләре булсын!), аны бик хөрмәтләп, шәкертләренә Курсавыйның «Гакаиде Нәсәфийә» китабына язган шәрехен укыткан.

Чалпы авылында булган олуг мөдәррис Галибай бине Ярмөхәммәд Әбеннасыйрның гыйлемен зурлаган вә шәкертләренә «Мәнар шәрхен» зур ләззәт белән укыткан. // [124]

Күчерелгән бер нөсхәсендә күргәнемчә, шәехе булган Мөхәммәд Ниязкол әт-Төрекмәни, Курсавыйга фарсы телендә язган хосусый хатында беркадәр вәгазь вә нәсыйхәтләр биргәч, бик хөрмәтләп үзе һәм нәселе өчен хәер-дога сораган.

Бохарадан чыгып асыл ватанына кайтканда, Хива аша үткәндә, андагы галимгоәма яхшылап каршылаганнар. Хива казые тарафыннан гыйлем вә диянәте, мәгърифәт вә камиллеге сыйфатлы бирелгәнгә күрә, хаким тарафыннан аерып хөрмәт күрсәтелгән. Затлы бүләк киеме кидерү белән бергә ике йөз алтын бүләк итеп бирелгән. Хивада мөдәррис буларак калуын сорасалар да, авыр тормышта булган анасын күрергә теләвен белдереп гафу үтенгән.

Без дә үз гомеребездә Курсавыйны гыйлем вә мәгърифәт, хөрмәт һәм һидайәт (тугры юл) иясе булганлыгын танып, күркәм иманын олуглаган күп намуслы затларны күрдек. Болар: шәйхе Зәйнулла бине Хәбибулла әл-Халиди, мөхтәрәм Галимҗан бине Мөхәммәдҗан әл-Баруди, ахун Хәйрулла бине Госман әл-Уфавый, казый Борһанеддин бине Насреддин, Хәбибулла бине Харис әл-Эстәрли, Хуҗаҗан бине Җарулла әс-Сатышый һ.б.

***Аның хакында булган хатлардан кайберләре***

1. Әбеннасыйр әл-Курсавый гыйлеме зур, хөрмәте бөек, фикере үткен, фәһеме ачык, сүзе үткен кылыч кебек, дәлиле исбатлы, җавабы сүздән туктатырлык, катгый карашлы бер зат булган. Аны исә лаек дәрәҗәсендә мактау һәм олуглаудан вә аның хакындагы хисләремне бәйан итүдән каләмем һәм телем гаҗиз.

Ниязмөхәммәд бине Сөләйман бине Габделбакый бине Сөләйман. Петропавел шәһәре.

2. Әбеннасыйрның «Гакаиде Нәсәфийә»гә булган шәрехен укыдык. Озын сөйләү вә кимчелекләрдән саф булып, тугры гына борынгылар карашына муафыйк язылган. Тәфтазани кебек, гакыйдә-ининуны какшатырлык // [125] сурәттә фәлсәфә катыштырмаган һәм Мәрҗани кебек авыр сөйләмәгән. Сөйләгән сүзләре бөекләргә лаек. Тәкъва бер зат булса кирәк. Ләкин җентекләп тикшерү һәм төгәллектә Мәрҗани дәрәҗәсендә күренми. Ихтимал, инсаф һәм суфыйлыгы моннан беркадәр тыйгандыр.

Мөхәммәдсабир бине Мөхәммәдҗан әл-Хәсәни.

Тройски шәһәре. // [128]

### *Мөляхәзә*

Моңарчы сөйләгәннәребездән Әбеннасыйрның кем икәнлеген без һаман белә алмадык. Чөнки барлык сөйләгәнебез дуст яисә дошманнарының фикерләрен күчерүдән гыйбарәт. Әгәр дә кайберәүләрнең сүзләренә һәм мактауларына таянып, ихласлылык зарур булса, икенчеләренең сүгүләренә күрә нәфрәтләнергә тиешбез. Шуңа күрә без Әбеннасыйрның үзен турыдан-туры тану теләгендәбез. Фәкать мондый бер максатка ирешү насыйп булырмы?

Кешенең уку һәм кәсеп, омтылыш һәм тырышлык белән теләгәненә // [129] ирешү – Алла мәрхәмәте. Ходай кайбер бәндәләренә рәхимлек күрсәтер, ә кайберәүләр кайчак мондый мәрхәмәттән мәхрүм калыр һәм моның өчен гаепле булмыйча, үзенә йөкләнгән вазыйфасын үтәү белән генә макталыр. Бу сәбәп өчен без дә Әбеннасыйрны тану һәвәсенә төштек. Ләкин аны белүдән әүвәл, аның карашларын вә сөйләгән фикерләрен аңлау зарур. Боларны белгәннән соң, Әбеннасыйр үзеннән-үзе беленер, танылыр.

Курсавыйның карашлары белән танышу нияте белән ике-өч әсәрен газета вә журналлар, яраткан әдәби китаплар кеби түгел, бәлки тагын да күбрәк дикъкать белән укыдык. Моның өчен вакытларның иң тынычларын сайлаган кебек, һәрникадәр даими кайгыру һәм эч пошу белән шомлансак та, күңелләребезнең беркадәр хуш вә шатлыклы чакларын да ихтыяр иттек.

Хасыйл булган нәтиҗәләребезгә күрә бу әсәрләр җитди, куәтле буларак, «ни Зәет сүзенә муафыйк булсын һәм ни Гомәр сүзенә каршы булсын»[41] өчен язылмыйча, ачык вә тугры хаклык өчен язылганнар. Укыган кешеләрнең күңелләрендә Аллаһны олуглау, Мөхәммәд рәсүлуллага мәхәббәт хисе уяныр, дәрәҗәярату, тәкәбберлек, ызгыш кебек нәрсәләргә нәфрәт хасил булыр. Шуңа күрә Курсавый үзе дә өммәт өчен хәер хаһ (изге теләктә) булган һәм, халыкны тугры юлга күндерүдә тырышлык күрсәткән бер зат булып, борынгылар мәзһәбенә хезмәт иткән һәм аны яклаган.

Әгәр дә берәр кеше минем фикеремә каршы сөйләсә һәм дәлил белән исбатласа, минем, әлбәттә, һич дошманлыгым булмас. Бу дөньяда кешеләрнең фикере хөр вә һәркемнең вөҗдан вә инсафы зур булганга, һичкем беркемнең фикеренә буйсынырга бурычлы түгел. Ислам хөкеменә күрә иярү фарыз һәм барлык фәрманнарына карышмыйча буйсыну зарур булган нәрсәләр фәкать хак юлны күрсәтүче Коръәни Шәриф вә юлбашчыбыз булган хәзрәти Мөхәммәт саллал-лаһу галәйһи вәссәллам җәнаплары.

Вә тулаем Әбеннасыйр мәмләкәтебезнең сирәк вә бәһале галимнәреннән булып, тарих китапларында «гомерләре кыска булганнарның гамәлләре озын» дип искә алынган, илләр яулау остасы Искәндәр Руми, ислам хәкиме Ибне Баҗҗәһ, фарсы һәм гарәп философы Ибнел-Мокаффәгъ, шәех Сәйбәвийә, шагыйрьләр падишаһы Әбү Тәммам, баһадир вә сәясәтче Әбү Мөслим әл-Хөрасани, әһле кәлям остазы Ибраһим ән-Низам кебек мәшһүр затларга беркадәр охшаган. Болгар дәүләте ислам динен кабул иткәннән соң әсәрләре зур игътибарда булган зат Курсавый булган кебек, Казан мөселманнарының (әгәр тиешенчә тырышлык булса) гыйлемдә камиллеккә ирешерлек хәлдә булуларын исбат иткән мисал да шушы зат. Барлык хезмәтләрен бастырып чыгару милләтебез өчен бер горурлык булса да, мондый эшләр зур байлык белән саф гыйлемгә ихтыяҗ бар чакта гына мөмкин булганга, вакыты һаман да җитмәгән әле. Күп галимнәребезнең кыйммәтле булган гомерләре дошманлык вә мәгънәсез низаглар белән үткән кебек,

RUHIAT

[41] Гарәп әйтеме.

никадәр байларыбызның мөлкәтләре дә хатыннарга ука-чук асудан артмый. Юкбарга акчалар исәпсез-сансыз бирелгән хәлдә, яхшы бер әсәрне нәшер итү яки гыйлем вә мәдрәсә юлына сарыф итәр өчен акча табу – иң авыр бер эш.

Кайбер мөхтәрәм затларга сукырларча ияреп, шәкертлек вакытында Әбеннасыйрга карата яман фикердә идем. Соңрак, Аллаһының тәүфыйгы аркасында, бөек затларның вә исламны яклаучыларның әсәрләрен уку насыйп булды. Шул вакытта, Курсавыйның бөек шанын аңлап, әүвәлге фикеремнән аерылдым. Яман фикерем сукырларча иярү нәтиҗәсе буларак, яхшы фикерләрем тырышлык вә төпченеп тикшеренүләрем нәтиҗәсе булды. // [131]

### 99. Рамазан бине...[42] әл-Болгарый

Фәезхан бине Хозырхан әл-Кабулиның эшен дәвам иттерүче. Асылы Болгардан булып, Бохарада яшәгән. 1228/1813 елда вафат булган. Суфый, тәкъва бер зат булып, үзен Бохара халкы ихластан хөрмәт иткәнлеге вә ышанулары мәгълүм.

### 100. Әхмәдҗан бине Әмирхан бине Кучкар бине Ягъкуб

1202/1788 елдан соң Малмыж төбәгендә Сасна авылында дөньяга килеп, гарәпләрнең «изге затлар кыска гомерле» дигән мәкальләрендәгечә, 28 нче яшендә, 1229/1814 елда Ушма авылында вафат булган. Гыйлемне атасы Әмирхан бине Кучкардан алган.

Шәкертләре: Габделмөэмин бине Фәез әл-Мишәви, Габделҗәлил бине Үтәкол әл-Үтәки, Ибраһим бине Ярмөхәммәд әл-Чалпыуый, Мөхәммәдвафа бине Габид әл-Мактамауый һ.б.

Хезмәтләре: «Сәнийәтүл-бәшарә фи сәнийәтил-ишарә», «Фәтхел-җәлил фи сәнийәти тәсвимел-гамаим фи җәмигыль-әхваль», «Рисаләти фил-җөлус билхилька», «Рисаләти фи сәнийәти ибтидаит-тагам бил-милк», «Рисаләти фи иннә кыйраәтил-Коръән бил-әҗрәти бидга», «Рисаләти сәнийәтил-вакъф гыйндә раәсә күлли айәт» һ.б.

Хәдис вә сөннәт гыйлеменә хезмәт итүгә сөенеп керешсә дә, кызганыч ки, гомере кыска булды. Хәлбуки азын гомер сөргән затлардан күбрәк ядкәр калдыруга һәм үзен могтәбәр авторлар янәшәсенә куюга иреште.

Хезмәтләре гарәп телендә, кимчелекләрсез язылганнар. Фәкать Гали әл-Карый әсәрләре белән бик мавыкканлыктан, аңа ияреп сәҗгы [рифмалы проза] белән артык шөгыльләнүе гаеп дип исәпләнергә лаек.

Габдеррәфигъ бине Таеш ән-Нөркәйинең Фатыйма исемле кызына никахланса да, зөфафка кадәр вафат иткән. Моның кебек заманының мөхтәрәм вә сирәк затларыннан булган угылының вафатына атасы Әмирхан хәзрәт гаять хәсрәтләнгән // [132] вә күп еллар буе кайгыдан дөнья ләззәтен күрмәгән. Чынлыкта да мондый өметле вә милләт хезмәтен күрерлек кешенең болай яшь килеш туфрак астына кереп югалуы атасы өчен генә түгел, бәлки барча гыйлем әһелләре өчен зур югалту.

Үзе риялык вә тәкәллефне белмичә, барлык эшендә тугрылык һәм хак сүзлелекне ихтыяр иткән.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Никадәр яшь булса да, гыйлемлеге белән мәшһүр иде, хәтере куәтле иде, китаплар язды, күп нәрсәләр ятлаган иде,

[42] Төп нөсхәдә шулай. – *Төз.*

хәтта ки, дүрт мең хәдис ятлаганлыгын сөйлиләр иде; фәһеме тугры, зиһененең дөрес икәнлегенә иҗат иткән хезмәтләре шаһит. Әгәр дә гомере булса, гыйлем өлкәсендә, әлбәттә, олуг бер эше булыр иде», – дигән.

Мөхтәрәм әтиемнең ир кардәше Фәхреддин бине Сөбханкол белән дуслыклары булган кебек, яшь вә гыйлем җәһәтеннән дә кордашлар иде. Әмирхан бине Кучкар илә Сәйфеддин бине Әбүбәкер әс-Сабавый боларның гыйлемнәрен чагыштырганда, Әхмәдҗан хәзрәтне өстен куйган хәлдә, Әмирхан Фәхреддин бине Сөбханколны өстен куюы мәгълүм.

Ул никахланган Фатыйма Габдеррәфигъ кызы, Әмирхан хәзрәт ишарәсе буенча, шәкерте булган Хәбибулла бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәвигә кияүгә чыккан. Хәзер исәндерме-юктырмы, белмим. Хәбибрахман исемле бер угылы Минзәлә төбәгендә, Зәй елгасында Кызыл Чапчак авылында имам, Мәхбүбрахман исемле икенче угылы шул авылда мөәззин булган. Болар күптән вафат иткәннәр. Габдеррәфигъ бине Таеш Вәлид бине Сәгыйдь (кара: 85) тәрҗемәи хәлендә телгә алынган зат.

Әхмәдҗан хәзрәтнең нәсел шәҗәрәсендә кайбер затлар, Ягъкуб урынына Нәриман дип язылса да, Үтәк авылында имам Хәбибеннәҗар әфәнде ачыклавына нигезләнеп, Ягъкуб дип язылды.

### 101. Сәгыйдь бине Ибраһим бине Габдулла бине Габделгафур әл-Барышый

Казан төбәгендә Кышкар авылында имамлык һәм дәрес әйтү белән мәшгуль булып, 1229/1814 елда вафат.

Остазлары: атасы Ибраһим (кара: 52) бине Гобәйдулла, Ишнияз ахун (кара: 60) бине Ширнияз һ.б. Җирнең түгәрәк икәнлеге хакында бер китапчык язып, // [134] балык, үгез өстендә торуы хакындагы кыйссаларны ялган-уйдырмалардан санаган.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Олуг вә галим, изге булып, заманасының сирәк адәмнәреннән иде», – дип язган. Шәмседдин исемле угылы Иске Кишет авылында имам булып вафат итте, кабере шунда.

### 102. Габделвәли бине Сәгыйдь бине Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Казаный

1230/1815 елда Бохара шәһәрендә вафат. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Үткен зиһенле, олуг зат иде. Камил шәхесләр һәм туганнары арасында иң абруйлысы иде; Әбеннасыйр Курсавыйны ихластан олуглаучы вә һәрвакытта әдәп һәм хөрмәтен саклар иде; аның хезмәтләренең күбесен җыйган иде», – дигән. // [135]

### 103. Габделкәрим бине Габдулла бине Солтан әл-Чалпыуый

Бабалары Казан вилайәтендәге Норма авылыннан. Үзе Бөгелмә төбәгендәге Чалпы авылында имам вә мөдәррис булып, 1230/1815 елда вафат булган. Мәгърифәт һәм олуглык белән шөһрәте булып, заманының күренекле шәхесләреннән.

Остазлары: Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый, Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле.

Шәкертләре: Тәуабил бине Сабикъ әл-Йөгәмеши, Габдессаттар бине Габдессәлам бине Хәсән һ.б.

## 104. Морадбакый бине Ишали бине Ишмөхәммәд бине Йосыф бине Сөләйман

Богырослан төбәгендә Гали авылында яшәп вафат булган. Тайсуган авылында Габдеррахман (кара: 43) бине Туймөхәммәд хозурында гыйлем алгач, Копал шәһәре тарафларында сәяхәт итеп, Нәҗмеддин ишан исемле берәүдән суфыйлыкка өйрәнгән. Кайбер язган хезмәтләре күренсә дә, буталчыклардан гыйбарәт.

Мөхәммәдҗан мөфти илә кайбер маҗаралары, мөфти һәм казыйлары хакында // [136] булган кайбер шигырьләрен күргәнебез булды. Аны гаять инкяр итүчеләр булган кебек, чиксез хөрмәтләүчеләре дә булган. Бар гомерләрен аның яхшылыкларын сөйләп кичергән затлар булганлыгы да мәгълүм.

Элекке заманнарның бөек вә изге галимнәре беткәннән соң язган китапларының күпчелеге изгелекләр вә гадәттән тыш хикәятләр белән тулы булганлыктан, Морад хәзрәт изгелекләрен санап гомер уздырган затларга гаҗәпләнмибез. Чөнки соңгы заман мөселманнарының гомерләре француз, инглиз, немец гомерләре кебек кыйммәтле түгел!..

Морад хәзрәт ачык гыйлемнәрдән камиллеккә ирешкәнче, суфыйлык белән шөгыльләнеп, мавыгып китеп, теленә килгәннәрнең һәммәсен тыңлаучыларга аерып-нитеп тормый сөйләгәнлеге дә билгеле.

## 105. Нигъмәтулла бине Рәхмәтулла бине Иманкол бине Рахманкол

Казан төбәгендә Наласа авылында имам вә мөдәррис булган. Хаҗ сәфәренә китеп, 1231/1816 елларда Искәндәриядә вафат вә имам Бусайри төрбәсе янында җирләнгән. Кабере билгеле, исеме дә язылган. Мәмләкәтебездә мәшһүр булган «Тәүзих» китабы белән күп шөгыльләнгәнгә, «әт-Тәүзихи» исеме белән танылган, имеш.

RUHIAT

Остазлары: Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстани (кара: 68), Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һ.б.

Шәкертләре: Габделләтыйф бине Әдһәм әл-Йулыкый, Габделләтыйф бине Чураш әл-Кенәли һ.б. // [137]

## 106. Муса бине Габдеррәшид бине Үтәгән бине Ярмөхәммәд бине Котлыгмөхәммәд бине Мөхсин әт-Түнтәри

Асылы Түнтәр авылыннан вә шәех Гали хәзрәтләренең кардәшләреннән. Мәмсә авылында имам буларак хаҗ сәфәренә китә һәм кайтуында, 1231/1816 елда, Искәндәрия шәһәрендә вафат булган.

Остазлары: Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстани (кара: 68), Ишнияз бине Ширнияз әл-Хәрәзми (кара: 60), Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле (кара: 46) һ.б.

## 107. Габдеррәшид бине Габделкәрим әс-Сәгыйди

Сәгыйдь бистәсендә (Оренбург Каргалысында) имам вә мөдәррис булып, 88 нче яшендә, 1231/1816 елда вафат булган. Көлке сүзле һәм мәзәкле бер кеше булган, диләр. Димәшкътә гыйлем эстәп, ике хәдис китабының берсен ятлаган, дип сөйлиләр. Әгәр дә бу сүз дөрес булса, әлеге затның гаять тырыш вә гыйлемгә ихласлы булганлыгы күренә. Ләкин мондый күп хәдис белгән бер затның хәдис гыйлеменә булган мәхәббәтеннән үзеннән соңгы буыннарга бер истәлеге-әсәре дә калмаган. Нәселе Сәгыйдь бистәсендә калган булса кирәк.

Шәкертләре: Сәйфулла бине Үтәгән, Ибраһим бине Габдеррәшид[43] һ.б.

### 108. Әхтәм бине Әхмәр

Бөгелмә төбәгендә Тимеркә исемле авылда дөньяга килеп, Сарлы авылында имам булып, мәдрәсәләр нигезләп, күп шәкерт туплады. 1231/1816 елларда исән-сау булган.

Шәкертләре: Хәбибрахман // [138] бине Мәхмүд әл-Әлмәти, Мөхәммәдкәрим бине Исхак әл-Мәчтәйи һ.б.

Оста әдип, мәзәкчән бер зат булган, диләр. Кайбер көлкеләре бүгенгә кадәр халык арасында мәгълүм.

### 109. Байым бине Динпакь әл-Бөрҗани

Ур (Орск) төбәгендә Байым авылында имам вә мөдәррис булып, 77 яшендә, 1231/1816 елларда вафат булган. Вәлид бине Әмин әс-Сәгыйди дусларыннан. Мөхәммәдгали исемле угылы 1274 ел ахырында/1858 ел урталарында вафат. Хаҗиәхмәд атлы угылы да голәмадан санала иде.

### 110. Габдүш бине Габдессәлам бине Исмәгыйль бине Нурмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Рысмөхәммәд баба

Ерак бабалары Сембер төбәгендәге Кырык Садак авылыннан мишәр таифәсеннән. Нурмөхәммәд, Исмәгыйль, Габдессәлам – Казан төбәгендәге Мәмдәл авылында яшәп вафат булганнар. Туганнарыннан Ихсан бине Габдессәлам Мәмдәлдә мөәззин, Әхмәр бине Габдессәлам Дөбъяз авылында имам булганнар. Зөбәйдә Габдессәлам кызы Мәңгәр авылында имам вә Диния Нәзарәтендә әгъза Сафкол бине Котый никахында булган.

Габдүш хәзрәт Кавал авылында имам булып, икенче мәртәбә хаҗ сәфәреннән кайтуында, 1232/1817 елда, Идел өстендәге көймәдә вафат булган. Саратов шәһәреннән 9 фәрсәх[44] түбәндә бер тарафка чыгарылып җирләнгән. Кабере «Золотой» исемле пристань янында билгеле булып, пароход өстеннән күренә, имеш.

Балалары: Галиеләкбәр, Гобәйдулла, Ганбәр, Сәгыйдә, Хәдичә, Шәрифә. Ганбәр Мостафа бине Мортаза әл-Мөндеши никахында, Сәгыйдә Ямаширмә имамы Сәйфеддин бине Хәлил никахында, Хәдичә Сәрдә имамы хаҗи Госман никахында, Шәрифә Көек авылында Фәхреддин // [139] атлы имам никахында булганнар. Галиеләкбәр Олы Кавалда имам булып, угылы Хөснеддин мөәззин вә аның угылы Җәлаледдин дә имам булды. Гобәйдулла хаҗи Сәрде авылында имам булган, угылы Исмәгыйль хаҗи бу көндә Истанбулда.

Шәкертләре: Газиз бине Госман бине Габдеррахман әл-Күлбаши, Мөхәммәделәмин бине Нәүрузгали, Максуд бине Корбангали әл-Күлбаши, Гобәйдулла бине Кәлим әс-Солабашый һ.б.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим, олуг, тәкъва, суфый иде. Аннан күпләр гыйлем эстәделәр», – дигән.

---

[43] Барон Виктор Розен исемле затның Петербургта булган Азия музейханәсендә саклана торган кулъязма китаплар каталогында (1881 елда төзелгән) 121 нче номер астындагы «Һәдиятес-сагълүке» китабының ахырыннан мондый юллар күчерелән. Бу нөсхә Болгар вилайәте Каргалы авылында мулла Габдеррәшид бине Габделкәрим мәдрәсәсендә Ибраһим бине мелла Габдеррәшид кулы белән 1202 елда күчерелде. Сибириядә Тара шәһәрендә имам булган кеше түгелме?

[44] Ф ә р с ә х – ераклык үлчәве. 1 фәрсәх 6–7 чакрымга тиң.

Үз кулы белән күчерелгән бер «Касыйдә» китабының ахырында болай дигән: «Бу касыйдәне Алла колы зәгыйфь Габдүш бине Габдессәлам әл-Болгарый (Мәмдәлдә туган һәм Кавалда яшәүче) Мәккәи мөкәррәмәдә 1232/1817 елның 1 шәгъбанында/16 июнендә күчереп тәмам иттем». Язуы бик матур һәм дөрес.

**111. Мөхәммәдъяр бине Габдулла** (кара: 67) **бине Мөслим**

Габдеррәхим бине Госман әл-Утыз Имәни шәкертләреннән булып, Бохарага барып укыган. Кабулга сәфәр итеп, шәех Фәезхан бине Хозырханнан ишанлык рөхсәте алган. Шул ук сәфәрендә хаҗда да була. Ватанына кайткач, янәдән хаҗ сәфәренә китеп, 1232/1817 елда чума авыруы илә вафат булган. Кабере Кара диңгез янындагы Анафа шәһәрендә, вә бер риваятькә караганда, Истанбулда. Ялгыз бер кыз баласы калып, Таиб бине Зәед бине Колмөхәммәд әт-Табыный никахында азмы-күпме торып, Мәдинәи мөнәүвәрәдә вафат булган.

Мөхәммәдъяр әфәнде гаҗәеп зиһенле галимнәрнең берсе булып, кыска төннәрдә ястү намазының фарызлыгы хакында гарәп телендә бер хезмәте бар. // [140] Аны остазы Габдеррәхим Утыз Имәнигә каршы язган, диләр. Мәкәрҗә базарына килгәч, махсус Оры карьясенә барып, Әбеннасыйр әл-Курсавыйдан өстен чыгу өчен Фәтхулла ахун илә дини бәхәскә кергән һәм җиңгәнлеге мәгълүм.

**112. Габделмөҗиб бине Габдулла** (кара: 67) **бине Мөслим**

Туганы Мөхәммәдъяр (кара: 111) әфәнде илә берлектә сәфәр итеп, 1232/1817 ел чума эпидемиясендә Анафа шәһәрендә вафат булган. Бер риваятьтә исә, хаҗдан кайтып, озын гомер сөреп, төп ватаны булган Ахун авылында дөнья куйган. Дөреслекне ачык белүче тарафыннан хәбәр алуга ирешә алмаганга күрә, бу ике риваятьне дә яздым. Юкса үз туган төбәгендә моның хакында дөресен белүчеләр күп булса кирәк.

Остазлары: Орыда Хәбибулла бине әл-Хөсәен һ.б.

Туганы Мөхәммәдъяр кебек галим вә мөхтәрәм булып, Мөхәммәдмәгъфур исемендә бер угылы булган. Бу зат та Ачулы авылында Габдеррәшидтән, Йулык авылында Габделләтыйф бине Әдһәмнән гыйлем алып, Габделхәким бине Корбангали әл-Чардаклыйдан ишанлыкка рөхсәт алган. Ләкин мөридләр җыю белән мәшгуль булмаган, диләр. 88 яшенә ирешеп, 1289/1872 елда вафат булган.

**113. Нигъмәтулла бине Гомәр әл-Утарый**

Казан төбәгендә Утар авылыннан Ибраһим әфәнде бине Хуҗаш әш-Шәрләмәвидән гыйлем өйрәнеп, Кабулга сәфәр иткән вә анда шәех Фәезханга мөрид булып, ишанлыкка рөхсәт алган. Аннан соң хаҗга сәфәр итеп, Истанбулга килгән вә, хуш кабул кылынып, Истанбулда шәехлек белән шөгыльләнгән. Истанбулда шәехләр башлыгы Сәед Исмәгыйль бине Ибраһим әл-Бәгъдадый // [141] (Гыйсмәт бәк) хәзрәтләре аңа мөрид булган. 1232/1817 елда Истанбулда вафат. Безнең мәмләкәттә Фәхреддин исемле бер угылы калып, Нигъмәтулла бине Рәхмәтулла әт-Тәүзихый кызына никахланган. Солтан Сәлим бине Мостафа исеменә атап язган гарәп телендәге «Рисаләи мәдәнийә» әсәре билгеле. Дәвәни вә башкалардан күчергән урыннары матур булса да, үзеннән сөйләгән җирләре алай ук түгеллеге укыганнарга мәгълүм булса кирәк. Замандашларыбыздан Мөхәммәд Әсгадь бине Мәхмүд бине Әхмәд бине әл-Хөсәен әл-Гыйракый әш-Шәһрәзвәри «Нурел-һидаййә вәл-гыйрфан» исемле китабында «Рисаләи мәдәнийә»дән кайбер сүзләрен күчергән.



RUHIAT

Казаннан Ибраһим әфәнде бине Хуҗашның фәтва сорап язуына җавап булырак, Кабул яки Истанбулдан язган бер хаты Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында (2 том, 322 б.) әйтелгән.

### 114. Мөхәммәдрәхим бине Йосыф бине Габделкәрим бине Арыслан бине Әбкә әл-Ашытый

Атасы Йосыф бине Габделкәрим Ашыт авылында имам булган. Ир туганнарыннан Габдеррәшид бине Йосыф хаҗга баргач, Каһирәдә Габдеррәфыйгъ бине Йосыф 1212 ел ахырында /1798 ел урталарында Семипалат шәһәрендә вафат булганнар. Кыз карендәшләреннән Йосыф кызы Мөнәүвәрә Ибраһим әфәнде бине Хуҗаш никахында вә Миһербан Йосыф кызы Госман бине Габдулла бине Иманкол бине Рахманкол әл-Ябанчыуый никахында булганнар.

Мөхәммәдрәхим хәзрәт Ашыт авылында имам булып, өч елдан соң Ибраһим бине Хуҗаш илә // [142] гыйлем эстәү өчен Дагыстан тарафына сәфәр иткәннәр. Ул якларда бөек гыйлем ияләреннән ун ел гыйлем өйрәнеп, күп мәгълүмат туплаганнар. Туган якларына кайткач, Мөхәммәдрәхим әфәндене Мәчкәрә байлары, үз мәчетләренә имамлыкка чакырып, имам вә мөдәррис итеп куйганнар. Имам вә мөдәррис вазыйфасыннан өстен ахунлык дәрәҗәсе дә өстәлеп, 1232/1818 елда[45] Мәчкәрә авылында вафат булган. Габдессәлам бине Үтәмеш исемле сәүдәгәрнең берсе артыннан икенчесен Мәхбүбә һәм Хәбибә исемле кызларына никахланган.

Балалары: Мозаффар, Габдулла, Гобәйдулла, Мөхәммәдшәриф, Мәүһүбә, Рәбига, Газизә, Шәрифә, Фаизә, Фатиха.

Шәкертләре: Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши, Фәхреддин бине Габдеррахман әл-Бәхтияри, Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани, Мөхәммәделәмин бине Дәмин әл-Казый, Шәрәфеддин бине Зәйнеддин әл-Эстәрли, Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли, Таһир бине Сөбхан әл-Мокраи, Ихсан бине Гомәр әл-Мәмсәви, Гаделшаһ бине Гомәр әт-Теләкәйи, Хәсән бине Мансур әс-Сәрдеки, Әмирхан бине Габделмәннан әт-Талкышый, Нигъмәтулла бине Гобәйдулла әл-Әлмәти, Рәхмәтулла бине Гобәйдулла әл-Кизләви, Фазыл бине Сәйфулла әл-Кизләви, Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри, Габделхәким бине Зәйнелгабидин әл-Мортыши, Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әл-Курсавый һ.б.

Бу зат фикъһ, ысуле фикъһ, мантыйк, кәлям, гыйльмет-тәүхид вәс-сыйфат фәннәреннән дәрес әйткән, мәмләкәтебезнең мәшһүр галимнәренә остаз булган бер бөек камил шәхес.

Моның хакында фазыйль Мәрҗани: «Мөхәммәдрәхим хәзрәт тәкәллефсез бер зат булып, дәресләре үрнәк дәрәҗәдә булган, // [143] гыйлемдә өстенлекле һәм хәтерен игътибарга алмаганлыклары өчен булса кирәк, Әбеннасыйр әл-Курсавый илә Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүшидән – һәр икесеннән риза булмаган хәлдә вафат булган», – дигән.

1816 елның 4 ноябрендә язылган бер хаты «Мөстәфадел-әхбар...»да (2 том, 36–37 б.) бирелгән. Үз кулы белән язылган икенче бер хаты[46] монда күчерелә.

«Изге һәм тугры булган Мәскәү мулла хәзрәтләренә... Угланчыкларыгыз Габделләтыйф вә Габденнасыйрның, инша Аллаһы Тәгалә, сәләт вә тырышлыклары бар. Сезләрдән һәм безләрдән хәер-дога булса, үзләренең дә теләк-омтылышла-

[45] Ахун хәзрәтләре милади илә 1817 елда вафат булган хәлдә, кайсы айда икәнлеге хакында мәгълүмат табылмады. Ул ел һиҗри илә 1232 вә 1233 елларга туры килгәнгә, бу рәвештә язылды.

[46] Бу хатны егерме елдан артык саклагач, юкка чыкмасын дип, монда яздым. Мөхтәрәм әтием, озак вакытлар саклап, миңа биргән иде.

ры зур булса, Аллаһы Тәгалә үзе бирүчедер. Киләчәктә хаҗәт китаплар табылса, алыр идек, дип, киңәшкән вакытларында әйткән идек: «Бохарадан алдыру яхшы, мондагының мәшәкате күп», – дип. Бу сүзне хуп күреп, сезләргә кәгазь (хат) күндерделәр дип беләбез. Оренбургта Казанлы сәүдәгәр Гомәр Мостай угылы бар, мәгъкуль күрсәгез, аңа мөрәҗәгать итегез, аннан кулай кеше юк. Чөнки китапны белеп алырга Бохарада аның кешесе бар. Вәссәлам (елы кәгазьдән өзелеп төшкән). Мөхәммәдрәхим».

Ошбу хат язылган зат Бөгелмә төбәгендә Чалпы авылында имам булып вафат итте. Фатыйма исемле бер кызы Ташлыяр авылында Әбүбәкер // [144] бине Шәмгун угылы – Мирзахан исемле затка 1253/1837 елда никахланган. Габденнасыйр атлы угылы хакында һичбер хәбәр беленмәде. Габделләтыйф исемле угылы да Чалпы авылында имам булган. Ахун хәзрәтнең мондый дуслыгына лаек булган затның тәфсыйльле әхвален белү өчен сорап язган хатыма Чакмак авылының Габдулла бине әл-Гафур хәзрәтләре «Мәскәү мулла безләргә мәгълүм бер зат булып, «Мәскәү мулла» диюдә артык камиллеге юк, гыйлемнән мәхрүм бер кеше иде» дип җавап язган иде. Мондый тәкъдирдә ахун хәзрәтләре югарыда бәйан ителгән хатын фәкать тәкәллефсезлектән вә шәкертләре өчен хәер хаһ булганлыктан язгандыр. 1215/1800 елда Бәрәскә авылында Гомәр бине Мостай бине Борнай исемле зат булган. Ошбу хатта телгә алынган зат, бәлки, шул кешедер.

Мөхәммәдрәхим хәзрәт угылы Мөхәммәдшәрифнең 1831 елда Эстәрлебаш авылында шәех Нигъмәтулла бине Биктимер хәзрәтләренә яртылаш гарәп, яртылаш төрки-татар телендә язылган бер хатын күргәнебез булды. Хаталы булганлыктан, бу урында бирелмәде.

RUHIAT

### 115. Таиб бине Уразай бине Имәкәй бине Бимкәй

Минзәлә төбәгендә Усы авылында имам вә мөдәррис булып, 1232/1817 елда вафат.

Остазлары: Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый, Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле һ.б.

Оста сүзле, зирәк бер зат иде, диләр.

### 116. Хәбибулла бине Әлхөсәен (кара: 58) бине Габделкәрим

1176/1762 елда җөмадиел-әүвәл 5 нче көн/22 ноябрь (дүшәмбе көн) дөньяга килеп, 1233/1818 елда 1 рамазанда/5 июльдә Оры авылында вафат булган.

Бохара шәһәренә барып, Гатаулла бине // [145] Габделһади (1210/1796 елда вафат) вә башка галим-голәмадан гыйлем алган. Аннан соң Кабулга сәфәр итеп, шәех Фәезханга мөрид булып, аннан ишанлыкка рөхсәт алган. Ватанына кайткач, күп шәкертләр җыеп, гыйлем өйрәткән. Тарафдарлары да хисапсыз күп булган. Хатыны Орыда мәшһүр байлардан Рәхмәтулла бине Туктамыш бине Мөслим бине Котлыг бине Җанмирза бине Хуҗасәед кызы Зөбәйдә.

Шәкертләре: Юныс бине Ибраһим әл-Какчырлый, Динмөхәммәд әл-Манчашый, Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Ашытый, Искәндәр бине Ишкәми, Габденнасыйр бине Габид бине Рахманколый, Мөхсин бине Биккол әш-Шашый, Фазыл бине Нигъмәтулла бине Бәшир әл-Әҗеми һ.б.

Эшен дәвам итүчеләр: угылы Габделгалим, Габделҗәмил бине Бикмөхәммәд әл-Куйсуый һәм угылы Мөхәммәдюныс әл-Куйсуый һ.б.

Фикердәш һәм тарафдарлары, хосусан мишәр таифәсе, аңа бик ихласлы булып, хәтта ки сәфәр вакытларында чана вә тәгәрмәч (көпчәк) эзләрен ятып үп-

кәннәр һәм елаганнар, нәзер вә садакаларын җыеп изге санаганнар, имеш. Мишәрләр, әгәр дә имам сайласалар, имам булачак заттан: «Изге Орыга бардыңмы? Изге суфый янына кердеңме?..» – дип сораганнар. Әгәр дә барган һәм кергән булса, имамлыкка уздырганнар, югыйсә, олуг бер галим булса да, кире каккannар. Орыда булган туфан (су басу) вакыйгасы моның вафатыннан аз көннәр элегрәк булган.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Орыда таш мәчеттә имам булгач, байлар илә арасына дошманлык вә нәфрәт төште, байлар тырышлыгы белән ахырында мәчеттән читләштерелде. Бервакыт мөфти булырга[47] омтылган һәм тырышты. Моны белгәч, мөфти Мөхәммәдҗан, үзенә дошман булып, үч алу өчен форсат эзләде. Мәчеткә зарар дип, мәчетне яндырырга фәрман бирде. Ләкин мөфтинең бу әмере ни сәбәптәндер җиренә җиткерелмәде. Үзенең ир туганы Фәтхулла ахун да, зур дошманы булып, һәр зур вә кечкенә эшләрдә араларында // [146] каршылык булыр иде. Бу ике мөбарәк хәзрәтне шәйтан бер фикергә туплаган иде. Кием-салым, тормыш-йөрмеш әсбаплары бик тәкәллефле булыр, ат-арбалары бик гүзәл вә яхшы булыр иде, кыйраәте хуш, фикъһ, ысуле фикъһ, нәхү фәннәреннән дәресләре булса да, күп дәгъва вә низаг илә мәшгуль булу сәбәпле, ахыр гомерендә әүвәлге дәрәҗәсе бераз төшкән иде», – дигән.

Аңа Фәезхан әл-Кабули тарафыннан фарсыча язылган хат түбәндәгечә.

Хатта иман һәм гыйлемнең сафлыгы, хөрлек турында язылган һәм «шәехләрегездән алданудан сакланыгыз» дип киңәш ителгән. Тоткан юлыгыз тугры, дип, ихлас теләктәшлек белдерелгән. Хат: «Ел саен Сезгә һәм башка Болгар галимнәренә хатлар күндерәбез. Ни сәбәпле барып ирешмиләрдер? Быел Баязид бай[48] һәм Габделкәрим мулла, Муса бине Нәзир[49] җибәргән Европа күлмәкләре, Вәли мулла җибәргән акчалар килеп иреште. Аларга Ходайның рәхмәтләре яусын! Дусларыгыз да хат язсыннар?! Ходай бу хатны мулла Хәбибулла әл-Болгарыйга ирештерсен иде», – дип тәмамланган.

RUHIAT

### 117. Сәлим бине Рәхимкол бине Урман бине Капкай бине Юлай бине Колай бине Сөләйман бине Тимери бине Рәми бине Ихсан

Бу нәсел шәҗәрәсе Оренбург төбәгендәге Мостафа авылында имам Гыймран бине Әхмәдҗан бине Сәлим һәм Эстәрлетамак шәһәрендә имам Мөхәммәдгариф бине Бәхтегәрәй бине Исмәгыйль әр-Рәмеви иске китаплар һәм кульязма җыентыклардан җыйнап җибәргән иделәр.

Риваятьләргә караганда, Тимери бине Рәми Мәскәү шәһәрендә дәүләт хезмәтендә булган һәм күп еллар, тәрҗемәче буларак, руслар арасында Митрий Рамеев исеме белән шөһрәт казанган. Рәмиев атамасы шуннан калган.

Рәхимкол бине Урманның Сәлим ахуннан башка Исмәгыйль исемле угылы булган, Исмәгыйльнең Габделкәрим атлы угылы булып, Эстәрле тирәсендәге Йөргән авылында 1268/1852 ел ахырында вафат булган.

Габделкәрим бине Исмәгыйльнең Бәхтияр, Бәхтегани, Бәхтегәрәй, Мөхәммәдсадыйк исемле угыллары булган. Бәхтегәрәй Толынхуҗа әл-Йөргәни, Габдеррахман әл-Балыклый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши, Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим әл-Казаныйлардан гыйлем алып, Эстәрлетамак авылында имам булган. Вә соңрак вазыйфасын угылы Мөхәммәдгариф әфәндегә тапшырган. 78 яшендә 1312/1894 елның мөхәррәм/июль аенда вафат булган. Тәкъва, сабыр

[47] Бу эш мөфти Мөхәммәдҗан әфәнде хөкем астында калгач булса кирәк.
[48] Кышкар авылының Баязид бай бине Госман бине Габделкадыйр булса кирәк. 1210/? елда вафат булып, Кышкар зиратында җирләнде.
[49] Оры авылында Муса бине Нәзир бине Туктамыш булса кирәк.

бер зат иде, диләр. Мөхәммәдсадыйк 1310/1893 елда Орски төбәгендә Йулык авылында вафат булган. Бу көндә Русия мөселманнарының зур сәүдәгәрләреннән саналучы Мөхәммәдшакир вә Мөхәммәдзакир Рәмиев әфәнделәр – моның угыллары.

Рәми угыллары, Зәй елгасы (Бөгелмә вә Минзәлә өязләрендәге мәшһүр бер елга) буеннан күчеп, Эстәрле төбәгенә килгәннәр // [150] вә, бер риваятькә күрә, Габделкәрим бине Исмәгыйль, Сарайлы авылыннан күчеп, Йөргәндә яшәгән.

Сәлим бине Рәхимкол, Кондыр вә Нугай исемле авылда Мөхәммәд бине Гали əд-Дагыстани хозурында гыйлем алып, укуын тәмамлагач, Уфа янында Тәтер суы буенда Арыслан авылында имам вә мөдәррис булган. Монда озак вакыт торып, Оренбург янындагы Сәгыйдь бистәсенә, Каргалы тамагы тарафына, икенче мәчеткә имамлыкка билгеләнә. (Ихтимал, мәншур-указсыз килеш бу хезмәтне үтәгәндер.) Аннан соң, Агыйдел янында Эстәрле елгасындагы Эстәрлетамак шәһәре нигезләнгәч, җамигъ мәчет төзелеп, аның беренче имамы итеп билгеләнгән. Анда гомеренең ахырына кадәр имам һәм ахун вә мөдәррис дәрәҗәсендә хезмәт итеп, 85 яшьләрендә вакытта, 1234/1819 елда дөнья куйган. Кабер ташында «әл-мәрхүм ахун Сәлим бине Рахманколый, 1234/1819» дип язылган.

Угыллары: Хәлим, Габделгалим, Мирзакай, Ибраһим, Әхмәди, Мөхәммәдҗан, Фәхреддин, Хөсәен, Фазылҗан, Әхмәдҗан. Кызлары: Мәймүнә, Сәгыйдә, Мөслимә, Шәрифә, Хамидә, Шәфига, Фатыйма. Болар арасыннан Әхмәдҗан турында язылыр.

### 118. Фәхреддин бине Сөбханкол (кара: 90) бине Бикмөхәммәд

Тумышы Кичүчат авылында булып, анасы Сахибә Каракай кызы. Әлкәй авылында Хисамеддин бине Мөэмин, Сабада Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарыйлардан гыйлем өйрәнеп, 1222/1807 елда Бохара шәһәренә сәфәр иткән. Вә бу сәфәрендә өч ай микъдар гомерен Сәгыйдьтә (Каргалыда) Габдеррахман әл-Кирмәни мәдрәсәсендә уздырган. Вә шул ук елда, Бохарага барып җитеп, галим-голәмасыннан 5 ел гыйлем алган. Аннан хаҗ нияте илә Бохарадан киткән. Мәккә һәм Мәдинәгә барып, галимнәре белән әңгәмәдәш булган вә, Истанбулга килеп, солтан Мәхмүд бине Габделхәмид әл-Госманый белән күрешкән. Аның тарафыннан Кара диңгез буендагы Анафа шәһәренә казый итеп билгеләнгән. Хезмәтен намуслы башкарып, 1234/1819 елда вафат булган. // [151]

Вафат хәбәре ирешкәч, анасы вә башка туганнары чиктән тыш хәсрәтләнгәннәр. Бу хәбәр мөхтәрәм әтием хәзрәтләре туган вакытка туры килгәнлектән, ядкәр булсын дип, аңа «Фәхреддин» дип исем куйганнар. Үзеннән аз көннәр соңрак хатыны да вафат булып, Ләтыйфа исемле бер кызлары калган. Үзендә булган газиз китаплары, хатынының атасында калып, бүген кем кулларына күчкәннәрдер? Бохара һәм Анафадан җибәрелгән хатлары Бәйрәкә авылында мәшһүр Исхак бай вакыйгасыннан соң туганнары тарафыннан яндырылганнар. Зиһенле, мәгълүматы ачык әдип бер зат булып, язуы гаҗәеп матур вә дөрес. Әхмәдҗан бине Әмирхан замандашларыннан булып, яшьли вафат булган. Бохарада вакытында Габденнасыйр бине Габдеррәхим әт-Тайсуганый моннан гыйлем өйрәнеп, якын фикердәшләреннән саналган.

Анасы исеменнән үз кулы белән язган васыятьнамәсе бу урында күчерелә. «Бисмилләһи рәхмани рәхим. Әлхәмделилләһи раббилгаләмин. Вәссаләте вәссәлам галә рәсүлиһи Мөхәммәдин саллаллаһу галәйһи вәссәллам вә галә алиһи вә әсхабиһил-кирам. Шул хосуста васыять иттем, мин, зәгыйфә, Аллаһ колы Сахибә Каракай мәрхүм кызы, үз карарым дөрес заманда. Әүвәл саф иманым белән гуаһлык бирәмен, Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән башка һичбер илаһи зат юк, ул ялгыз, охшашы да юк. // [152] Икенчедән, васыять итәмен, мин, зәгыйфә кол Са-

хибә Каракай кызы, балаларыма, ягъни угылларыма вә кызларыма, туганнарыма һәм якыннарыма, Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалык итегез! Минем мал-мәтрүгем булса, үз малымнан, булмаса, үз көчегез җиткәнчә кәфенләп, җиһазлап җирләгез. Вә моннан соң бирәчәк бурычларымны үтәп, алачакларымны алыгыз!.. // [153] Ошбу васыятьләремне үтәү өчен васый иттем угылларым мелла Сәйфеддин, мелла Фәсыйхеддин вә Фәхреддиннәрне, әманәтләренә, диянәтләренә, шәфкатьләренә ышанып һәм тагын җирләгәннән соң, һәркайсыгыз угылларым вә кызларым, берәр Коръән укып рухыма багышлагыз!

Вә без – зәгыйфь коллар Сәйфеддин, Фәсыйхеддин, Фәхреддин мулла Сөбханкол угыллары – Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең шәфкатенә ышанып, әнкәбезнең ошбу васыятен кабул иттек».

Бабабыз Сәйфеддин бине Сөбханколның кульъязма «Мөхтәсарел-Коддури» нөсхәсенең бер читенә, «1801 ел рабигыль-әүвәл 17 сендә «Холәсател-Коддури»дан дәрес башладым» дип, Фәхреддин әфәнде язып куйган.

### 119. Мәүлед бине Мостафа бине Юныс

Уфа шәһәреннән ике станса ераклыкта Калтай авылына нисбәтле булып, Сөләйман ахун (кара: 95) һәм мәшһүр затлардан Габделмәннан ахуннарның ир туганы. Язуы бик матур булып, дагыстанлылар язуына охшаган. Имамлыгына өстәмә буларак 1778 елда ахунлык мәншуры [указы] да алган. 1236/1821 елда вафат булып, Калтай зиратында җирләнгән. Тәкәллефсез садә бер зат, дөньясы иркен булган. Пугачев явыннан куркып бөтен авыл халкы урманга качкан вакытта, Мәүлед ахун берьялгызы авылда калган. Пугачев кешеләре, авылга килеп, ахунның күз алдында алтын вә көмеш һәм башка әйберләрен алып, йортына ут төрткәннәр. Бер сәгать эчендә // [154] бөтен авылны җир белән тигезләгәннәр.

Шәкертләре: Габделкадыйр бине Сөләйман һ.б.

Балалары: Йосыф, Мөхәммәделәмин, Әхмәд, Исмәгыйль һ.б. Йосыф исемле угылы Үршәк елгасында Аерыкул авылында имамлык иткән, яхшы гыйлемле иде, диләр. Угылы Әхмәд Калтайда ахун хәзрәт урынына имам булып, 63 яшендә 1265/1849 елда дөнья куйган. Аның Фатыйма атлы кызы Уфа шәһәрендә мөәззин Хәйреддин бине Һашим бине Рахманкол никахында иде.

Мәүлед ахунның үз кулы белән язган бер хаты бу урында күчерелә.

«Солтанай авылында булган дин карендәшләребездән Чалпы мулласы Биккенә вә башка ил җәмәгатьләре һәм тирә-як авыл әһелләре – барчалары берләшеп, әлеге авылда җомга вә гает уку хакында миңа килеп рөхсәт таләп иттеләр. Газиз ислам динебезнең көннән-көн бөек һәм куәтле булуы теләгеннән җомга вә гаетләр укуга рөхсәт бирелде... Имам Шафигый вә Мөхәммәд хәзрәтләре «имамнан башка кырык кеше булсалар, ни җирдә теләсәләр дә, җомга уку дөрес» дигән. Бу заманда моңа фәтва һәм гамәл булды. Боларны әйтте һәм язды ахун Мәүлед бине Мостафа».

Бу фәтвасының елы куелмаса да, Аллаһы әгъләм, бу Уфа шәһәрендәге Диния Нәзарәте нигезләнгәнче булган язу.

### 120. Габдессәлам бине Габдеррахман бине Габделгазиз бине Рәфыйк (кара: 32) әл-Курсавый

Ташкичүдә имам булып, 1236/1821 елда вафат булган. Озын гомер сөреп, хаҗга бару бәхетенә дә ирешкән.

Остазлары: Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

RUHIAT

Балалары: Җәмаледдин, Фәхреддин, Насреддин, Сираҗеддин. Җәмаледдин, Бохарада гыйлем эстәп кайтканнан соң, юкка мал исраф итеп, Эрбет тарафында һәлак булганлыгын сөйлиләр. // [155]

### 121. Сәфәр бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт (Кадермөхәммәд) бине Әхмәд бине Җәлмәт бине Гәрәй әт-Талкышый

Ерак бабасы Җәлмәт бине Гәрәй, Сембер тарафыннан күчеп килеп, Чистай төбәгендә Чирүле Шонталы исемле авылга тукталган. Морад бине Кадермәт Шонталыда җирләнеп, гади халык аның каберен зиярәт итә, имеш. Исмәгыйль бине Морад Талкыш авылында игенчелек белән шөгыльләнгән.

Сәфәр бине Исмәгыйль Малмыж өязе Сасна авылында укып, соңрак шул авылда имам вә мөдәррис булган. Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәкидән әүвәлрәк, Югары Саснада икенче мәчеттә, «Сәфәри мулла» дип танылган зат ошбу булса кирәк. Ун еллар торгач, Сасна байлары илә дуслыгы китеп, төп ватаны булган Талкыш авылына кайтып, имам булган. 1236/1821 елда вафат. Вафат булгач, шәехе Гобәйдулла бине Җәгъфәр әл-Кизләви махсус Талкыш авылына килеп зиярәт иткән һәм вафатына бик тә кайгырган. Аның мәдрәсәсендә күчерелгән түбәндәге кулъязма китапларны күргәнем булды. Бер «Холәсател-Коддури» китабы ахырында «Казан вилайәте Талкыш авылында Сәфәр бине Исмәгыйль мәдрәсәсендә 1202/1788 елның шәүвәл/июль аенда тәмам булды», бер «Тәфсире Сәгъләби» китабы ахырында «Казан вилайәте Талкыш авылында Сәфәр бине Исмәгыйль мәдрәсәсендә 1206/1792 елда күчереп язылды» диелгән.

Шәкертләре: Габделләтыйф бине Чураш әл-Колшәрифи һ.б.

Хәзер Талкыш авылында имам булган Шамил әфәнде бине Фәхреддин Сәфәр хәзрәт хакында мондый эчтәлектәге бер хат күндергән иде: «Хатыгызны алу белән Сәфәр хәзрәт әхвален белешә башладым. Ләкин Сез сораган нәрсәләр хакында мәгълүмат табу бик тә кыен. Аның әхваленнән беркадәр булса да Фатыйма Әбүбәкер кызы исемле бер килененнән сораштым. Ул, Сәфәр хәзрәтнең укуы Саснада икәнлеген сөйләсә дә, остазы кем булуын белми. Сәфәр хәзрәтнең китаплары күп тапкырлар булган янгыннарда юкка чыкканнар. Сәфәр хәзрәт, бик гайрәтле бер зат булып, күп гамәлләрне үтәгән, дәресе куәтле, шәкертләре күп булганлыгы билгеле булса да, мәдрәсәсендә гыйлем // [156] эстәгән затлар бу якларда ишетелми. Каберендә булган ташын карау өчен бардык. Таш мүкләнгәнлектән, язуын уку мөмкин булмады. Су илә юып чистарткач, күп тырышкач укыдым. Гәрчә укылышында кайбер шөбһәләрем булса да, төп максат мәгълүм булды. Җиде юлга язылганнардан: таш иясе Җучи нәселеннән бер хан булып, 700/1301 ел шәгъбан/апрель аенда вафат булган. Авыл халкының Сәфәр хәзрәт ташы дип белгән ташлары шулай булып чыкты. Ташны кем куйган вә бу җиргә ни мөнәсәбәт белән килгән, моннан беркемнең хәбәре юк. Сәфәр хәзрәтнең тормыш юлы бу якларда бөтенләй онытылган. Ничек булса да, исеме калган, халкыбызның хәленә күрә исеме калу да бик гаҗәп!..» // [157]

Балалары: Әхмәд, Мөхәммәд һ.б. Мөхәммәд, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши хозурында гыйлем эстәп, атасы вафат булгач, аның урынына имам булган. Кадер-хөрмәте бар иде, диләр.

### 122. Үзбәк бине Сөбханкол бине Мостафа

Оренбург Каргалысында имам булып, 1236/1821 елда вафат булган. Чыгышы белән Сембер губернасы Шәйморза авылыннан. Госман, Гатаулла исемле угыл-

RUHIAT

лары Каргалыда имамлык иткәннәр. Гатаулла оста хаттат [каллиграф] булган. Оныгы Габдессәлам бине Госман яхшы карый буларак шөһрәт казанган.

Шәкертләре: Алты Ата авылының Мөхеддин бине Хәсән һ.б.

### 123. Фазыл бине Ибраһим бине Котлыгъәхмәд әл-Эчкени әл-Әлмәни

Төп чыгышлары Кирмәннән (Касыймнан) булып, Тенәкәч кабиләсенә нисбәтлеләр. Чиләбе төбәгендәге Әлмән авылында имам вә мөдәррис булып, 1237/1822 елда вафат. Бәләбәй төбәгендә Габделваһаб бине Шәриф[50] исемле зат хозурында // [158] гыйлем алганда, 1187/1773 елда «Фәраизе Сираҗийә шәрхе» китабын күчереп, тәмам иткән. Моннан соң Оренбург Каргалысына барып, гыйлем эстәгәнлеге дә мәгълүм.

Балалары: Фәхреддин, Габделхак, Габделфәттах, Әхмәд, Бәдреддин, Гыйльмия, Сабира, Хаифә, Сагыйрә. Гыйльмия исемле кызы Мөхәммәдзариф бине Габделҗәмил никахында булган.

Шәкертләре: Гайнулла бине Әсәдулла әл-Эчкени, Шәфи бине Янбулат әл-Эчкени, Габделкадыйр бине Каһарман әс-Сафакүли, Руза ишан әт-Туплый, Габделмөҗиб бине Илхан әл-Карманый һ.б.

Бу шәхес шул якның олуг затларыннан һәм ышанычлы галимнәреннән булып, Әбеннасыйр әл-Курсавый фикерендә буларак, һәрвакыт аңа өстенлек биргән. Бохара шәһәренә илчелек сыйфаты илә барып, Истанбул вә Дагыстан тарафларында сәяхәт иткән. Ошбу вакытта хаҗ кылу бәхетенә дә иреште. Нәхү, фикъһ, мантыйк, кәлям, гакаид, ысуле фикъһ, мәгънә һәм тәфсир фәннәреннән дәрес әйтеп, күпләргә гыйлем өйрәткән. Тройски, Кызылҗар төбәкләрендә вә Себердә күп мәртәбә сәяхәт итеп, сәфәр вакытларында үзе белән бергә шәкертләрен дә алып, һаман укыту һәм гыйлем тарату белән мәшгуль булган. Һәм йөргән җирләрендә, мөмкин булганда, шәкертләрен укыту өчен урнаштырып та калдырган.

RUHIAT

1231/1816 елларда Тара ягына барып гыйлем өйрәткән һәм шул тарафта булган галим-голәма, берләшеп, дәресләр тыңлаганнар. Берникадәр вакыт шулай дәвам иткәч, Ибраһим бине Җәгъфәр атлы шәкертен дәрес әйтү өчен билгеләп, үзе асыл ватаны булган Әлмән авылына кайткан. Аның заманында Әлмәндә Габденнасыйр бине Сабит исемендә икенче бер галим вә мөдәррис булса да, бу тарафларда, күп сүзле, аз эшле халыклар булмагангамы, ни хикмәттер, аралары тәмам дуслык һәм ихтирам белән кичкән. // [159]

### 124. Җәгъфәр бине Әднакол әл-Әгерҗеви

Төп чыгышы Гәйнә илендәге Мәл авылыннан. Вятка губернасында Әгерҗе исемле авылда имам вә мөдәррис булып, 1237/1822 елда вафат булган. Язуы матур булып, ул күчергән кульязма Коръәни Шәриф нөсхәләре бүгенгә кадәр халык арасында кулланылуы мәгълүм.

Остазы Габдессәлам бине әл-Кариле булып, хатыны да шул ук остазының кызы Хәбибә булган. Улы Әбүбәкер турында алдарак сөйләнәчәк.

---

[50] Чакмагыш авылында Габдессәлам әл-Кариле кияве Габделваһаб ахун вә аның угылы Хәбибулла ахун исемле мәшһүр галимнәр бар. Боларның, беренчедән, шәкертләре күп булганлыктан һәм, икенчедән, алдарак сөйләнгән Сөләйман ахун белән кардәшлекләре дә булганга, тәрҗемәи хәлләрен белү өчен бик тә тырыштым. Туганнарыннан һәм нәселдәшләреннән билгеле булган затларга хосусый вә гомуми хатлар яздым. Бәлки, ирешмәгәннәрдер дип, яңадан яздым вә кайбер затлар аркылы да үтендем. Әмма бу тырышлыкларым нәтиҗәсез калды, бер җавап та килмәде. Шул сәбәпле бу затларның хәле минем өчен караңгылыкта калды.

**125. Фәйзулла бине Габбас бине Мөэмин бине Мөслим**

Минзәлә ягындагы Мөслим авылында мөдәррис булып, 1238/1823 елда вафат булган.

Остазы – Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңари. Остазыннан Саба авылында беркадәр вакыт гыйлем өйрәнгән. Соңрак үз авылына кайтып, шәкертләр җыйган. Берара хаҗга да сәфәр иткән.

**126. Гобәйдулла бине Җәгъфәр** (кара: 69) **бине Ибраһим**

Чирмешән елгасы буендагы Кизләү авылында имамлык һәм шәехлек иткән. 72 яшендә вакытында, шәүвәл аеның 26/6 июль көнне, 1238/1823 елда вафат булган. Кабере Кизләүдә булып, өстенә куелган ташы да бар. Габдессәлам бине әл-Кариле хозурында гыйлем өйрәнгәч, Вәлид бине Әмин әс-Сәгыйдидән белем алып, камиллеккә ирешкән һәм үзеннән дә күп затлар укып өйрәнгәннәр. Хатыны Иске Сәлман авылының Әбелкасыйм кызы Хафизә булып, 1248/1833 ел зөлкагдә-/апрель аенда вафат булган. Вә икенче хатыны Габидә Әхтәм кызы да шул ук Сәлман авылыннан булып, 1258/1842 елда Казан шәһәрендә вафат булган.

Балалары: Нигъмәтулла, Рәхмәтулла, Мөхәммәд, Хәбибулла, Габделбәдигъ, Әхмәд, Хәбибә, Мәхбүбә, Гайшә, Фатыйма. Хәбибулла Кәкре Тау авылында һәм Габделбәдигъ Исәнтимер авылында имам булып, Әхмәд кечкенә яшьтә вафат булганнар. // [160] Хәбибә Алабуга өязе Илмәт авылы Назар Илмәт угылы никахында, Мәхбүбә Уразгилде фамилиясендә Бикмөхәммәд бине Мөхәммәдрәхим никахында, Гайшә Чистайда Габделхәким исемле зат никахында, Фатыйма Казанда Кәшәй Мортаза никахында булганнар. Башка балалары турында алда аерым сүз булачак.

Шәкертләре һәм тарафдарлары: Габделваһаб бине Иманкол әр-Рәҗәби, Бәшир бине Җомгаколый әл-Җәбәли, Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәти, Монасыйб әл-Җәбәли, Һибәтулла бине Исхак әл-Мачауый, Әхтәм әл-Җәбәли, Ярулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышый, Хәмзә әл-Җәбәли һ.б. Үз телебездә тарикать-ишанлык әдәпләре хакында бер китабы булган. Бу зат хакында Мәрҗани: «Заманында мәшһүр вә олуг галимнәрдән бере иде. Мөридләр тәрбияләп, ишанлыкта шәех иде», – дигән.

**127. Биниәмин бине Йәһүд бине Балтач**

Уса төбәгендә Аклуш авылында имам булып, 1238/1823 елларда вафат булган.

Остазы – Олы Саба авылында Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд. Ахун Мөхәммәдкасыйм әл-Мансури хәбәренә караганда, тирә-ягында гыйлеме белән шөһрәтле булган.

RUHIAT

# ДҮРТЕНЧЕ КИСӘК

دورتنچی جزء

برنچی جلد

# آثار

مملکتمزده اولان اسلام عالملرینک ومشهور کیشیلرینک ترجمه وطبقه‌لری
تاریخ ولادت ووفاتلری وباشقه احواللری حقنده یازلمش کتابدر .

دورتنچی جزء

RUHIAT

صاحبی
رضاء الدین بن فخرالدین

ان آثارنا تدل علینا    فانظروا بعدنا الی الآثار

« اوفا »

۱۳۲۰ سنه

Дозволено цензурою С.-Петербургъ, 13 Іюня 1903 года

باشلمه‌سنه رخصت بیرلدی سانکت پیتربورغده ۱۳ نچی ایون ۱۹۰۳ سنه

Оренбургъ.
Типографія М.-Ф. Г. Каримова.
1903.

**128. Габделкадыйр бине Сөләйман** (кара: 95) **бине Мостафа бине Юныс**

Уфа шәһәреннән көнбатышка таба Кармасан елгасы буендагы Каршин Шәриф авылында имам, мөдәррис, ахун булып, 1238/1823 елда вафат булган вә иске зиратка күмелгән. Хатыны Чакмагыш авылының Габделваһаб ахун, ә бер риваятькә күрә, Габделваһаб ахун угылы Хәбибулла ахун кызы.

Балалары: Габделгалләм, Сибгатулла, Хәйрулла, Сөнгатулла, Габделфәттах, Габдессамад, Хәбибә.

Остазлары: Мәүлед бине Мостафа, Габделләтыйф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви (бу кеше 1203/1789 елда әле исән булган) һәм башкалар. Язылып тәмам ителгән бер «Ифтитах» ахырында мондый язу бар иде: «Бу рисалә 1198/1784 елда Калтай авылында заманының абруйлы вә олуг галиме ахун Мәүлед мәдрәсәсендә Габделкадыйр бине Сөләйман кулы белән язылды».

Габделфәттах вә Габдессамад исемле угыллары ягыннан бу көндә нәселе юкка чыккан. Заманасында гыйлем вә мәгърифәт илә мәшһүр булып, шәкерте күп вә дәресе куәтле вә файдалы булган икән. Җәгъфәр ишан турында инануы камил булып, беренче тарафдарларыннан булган, диләр.

Үз каләме белән язылган беркадәр хатлары биредә китерелә.

*Беренче хаты.*

[1815 елның 25 сентябрендә Бубый авылында укучы улы Габделгалләмгә язылган.] // [163]

*Икенче хаты.*

Бубый авылында Габделкәрим хәзрәт мәдрәсәсендә угылларыбыз Габделгалләм илә Сибгатуллага. Каршин Шәриф авылыннан.

Габбас, Габделгалләм илә күндерелгән хәбәрегезне алып, сәламәтлекләрегезне белеп хуш булдык. Уку-язуга күз йоммагыз. Китаплар турында Әхтәм кияү илә сөйләшкән юк, чөнки бу араларда өйдә күп торганы юк. «Аксакал» кантоныбыз илә Алкин һаман низаг илә торалар. Алкин берничә көн вазыйфада булган иде. Хәзер һәр икесен яңа военный Оренбургка чакырып алды. Кайсы булып кайтыр? Ун көнләп Алкинда кунак булдык, бик нык хөрмәт итте. Дустыбыз мелла Габделмәҗид агайга сәламебезне җиткерегез. Үзенә хат язарга вакыт тар булды. Үзенең хатын хәзер генә алдым. Мелла Габделгалләм китәр өчен атын иярләгән иде. Шуның өчен язу мөмкин булмады. Уку, гыйлем алуны кайгыртыгыз. Гомерне заяга үткәрмәгез. Хаҗәт китапларны кулга төшерергә тырышыгыз. // [164]

Габделфәттах һаман йортта, һич кәсеп теләге юк. Писарьлек өчен Алкин үтенгән иде, үзе ни хәлдә кайтыр. Әгәр дә булып кайтса, бирергә дә ярар иде. Вәссәлам. Һәрдаим хәер илә дога кылучы әткәгез Габделкадыйр бине мелла Сөләйман. 10 апрель, 1817 елда.

*Өченче хаты.*

Сәгыйдь бистәсендә олуглардан олуг остазыбыз Габдеррахман хәзрәт хезмәтендә гыйлем алучы угылыбыз Габделгалләмгә Каршин Шәриф авылыннан.

Почта илә күндерелгән хатларыгызны алып, сәламәт булуыгызны аңлап бик куандык. Моннан соң да сәламәтлек хәбәрегезне көтәбез. Чакмагышларга җибәргән хатыгызны монда Гыйсмәтуллага тапшырдык, Уфадан кайтканда кунак булып китте. «Хашияи мәгъһүдә»не алып җибәргән икән, мелла Габдессаттар илә юлладык. Бик каты авыру булганга, Габдессамадны ул тарафка җибәрү мөмкин булмады. Әлхәмдүлилләһи, хәзер сыйхәтләнеп, аягына басып йөри башла-

RUHIAT

ды. Анда гошер буларак бирелгән ашлыкларыгызны угланнардан берсе барып алып кайтыр, ләкин хәзергә ашлыкның кыйммәте юк. Быел йорттан бал чыкмады. Бибихәбибә кечерәк чиләк илә аз гына бал, ярты кадак чәй, бер каз, азрак җиләк кагы, бер сөлге җибәрде. Аллаһы насыйп итсә, тозга баручылар илә үзегезгә нәрсәләр җибәрелер. Юкса хәзер җибәрергә мөмкин түгел. Махсус яллап җибәрелсә, азыкның хакы үз хакыннан күпкә кыйммәт булыр. Мелла Габдессаттарга аңа охшаган зат илә «Казыйхан»ны монда кайтарып җибәр. Шулай ук «Гакаиде Нәсәфи» китабын Ильяс илә кайтарып җибәр! Чөнки бу китаплар хәзер монда зарур була. Мелла Сәгъдулла мәсҗид астында торырга барыр идем, дип хәбәр // [165] итә, китаплар хаҗәт булыр. Әхтәм кияү «Казыйхан» китабын баручы Ибрай угылы илә җибәрергә, дип әйтте, мелла Габдессаттарга да әйтте.

Бу заманнар авыр, форсатны бәхет санап, дәрес вә язу җәһәтендә буласыз, кергәннән чыккан күп булмасын. Габделфәттах кантоннан билет алып, Габдессаттарга тапшырыр. Бу билетны алганнан соң, искесен ертып, сандыкта сакларсыз, килүче булса, монда җибәрерсез. «Ягъкуб Чәрхый»ны, «Ногман» вә «Гыйсмәтулла»ны кайтарырсың, анда китап табыла торган урын, кирәк булганда табарсыз. Кызыбыз Хәбибәгә Аллаһы Тәгалә бер кыз насыйп кылды, Бибифатыйма дип исем бирдек. Аллаһы Тәгалә тәүфыйклы вә гомерле итсен!

Әткәгез Габделкадыйр бине мелла Сөләйман. 4 гыйнвар, 1818 елда.

*Сигезенче хаты.*

Саба авылына. Угылларым Габделгалләм илә Сибгатуллага, мелла Мөхәммәдигә сәлам юлладык.

Кадерле әнкәбез бер // [170] көенчә гыйбадәтендә дәвамлы хәер-дога кылып тора. Габделфәттах сау-сәламәт, һаман хат алгалап торабыз. Быел ул якларда ашлык вә печән булмаганга, беразга кайту ихтималын яза. Бөгелмәгә баручылар илә җибәргән хатыбыз Исмәгыйль Искәндәр угылына бирелгән икән, шаять, сезгә тапшырылгандыр. Күзләре авыру булганга, Габделкаһир үзе Бөгелмәгә бара алмады.

RUHIAT

Бу тарафта ашлык көннән-көн кыйммәтләнеп бара.

Арыш оны Уфада бер сум сиксән-бер сум туксан тиен, бодай оны ике сум илле тиен булды. Сыер хайваны зарарланып үлеп бетте, үзебезнең әле исәннәр. Габделвәли урынына кантон сайларга Уфага җыелганнар иде, Алкинны земский суд военныйга тәкъдим итү сәбәпле тоткарладылар, аннан карар көтәләр. Хәбибулла Гобәйдулла угылы илә әниегез чиләге белән ун кадак бал җибәрде. Остазыгызга безнең сәламебезне тапшырыгыз. Дога кылып, әткәгез Габделкадыйр бине мелла Сөләйман. 1 октябрь, 1821 елда.

*Тугызынчы хаты.*

Каршин Шәриф авылыннан Олуг Саба авылында бәгъребез парәсе угылыбыз Габделгалләмгә күп сәламнәребезне күндерәбез.

Угылыбыз Хәйрулла ике көннән бирле хаста булып тора. Кадерле әнкәгезнең биш вакыт намазда җитешсезлеге юк. Сибгатуллалар ошбу көн сәламәт кайтып җиттеләр, сәламәтлек хәбәрегездән шат булдык. Габделфәттах исән-сау кайтып җитте. Быел кәрван һәм кыргыз булмаганга, чыгымнары азрак, мәгәр дә уннан артык аты бар. Габделкаһир илә уртакка Габдессамад он алды. 1900 пот оныбызны салырга урын юктан гаҗиз булып торабыз. Габделкаһир ун меңнән артык подряд салды. Гәрәй урынына һаман кантон юк, хезмәтен ярдәмчесе Габделгазиз үтәп тора. Безнең мишәрләр шар салыр өчен Сәфәр авылына җыелдылар, кемгә шар күп булыр. Ләкин Габделвәли, эшеннән тазарынса, кире үз урынына

керергә исәпләп тора. Алкин кире кагылды, һич булачак түгел. Габделфәттахның өе тәмам булды, тиз көннән җәмәгатен китермәкче. Җай булганда башка мәдрәсәгә күчәргә теләсәгез, бездән рөхсәт, ләкин остазыгыз рәнҗерлек булмасын. Бу авылда һич нәтиҗәсе юклыктан, атабыз бер хәерле // [171] урынга күчәргә әмер бирде, диярсез. Акмәттә дә урын булырга тора. Шунда сезнең өчен тамга алырга ярар дип хисапланыла. Шәкертләр илле-алтмышлап бар. Хәзергә «Мелла Җами»дан югары дәрес юк.

Дога кылучы әткәгез Габделкадыйр бине мелла Сөләйман. Декабрь, 1821 елда.

*Унынчы хаты.*

Каршин Мөхәммәдшәриф авылыннан Саба авылында гыйлем алучы угылым Габделгалләмгә. Хатыгызны алып шатландык. Габделкаһир, Уфага барып, паспорт алды һәм аның кешесе Бәшәр Исмәгыйль Искәндәр угылына биреп җибәргән, шаять, алгансыздыр. Сибгатулла Чакмагышка киткән иде, бәлки, Мәкәрҗәгә баручылар илә бәрабәр китәр. Быел керем-чыгым хәле мөшкел, сыер җенесе бетте, ашлыкны елдан бирле сатып алабыз. Бу көнгә кадәр арыш оны бер сум алтмыш, бодай оны ике сум илле тиен булды.

Башкортларга Габделгазиз, мишәрләргә Габделгаффар карендәшебез кантон булды. Казарма вә чакмагышлар кантонлык теләгеннән өзелделәр. Дәүләтбай кантонны ашамый, эчми, голәмага дус, диләр, безгә ихласы бар, берничә бүләге дә килде. Ләкин никадәр кунакка чакырса да, бару мөмкин булмады, анабызны ташлап йорттан чыгу лаеклы күрелмәде. Габделкаһирның кантонлыгы бик хәтәрдер, ахыры хәерле булсын. Мелла Мөхәммәдвәли аркылы мелла Габдессаттардан хат алдык, барча җәмәгатьләре илә сәламәтләр икән. Мелла Габделкаюмнан һич хәбәр юк. Ул яктан хәбәр булса, язарсыз. Гыйлем алуда иҗтиһадлы булып, усал фигыльле кешеләр белән аралашмассың, хаҗәт китапларны тырышып яз!

RUHIAT

Дога кылучы әтиегез Габделкадыйр бине мелла Сөләйман. 20 июль, 1822 елда.

Ошбу хатларда исемнәре күрсәтелгән затлардан Габделгалләм, Сибгатулла, Хәйрулла, Сөнгатулла, Габделфәттах, Габдессамад ахун хәзрәтләренең үз угыллары вә Бибихәбибә – кызы, Бибифатыйма – кызының кызы вә Әхтәм – кияве. Әхтәм илә Бибихәбибәнең угылы Габделхаликъ булып, бу көндә Уфа шәһәрендә дәгъва вәкиле булган Әбессәгуд әфәнденең атасы була. // [172]

Габделкаюм, Оренбургта булган Габдессаттар ахун хәзрәтнең туганнары вә Шәмседдин илә Фәхреддин туганы булган Нәриман угыллары. Йосыф Мәүлед ахунның угылы була.

Мөхәммәдвәли бине Мостафа бине Юныс Уфа ягындагы Казарма авылында имам булып, соңрак Оренбург тирәсендәге Сәгыйдь бистәсенә имам вә ахун буларак күчкән.

Алкиннан Йосыф мирза бине Мөхәммәд бине Гали әш-Шәмәки булса кирәк. Бу затның милке Уфа янында вә бу көндә Самара-Златоуст тимер юлы өстендә Юматау илә Чишмә арасында. Йосыф мирзаның хатыны Суфия бинте Йосыф мирза бине Котлыгмөхәммәд әт-Тәүкили булып, сиксән яше ахырында, 1842 елда вафат булды вә Алкин каберлегендә күмелде. Боларның угыллары Мөхәммәдгәрәй вә аның угылы Гаделгәрәй. Гаделгәрәй исә Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәтендә берара сәркәтиблек хезмәтендә булган. Маһипәрвәз исемле кызы генерал Мәхмүд бине Шәехгали никахында булып, бу көндә Уфа шәһәрендә исәнсау.

### 129. Габделҗәлил бине Габдеррәшид бине Мөэмин бине Мөслим

Минзәлә өязендәге Мөслим авылында имам вә мөдәррис булып, 1239/1824 елда вафат булган.

Остазлары Рәфыйк бине Таиб әл-Курсавый, Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле һәм башкалар. Габдессәлам бине Хәсән хозурында бер китап язып, 1187/1773 елда тәмам итүе мәгълүм. Әлеге китабын исә 1819 елда үз угылы Ибраһимга бүләк иткән. Ибраһим исә 1838 елда моны башка бер кешегә сатуы китабының читенә язылган. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Гарәбият гыйлемендә осталыгы белән шөһрәте бар иде», – дигән. Бу угылы 1249/1833 елда Мөслим авылында имам булган.

### 130. Шәмседдин бине Дәванай бине Мәмбәт суфый бине Сөләйман бине Колмөхәммәд бине Кодрәтвирде бине Бикмәт абыз

Бөре тарафындагы Иске Бикмәт авылында имам вә мөдәррис булып, 1139/1727 елларда вафат булган. Вәлид бине Әмин әс-Сәгыйди хозурында гыйлем алып, әтисенең туганы булган Җәгъфәр (кара: 82) бине Имай исемле шәехтән тарикатьтә рөхсәт алган. Тереклеге тәкәллефле // [173] булса да, тиешле садаканы кабул итмичә, үз кул көче илә дөнья кичерүе сөйләнә. Вафат булганнан соң, Бикмәт авылының Мөхсин бине Мәхмүд исемле шәкерте эшен дәвам иткән.

### 131. Нәриман бине Сөләйман (кара: 95) бине Мостафа

Уфа янындагы Кизәк елгасы буендагы Чуалкиб авылында имам вә мөдәррис булып, 1139/1727 ел ахырында вафат булган. Мәган вә бәйан фәннәрендә маһир, шәкерте күп булган, диләр.

RUHIAT

Остазлары: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле вә гайреләр.

Шәкертләре: Җәгъфәр бине Габди әс-Сәфәри, Насреддин бине Зәйнүш әл-Калмакый, Бикмөхәммәд бине Зәйнеддин әл-Бәшири, Фазлулла бине Гыйсмәтулла әл-Күли, Габдеддәйан бине Зәйнеддин әл-Ибрайи, Габделхәким бине Габделлатыйф әт-Теләши һәм башкалар.

Балалары: Мифтахеддин, Шәмседдин, Фәхреддин, Сәгъдеддин, Габделҗәббар, Фәттахеддин, Фәхренниса, Бәдренниса. Мифтахеддин шәкерт вакытында, Шәмседдин Шәриф авылында имам булып торганда вафат, Сәйфеддин бине Әбүбәкер әс-Сабавый шәкертләреннән булган. Бу көндә Шәрәфеддин исемле угылы Каршин Шәриф авылында имам. Фәхреддин, Җиһангир хан бине Бүкәй хан хозурында торып, аның бертуган карендәшенә никахланган вә шул вилайәттә вафат булган. Сәгъдеддин, унбиш ел дәвамында Мәдинәдә мөҗавир-кабер сакчысы булганнан соң, ахирәткә сәфәр кылган, нәселе калмаган икән. Габделҗәббар Бөре өязендәге Чишмә Сарт авылында вә Фәттахеддин Уфа янындагы Мәмәк авылында имам булып, вафатлар. Нәриман хәзрәтнең хатыны Шәмсия бинте Сәфәр иде. Мәдрәсәсендә язылган китаплар вә тарихлары: 1) «Шәрхе Мәрах». «Моны Габделгалим бине мелла Йосыф остазыбыз Нәриман бине Сөләйман мәдрәсәсендә 1806 елда язды». 2) «Мөгыйнел-хөккям». «1814 елның 1 җөмадиел-әүвәлендә Нәриман бине Сөләйман мәдрәсәсендә. Күчереп язучы Габделхәким бине дамелла Габделләтыйф бине Габделгазиз». Соңгысы Нәриман бине Сөләйманның үзенең тезмә әсәре, «Асар»да урын алган. // [176]

### 132. Җәгъфәр бине Габди бине Исхак бине Котлыгмөхәммәд бине Нәриман

Асылы Уфа ягындагы Чишмә исемле тимер юл тукталышыннан ун чакрымда булган Сәфәр авылыннан. Атасы Габди бине Исхак вафат булгач, анасы Рәҗәб бинте Хәлил бине Асылхуҗа бине Әмирхан бине Шәриф исемле хатын Арыслан авылының Балтач бине Гакәшә бине Сөбхан исемле кешегә никах ителгән. // [177] Җәгъфәр бине Габди дә әлеге зат тәрбиясендә үскән. Нәриман бине Сөләйман вә башкалар хозурында укыганнан соң, Бохара ягына киткән. Кабул шәһәренә барып, Фәезхан бине Хозырхан хозурында тәрбия ителгән вә ишанлыкка рөхсәт алган. Җитмеш җиде яшендә, 1239/1824 елда Мөхәррәм әл-хәрам әүвәлендә вафат булып, Үршәк елгасының уң ягындагы Тимошка каберлегендә җирләнгән. Бервакытта никахында җыелган хатыннары: Сәгыйдә, Мәгърифә. Болардан башкалары да булуы сөйләнә.

Балалары: Һөмаюн, Көтәбун, Фатыйма, Фәрхисорур һәм башкалар.

Шәкертләре: Габбас бине Габдеррәшид әл-Күшәри, Рәхмәтулла бине Морадбакый әт-Тактавый, Насреддин бине Зәйнүш әл-Калмакый, Габделҗәлил бине Мирсәлим әл-Ахунди, Хәсән бине Әбүталиб әл-Гомәри һәм башкалар.

Дәвамчылары: Рәхмәтулла бине Морадбакый әт-Тактавый, Әхмәд әл-Эстәрли, Насреддин бине Зәйнүш әл-Калмакый вә гайреләр. Үз кулы вә үз язуы илә язылган бер хаты бу урында бирелә:

«Гыйzzәтлебез дамелла Ибнейәмингә догаларыбызны юлладык. Күп елларга сау вә сәламәт буласыз. Бу тарафта, Аллага шөкер, хәер-догаларыгызда сау-сәламәтбез. Андагы умарталарны, балларын карап алган булсагыз, бу хат аркылы җибәрегез, никадәре булыр... Башка язар нәрсә юк. Догачы хадимегез Җәгъфәр бине Габди. 9 март, 1814 елда».

Тирә-якта Җәгъфәр ишан дип мәшһүр булган зат шушы кешедер. Бик тә күңелле вә көлке сөйләүче кеше булып, кайбер вакытта төрле уен коралларында уйнавы да мәгълүм. Кайбер вакыт нәсыйхәт вә хикмәтле сүзләр сөйләгән. Бу зат хакында халык ике төркем булып, бере инкяр вә гайбәт иткән, ә икенчесе исә үзенә тартып торучы вә хак вәли дип инанганнар. Дуслары вә якыннары бик күп булып, Уфа, Казан, Пермь якларына сибелгән. Нәсел-нәсәбе бу көнгә кадәр исән булып, һаман да могтәбәрдер. Күбрәк // [178] гомере Үршәк елгасы буендагы Тимошка авылында булып (бу авылны беренчеләрдән Тимошка исемле бер чуаш нигезләгән икән), һәр ел саен Казан вә Пермь вилайәтләренә сәяхәт итә торган булган. Казанга баруында Кичүчат авылында бабабыз Сөбханкол (кара: 90) бине Бикмөхәммәд өенә төшеп, бер-ике көн кунак булган. Күбрәк вакытта бай вә түрәләр кыяфәтендә, тәкәллефле йөри торган булган. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Бер мәҗлестә мирзалар җыелып, үзләренең шәҗәрәләрендәге бабаларының мирзалык хасил итүләре хакында, безнең фәлән бабабыз фәлән хезмәт сәбәпле мирзалык алган, вә фәлән бабабыз мондый хезмәте илә мирзалык хасил иткән, дип, һәрберсе ата вә бабалары илә горурланганда, Җәгъфәр ишан да, сүзгә керешеп, безнең атабыз да ахыр гомерендә мирза булып вафат итте, дигән. Моңа исә мирзалар бик гаҗәпләнеп (чөнки аларның күпләре мирзалыкны олуг камиллек дип саныйлар, шуның өчен бу кәмаләтнең икенче бер кешедә булуына бик тә гаҗәпләнәләр), һәммәсе дә бертавыштан: «Хәзрәт, атагыз ни сәбәпле шулай ахыр гомерендә мирза булды?» – диюләренә: «Гакылы бетте, намаз укымады, аяк өсте бәвел итте, тәмәке тартты – моннан артык мирзалык булырмы?» – дигән. Хасталыкларыннан сәламәтләнү өмете илә хәер-дога алыр вә өшкертер өчен килүчеләрнең кайберләренә фәлән кадәр бирсен, дип, сәүдә вә базарлык

итә икән. «Хәзрәт, минем ул кадәр байлыгым вә көчем җитми» диючегә: «Тергезәсең килсә табарсың», – дип әйтә икән. Чыннан да, дога укыган вә өшкерткән авырулары сәламәтләнә икән. Бохарада вакытында кайбер шәкертләр үзеннән таяныч алырга ният итеп йөрсә дә, кайбер гадәтләреннән нәфрәт итеп, икенче бер шәехкә тапшырылырга теләгән, шул вакытта төшендә бер бөркет, бер зур үләксәне күтәреп килеп, бер зур күлгә ташлавын күргән. Төшен һичкемгә фаш итми йөргәндә, Җәгъфәр ишанга туры килеп сәлам биргән. Җәгъфәр ишан да үз гадәтенчә: «Вә галәйкүм әс-сәлам! Белдеңме бөркет ни-нәрсә, үләксә илә күл ни-нәрсә? Син белмәсәң, мин әйтәм: бөркет мин идем, үләксә минем нәфесем иде, күл исә гыйлем вә мәгърифәт иде. Мин нәфесемне гыйлем вә мәгърифәт күленә батырдым», – дигән. // [179]

Хаҗ сәфәрендә диңгездә куәтле давыл калкып, көймә халкы һәммәсе җаннарыннан өмет өзеп, тәүбә итеп вә гафу сорап, куркып, котлары очып еларга керешкәндә, Җәгъфәр ишан, көймәнең бер урынында үзенең кәефендә рәхәт-рәхәт тамаша иткәндә, халыкка мөрәҗәгать итеп: «Артыгыздан төшкәч кенә тәүбә хәтерегезгә килгән икән, андый тәүбәдән файда юк, алданрак кирәк иде!» – дип көлгән икән. Җәгъфәр ишанның бу көймә хикәясе Мәдинә шәһәрендә гаять куркыныч җил чыгып, һәммә халык куркуга төшкән вакытта Әбү Исхак әл-Мизбәд исемле бер кешенең йорттан йортка кереп: «Тәүбә итәргә ашыга күрмәгез, моның кебек эшләргә генә каушарга ярамый, хәзер бетәр!» – дип, халыкны юатып, шаяртып йөрүен хәтергә китерә. Үзенә Габделлатыйф бине Габделгазиз[51] исемле кеше вә мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен вә кайбер тарикать шәехләре вә тарафдарлары аеруча дошман булулары сөйләнә. Бу сәбәпле аның хакында булган сүзләрнең күбесе яла вә ялган булуы ихтимал. Вафатыннан соң шөһрәт казанган тарафдарларыннан берсе – Насреддин әл-Калмакый. Үршәк елгасындагы Мирас авылының кантон Локман әл-Хәким бине Госман бине Ибраһим бине Мирас[52] үзенә ихласлы булган, вә Мәгърифә исемле хатыны да шушы Локман әл-Хәким кантонның туганы вә Госман кантонның кызы иде, диләр.

Җәйнең иң гүзәл бер вакытында мин дә Уфа шәһәреннән ишан хәзрәтләренең // [180] зияратына бардым. Угылларым Габдеррахман вә Габдеррәшид илә башта Үршәк елгасында икенде намазын укыдык, соңрак җәяүләп беркадәр үргә менеп, каберлеккә кердек вә төрбәләрендә «Салават» вә «Истигъфар» вә башка догаларны укыдык. Төрбәсе гүзәл җирдә булып, өстендә нарат агачлары бар. Хәтта бу агачларны Мирас авылы сыртыннан бик ерактан күреп килгән идек. Өстендәге ташының язуы мондый: «Руми 1823 мизан 18 дә дарелфәнадан дарелбакага күчте. Хаҗ вә ишан вә әфәнде әз-заман 77 ел гомер сөрде. Сәед Җәгъфәр Габди угылы». Язуы гүзәл вә ачык.

Аяк очында Сәгыйдәбану исемле хатыны вә аның төн ягында өч яшендә вафат булган Фәрхисорур исемле кызы күмелгән икән. Төрбәнең тирәсе чуен рәшәткә илә әйләндерелгән вә эченә керер өчен ишек тә куелган. Моны исә 1314/1896 елда Уса шәһәрендә Мөхәммәдгата хәзрәтләре бине Әрмәншаһ әл-Мансурый 300 сум чыгым белән төзеткән. Чыннан да бик гүзәл ясаткан. Чөнки бу каберлек бүген, башкортлар милкеннән чыгып, махсус кешеләр милкенә кергән. Күп вакытлар үтмәсә кирәк, латыш вә немецларга сатылган. Ахирәт өйләре

RUHIAT

[51] Бу кеше, голәмадан булган хәлдә, Уфа шәһәре янындагы Теләш авылында тереклек иткән вә гомерен дә башкортларның җир дәгъваларында вәкил сыйфатында кичергән. Бер борынгы китап ахырында мондый сүзләр күренде: «Уразайбаш авылында остазыбыз Зәйнелгабидин бине Азамат мәдрәсәсендә тәмам булды. Аны Әхтәм бине Монасыйб Габделлатыйф бине Габделгазиз бине Ишкә өчен 1198/1784 елда язды».

[52] Локман кантон, 67 яшеннән узып, 1276/1859 елда вафат булган.

булган каберләре вә Аллаһы өйләре булган мәсҗидләре хөрмәтсез булмаса да, мондый төзек ихатасы булып торуы зарарсыз. Кабереннән аерылып киткән вакытта: «Җәнабыгызның аталары, Сезнең хәбәрегезгә күрә, ахыр гомерләрендә мирза булган хәлдә, хәзер башкортлар мәдәният кәсеп иттеләр, тәрәккый иттеләр, 15–20 яшенә ирешкән яшь егетләр, Сезнең мәзһәбегезгә күрә, һәммәсе мирза булганнар!..» – дип сөйләдем. Әгәр дә сөйләргә кодрәте булса, әлбәттә, хикмәтле бер җавап биргән булыр иде. Мин дә балаларыма бу затның көлкеләрен вә гыйбрәтле сүзләрен, көлкеләре дә кеше көлдерер өчен сөйләнгән сүзләр түгел, бәлки игътибар җәлеп итәр өчен икәнлеген юл буе бәйан иттем.

Бу көндә бер хатыны исән вә ишанның да кайбер хәлләреннән хәбәрдар икәнлеген // [181] ишетсәм дә, хатыннарда булган хәбәр могҗиза вә гадәттән тыш эшләр сөйләүдән башка булмас дип, әлеге хатыннан сорашырга вә кешеләрдән тикшертергә иҗтиһад итә алмадым.

Габделгалләм бине Габделкадыйр әс-Сабавыйдан: «Җәгъфәр ишан әсәрләнүчән кеше иде. Әсәрләнү хәлендә төрле-төрле хәлләрдә булыр вә сүзләр сөйләр. Әмма айныгач, әлеге эшләре хакында елый вә үкенә иде», – дип сөйләве мәгълүм.

### 133. Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен *(кара: 55)* бине Габдеррахман

Русия дәүләтендә Диния Нәзарәтендә иң беренче мөфти булган зат. 68 яшьләрендә 1239 ел, 2 зөлхиҗҗә, пәнҗешәмбе көн (милади илә 1824 ел, июнь 17 көн. Русча басылган юбилей рисаләсенең 40 битендә матбага хатасы буларак июнь язылган) Уфа шәһәрендә вафат булып, үзенең васыяте буенча, Уфадан 60 чакрым кышкы кояш чыгышы ягындагы Атҗитәр авылы каберлегендә күмелгән.

Элек Сәгыйдь вә Оренбург ягында гыйлем алып, Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаныйдан да файда күргән. Соңрак Бохара вә Кабул якларында беркадәр сәяхәт иткән вә гыйлем туплау теләге белән дә йөргән. Риваятьләргә күрә, Гатаулла бине Һади, казый Торсынбакый бине Габдеррәхим һәм башкалар белән аралашкан, Кабулда шәех Фәезхан бине Хозырхан сохбәтендә булган. Камил булмаса да, бу сәфәрендә фарсы телен дә өйрәнгән. // [182]

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Бу мәмләкәткә кайтканнан соң үзенең тырышлыгы вә яхшы иҗтиһады сәбәпле»[53] Русия дәүләтенең олысына вә кечесенә мәгърифәт пәйда итеп, Русиядән вәхшәт вә буйсынудан нәфрәт иткән казакъ вә башкорт вә башка таифәләрне кызыктыру вә куркыту илә буйсындыру хосусында юл күрсәтүче мәэмүр булды, үзенең таләбе яки башка бер сәбәп илә Диния Нәзарәте оештырылгач, биредә башлык һәм мөселманнарның мөфтие итеп билгеләнә. Гаять зур ышаныч казанган бер зат булганга, мәсҗид салырга рөхсәт иткәндә яки берәр кеше хакында «фәлән урынга лаек» дип бер кәгазь язып мөһер сугып биргәндә, сүзе үтә торган булган. Мондый ышаныч, әлбәттә, арзан төшмәгәндер, казыйларны хезмәтчеләре урынына тотып, нинди эш булса да әмер итә торган булган, теләгән кешеләрен казыйлык вазыйфасына чакыра торган булган. Ахыр гомерендә казыйлар арасында абруе шактый төшкән, казыйларының инкяр вә бәхәсләре сәбәпле, Нәзарәтнең хөкемнамәләре прокурор карамагына җибәрелгәннәр. Муллаларга исем сатып, күп дәүләт туплаган. Атабыз Баһаведдин вә Фәтхулла ахун, Байморад бине әл-Мөлкәри һәм башкалар моның камиллеген вә гыйлеме күплеген раслыйлар, ләкин язган риваятьләре вә

[53] «Мәҗмәгыль-имсаль лилмәйдани», 2 нче кисәк, 192 биткә мөрәҗәгать ителде.



RUHIAT

язу рәвешләре, һич шөбһәсез, зәгыйфь вә сүзләре дә бозык, моннан башка фарсы гыйбарәләре дә гыйлеменең азлыгына вә булдыксызлыгына дәлилдер. Бу фәкыйрь Фәтхулла ахуннар дәрәҗәсеннән күп түбән булып, хәтта Габдессәлам мөфти дәрәҗәсендә булуы да шөбһәледер», – дигән.

Диния Нәзарәтендә 1815 ел белән расланган тәрҗемәи хәлләр (формулярный списка. – *Р.Ф.*) кәгазендә бәйан ителгәннәргә күрә, бу елда мөфти хәзрәтләре илле җиде яшендә булган (ягъни 1171/1758 ел ахырында дөньяга килгән буладыр). Мирзаәхмәд исемле улы 19 яшендә булып, Петербургта чит диннәрне карый торган мәхкәмә хезмәтендә булган.

Мирзашаһбик 10 яшендә, Мирзаҗан 6 яшендә булган. Вә башка рәсми // [183] кәгазьләргә күрә, Мөхәммәдҗан мөфти, сәүдәгәр кавеменнән булып, бишенче ревизия хисабына күрә, Уфа ягындагы Хәрәмабад (Солтанай) авылына караган булган. Әүвәлрәк иностранный коллегиядә хисап ителеп, соңрак Оренбургта офицерлык хезмәтендә булган. 1785 елның 9 июлендә чик комиссиясендә кыргызлар өчен ахун булып, соңрак, 1789 елның 22 сентябрендә, Диния Нәзарәтендә җитәкче вә мөселманнарга мөфти булган. Мөфти булганга кадәр кыргызларның Русия дәүләтенә буйсынулары хакында зур хезмәте булып, Кавказ якларына барып, Русия әсирләрен азат иттергән вә кабарты [кабардин] таифәсен Русия кул астына керүгә ант иттергән. Әстерханнан көнчыгыштагы төрекмәннәр арасында сәяхәт итеп, Русиянең абруен күтәргән. Бу хезмәтләре өчен Русия дәүләтеннән бүләкләр алган. Императрица Екатерина вә император Павел бине Петр җәнабыннан бриллиант илә зиннәтләнгән медаль вә Оренбург шәһәрендә казнадан бер йорт вә моннан башка төрле вакытта күп акчалар вә киемнәр бирелгән.

Мөфти хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлләреннән әүвәлге өлеше безгә караңгы. Кешеләр Бохарадан килеп мөдәррис булулары вә Кабулдан кайтып шәехлек иткән хәлдә, ни сәбәпкә нигезләнептер ки, бу зат Бохара вә Кабулдан килеп офицер булган, диләр. Фәлсәфә тарихы гыйлеме илә шөгыльләнгән затлардан берсе бу кешенең Бохара вә Кабулда ислам гыйлемен камил үзләштерү өчен йөрми, бәлки әүвәл эштән Русия тарафыннан җибәрелүен вә сәясәткә бәйле эшләр белән шөгыльләнеп көн кичерүе турында фикер йөртә. Хакыйкатьне Аллаһы җәнаплары белер. Мөфти булгач, тормышын бик тәкәллефле сурәткә куеп, киемсалым, ат вә туннары, зиннәт вә бәһале нәрсәләре булганнар икән. Шәһәр урамында дүртәр ат җиктереп, дәрәҗәсен белеп йөри торган булган. Никадәр генә бәхет кояшы тәмам югары күтәрелеп бетсә дә, // [184] ахыр гомерендә дәрәҗәсе тәмам бетеп, халык арасындагы абруе сүнгән. Вә дөньяның мәртәбәсендә карар, байлыгында да рәхәт вә ныклык юклыгын, бәхете сүнеп баруын күреп, вафат булуы сөйләнә. Алтыны, хисапсыз хайваны, йортлар вә җиһазлары, Уфа ягындагы башкортлардан юк кына бәяләр белән алынган ничә урыннардагы җирләре мирас булып калган. Бары Атҗитәр авылындагы җире дә 2284 дисәтинә булып, моны исә гаять арзан хак илә Үршәк буендагы Мирас авылы башкортларыннан алган.

Мөфти хәзрәтләренең Гайшә исемле бер хатыны үзеннән алда вафат булган. Риваятьләргә күрә, элек Русия илә Төркия арасындагы сугышларның берсендә әсир алынган төрек кызы булып, башта Казан шәһәрендә Исмәгыйль бине Апанайда никахта булып, Исхак вә Хәбибҗамал исемле балалары туган, ә Исмәгыйль вафаты соңында мөфтигә никахланган вә 79 яшендә 1209/1795 елда Казанда вафат булып, ике бистә арасындагы зиратта җирләнгән.

Кәримә исемле хатынының туган җире Кара диңгез буендагы Анафа шәһәре икән. Мөфти вафат булганнан соң, кызы Фатыйма янына китеп, Җиһангир хан тәрбиясендә дөнья кичереп вафат булган, диләр.

Суфия исемле хатыны чиркәс кызы булып, 1172/1759 елда дөньяга килгән. Мөфтинең угыллары бу хатыннан. Мөфти вафат булгач, Атҗитәр авылындагы милекләрендә тереклек иткән вә һәр әгъзасы тәмам сәламәт хәлдә, 110 яшенә җитеп, 1866 елның 2 мартында вафат булган, мөфти төрбәсе вә мөселманнар зиратыннан төньякка таба бер чакрым сахрада бер түбә өстендә җирләнгән.

Мирзаәхмәд, мал туздырып, бөтен гомерен, һичбер эшсез, Анфиска дип танылган бер рус кызы илә кичергән. Үз милкендәге // [185] йортында (мөфти хәзрәттән мирас булып калган йортта) әлеге хатын илә бикләнеп ятуы вә кайсыбер вакытта Уфа шәһәренә барып килеп йөрүе билгеле. Аңардан дүрт кызы булып, Д... исемле кызының балалары Уфа шәһәрендә күп, кайберләренең, хосусый буларак, маҗаралары да сөйләнә. Мирзаәхмәднең (Мирзакайның) мөфти хәзрәтләреннән мирас итеп алган милке вә җирләре шушы мөселман булмаган дүрт кызына калган. Шулай ук анасы Суфия шушы дүрт кызга 500 дисәтинә җирен вафатына кадәр үк мәхкәмәләрдә яздырып тапшырган.

Ләкин Күди башкортларында булган җирләре халык илә тоташтан ничә еллар дәгъва ителгәннән соң, мөфти хәзрәт варисларына түгел, бәлки башкортлар милкенә кире кайтарылган. Ләкин башкорт халкының бу дөнья йөзендә булган бөтен әмәле вә ахирәттә дә файдасын күрү өмете илә калган ихлас гамәле туфрак (җир) сату булганга, Мөхәммәдҗан мөфтидән кайткан җирләрен Күди башкортлары тиз көндә немецларга, латышларга шалкан илә ширпы бәһасенә сатылачак вә яки сатылгандыр.

Мирзаәхмәднең кабере анасы Суфия кабере илә янәшә булып, өсләрендә таш вә ихата-фәлән юк. Боларның болай бер тарафта күмелүләренең сәбәбен, Атҗитәр халкы илә даими низаг белән торганга, әлеге авыл халкының үз каберлекләренә күмдерергә риза булмаулары, диләр. Шуңа үз җирләренә күмелгәннәр икән. Болар үлгән вакытта мондый бер васыять тә булуы ихтимал.

Әмирҗан исемле угылы Оренбургта гаскәри хезмәттә булып, офицер иде. Якынча 1850–1860 елларда вафат булган. Үзеннән бер хатыны[54] илә Хөсни исемле бары бер баласы калды. Хатыны Бикмәй фамилиясеннән Гайса мирза исемле берәүгә никах ителде. Мөхәммәдҗан // [186] мөфтидән калган китапларның бер өлеше шушы хатын аша әлеге Гайса мирза милкенә күчүе сөйләнә.

Фатыйма исемле кызы казакъ вә Бүкәй иле ханнарыннан Җиһангир хан бине Бүкәй хан никахында булып, Ибраһим, Әхмәд, Гобәйдулла исемле угыллары; Зөләйха, Хәдичә исемле кызлары дөньяга килгән. (Җиһангир хан тәрҗемәсенә карагыз.)

Мөфти хәзрәтенең дөрес бәхетле вә үзенең дә хәер илә исеме хәтердә калуына сәбәпче баласы шушы Фатыйма булган, диләр. Чөнки барлык туганнарыннан аермалы буларак, гаять диндар, тәкъва, инсафлы, гакыллы, уйлап эш итүчән бер хатын булып, ханның мәхәббәтен җәлеп иткән вә ханның үзен тәрбия иткән кебек, бөтен Бүкәй иленә мәдәният керүенә сәбәп булган. Казакъ гаиләләренә шәхсән үзе гореф-гадәтләренең гүзәл булганнарын өйрәткән, ә исламга туры килмәгәннәрен кире каккан, тәһарәт вә пакьлеккә аеруча зур игътибар биргән. Хан хатыны булып барганнан соң, Бүкәй иле белән Оренбург, Уфа вилайәтләре арасында килеп-китеп йөрү халык арасында таралу белән арада бөек бер дуслык вә танышлык пәйда булган. Казакъларның дәүләтлеләренең угылларын үз байлыкларыннан, мохтаҗ вә фәкыйрьләрнең балаларын үз кесәсеннән чыгым тотып, Эстәрлетамак вә Эстәрлебаштагы мөселман мәдрәсәләренә җибәреп укыткаңнар. Бүкәй илендә бу көндә булган могтәбәр галимнәр һәм танылган мөдәр-

[54] Моның Хөсниҗамал бинте Габдессаттар исемле бер хатыны бар иде.

рисләр әлеге ике мәдрәсәнең вә аларны тәрбияләгән шәехләрнең тәрбия җимешләреннән. Җиһангир ханның, мәсҗид салдырып, һәртөрле ыруг вә кабиләләргә имамнар билгеләве вә аларга рәсми сурәттә хокук кәгазе биреп, мәхәллә балаларын укыту вә сабыйларга борынгылардан калган исем бирү нәтиҗәсендә танылуы шушы хатынның уйлап эшләве белән булган.

Мөфти хәзрәт хөкем астында калып, зур җәфалар чиккән вакытында вафат булдымы, юкса болай бәлаләрдән азат буларак, эштән бушанып, гыйлем туплый идеме? Бу турыда ачык мәгълүмат юк.

Бу җирне акка күчергән вакытта махсус Атҗитәр авылына бардым. // [187] Юл буенча мөфти хәзрәтнең китап илә тулы китапханәсенә керермен, нинди китаплары бар икән, Бохара, Кабул якларыннан китергән борынгы әсәрләрен карар идем, төрле галимнәр вә бөекләрдән килгән хатларны укырмын вә монда карарсыз файда вә мәгълүмат туплармын, дип барган идем. Ләкин баруыма хәрабәгә әйләнеп баручы бер төрбәдән башка һичбер әсәр вә билге күрмәдем.

Баш очындагы зур таш гүзәл рәсем илә батырып язылган. Иң әүвәл юлы түгәрәкләнеп язылган аять шәрифеннән гыйбарәт булып, аннан соң шушы тугыз юл бар:

1. Һуәл-хәллак әл-бакый [ул – Яратучы, ул – Мәңгелек]
2. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфур [ярлыканган]
3. Шәйхел-ислам вәл-мөслимин мөфти
4. Әл-әнам Мөхәммәдҗан
5. Бине Хөсәен
6. Әл-Болгарый тәваффа [вафат] фи
7. 1239 фил-
8. мизан [1824, сентябрьдә] рухына
9. фатиха.

Сигезенче юлдагы мизан, минем уемча, дөрес түгел. Чөнки мөфтинең вафаты мизан/сентябрьдә түгел, әсәд/июльдә, бу исә рәсми кәгазьләр белән беркетелә. Бәлки, таш мизанда язылганга шулай бирелгәндер.

Кирпечтән төзелгән, бинасы яңартылмаганга, бик искергән, вә тиз көннәрдә харап вә вәйран булачагы ап-ачык.

Мөфти хәзрәтләренең хәл вә тормышы тикшерелгәндә гыйлеменә нисбәтле гакылы // [182] артык вә мәгърифәтенә күрә һиммәте зур булуы аңлашыла. Сөйләргә осталыгы вә кыюлыгы аркасында, гыйлем өлкәсендәге кимчелеген пәрдәләтмичә, хәтта ки башкортлардан үзен бөек гыйлем иясе дип инандырырга муафыйк булган. Якыннарыннан берәү халык арасында мөфтинең карендәше икәнлеген белдерүенә каршы мөфти хәзрәтләре: «Юкны сөйлисең, мөфтинең һич карендәшеме булыр?..» – дип әйткәне мәгълүм. Бу сүзеннән максаты – каза вә хөкем маддәләрендә мөфтинең һич дусты вә карендәше булмас дию, һәрникадәр мөфтилек хезмәтенә күрә бөек бер сүз булса да, беркадәр сәбәбе бар. Әмма үзен олы күреп, башкалардан өстен уйлап сөйләвендә иң һәлакәтле бер фикер илә бәхетсезлеккә дучар булуы ачык күренә. Ислам фикер иясе Ибне Рөшд (Аллаһының рәхмәте булсын) тәрҗемәсен язучылар бер хикәя китерәләр. Ул Мөхәммәдҗан мөфтинең биредә сөйләнгән хәленә туры килә. Ибне Рөшд хәзрәтләре солтан Ягъкуб әл-Мансур илә тәкәллефсез сөйләшү мәртәбәсенә ирешкән бервакытта, солтанга мөрәҗәгать итеп: «Карендәшем!..» – дигән. Бу сүз падишаһларга һич мөнәсәбәтле булмаганга, мәҗлестәге вәзирләрнең йөзләре бозылуын күреп, солтан да: «Дөньяда дус вә карендәш булу нигъмәтеннән солтаннар мәхрүм, ләкин мин андый мәхрүм падишаһ вә солтаннардан түгелмен, чөнки минем дустым бар. Ул исә Ибне Рөшд», – дип җавап биргән. Инде Фас падишаһының

RUHIAT

дусты булган хәлдә, Русиядә мөфти булган затның карендәше ни өчен булмасын!..

Мөфти хәзрәтнең русчага гаять тә маһир бер зат булуын сөйләсәләр дә, имзалар сакланмаган.

Уфа шәһәрендә яшәгән урыны үзенең милке булып, Телеграфный илә Пушкин урамнарының көнчыгыш почмагында булган. Аның йортлары агач булганга, Уфа шәһәрендәге янгыннар вакытында юкка чыккан вә аның җиренә таш бина салынган. Ихтималга күрә, Диния Нәзарәте дә үз биналарының берсендә булган.

Язган хөкемнамәләрен күрү өчен зур тырышлык сарыф ителеп, табу җиңел булмады. Фәкать сигез хаты вә моннан әүвәлге дүртесе // [189] үз язуы илә, хәтта ялгышларын үз хәлендә калдырып, биредә китерелә[55].

### *Мөляхәзә*

Үзебезнең ана телебез төрки телебез булган хәлдә, мөфти хәзрәтләре ошбу әмер вә фәтваларны ни сәбәпкә нигезләнеп фарсы телендә язган? Моның исә, әлбәттә, берәр хикмәте булыр. Фәкать бу хикмәт безгә әле билгеле түгел. Фәнни китапларны вә яки бөтен дөнья халкы куллануына лаек әсәрләрне (кагыйдәләрне муафыйк язу шарты белән) фарсы яки гарәп телендә язу зарарлы булмас. Ләкин мөфти хәзрәтләренең биредә аталган әсәрләре гомум ислам галәменә кагылышлы нәрсәләр булмаган кебек, фәнни бәхәсләр дә түгел. Хәл болай икән, үз ата-бабаларыбыз вә сөекле аналарыбыздан бөек бер ядкәр буларак калган телебезне читкә куеп, фарсыча язуыбыз – кирәк тәмам кагыйдәсенә туры китереп язылсын – һичбер вакыт гафу ителмәячәк көфер нигъмәт булыр. // [195]

Гәрчә элек яулап алынган заманда ислам дәүләте Гыйрак вилайәтләрендә фарсы телен рәсми сурәттә куллансалар да, бу бары тик җирле халыкның хәтере өчен генә булган. Шушы ук сәбәп белән Мисырда кобыт, Сүриядә рум язуын рәсми кулланылуы турында сөйләнелә. Бераз вакыт узуга, бу гадәтләр бетерелеп, гарәп теле кулланыла башлаган.

Ни гаҗәп! Тибетта утыручы лама үз диндәшләре вә җенестәшләренә фәрман вә дини нәсыйхәт язганда гарәп вә яки латин телендә язамы икән?.. Минемчә, бу зат хат җибәрәсе кавемнәрнең үз телләрендә һәм иң ачык сурәттә язар иде. Безнең мөфти хәзрәтләре исә Тимербай, Сәвәләй башкортларына иң мөһим фәрманнарын ни өчен фарсы телендә язган?.. Язылган кавемнең хәле кайгыртылса, үз телләрендә, утырган урыны кайгыртылса, дәүләт теле булган русча язылырга тиеш иде.

Телебез ярлы, сөйләшергә вә язарга җитми дип дәгъва иткән карендәшләребезнең сүзләре укучыларга бер нәрсә язмауга, язылганнары укымауга ялкаулык икәнлеген яшерер өчен корылган бер пәрдә. Тиешле урында бу сүз дөрес бер сүз дә булсын, ләкин телләрне баетучылар вә киңәйтүчеләр алар илә сөйләүче вә язучы адәмнәр булса кирәк, юкса тик торган вә яки юеш урында тутыгып яткан тимер кебек бозылып яткан хәлдә һичбер телнең баеганы вә мәйданга чыкканы, минемчә, ишетелгәне юк.

Шул сәбәпле Казан шәһәрендә гарәби хәреф илә 1177/1764 елда ачылган матбагадан әдәбиятыбыз кирәк дәрәҗәдә файдалана алмады. Чөнки 100 ел эчендә таралган китапларыбыз вә рисаләләребезнең 5–10 тирәсе саналмаганда, бары тик гомер ашаучы вә вакыт үтерүче нәрсәләр генә булыр.

RUHIAT

---

[55] Р.Фәхреддин Мөхәммәдҗан мөфтинең кыска-кыска сигез хатын китерә. Аларның алтысы фарсы, икесе татар телендә. Мөһим мәгълүматлар булмау сәбәпле, хатларның тәрҗемәләре биредә китерелмәде. – *Төз.*

Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә күп шөкерләр булсын ки, күктәге Кояш файдасы илә аналардан ядкәр калган тел нигъмәте һичбер җирдә һичбер кавемгә артык күрелмәс. // [196]

### *Мөфти хәзрәтләренә язылган хатлар*

*Беренче хат.*

Духовный собрание шушы 1810 елның июнь көннәрендә олуг император Александр Павловичның фәрманы илә мине, Рахманколый углын, Мәкәрҗә ярминкәсендәге мәсҗидтә мөселман сәүдәгәрләргә имам буларак намаз укырга вә башка дини эшләрне үтәргә җибәргән иде. Мин исә әлеге әмер буенча боерылган хезмәтләрне үтәгәндә, Казан губернасы Сары Кукшай (Царевококшайск) өязе Оры иленең указлы имамы Хәбибулла Хөсәен угылы минем хезмәтемә тарлык ясады. Бу гамәленә Казан шәһәренең гражданский губернаторыннан указым бар, дип, сәбәбен күрсәтә. Икенче, Казан шәһәрендә Иске бистәнең Өченче таш мәсҗид мулласы Сәгыйдь ахун да минем хезмәтемә тарлык күрсәтте. Хәлбуки һичбер урыннан әмере юк. Тиешле булган мәхкәмәләргә мәгълүм итми, үзенең хезмәтен ташлап, монда килгән. Шулай ук үзенең мөәззине Халидне дә бергә алып килеп, мөәззин куяр өчен миңа ихтыяр бирмәде. Иске бистәнең агач мәсҗидендә имам Мортаза да монда килгән. Болардан башка кешеләрдән тарлык булмады. Шулай ук мәсҗидкә караган кибетләрдән җыелган акча Иске бистәнең сәүдәгәр Бәшир Гаед углында калып, безгә бөтенләй акча бирелмәде. Мәсҗид ерак булганга, тактадан мәсҗид ясатып, намаз кылдык, падишаһыбыз император хәзрәтләренә дога укыдык. Чистай өязе Кече Бахта волосте Колай авылында имам, мөдәррис, мөхтәсиб Әбүшәхмә Рахманколый угылы. 1810 ел, 18 сентябрьдә.

RUHIAT

*Икенче хат.*

Тиешле мәхкәмәләрдән рөхсәт алмаган хәлдә Сары Кукшай өязе Оры авылының Хәбибулла мелла Хөсәен углының Петербург шәһәренә баруын, быел 20 гыйнвар һәм 2 мартта булган кәгазьләрегез илә күрсәтелгәннәргә нигезләнеп, мин падишаһ император хәзрәтләренә // [197] мөрәҗәгать иттем. Әлеге мелла Хөсәен углын үз авылына кайтарып җибәрү хакында император хәзрәтләре фәрман чыгарды. Бөек император хәзрәтләрен мондый бөек чараларын җәнабыгызга шушы кәгазь илә белдердем. Князь Лопухин. 1804 ел, 14 апрель.

*Өченче хат.*

9 нчы санда булган язуыгызга күрә бәйан итәм: Орының мелла Хәбибулла Хөсәен угылы мөселманнар арасында гыйбадәт үткәрергә лаек булса кирәк. Чөнки мөселманнарның дин хезмәтләрен үтәүгә рөхсәт ителеп, 1802 елның 4 сентябрендә Бөек император хәзрәтләренең Указлары әлеге затка бирелгән.

Икенче, 1810 елның июнь аенда мөселман сәүдәгәрләре, гариза биреп, әлеге Хөсәен углын имамлык өчен билгеләргә миннән сораганнар иде. Шуңа күрә ярминкәгә килгән мөселманнарга имамлык өчен мәгълүм Хөсәен углын расларга Нижгород губернаторына фәрман язган идем. Моны исә сезгә бәйан итәм. 1765 нче номер. 1811 ел, 29 март. Петербург. Имзасы ачык түгел. Башкача тамгалар юк.

*Дүртенче хат.*

[1812 елның 12 мартында Петербургтан князь Александр Голицын тарафыннан Хәбибулла Хөсәен углын яклап язылган.] // [199]

*Бишенче хат.*

Үткән 1812 елның 12 октябрендә язганыгызга мөнәсәбәтле рәвештә, Хөсәен угылы хакында Казан губернаторыннан сорадым. Казан губернаторы исә, тикшергәннән соң, әлеге шәхесне гүзәл холыклы вә инсафлы бер зат дип тапкан икән. Тикшерү кәгазенең күчермәсе дә шушы хат илә Сезгә җибәрелде. Шул сәбәпле, минем фикеремчә, бу зат илә булган дәгъваларыгызны бетерү тиештер. Кенәз Александр Голицын. 381 нче номер. 1813 ел, 21 август. Санкт-Петербург.

### ***Мөляхәзә***

Бу хатларның беренчесеннән башкасы, фәкать эчтәлеген биреп, тәрҗемә ителгән мөфтинең үз хатлары бигрәк озын булганга һәм үткән гасыр гадәте буенча, язуы танылмаганга һәм бик төгәл булмаганга, тәрҗемәсеннән ваз кичелде. Ни булса да, Хәбибулла ишанны хөрмәтләмәве, мактамавы язган кадәребездән дә мәгълүм була. Фикеребезчә, Хәбибулла ишанга бу кадәр ачу күзе белән каравы әлеге затның мөфти булуыннан куркудан. Хәтта моны бер-ике хатында кенәз Голицынга да сөйләгән. Мөфти белән үзара хәбәрләшкән кенәз Голицын шул заманда синод идарәсендә обер-прокурор вазыйфасында булган икән. // [200]

Мөфти хәзрәт заманында мөселманнарны җирләр өчен үзләренә махсус бер каберлек вә җәмәгать намазы укыр өчен мәсҗид Уфа шәһәрендә булмавы сөйләнелә. Фәкать моның мәслихәт күрүе белән Казан шәһәрендә кайбер нәрсәләр басылган, моның өчен үзен кулыбыздан килгән кадәр хәер-дога илә искә алу безнең бурычыбыз. Бу уңайдан Габделгазиз Туктамыш угылы тарафыннан 171 битле 1802 елда Мөхәммәд бине Бәркиленең (Мөхәммәд әфәнде Бәркәви) тезмә бер әсәре басылып, ахырында: «Мөхәммәдҗан мөфти фәтвасы илә», – дип, бер гыйбарә бирелгән. Моннан башка әүвәл Ислам мәхкәмәсе ачып юлга куюы вә Диния Нәзарәтен рәсми сурәттә мәхкәмәләргә кабул иттерү дәрәҗәләренә китерү аз мәшәкать илә мәйданга килмәгән. Мондый эшләрнең гамәлгә чыгуы көч җитмәстәй тырышлык сарыф ителүгә бәйле икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре һәрникадәр гафу вә гофран әйләсен!

### **134. Әбелмәних бине Әбелфәез бине Габдессәлам** (кара: 37) **бине Урай**

Сәгыйдь бистәсендә (Каргалыда) мәшһүр бер әдип вә шагыйрь. «Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних» исемле әсәре элекке елларда басылган кебек, соңрак 1889 елда Казан шәһәрендә 34 битле булып басылды. Бу кеше 1231/1816 елда, Мөхәммәдйосыф исемле бер илчегә юлдаш булып, Истанбул шәһәренә барган вә аннан // [201], Хиҗазга китеп, Мәккә, Мәдинә шәһәрләрен зиярәт кылган. Кырык яшендә икенче тапкыр хаҗга бару максатында асыл ватаны белән саубуллашып чыгып киткән вә бу сәфәрендә 1240/1825 елда вафат булган, диләр.

Кайбер шигырьләре биредә китерелә[56].

Хөлүс үзрә йөри мөшкелләре асан идән улдыр,
Тәвәккәл әһленә ихсан ки мәүля бихисаб әйләр.

[56] Төп нөсхәдә өч шигыре урын алган.

RUHIAT

Сакыйн бәхер гам алама гаувас улма сабыр әйлә,
Ходай мөстәган, әлбәттә, беркөн фәтхе баб әйләр.
Хәзин улма, бу дөнья кемлегенә гамь бөйлә, әй, яр!
Хода беркөн кара бәхетең сәнең һәм маһитаб әйләр. // [203]

Һай, шулай булса иде!..

Бу урында язылган шигырьләр һичбер җирдә вә һичбер гасырда йөз кызартачак түгелләр. Кайчандыр Сәгыйдь бистәсендә мондый матур, дөрес язучы шагыйрьләр вә хуш күңелле сөйләүчеләр, мәҗлесләре җан азыгы булган саф күңелле әдипләр бик күп булган икән. Хәзер исә болар аз калдылар. Әгәр алга таба да шулай дәвам итсә, бер көн килер, болар да тәмам бетәчәкләр вә урыннарына да кара карга вә байгышлар урнашачаклар.

**135. Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза** (кара: 38) **бине Гали**

Тау ягында Чокалы авылында имам булып, озын гомер сөргән вә 1240/1825 елда вафат булган.

Остазлары: үзенең атасы Мозаффар вә Габдеррәшид бине Мөхәммәд әл-Байланлары.

Балалары: Габденнасыйр, Хәмәди, Зиядә.

**136. Салих бине Сәгыйдь бине әл-Хәсән әл-Кили**

Казан шәһәрендә икенче таш мәсҗидтә имам вә мөдәррис булып, 1240/1825 елда вафат булган. Кабере Казан каберлегендә. Чыгышы Казан ягындагы Кили авылыннан булган. Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле хозурында гыйлем алганнан соң, Бохарага барып, Гата бине Һади әл-Бохарый вә башкалардан укыган. 1199/1785 елда Бохарадан кайтып, Иске Кенәр авылында укыткан. Вә аннан Казанга күчкән һәм, зур мәдрәсәләр тотып, анда да укыту белән шөгыльләнгән. Балалары Габделвәли, Габделгани, Габдессаттар исемле булып, хәзерге вакытта нәселе юкка чыккан.

Шәкертләре: Габдессаттар бине Сәгыйдь, Габделгаффар бине Сәгыйдь, Максуд бине Корбангали әл-Күлбаши, Хөснеддин бине Ибраһим әл-Әначи, Фәтхулла бине Сәфәр әл-Мәнәвези, Габдессәлам бине Мортаза һәм башкалар. Олы бәдәнле, тиз җаваплы, нәфис сөйләүче, киеме яхшы, шәкерте күп булган, диләр.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани болай дигән: «Кенәр авылыннан Казанга күчеп килгәннән соң, Кенәр карчыкларының «исәнмәле Саликъ!..» диюләреннән котылдым, дигән. Бервакыт берәүнең: «Хәзрәт, син яхшы мулла булгансың, юкса ат карагы булыр идең!» – диюенә каршы: «Әлбәттә, бер кәсеп кирәк!..» – дигән. Бер җиргә кунакка барып, бер чынаяк чәй эчеп каплагач, йорт хуҗасы: «Хәзрәт, сине алтмыш чынаяк чәй эчә, диләр иде, хәлбуки бер чынаяк эчеп канәгатьләндең», – диюенә: «Илле тугызны өйдә эчеп чыккан идем», – дигән. Бер җәмгыятьтә араларында низаг чыгып, Ибраһим әфәнденең: «Син кәфер!» – диюенә җавап итеп: «Әфәнде! Син кәфер, дигән булган идең, иманны онытып тора идем, күптәннән шәһадәт кәлимәсен әйткәнем юк иде, ләә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүлуллаһы», – дигән».

Моның заманында Казан шәһәрендә гимназиядә тәрҗемәче булган Ибраһим бине Исхак бине Сәгыйдь исемле кеше карамагында Әбелгазый Мөхәммәд бине Гарәбхан бине Хаҗимөхәммәд әл-Хәрәзми әсәре булган «Шәҗәрәи төрек» исемле мәшһүр тарихы басылган.

## *Үтенеч*

Рисаләбездә арттырырга вә яки төшерергә тиешле кайбер сүзләр, ихтимал ки, каләмебез хата язган урыннар булыр. Чөнки тулы камиллек Аллаһы Тәгаләгә генә хас сыйфат. Әгәр дә укучылар мондый нәрсәләрне безгә белдерсәләр яки язылырга тиешле тәрҗемәләрне һәдия итсәләр, рәхмәтләр белән кабул кылырбыз. Китапның мәсләгенә каршы булмаган тәкъдирдә, ни язсалар да, икенче басмага кертелер.

*Бер хат.*

«Әфәндем! Күп кешеләр: «Асар»ны язучы юк нәрсә илә шөгыльләнә, кабер ташларын күчерүдә ни файда булыр? Моның кебек нәрсәләр гыйлем саналырмы?» – диләр. Берәр мөмкин урында җавап яза алмассызмы?»

*Җавап.*

«Булмас, туганым! «Асар»ны мин алар өчен түгел, бәлки киләчәк буыннар өчен язам. Сөекле киләчәк буыннарыбыз кабул итәр дип уйлаган нәрсәләрне язудан, гасырдашларымның инкярләреннән куркып, тукталачак түгелмен. Җәнабы Аллаһы ярдәм итсә, «Асар»ны, һичшиксез, язачакмын.

Ризаэддин».

RUHIAT

## БИШЕНЧЕ КИСӘК

برنچی جلد

# آثار

سکنمزده اولان اسلام عالملرینك ومشهور کیمسه‌لرینك ترجمه وطبقه‌لری، اریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش برکتابدر.

بشنچی جزء

RUHIAT

صاحبی
رضاءالدین بن فخرالدین

اوفا — ۱۳۲۱

جزى الله خيرا كل من كان ناظرا * لمجموعتي هذي بستر القبائح
واصلح ما فيها من العيب كله * فهذا الذي ارجوه من كل ناصح

ویسف بلادسنده « خدمت شرکتی » مصارفیله نشر اولندی .

Дозволено цензурою С.-Петербургъ, 29 Декабря 1903 г.
Оренбургъ, типографія М.-Ф. Г. Каримова 1904 г.

### 137. Сәйфеддин бине Әбүбәкер бине Сәлим әш-Шыңарый

Мамадыш ягындагы Шыңар дигән авылдан. Сабада имам вә мөдәррис булып, 1824 елның февраль башында хаҗ нияте белән Сабадан чыгып, Кырым мәмләкәте һәм Кара диңгезне кичеп, Амасия шәһәренә барган вә анда 1240 елның сәфәр аенда/1824 елның сентябрь башында вафат булган. («Мөстәфадел-әхбар...»ның 200 нче битендә «Мөхәррәмнең алтысы вә шобат әүвәлендә сәфәр итде» дигән сүзләр типография хатасы булса кирәк, чөнки Сәйфеддин хәзрәтнең хаҗ сәфәре 1824 елның февраль башында мәгълүм. Бу февраль исә мөхәррәмгә түгел, бәлки җөмадиел-ахиргә туры килгән.)

Остазлары: Габделхаликъ бине Әгъзам әт-Тенеки әл-Казый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный; Бохарада Мөхәммәдгата әл-Бохарый, Кабулда шәех Фәезхан бине Хозырхан һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Рәмкол бине Максуд әл-Иштирәки, Габделгафур бине Габделмәннан әл-Чистайи, Җарулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышый, Габделләтыйф бине Әбүбәкер әл-Йолыкый, Габделгалләм бине Габделкадыйр әш-Шәрифи, Морадым бине Мөхәммәдйосыф әл-Уфавый, Габделваһаб бине Габдеррәшид әл-Әшири, Мөхәммәд бине Гобәйдулла әл-Ибрайи һәм башкалар.

Балалары: Садреддин, Фәхреддин, Әбелкасыйм, Сәгадәт. Ошбу Сәгадәт исемле кызы Кышкарда Габделмәннан исемле кеше никахында 1292 елның җөмадиел-ахирәсендә/1875 елның июль аенда вафат булган. Мәдрәсәсендә язган китаплары: «Мохтасарел-викайә» дигән китабын Фәсыйхеддин бине Хисамеддин исемле кеше 1233/1818 елда язып тәмам иткән, «Тәнбиһел-гафилин» – Фәхреддин бине Нәриман бине Сөләйман әл-Чуалкиби 1817 елда язып тәмам иткән.

Бервакыт дәрес биреп утырганда, // [208] чит мәдрәсә шәкертләре, бәлки, урынына калганнардан, берсе бик озын буйлы, икенчесе, киресенчә, кыска буйлы, икәү кереп, бер-ике минут утырганнан соң: «Тәкъсир, ләм ләә йәҗүз болай булса, вә ләм ләә йәҗүз шулай булса!..» – дип бәхәс йөрткән булып, саташуларына (тәртипсезлек вә әдәпсезлек, гыйлем хакында хөрмәтсезлек безгә бик борынгы заманнардан мирас булып килә. Һич шөбһәсез, школларда сабак бирүче мөгаллимнәр хозурында мондый эш булса, «ләм ләә йәҗүз, сезне диваналар йортына җибәрергә!» дип, һич кичектермичә озатырлар иде!..) Сәйфеддин хәзрәт тә, боларга туп-туры карап: «Берегезне кисеп, икенчегезгә ямаган булсалар, бәлки, һәр икегез берәр адәм булган булыр идегез», – дип, дәресен дәвам иткән. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Заманасында гыйлемлеге белән танылган иде, Бохара ягыннан күп чит вә сирәк очрый торган китаплар алып кайтты, мөселманнар тарафыннан Мәкәрҗә базарына имам буларак та җибәрелде, Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйга каршы булып, «Бохарада шул зат хакында бөтенләй белмәделәр», – дип, кайгыга төшүе сөйләнә», – дигән. [Төп нөсхәдә биредә биш хаты китерелә.]

### 138. Габдессәлам бине Мортаза бине Максуд бине Габдеррәхим

Чыгышлары Мамадыш өязендәге Ушма авылыннан. Максуд бине Габдеррәхим, туган авылыннан күчеп китеп, Минзәлә ягындагы Мөслим авылына килеп урнашкан. Габдессәлам, башта әлеге Мөслим авылында Габделҗәлил (кара: 129) бине Габдеррәшид мәдрәсәсендә дәрес бирү белән шөгыльләнсә дә, соңрак, ни сәбәптәндер бу вазыйфасын ташлап, бөтен гомерен китап укуга сарыф иткән.

Илле биш яшендә 1241/1826 елда вафат.

Остазлары: Габделҗәлил бине Габдеррәшид, Салих бине Сәгыйдь әл-Кили, Габделгаффар бине Сәгыйдь һәм башкалар.

Шәкертләре: үзенең угылы Әбелмәгалим һәм башкалар. Габделхәбир бине Габделваһһаб әл-Мөслиминең ата ягыннан абыйсы һәм Туйгилде авылындагы ахун Минһаҗеддин бине Әбелмәгалимнең бабасы. Гыйлем вә камиллек иясе булуы турында сөйләнелә.

### 139. Ибраһим бине Хуҗаш

Казанда «Әфәнде хәзрәт» дип // [226] танылган зат. Атасы Малмыж өязендә Янгул авылында вафат булган вә кабере дә мәгълүм икән. Ибраһим әфәнде Бөгелмә өязендә Зәй елгасының уң ягындагы Шарлама исемле авылдан. Әлеге авылның нигезләнүенә 150 еллар булган хәлдә, рәсми рәвештә мәсҗид алырга рөхсәт алырлык балигъ җан хисабы юк, шул сәбәпле бу авыл рәсми рәвештә имам вә мәсҗидтән мәхрүм. Ибраһим әфәнде, озын гомер сөреп, Казан шәһәрендә беренче мәсҗидтә имам вә мөдәррис булган хәлдә 1241/1826 елда вафат булып, Казан зиратында җирләнгән.

Бу мәмләкәт мәдрәсәләре арасында йөреп беркадәр гыйлем алганнан соң, имам булып бер-ике ел торган, ләкин гыйлеме камил булмаганга кайгырып, белемгә омтылышы да зур булганга, каенагасы Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый илә, янәдән гыйлем алу һәвәсе илә, Дагыстанга сәфәр иткәннәр. Анда Гали әфәнде әш-Ширвани[57] исемле кеше хозурында укып, Диярбәкер вә Сивас шәһәрләренә дә сәяхәт иткән. Гали әфәнде әш-Ширвани хозурында 1195 елның рәҗәбендә /1781 елның июлендә «Рәбгыль-мокантарәт» язып тәмам иткән. Бу елда мәмләкәткә дә кайтырга чыгып, зөлхиҗҗә аенда/декабрьдә Хаҗитархан шәһәренә килгән. 1197/1783 елда Казан тарафындагы Утар авылында имам булган. Бу авылда 1199/1785 елда язылган бер фәтвасы күрелде. Аннан Кишет авылына имам булып күчкән. 1208 елның зөлкагдә аенда/1794 елның июнь аенда Казанга күчеп килеп, беренче мәсҗидкә имам булган һәм ахунлык дәрәҗәсе дә өстәлгән. 1212/1797 елда император Павел бине Петр Казанга килгәч, Ибраһим әфәнде имамнарны җыеп, бергә каршы алганнар. Казан календарьлары бәйанына күрә, имамнар һәммәсе дә чалма киеп каршы алганнар. 1213/1798 елда император тарафыннан бүләк буларак 500 сумлык алтын сәгать бирелгән, моңа каршы Ибраһим әфәнде дә бер тәшәккернамә (рәхмәт язуы) язган. Вакыйганың сурәте вилайәт рәсми газетасында // [227] бәйан ителгән. Сөйләгәннәргә караганда, император бу сәфәрендә, Ибраһим әфәнденең җомга намазында булып, гыйбадәт рәвешләрен карап торган. 1235/1820 елда Болгар һәм Биләргә барып, борынгы истәлекләр вә бабаларыбызның аяк эзләрен зиярәт иткән. Бу сәфәре шәүвәл аенда булганга, июнь ахыры белән июль башына туры килә. Ибраһим әфәнде барган вакытта Болгардагы манараларның икесе дә исән булган[58].

Рамазан аенда ураза тоту һәм авыз ачу хосусында зур игътибар биреп, һәр ел саен тырышлык белән дикъкать иткән. Шулай ук кыска төннәрдәге ястү намазы хакындагы бәхәсләрне монда күреп вә ишетеп киткәнгә, Дагыстан вә Анатолия

---

[57] Бу зат Гали бине Ибраһим бине Мөхәммәд Әкмәледдин әз-Зәһри әш-Ширванидән башка кеше. Чөнки Ибне Ибраһим әш-Ширвани 1118 елның җөмадиел-ахирәсендә Мәдинәи мөнәүвәрәдә вафат булган. «Сәликед-дөррер» китабына мөрәҗәгать ителде. Ибраһим әфәнденең остазы булган. Гали әш-Ширвани турында кулыбызда булган китапларда очрамады.

[58] Болгардагы олы манараның авып төшүе 1260 елның 10 рамазанында, сишәмбе көннең төн уртасында булган. Миладидә белән 1844 елның 22 сентябрендә булса кирәк.

RUHIAT

вилайәтләрендә сәяхәт иткәндә, галимнәренә мөрәҗәгать итеп, күпләреннән хатлар илә мәсьәләне ачыклауны сораган. Моның нәтиҗәсе буларак бу намазның әлеге вакытта фарыз булуы турында һич шөбһәсе калмаган. Мөхәммәдҗан мөфтине хуш күреп вә якыннарыннан булып, Ибраһим әфәндегә яхшы булсын өчен, мөфти дә ястү намазын уку турында инануы юкка чыккан Казан галимнәрен төрле нәрсәләр илә куркытып кисәткән. Хәтта мөфти вә яки Диния Нәзарәте тарафыннан булган әмерләргә буйсынырга мәҗбүр булган кайбер галимнәр мөәззингә «Ястү намазына азан әйткәннән соң, кулларыңны күтәргән хәлдә, «Йә Аллаһ! Бу азан вә бу намазның гөнаһын хәлебезне мәхкәмә карамагына тапшырган мөхтәсиб өчен әйлә» дип дога кыл!..» мәгънәсендә хәбәр дә бар[59]. // [228]

Шәех Зәйнулла әл-Халиди хәзрәтләреннән ишетүемә күрә, Казанда кабат басылган «Шәраител-иман» рисаләсен Верхний Урал ягындагы Ахун авылында ахун Ягъкуб бине Әхмәд Ибраһим әфәнде илә шәкерте Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәкигә нисбәт биргән икән. Ләкин, безнең фикеребезчә, әлеге рисаләдәге кайбер сүзләрне язудан боларның һәр икесенең гыйлемнәре вә каләмнәре югары. Мортаза әфәнде бине Котлыгыш әсәре булса, гаҗәп түгел. Аеруча шәҗәрә бәхәсләре моның каләменнән чыгуына беркадәр дәлилләр бар иде. Моннан өстен Мортаза әфәнденең шәех Әхмәд Ясәви тарихына бәйле рәвештә шәехлек итүе сөйләнә.

Хатын-кыз дәгъваларында күп вакыт хатыннар файдасына хөкем итүе сөйләнә. Бу гамәленнән исә иҗтимагый тормыш максатлары илә таныш булуы, гореф-гадәт, әхлак дәресләрен яхшы аңлавы турында нәтиҗә чыга. Безнең милләтебезгә күрә бу бик зур бер мәсьәлә булып, моннан хәбәрдар булуны хатыннарыннан иркәләнеп көн кичергән галимнәр түгел, бәлки һәрбер катлауда күренгән хатын-кыз дәгъваларын хәл итү белән борчылган затлар белер. Ибраһим әфәнде дә бу затларның берсе. Чөнки бервакыт бөтен Казан вилайәтендә булган никах вә талак дәгъваларын хәл итүе сөйләнә.

Ибраһим әфәнде бу мәмләкәтнең бөек адәмнәреннән булып, фикъһ, ысуле фикъһ, хәдис, тәфсир фәннәрендә яхшы камил булганы кебек, гарәп теле гыйлеменнән дә белемле булуы сөйләнә. Һәм кайбер кешеләр тәфсир вә хәдис дәресләренә гаять тә маһир булуын сөйләсә дә, заманасына вә замандашларына нисбәтле каралыр. Чөнки бу гыйлем шәрифендә булган маһирлык эчендәге яшерен хәзинәләрне чыгару, шәкертләргә дә һәрбер нокталарыннан исламга мәхәббәт уятырлык серләрне бәйан итәргә сәләтле булудан гыйбарәт. Ибраһим әфәндегә никадәр ихласлы булсак та, әйткән дәрәҗәгә җитешү түгел, хәтта ишегеннән булса да атлап кергәндер дип уйламыйбыз. Ибраһим // [229] әфәндегә түгел, 500–600 ел элек яшәгән ислам мөфәссирләренә [тәфсирчеләренә] дә бу нәрсәләр җиңел булмаган. Коръән вә хәдисе шәрифләрдә осталыкка ирешү өчен иң элек гыйлем вә фән юлында тәфсир юлы ачу кирәк. Юл ачылганнан соң, осталыкка, шаять, ирешеп булыр. Мондый бөек вә әһәмиятле хезмәтләр Европа вә Америка университетларында һәм академияләрендә укып чыккан тирән гыйлем вә күркәм холык ияләреннән булса булыр, юкса башкалардан моны көтү файдасыз. Киләчәк бер гасырда Коръән вә хәдисе шәрифләрдәге гыйлем вә серләрнең мәйданга чыгачагында һич шөбһә юк.

Ибраһим әфәнденең кыяфәте солтанатлы, сөйләргә маһир, гарәп хатыйблары кебек, бик матур нотыклар сөйли торган булган. Меңнәрчә адәм арасында бары бер-ике кешегә генә бирелгән бу камиллекне урынына, ягъни гомум вә милләт файдасы өчен сарыф ителүе сөйләнер. Хәтта бу яктан хәзрәтне бер яңалык кер-

[59] «Назурател-хак», 154 б.

түче дип саныйлар. Чөнки Казанда һәм тирә-ягындагы начар, мәкруһ гадәтләрдән күпләрне арындырырга муафыйк булган. Ибраһим әфәндедән элек Казан мөселманнары кара эшләпә, бөрмәле чикмән, күн итек киеп, туй вә башка мәҗлесләрдә хатын-кыз, ир-егет һәммәсе бергә утыра торган булганнар. Әфәнде исә, чалма киюне таратып, мәсҗидкә йөрергә күндергән. Читек-кәвеш кию намаз укырга әмәл булсын өчен, никах вакытында кияүгә кыз тарафыннан намазлык бирү, кияү йортына күчкән вакытта таз вә комган алып бару моның заманында булды, диләр. Без болай дибез: әфәнденең бу эшләргә ирешүенә, бәлки, үз заманасы ярдәм иткәндер. Ихтимал, Казанның бүгенге гакыллылары, бәлки, Әфәнде заманында булмаганнардыр. Казан шәһәрендә бу көннәрдә туй вә мәҗлесләрдә булган тәкәллефләрне, мәҗлесләрдә гомер әрәм итүләрне, ат, тун, арба вә чана һәм башка әсбапларда булган әрәм-шәрәмнәрне, аеруча хатын-кыз // [230] таифәсенең мода әсире булып, бер-береннән ярышып, зур-зур акчаларның өсләреннән кереп, асларыннан чыгуларын Казан халкы белән таныш вә хәлләреннән хәбәрдар булган затлар сөйләп бетерә алмый. Бу уңайдан Ибраһим әфәнде түгел, Ибраһим пәйгамбәр килеп нәсыйхәт итсә дә тәэсир булмас, диләр.

Хатыннары: 1) Мөнәүвәрә бинте Йосыф бине Габделкәрим бине Арыслан әл-Ашытый. Мөхәммәдрәхим ахун бине Йосыфның бер туганы булып, Әфәнденең балалары ошбу хатыннан. Әфәнде үзе Дагыстан якларында йөргәндә, ун елдан артык көтеп торган. 2) Фатыйма бинте Мөхәммәд бине Габдерраззак. Семипалат шәһәрендәге Әхмәд ишан бине Мөхәммәднең туганы. Элекке ире Салих бине Гаед вафат булганнан соң, 1223/1808 елда Ибраһим әфәнде тарафыннан никахландырылган иде һәм алты елдан соң, 1229 елның зөлхиҗҗә аенда/1814 елның ноябрендә вафат булган. 3) Хөсниҗәмал-бану бинте Габделваһаб бине Мортаза. Моны исә Фатыйма бинте Мөхәммәд вафатыннан соң, 1230 елның 6 рабигыльәүвәлендә /1815 елның 4 февралендә алды. Әфәнде вафатыннан соң бу хатын Габденнасыйр ахун бине Рахманколыйга вә аның вафатыннан соң Габделвәли исемле берәүгә барган.

RUHIAT

Балалары: Мәхәббәт, Фәхреддин, Мәүдүдә, Мәхбүбә, Гыйсамеддин, Нурмөхәммәд, Гафия. Ир балаларының тәрҗемәләре һәрберсенең тиешле җирләре илә бәйан ителер. Мәхәббәт исемле кызы Дауд бине Биккенә исемле кешегә никахланып, аерылды, соңрак Фәхреддин бине Мортаза бине Габделгазизгә кияүгә чыкты. Мәүдүдә Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки никахында булган. Башка кызларының хәлләре мәгълүм булмады. Кайсыдыр кызының Бохарада укучы Мөхәммәдсадыйк исемле угылының хатыннан бер нөсхәсе күренде. Кыскача шушыдыр: «Бабабыз Әфәнде хәзрәтләренең исән вакытындагы бүләкләреннән вә вафатыннан соңгы васыятьләреннән мәхрүм булсак та, саф мәгыйшәтен очрактан файдаланып белә идек. Вафатын ишетеп бик кайгырдык. // [231] Аллаһы Тәгалә үзен ярлыкап, җәннәттә урын бирсен. Хәзрәт мәрхүм фәкыйрьләрне кайтару теләге белән бераз акча Битаман Нигъмәтуллага тапшырган икән, ләкин ул елны Бохарага килми, юлдан кайтып киткән. Инде ишетүебезчә, мелла Нурмөхәммәд бай әлеге акчаны сорап язган, ди, бәлки, алгандыр. Мәрхәмәт кылып, әлеге акчаны фәкыйрьләргә миһербан итәргә димләсәгез, шаять, әниемә вә башка туганнарга кайтып күрешергә сәбәп булыр. Калган хәл-әхвальләр Мамыш Габделхаликъ агабыз тәфсыйльләп бәйан кылыр. Дустыбыз Мөхәммәдрәхим бай Исмәгыйль угылына догаларыбызны юллыйбыз. Догагыздан өметләнеп, Мөхәммәдсадыйк бине мелла Рәфыйк[60].

[60] Бу кешенең исеме «Мөстәфадел-әхбар...»да да очрый (2 нче кисәк, 30–31 б.).

Шәкертләре: Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки, Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңари, Хәбибулла бине Сәйфулла бине Морадым бине Хуҗаш әл-Олыви, Максуд бине Корбангали әл-Күлбашый, Гали бине Көчек әл-Хаҗитарханый һәм башкалар.

### ***Хатлары***[61]

*Икенче хаты.*

38 нче номер илә 1815 елның 15 сентябрендә белдерелә, Казан округында Күкчә-Бирәзә авылының ил җәмәгатьләренә бу хосуста ки: указ илә имам булып торучы мулла Габделфәез мулла Әмин углына хөрмәт күрсәтмичә, башка бер указсыз имам китереп рәнҗетмәсеннәр, үзләренең // [232] горурлыклары илә. Сәгадәтле, бөек дәрәҗәле бөтен Империягә мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәен углының фәрманыннан башка. Һәм шуның белән бергә сәгадәтле бөек духовный министр кенәз Голицын Александрның 1812 елның 4 мартындагы 283 нче номерлы указы буенча, мулла указлы муллага катгый рәвештә буйсынмыйча, ил җәмәгатьләренә вәсвәсә бирмәсен һәм ил җәмәгатьләре указсыз мулланың вәсвәсәсенә яки мәсҗид салучы вәсвәсәсенә күңел биреп, указлы имамны рәнҗетмәсеннәр дип, аеруча Уфа губернасыннан килеп, Казан губернасыннан килеп, Казан губернасында указ илә имам булып торучы имам рәнҗетмәсен дип, Уфа каласы губерна правлениясенең указы буенча югарыда аталган указлар нигезендә сезгә, Күкчә-Бирәзә авылының барча җәмәгатьләренә белдерәбез, бу имамыгыз мулла Габделфәезне рәнҗетмәгез бөек дәрәҗәле мөфтинең әмереннән башка. Әгәр тыңламыйча рәнҗетсәгез, хөкем тәхетендә булырсыз. Имам, мөдәррис, старший ахун Ибраһим әфәнде Куҗаш угылы. 1815 елның 18 сентябрендә. Мөһер.

RUHIAT

*Өченче хаты.*

Тарих 1816 ел, 6 апрельдә. Безнең хозурыбызга килеп, дәгъва белдерде Лаеш округы Кече Елга авылының шаһ хезмәтенә солдат буларак бирелгән Вәлид Габдеррәхим углының хатыны Зөһрә Фәйзулла кызы. «1812 ел эчендә ирем, шаһ хезмәтенә бирелеп, походка чыгарылып җибәрелде, бер ир бала белән калдым. Бу ирем Габдеррәхим углына: «Балаң илә калдырып китәсең, безнең тормышыбыз ничек булыр? Безгә яшәр өчен бераз нәрсә биреп китсәгез иде, кулыбызда һичнәрсәбез юк, үзегезгә мәгълүм», – дидем. Моңа каршы: «Атам Габдеррәхим илә агама тапшырып китәм», – диде. 1816 елга кадәр каенатам илә каенагам янында тәрбияләндем. Хезмәт итеп тормыш алып бардым. Бу ел эчендә каенагам вафат булды, каенатам картайды, үзе башка кеше тәрбиясендә яшәп тора һәм: «Килен, үз кайгыңны үзең күр, мин тәрбия итә алмыйм!» – диде. Үзем сырхау булдым, // [233] хәрәкәт вә кәсеп итәргә хәлем булмады. Кардәшләрем дә тәрбия кылмады. Бу елларда тормыш кыйммәт булу, иремнән ярдәм булмау сәбәпле, гаҗиз булдым». Без бу дәгъваны ишеткәч, әлеге дәгъва бирүче Зөһрәдән шаһитлар сорадык. Ул исә дәгъвасының раслыгына ике шаһит хәзерләгән, исемнәре түбәндә китерелә. Алар, Зөһрәнең дәгъвасы рас дип, шаһитлык китерделәр, бу шаһитлыкны раслап, Зөһрәдән ант китертеп, кулына никахы юкка чыгарылуы турында язу бирелде. Кече Елга авылының мин, Габделгафур Габдеррәшид шаһитлык иттем. Имән Кискә авылының унсигез яшемдә булган Әбкәни Габдеррәшид угылы шаһитлык иттем.

Казанда комитетский член, имам, мөдәррис, старший ахун Ибраһим әфәнде Куҗаш угылы. 1816 ел, 7 апрель.

---

[61] Төп нөсхәдә алты хаты китерелә. – *Төз.*

*Дүртенче хаты.*

Сембер губернасы Буа округы Бизнә авылының Хәбибә Сәгыйдь кызы атасы Сәгыйдь аркылы без, Казанга Иске бистәдә имам вә мөдәррис һәм старший ахун Ибраһим әфәнде Кужаш угылы хозурында мондый дәгъва кылды: «Бизнә авылының Мәҗид Сәфәргали угылы, ялган шаһитлар илә, гүя мине 1818 елда никахлады дип дәгъва итә. Хәлбуки арабызда һичбер ризалык булганы юк, ләкин атабыз Сәгыйдь колак сөенече мәҗлесе ясап, безләрдән рөхсәт таләп итеп, Бахты Хөррәмшаһ углын, Тимербулат Габделхаликъ углын вә өч хатын җибәрделәр, мин исә кире кактым, хатын өстеннән // [234] барырга риза булмадым. Мәҗид Сәфәр углының шаһитларыннан Бизнә авылының Әмин Сапакай угылы атама дошман, чөнки атам, начальник булып торганда, әлеге Сапакай углын имана акчасы хакында кыйнаган. Атама дошман кеше миңа дошман, шул сәбәпле аның шаһитлыгына ышанмыйм. Икенче шаһиты Габделхаликъ Рәхимкол угылы, өченче шаһиты Вәлид Әбүшай угылы – бозыклар, намазсызлар, исерткеч эчүчеләр. Мин исә, әлхәмделилләһи, салиха (яхшы) кызмын, ялганнан чирканмаган усал кешеләрнең шаһитлыгына ышанмыйм. Дүртенче шаһиты атам илә бертуган агам Фәйзулла Гаед угылы. Ул углын солдатка бирү хакында атам илә дошман. Бишенче вә алтынчы шаһиты Котлымәт Айлазый угылы илә Габденнасыйр Габдулла угылы, имамыбыз Хисамеддин Зәбир угылы бу эшне тикшергән көннәрдә өйдә юк иделәр, аларга да ышанмыйм, чөнки бозык вә дошманнар. Миннән ризалык сорарга барган Бахты Хөррәмшаһ угылы, Тимербулат Габделхаликъ угылы, Мөхибә Котлымәт хатыны, Мәүлия Вәлид хатыны, Фәния Габделхаликъ хатыны – болар барчасы усал кешеләр, намазсызлар, бозыклар, усаллыктан һич чиркана торган түгелләр. Моннан башка тыш ярәшелмәү турында мин үзем шаһитлар илә исбат итәм. Бу шаһитларым колак сөенече мәҗлесендә бар иделәр. Болар – имамыбыз мулла Хисамеддин Зәбир угылы, Мәҗид Гаделшаһ угылы Җәмил Габдеррәшид угылы. Болар исә минем риза булмавыма да шаһитлар. 1818 елның 12 февралендә указлы имам Хисамеддин Зәбир угылы минем шаһитларым илә берлектә һәм Сембер губернасы ахуны Шаһингәрәй Әхмәр угылына шаһитлык китерде».

Әлеге Хисамеддин Зәбир угылының ахун Әхмәр угылына биргән җавабын күрсәтте. Шул сәбәпле без, ахун Ибраһим әфәнде Кужаш угылы, әлеге Хәбибә Сәгыйдь кызының үзенең вәкиле аркылы җибәргән гаризасын карап вә шәригать хөкеменчә тикшереп, югарыда телгә алынган Мәҗид Сәфәр угылының шаһитларының күрсәткән шаһитлыкларын кире кагып, Мәҗиднең дәгъвасын дөрес түгел дип таптык. Хәбибә Сәгыйдь кызының югарыда күрсәткән шаһитларының шаһитлыгын кабул калдык (хәлбуки хәзрәтегез шаһитлык алмады). Могтәбәр китапларда сөйләнгәннәргә нигезләнеп вә һәм бу кәгазьдә язылганнарны шәригать әһелләре күрсен дип яздык. Янә ошбу Мәҗид Сәфәр угылы Хәбибә Сәгыйдь кызын, минем никахлы хатыным, дип рәнҗетмәсен өчен, кулына бу язуны бирдем.

Имам, мөдәррис, старший ахун, комитетский духовный член, үткәндәге олуг шаһ император Павел Петрович бөек җәнапларыннан 500 сумлык алтын сәгать илә бүләкләнгән Ибраһим әфәнде Кужашев. 1819 ел, 10 октябрь.

Моңарга өстәп, ахырында болай язылган: «1819 елның 17 октябрендә Казанның Иске бистәсендә духовный член Ибраһим әфәнденең Сембер шәһәре ахуны Шаһингәрәй Әхмәр угылының хөкемен шәригать нигезендә имза кылуы буенча голәма белән берлектә булганга, мин, Буа сәүдәгәре Нигъмәтулла мелла Бәшир угылы, Бизнәнең Хәбибә Сәгыйдь кызын 400 сум мәһәр илә шул бизнәнең Сәйфеддин Бикбау угылына гадел шаһитлар хозурында никах кылдым һәм кулымны куйдым». Бу турыда мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәен угылының да бер фәтвасы бар, 191–192 битләрдә язылды. // [236]

RUHIAT

*Алтынчы хаты.*

Оренбург Духовное собрание без, ахун Ибраһим әфәнде Кужаш углыннан рапорт:

1822 елның 19 октябрендә Казан округы Чәмәк авылының Рабига Габид кызы болай язды: «1822 елның октябрендә атам Габид 12 нче яшендәге сеңлем белән урак урырга җибәргән иде. (Октябрь башында урак!..) Шул Чәмәк авылының Мостафа Сәйдәш угылы, үзенең юлдашы Әхәд Шәфи угылы илә урак ура торган җиребезгә килеп: «Без сине алырга килдек, арбага утыр!» – диделәр. Без кычкырып елый башладык, болар исә, минем кул вә әгъзаларымны бәйләп, көчләп арбага салып киттеләр. Бистәгә җиткәч чишеп, ахун ...га алып керделәр. Ахун бер мулланы чакыртып китерде дә: «Үзеңә алып барып, болар арасына никах укы!» – дип боерды. Мулла минем риза яки риза түгеллегемне сорады, мин исә барча хәлне сөйләдем. «Алай булса, мин никах укый алмыйм», – дип, мулла чыгып китте. Моннан соң бер кечкенә язу язып, үзенең хезмәтчесен Гыйсамеддин исемле муллага җибәрде вә, ул мулла килгәнгә кадәр: «Гыйсамеддин мелла алдында бу егет илә 400 сум мәһәр илә никахыбыз булган иде, сезгә мәгълүм итәргә килдем, дип сөйлә! Юкса мин сине земскийгә җибәрермен», – диде. Мин моннан курыкканга күрә, Гыйсамеддин // [237] мелла алдында бу сүзне әйттем, башка сүз булмады. Моннан соң әлеге Мостафа: «Син минем хатыным булдың», – дип алып китте. Хәл болай булгач, атам Габид ахун Ибраһим әфәндегә аңлаткан һәм шуңа күрә, Ибраһим әфәнде волостнойга язу язган дип ишеткәч, бу Мостафа куркып, атам Габидкә 50 сум бирмәкче булып, ахунга барды, ахун талак язуы язып бирде дип, талак язуын күрсәтте. Моннан соң без ахун язган талак язуын һәм безгә әлеге Рабига биргән гаризаны рапортыбыз илә Духовное собрание җибәрдек, тикшерер өчен.

Мәгълүм булсын ки, ирексезләү вә мәҗбүрләү илә өч имам каршында никах дөрес түгел, шул ук вакытта бөек мәртәбәле мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәен угылы: «Вәкилсез никах дөрес түгел, гәрчә кыз риза булса да», – дип фәтва биргән. Ахун мондый дөрес түгел никахны дөрес күреп, талак язуы ни сәбәп белән булыр?! Никахның дөрес түгеллегенә бу кадәр нәрсә җитә. Янә әлеге ахунның урланган кызлар хакында сүз илә әмере күп булып, фәкать язудан саклануы мәшһүр хәбәрләр илә мәгълүм.

Цивиль округында Акъегет авылындагы кияүләре ... угылы узган өч ел эчендә 18 урланган кызга никах укыган. Акъегет авылының күбрәк җәмәгатьләре һәр никахтан кырык сум акча алды, яртысы үзенә вә яртысы ахунга, дип сөйлиләр. Әлеге мулла: «Без ахун әмере илә итәмез, юкса кайчан җөрьәтлек кылыр идек», – дип икърар итә икән. Ошбу рәвешчә икърары күп җәмәгать хозурында булуын Зөя округы Пәчек авылында Сәлимҗан Йосыф угылы илә Цивиль округы Бакырчы авылында имам Халид Әхмәд угылы безгә бәйан иттеләр. Шул сәбәпле, әлеге ахунны эшеннән алып, хөкем итәргә тиешле булыр. Без Духовное собрание белдерәбез: мондый бозык эшләр булмасын вә мөфти хәзрәтенең фәтвасына хилафлык ителмәсен, дип.

Имам, мөдәррис, старший ахун, комитетский духовный член Ибраһим әфәнде Кужаш угылы. 1822 елның 13 декабре. // [238]

RUHIAT

***Мөляхәзә***

Әфәнде хәзрәтләре «әфәнде» сүзен һәр җирдә «е»сыз, «әфәнд» рәвешендә язган. Соңгы хатында ныклы дәлил дәрәҗәсендә мисал китерелүе мөфти Мөхәммәдҗан хәзрәтләренә яхшылык итүе кебек бер нәрсә дип уйланылыр. Юкса мөфти фәтвасы илә бәхәстә өстенлек юклыгы әфәнде хәзрәтләренә мәгълүм. Әлеге фәтва сурәте Мөхәммәдҗан мөфти тәрҗемәсендә 193 нче биттә язылган иде.

### 140. Әмирхан бине Кучкар бине Ягъкуб

Эстәрлетамак ягындагы Үтәк авылыннан. Алабуга өязендә Юбраш авылында 1242/1827 елда вафат булган, кабере мәгълүм. Бу ил галимнәреннән файда күргәннән соң, Мисыр, Төркия, Дагыстан голәмасы хозурында йөреп гыйлем алган. Вә бу сәфәрендә 13 ел вакыт уздырып, хаҗ кылган. Бу вакытта Сасна авылының бер кешесе илә аң-белем туплаган. Әлеге кеше исә үз чыгымнары илә Саснага алып кайткан һәм кызына өйләндергән.

Бу хатыннан Әхмәдҗан исемле угылы Саснада дөньяга килгән, диләр. Хатынын вә ошбу углын Саснада калдырып, яңадан хаҗ кылып кайткан вә Бөгелмә өязендәге Чалпы авылында вә аннан соң Малмыж өязендәге Адай авылында, соңрак Мамадыш өязендә Ушма авылларында имам булып, укыту белән шөгыльләнгән, ахырында Юбраш авылына күчеп, 12 ел гомер сөреп, җитмеш яшендә вафат булган. Моның урынына Габделвахид исемле Бохарадан кайткан бер адәм имам булган.

Әмирхан хәзрәтнең хатыннары: Минкә вә Гайшә бинте Хәнәфия. Әүвәлгесеннән икенче Әхмәдҗан, Мөхәммәдҗан исемле вә икенчесеннән Мөхәммәделәмин исемле сукыр бер угылы дөньяга килгән. Болардан башка Фатыйма исемле кызы булган. Үзе вафат булгач, Минкә исемле хатыны Казанга китеп, Хөсәен Ягъкуб угылы Субайи тәрбиясендә тормыш иткән. Мөхәммәдҗан исемле угылы, Казанга барып, сәүдә // [239] иткән вә байлыкларын арттыручы булды. Моның Мостафа исемле бер угылы бу көндә Казанда яши. Фатыйма исемле кызы Минзәлә өязендәге Шәнгәлче авылында Әхмәдҗан бине Габдулла исемле имам никахында вафат булган. Әхмәдҗан илә Мөхәммәделәмин асыл ватаннары булган Үтәк авылына кайтып вафат булганнар. Һәрберенең балалары, нәсел-нәсәпләре күп, диләр.

RUHIAT

Шәкертләре: Габделләтыйф бине Сөбханкол әл-Корычый, Сәйфеддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Нәүширван бине Рахманкол, Сәгъдеддин бине Габделҗәлил әд-Диметри, Мозаффар әд-Дөмдөми һәм башкалар. Үзе фазыйль һәм үткен булып, һәр гыйлемнең хасыйлен ачык белгән. Күбрәк тәфсир дәресе, хәдис һәм гарәбият гыйлеменнән белемле булуы сөйләнә. Мәмләкәтебезнең сирәк галимнәреннән булган Әхмәдҗан бу затның угылы булган кебек, бары моннан файда алып, мондый камиллеккә ирешкән. Һәрбер мәсьәләдә вә сүз чыкканда хәдисе шәриф укып җавап биргәнгә, күп гамәле мәзһәбкә бәйле түгел, ә бәлки хәдискә яраклы булуы дәлилләнә.

Үз кулы белән язылган хаты биредә китерелә: «Бисмилләһи-рахмәни-рәхим. Гыйззәтле, сәгадәтле кардәш газизләрем мелла Корбангалигә барча өй җәмәгатьләрегез, угылларыгыз илә Аллаһы Тәгалә һәрберегезне сау вә сәламәт итеп, тәүфыйк берлә бәхет вә сәгадәтләрегезне артык кылсын. Амин, Раббелгаләмин. Вә янә хәләлем Минкәгә вә туганым Фатыймага шулай ук Аллаһы Тәгаләдән сәламәтлекләрегезне телибез. Ике хатыгыз сәламәтлек хәбәрегез илә, әлхәмделилләһи, килеп иреште. Үзебезнең әхвалебез: Әхмәдҗан илә Сәрви тугыз көн инде

тир авыруы белән яталар. Мулла Мөхәммәдҗан да бер-ике көннән бирле ята башлаган, хуш, әле тамагына кабыштыра, чәй эчә. Аллаһы Тәгалә һәрберсенә сыйхәт вә шифа бирсен, амин. Үзегез дә, иншә Алла, кайту җәһәтен тиз кыла күрегез, угланнар барчасы сагынышканнар. Кардәшләр, барчагыздан хәер-догалар үтендек, // [240] безгә дә барча угланнарыбыз илә хәер-догалар кылсын! Аллаһы Тәгалә сәламәтлек илә хәерле максудларын хасыйль кылсын, амин!» Моннан соң кәгазе өзелгән. Ошбу хат язылган Корбангалинең тәрҗемәи хәле «Мөстәфад-ел-әхбар...»да 352 нче биттә бар.

### 141. Хәмид бине Ислам бине Нурмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Рысмөхәммәд

Казан өязендәге Юртыш авылында имам, шәех вә мөдәррис булып, 1242/1827 елда вафат.

Угыллары: Хәсән, Хөсәен, Сабит, Мөхәммәдъяр. Хөсәен Юртыш авылында, Мөхәммәдъяр Сөрде авылында имам булганнар. Мөхәммәдъярның Мөхәммәдгали исемле угылы Вятка ягындагы Портнурда, Мәгъсүм исемле угылы Сөрдедә имам булып вафат.

Остазлары: Бикчәнтәй бине Ибраһим әс-Сабаи, Ишнияз бине Ширнияз әл-Хәрәзми, Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый һәм башкалар.

Шәкертләре: угылы Хөсәен, Сәлимҗан бине Исхак әл-Әлдермеши, Газиз бине Госман әл-Җәбәли, Мөхәммәдрәхим бине Җәгъфәр, Гомәр бине Сәедкол әл-Чуашили һәм башкалар. Габдүш бине Габдессәлам бер кабиләдән була. Үзе суфый һәм тәкъва бер зат иде, диләр.

### 142. Мостафа бине Биктимер бине Дәүләтъяр

Сәгыйдь бистәсендә имам булып, 1242/1827 ел ахырында вафат булган, кабере Сәгыйдьтә, укыту белән шөгыльләнүе дә сөйләнә. Вәлид бине Мөхәммәделәмин ошбу кеше илә бергә имамлык вазыйфасын башкарган. // [241]

### 143. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни

Чыгышы Ханкирмәндәге Яубаш авылыннан. Сәгыйдь бистәсендәге беренче мәсҗидтә Габдессәлам бине Муллакол исемле кешегә иптәш имам булып, 83 яшендә 1242/1827 елда вафат булган, кабере Сәгыйдьтә билгеле. Бу зат мәмләкәтебездә булган галимнәрнең иң гыйлемле һәм укымышлыларыннан. Ерак урыннардан килеп, аңардан файда күргәннәр. Хәбибулла бине Рәхмәтулла әл-Атнаколыйдан: «Габдеррахман хәзрәтнең элек хәлендә гыйлеме камил түгел иде, ләкин һәртөрле дәресләр илә шөгыльләнгәнгә һәм даими китап укыганга, төгәл гыйлемнәр туплады, аеруча шәкертләреннән зирәк һәм гыйлемгә һәвәсле адәмнәр булуы моның гыйлеме күбәюгә күп ярдәм итте», – дип ишеткән идем. Мәдрәсәсендә язылган китаплардан күпләре күрелде. Шәкертләренең язулары гүзәл һәм дөрес. Күбесенчә «Тәүзыйх» вә «Тәлхыйс» китаплары очрый. Бохара әмире Хәйдәр бине Шаһиморад илә язышкан хатлары бар. Кыска төннәрдә ястү фарыз яки фарыз түгел мәсьәләсе заманасында бик бәхәсле булса да, бу зат битараф булып, һичбер якка да кушылмавы да сөйләнә.

Хатыны Исхак бине Габделкәрим бине Балтай кызы булган.

Балалары: // [242] Хәбибулла, Хәйрулла, Гатаулла. Бу балаларыннан киткән нәсел-нәсәбе гаять тә күп һәм төрле урыннарда таралганнар.



RUHIAT

Остазлары: Исхак бине Габделкәрим бине Балтай, Габдеррәшид бине Габделкәрим, Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаный.

Шәкертләре: Габделлатыйф бине Әдһәм әл-Йулыкый, Габделгафур бине Сәйфулла әл-Балтачый, Габденнасыйр бине Габдеррәхим әт-Тайсуганый, Гобәйдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви, Габделхәлим бине Зәйнеддин әл-Мортышый, Габденнасыйр бине Рахманколый әл-Казаный, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим, Габбас бине Габдеррәшид әл-Күшәри, Хисамеддин бине Габделмөэмин әл-Әлкәйи, Габделкадыйр бине Сөләйман әш-Шәрифи, Габделгаффар бине Габделхәмид әт-Түнтәри, Габдессәлам бине Габдеррахман әл-Курсавый, Габбас бине Рахманкол әл-Әсәйи, Сабит бине Вәлид әл-Мәсгуди, Бәдреддин бине Сәйфелмөлек бине Габделгазиз әс-Сәгыйди, Сәгъди бине Максуд әл-Атавый, Хәбибулла бине Рахманколый әл-Казаный, Габделфәттах бине Габделхәмид әт-Түнтәри, Нигъмәтулла бине Рәхмәтуллаән-Наласавый, Нигъмәтулла бине Гобәйдулла әл-Әлмәти, Рәхмәтулла бине Гобәйдулла әл-Кизләви, Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәти, Нигъмәтулла бине Максуд әл-Күккуяный, Гыйсмәтулла бине Габдеррахман әш-Шәлчәли, Ибраһим бине Госман әл-Манчыли, Ахунҗан бине Нияз әл-Хаҗитарханый, Габдеррәхим бине Гашур әл-Хаҗитарханый һәм башкалар.

Вафаты алдыннан авырып ятканда, Габделмәҗид бине Илхан исемле дәвамчысына: «Минем вафатымнан соң шәкертләремне таратмый, угылым Гатаулла илә берлектә, бер ел мәдрәсәмне тәрбия ит, шәкертләремне укыт, әмма аннан соң монда торуны муафыйк күрмәсәң, Габденнасыйр мәдрәсәсенә бар!..» – дип васыять иткән.

Хәзрәтнең үз кулы белән язган хатлары болар[62].

Бу хатлар үзенең шәкерте Бөре тарафындагы Күк Каен авылындагы имам Нигъмәтулла бине Максуд исемле кешегә язылган.

Габдеррахман хәзрәтнең Гатаулла исемле угылы үз мәсҗиде хозурында имам булып, 1259/1843 елда вафат булган. Аның улы Хәйрулла да шушы мәсҗидтә имамлык итеп, 1299 елның зөлкагдә аенда/1882 елның сентябрендә хаҗ сәфәрендә вафат булган, кабере Мәдинәдә. Кабер ташында ялгыш «Гатаулла бине Хәйрулла» дип язылуы сөйләнә. Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши шәкертләреннән иде. Моның угылы Гыйнәятулла да әлеге мәсҗидтә имам булып, 1310/1893 елда хаҗ сәфәрендә Мәккәдә вафат булган, Исхак бине Мәхмүд, Мөхлисулла бине Максуд әл-Мәчкәрәви шәкертләреннән иде.

### 144. Хәмзә бине Мөхәммәд бине Хәсән бине Җиһанмөхәммәд әл-Казаный әл-Бирәзәви

Хисап гыйлеменә маһир булганга, «Хәмзә әл-Мөнәҗҗим»[63] дип танылган. Имамлык һәм укыту белән шөгыльләнмичә, сәүдә һәм кәсеп иткән, 1242/1827 елда Бирәзә авылында 50 яшендә вафат булган, ир угыллары калмаган һәм нәселе дә юкка чыккан. Фикъһ гыйлеменнән камил булып, риязия – математика гыйлеменнән мәртәбәсе (Казан мөселманнары белән чагыштырганда булса кирәк) югары булуы билгеле. Кыска төннәрдә ястү намазының фарыз икәнлеген сөйләп, Морад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәригә вә төн уртасында көтеп, уку кирәклеген сөйләп, Мөхәммәдәмин бине Сәйфуллаән-Наласавыйга каршы булган. Бу уңайдан Мәңгәри илә ызгышулары күп вә көчле булуы турында сөйләнә. Казан шәһәрендә элекке вакытлардан бирле басылып килгән «Горрәлек» [календарь]

[62] Төп нөсхәдә өч хаты китерелә.
[63] М ө н ә җ җ и м – йолдызлар өйрәнүче, астроном мәгънәсендә. – *Төз.*

RUHIAT

ошбу зат әсәре, диләр. Бохара вә Кабул вилайәтләренә сәяхәт итеп гыйлем алган һәм кәсепкә өйрәнгән Фәезхан бине Хозырхан хәзрәтләре илә вә Бохара әмире Хәйдәр бине Мәгъсүм илә якыннан аралашкан. Шулай ук Мөндеш имамы Мостафа бине Мортаза илә дуслыгы бар иде, диләр. Фәйзулла бине Мөхәммәдкол бине Мәмәтәй ошбу заттан рыязыя гыйлемен өйрәнгән.

**145. Борһанеддин бине мелла Шәриф** (кара: 50) **бине Сөләйман**

Минзәлә өязендәге Шыгай авылында имам вә мөдәррис булып, 1242/1827 елда вафат булган, 1179/1765 елда туган. Хатыны Мәүһүбә бинте Фазлулла бине Габделмәннан әт-Тайсуганый үзеннән соң 1274/1858[64] елда вафат булган.

Балалары: Фәхреддин, Фәридеддин, Мәүләви Җәләледдин, Әхмәдшаһ, Шәрәфеддин, Фатыйма, Гайшә, Хәдичә. Шыгай авылында имамлык итү өчен Уфада Наместнический управление тарафыннан 1791 елның 4 декабрендә 17499 номерлы указ алган. Үз каләме илә язылган бер язмасы ошбудыр:

«950/1543 елда көн тотылды.

959 гакрәб чаян икенче көн/1552 елның 2 октябре – Казан шәһәрен рус алды.

977/1569 – Шыгай хан дөньядан үтте, барс елы иде. // [248]

1010/1601 – олуг ачлык булды.

1017/1608 – Метрий явы булды.

1024/1615 – Янали явы булды.

1052/1642 – Сахрага (Самарага) гаскәр барды.

1053/1643 – кенәз Алексей Михайлович хан (падишаһ) булды.

1065/1655 – халык арасында мур кырылыш булды.

1071/1661 – Башкорт сугышы булды.

1070/1661 – Разин сугышы һәм Казан сугышы булды, Тау халкында һәлакәт булды.

1092/1681 – Сәед сугышы булды.

1105/1694 – Рус падишаһы Азауга барды.

1110/1699 – Азауны алды.

1119/1707 – Прил сугышы булды, Казан халкына һәлакәт булды.

1155/1742 – мәсҗидләр бозылды, Эт елы иде.

1188/1774 – Пугачев явы булды.

1735 – Акай Килмәк явы булды.

1773 – яңа яу, ягъни соңгы Пугачев явы булды.

Ошбу яңа яуның кышында мин, Борһанеддин мелла Шәриф угылы, җиде яшем тулып, сигезгә чыккан икәнмен, әнкәм кәгъбәм шулай әйтә иде».

### *Мөляхәзә*

Бу тарихларны даталарны иске китап читләреннән күчереп язган булса кирәк, шул сәбәпле кайбер хәреф үзгәрешләре булган. Бабаларыбыздан безгә мирас вә ядкәр булып калган тарих кәгазьләреннән кайберләре шушы юллар. Моны язганнары өчен дә рәхмәт укырга кирәк. Иске китап читләрендә сирәк кенә шушындый нәрсәләр очрый. Бер китапка шулай язылган иде:

1114/1702 – падишаһ урманга керүдән тыйды.

1119/1707 – җомга көн кояш тотылды. // [249]

1147/1734 – Котлымәт (Котлымөхәммәд булса кирәк) явы булды.

1155/1742 – мәсҗидләр харап ителде.

---

[64] Матбугат хатасы булуы мөмкин, бәлки, 1247/1831 елдыр. – *Төз.*

### 146. Мөхәммәдхәнәфия бине Салих бине Сөлүк бине Бикчура бине Бикәй бине Җанъегет бине Җаник бине Балтач бине Ябынчы

Бәләбәй ягындагы Богады авылында 1243/1828 елда вафат булган. Туган 1157/1744 елда. Үзе язып тәмам иткән «Шәрхе Җами» ахырында мондый язуы бар: «Бу күркәм нөсхәне Мөхәммәдхәнәфия бине Салих казый Мөхәммәд әл-Казылды мәдрәсәсендә 1187 елның 5 рабигыль-әүвәлендә/1773 елның 16 маенда язып тәмамлады». Моннан аңлашылганга күрә, остазы Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстаный (Казакай ахун) булган.

### 147. Исмәгыйль бине Габид бине Габдулла бине Мөслим бине Бикбулад бине Ишкенә бине Ишбулат бине Шаһфулад

Сөйләгәннәргә караганда, Бикбулад бине Ишкенә Бутай Хафиз дип танылган бер зат. Исмәгыйль Казан өязендәге Мәңгәр авылында имам булып, 1243/1828 елда хаҗ сәфәрендә суга батып үлгән. Бохарага барып укыган һәм анда озак вакытлар гомер сөргән. Габдессаттар исемле бер угылы калган. Остазы Таһир бине Бигеш әл-Мәңгәри. Исмәгыйль бөек галимнәрдән саналган Әхмәд бине Халид әл-Мәңгәринең атасы ягыннан туганы буладыр.

### 148. Габделҗәлил бине Әбулай бине Йосыфкол бине Алтынбай бине Камыш би бине Урак би

Уса ягындагы Каҗмакты авылында // [250] имам булып, 1243/1828 елларда вафат. Мөхәммәдсадыйк исемле угылы калган. Үзе Вәлид бине Мөхәммәделәмин әс-Сәгыйдинең дәвамчыларыннан булып, шөехлек итүе сөйләнә.

RUHIAT

### 149. Әмирхан бине Габделмәннан бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт бине Әхмәд бине Җәлмәт бине Гәрәй әт-Талкышый

Казан шәһәрендә алтынчы мәсҗидтә имам булып, 1244/1828 елда вафат булган. Казан зиратында күмелгән. Бохарага да барган, аннан кайтканнан соң, Казан өязендәге Югары Курса, Тимершәех, Төрек авылларында имамлык иткән вә 1245 ел ахырында/1830 ел урталарында Казан шәһәренә күчкән.

Хатыны – остазы Мөхәммәдрәхим ахун бине Йосыф әл-Ашытый кызы Газизә.

Балалары: Ибраһим, Хөсәен, Фатыйма. Фатыйма 1271/1855 ел ахырында вафат булган.

Остазлары: Сәфәр бине Исмәгыйль бине Морад әт-Талкышый, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый һәм башкалар.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Мостай ән-Норлатый, Җарулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышый, Мифтахеддин бине Сәлимҗәүһәр әл-Калмашый һәм башкалар.

### 150. Хәмзә бине Ишкуат бине Баеш

Бәләбәй ягындагы Кодаш елгасы буендагы Турай авылында имам булып, 1244 ел ахырында/1829 ел урталарында вафат булган. Бу кеше хакында Гали бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәви: «Галим, фазыйль һәм тәкъва бер зат иде. Атам Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуатның туганы иде», – дигән иде. Башка хәлләре мәгълүм булмады.

### 151. Габделҗәббар бине Габдеррахман бине Морадым бине Җиһанмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Ярмөхәммәд бине Нәзар бине Юныс (кара: 33) бине Иванай

1242/1827 елда Казан шәһәрендә Барудия мәсҗиденә имам булып, // [251] 1245/1829 елда вафат булган, кабере Казан зиратында. Бабасы Акмөхәммәд Акман хафиз исеме белән мәшһүр булып, Орнашбаш авылында тереклек иткән. Габдеррахман бине Морадым да Орнашбашта имам булган. Габделҗәббар Дини Нәзарәтендә берара әгъза булып, мөфти Мөхәммәдҗан вафат булганнан соң мөфтилек хезмәтендә булуы сөйләнә. Мәшһүрләрдән Фәхреддин бине Габдеррахман әл-Бәхтияринең бертуганы була. // [252]

### 152. Котлыәхмәд бине Заһид бине Габделмәннан

Оренбург ягындагы Дусмәт авылында имам вә шәехлек итеп, 1245/1826 елда вафат булган. Остазы вә шәехе Вәлид бине Әмин әс-Сәгыйди. Үзеннән соң Сәгъди бине Максуд рөхсәт алып калган.

Тарафдарлары: Мөхәммәдҗан бине Мәхмүд әл-Атавый, Габдессаттар әл-Камывый һәм башкалар.

Балалары: Мөхәммәд, Хәмид, Мәхмүд, Нәүбәһар. Нәүбәһар кызы Габденнасыйр бине Рахманколый әл-Казаный вә аның вафатыннан соң Нигъмәтулла бине Гобәйдулла әл-Әлмәтигә никах ителгән.

### 153. Ишемхуҗа бине Дәүләтбирде

RUHIAT

Ор өязендәге Тимәч авылында имам булып, 1245/1829 елда вафат булган. Ул тарафның могтәбәрләреннән иде. Вафатына җитмеш яшеннән узган булган икән. Хәбибулла исемле угылы да әлеге авылда ун ел буе имам булып, 40 яшендә 1255/1839 елда вафат булган. Укуы хуш вә тавышы гүзәл иде, диләр.

### 154. Габдеррәшид бине Мөхәммәд бине Габдулла бине Колмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Үтәш суфый бине Урманче

Чыгышлары Тау ягындагы Кошман авылыннан. Габдулла бине Колмөхәммәд, Кошман авылыннан күчеп, Бөгелмә янындагы Бишмунча авылына урнашкан. Габдеррәшид башта Зәй елгасы буендагы Колшәриф авылында имам булып, соңрак, 1777 елда, Шушма елгасы буендагы Шөгер авылына күчеп киткән һәм анда имам вә мөдәррис булып, сиксән өч яшендә 1245 елның 12 зөлхиҗҗәсендә/1830 елның 23 май, чәршәмбе көн вафат булган. Кабере мәгълүм.

Остазлары: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Габделмәннан бине Габдеррахман // [253] әт-Тайсуганый һәм башкалар.

Шәкертләре: Габдулла бине Мөслим әл-Балыклый, Сәгъдеддин бине Өметәй әл-Камышлый, Вилдан бине Сәйфулла бине Каракай әш-Шөгери, Таҗеддин бине Мирзахан әш-Шәлчәли, Мифтахеддин бине Рәхмәтулла әл-Урдалый һәм башкалар.

Хатыны Фәрхәнә бинте Сөбханкол бине Бикмөхәммәд 1189/1775 елда Кичүчат авылында дөньяга килеп, илле бишенче яшендә 1244/1830 елда Шөгер авылында вафат булган.

Балалары: Гыйсамеддин, Могыйнеддин, Фәридеддин һәм башкалар.

Гыйсамеддин Фәрхәнә бинте Сөбханколдан элегрәк алган хатыннан булса кирәк. Шөгер авылында икенче мәсҗидтә имам булган. Нәсел-нәсәбе бу көндә дә бар.

Могыйнеддин 1217 елның 15 зөлкагдәсендә/1803 елның 22 февраль көнендә дөньяга килеп, 1291 елның шәүвәл аенда/1874 елның ноябрендә вафат булган. 1238 елның 2 рабигыль-әүвәлендә/1822 елның 5 ноябрендә. Гыйсмәтулла бине Габдеррахман кызы Фәхрелҗәмалны никахлаган.

Угыллары: Зыяэддин, Хәйреддин, Фәтхеддин, Шиһабеддин, Бәдреддин. (Бу соңгысының тәрҗемәсе вә гаять яхшы хатлары да китерелер.) Могыйнеддин хәзрәт, Габделгафур бине Габделмәннан вә Исхак бине Сәгыйдь хозурында укып, сабыр, түбәнчелекле, күп сүзле, оста телле, мәзәк сөюче, язуы гүзәл, ягымлы бер кеше иде. Мөхтәрәм атам илә араларында ныклы бер дуслык булып, һәрвакыт берлектә булыр, карендәш вә кабилә әхвален, үткән заман маҗараларын, заманының мәшһүр голәма вә сәяхәтчеләре арасында булган вакыйгаларны сөйләшерләр иде. Мин никадәр яшь булсам да, боларның мәҗлесләрендә күп вакыт була идем. Ләкин, кызганычка каршы, «Асар»ыма бастырырлык бер юл да мәгълүмат файдалана алмадым. Хәлбуки алар бик күп нәрсәләр белә иделәр. Бәлки, файдаланган да булыр идем, ләкин бу көндә миндә булган фикерләрнең ул вакытта хәтта орлыгы да юк иде. Бу көндә нәсел-нәсәбе бик күп. // [254]

Фәрideддин 1223 елның 8 мөхәррәмендә/1808 елның 22 февралендә дөньяга килеп, Бигәш авылына 1252/1836 елда имамлык өчен хокук алды. Остазы Мортышбаш авылында Габделхәлим бине Зәйнелгабидин булган. 1303/1886 елда вафат булып, Бигәш вә башка авылларда нәсел-нәсәбе калган. Бу зат та, атабызның могтәбәрләреннән булып, Фазлулла бине Хәбибулла әт-Тактавыйга буйсынган.

Габдеррәшид хәзрәт язган китаплардан бер «Төхфәтел-мөлек», бер «Ширгател-ислам», бер «Шәрхе Җами» китаплары күренде. Әүвәлгесен 1179/1765 елда, икенчесе 1179/1765 елда Габделмәннан бине Габдеррахман әт-Тайсуганый мәдрәсәсендә, өченчесен 1190/1776 елда Габдессәлам бине Хәсән әл-Карили мәдрәсәсендә тәмам ителгән. Язулары зарарсыз.

Ошбу фамилиянең кулларында бер рисалә бар. Әлеге рисаләгә күрә, гүя болар Сәлман әл-Фарси (Аллаһы аңардан риза булсын) хәзрәтләре нәселеннән буладыр.

RUHIAT

**155. Габдессаттар бине Сәгыйдь (моннан соңгы бабалары атасы Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый тәрҗемәи хәлендә атала)**

Казан шәһәрендә имам вә ахун булып, 1246 елның 14 рабигыль-әүвәлендә/1830 елның 21 август көнендә вафат. Мәкәрҗә базарында булган мөселманнарга имамлык хезмәте иткәндә вафат булып, Казанга китереп күмелгән.

Остазлары: атасы Сәгыйдь бине Әхмәд, Салих бине Сәгыйдь әл-Кили, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый һәм башкалар. Бохарага барып Коръәни Шәрифне ятлаган. Өйләнгән. Бохара әмире Әмир Хәйдәр илә аралашкан. Бохарада вакытында, 1217/1802 елда, Гыйсамеддин, 1220/1805 елда Габделкаһһар, 1223/1808 елда Галим исемле балалары дөньяга килгән. Соңрак Казанга кайтып, атасына иптәш имам вә ахун да булган. Мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен вакытында мөфти булырга теләсә дә, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхимнең тырышлыгы өстен чыгу сәбәпле, тормышка ашмады. Вафат вакытында бер угылы һәм өч кызы калган. Фазыйль һәм галим булса да, дәрес бирү белән шөгыльләнмәгән, мөфти булырга да лаек бер зат иде, диләр. Дөньясын авырлык илә кичереп, һәр ел Мәкәрҗәгә барып, беркадәр файда табып, шуңа ел уздырган. Үз каләменнән булган ике хаты биредә китерелә.

*Беренче хаты.*

Казан шәһәрендә старший ахун Габдессаттар мелла Сәгыйдь углыннан Казан өязе Түбән Иши авылында указлы имам мөдәррис вә мөхтәсибел-ислам мелла Габденнасыйр Рахманкол углына.

Мөфти хәзрәтләре, әүвәл җөмләгә мәрхәмәтле вә гыйнәятле бөек император Николай Павлович хәзрәтләренә дога кылу өчен рәсми дога вә риваять кылып, Казан өязендә булган барча голәма вә имам һәм мәсҗид әһелләренә бирелеп, дога кылу өчен мөбарәк әмерләрен җибәрде. Шул сәбәпле мөхтәсибел-ислам мелла Габденнасыйрга язабыз: Сез үзегез тирә-ягыгызда булган // [259] гыйззәтле имамнарга ошбу рәсми догадан басылган кәгазьне тапшырасыз, һәрберсе җомга вә башка намазларда укып, язылган рәвешчә әһле мәсҗид илә дога кылсыннар. Соңыннан рапорт илә мәгълүм итәрсез.

Старший ахун Габдессаттар мелла Сәгыйдь угылы. 1826 ел, 30 октябрь.

*Икенче хаты.*

Казанның старший ахуны Габдессаттар Сәгыйдь угылыннан Казан өязе Иши авылында указлы имам мелла Габденнасыйрга.

Шул турыда ки, Казан өязе Тимерче авылының Зөлхиҗҗә Фәез кызы, килешмәгән эш кылып, ире Габдулла угылының ятагын кабул итми, атасы Фәез өенә кайтып тора икән. Әлеге Фәтхулланың остасы Габдулла безгә мәгълүм итте. Шул сәбәпле Сезгә язабыз: ул авылга барып, әлеге хатынга вәгазь вә нәсыйхәт итеп, ире Фәтхулла хозурына тапшырыгыз! Әгәр дә эшләре анда тәмамланмаса, безгә рапорт бирегез.

Старший ахун Габдессаттар мелла Сәгыйдь угылы. 1828 ел, 7 июль.

RUHIAT

### 156. Габделгаффар бине Сәгыйдь әш-Шырданый

Туганы Габдессаттар бине Сәгыйдьтән бер атна соңрак, 1246/1830 елда, Казан шәһәрендә 53 яшендә вафат булган. Бу да Бохарага барып, олугларыннан белем алган. Казанга кайтып имам булу белән, тырышлык белән дәрес бирде.

Остазлары: атасы Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Салих бине Сәгыйдь әл-Кили, Гайсә бине Рәхмәт әл-Хуканди, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый һәм башкалар.

Шәкертләре: Габделләтыйф бине Яһүдә әл-Җәбәли, Зәбир бине Габделгазиз әл-Мәрҗани, Хәммад бине Халид, Һибәтулла бине Габделгазиз әл-Мәрҗани, Шәмседдин бине Зәбир әл-Ятим, Мәүләви Җәлаледдин бине Борһанеддин әш-Шыгайи, Габдессәлам бине Мортаза әл-Мөслими, Гайнан бине // [260] Ихсан әл-Казаный, Сәгъдеддин бине Хәбибулла әс-Салихи һәм башкалар.

Балалары Габдулла, Габделкадыйр, София булып, бу көндә исә ир баласы ягыннан дәвамы юк. Бохарада Габделгазиз бине Габделгани исемле кеше белән Әмир Хәйдәр хозурында бәхәс итеп, моны исә соңрак рисалә шәкелендә язып, 200 дирһәм күләмендә бүләк алган. Гарәби бер язмасы «Мөстәфадел-әхбар...»да искә алына: II том, 95 б.

### 157. Әбүбәкер бине Йосыф бине Ильяс әл-Җәбәли

Казан шәһәрендә имам булып, 1246/1830 елда вафат. Чыгышы Тау ягыннан, Зөябашы исемле авылдан. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни хозурында укыганнан соң, Бохарага барып гыйлем алган.

Шәкертләре: Хәбибулла бине Рахманкол әл-Казаный, Нигъмәтулла бине Монасыйб әл-Бубый, Габделҗәббар бине Мөстәкыйм әл-Кайбычый, Максуд бине Габделкәрим, Хәммад бине Халид әс-Салавый, Сибгатулла бине Габделкадыйр әш-Шәрифи, Фәхреддин бине Мостафа ән-Норлатый, Салих бине Йосыф әл-Җәбәли, Хәбибулла бине Исмәгыйль әс-Сәлмәни һәм башкалар.

Хатыны Әбүбәкер бине Ибраһим бине Йосыф кызы Гафиядән Садреддин исемле бер угылы калып, Зөябашы авылында мөәззин булган.

### 158. Сәгыйдь бине Әхмәд бине Хөсәен бине вә, бер риваятькә күрә, Әхмәд бине Мөхәммәд бине Йосыф бине Габделгазиз бине Галикәй бине Йосыф бине Габдерраззак бине Габдулла

Әхмәд 1164/1751 елда вафат булуы сөйләнә. Үзе Зөя өязе Шырдан исемле авылдан. Сәгыйдьтән башка Фазыйлә, Исламкол, Зөләйха, Сахибә, Җәгъфәр, Иманкол, Сәлимә, Сәгыйдә исемле балалары булган. Җәгъфәр бине Әхмәд Шырдан авылында имам, Сәлимә Үрә авылында Мортаза бине Тукмөхәммәд никахында булган. Фазыйлә Габденнасыйр бине Хөсәен бине Әлмөхәммәд исемле кеше никахында, Казан мөхәррирләреннән булган Габделкаюм әфәндене дөньяга китергән. Сәгыйдь бине Әхмәд элек Казан өязендәге Ашыт авылында вә аннан соң Югары Сәрдә авылында вә аннан соң Кишет авылында имам булып, 1225/1810 ел ахырында Казан шәһәрендә имам булган. Туксан яшендә 1246 елның зөлхиҗҗә ахырында/1831 елның май (июнь) аенда вафат булган[65]. Кабере Казанда. Күрсәтелгән авылларның һәрберсендә дәрес белән шөгыльләнеп, гарәп теле һәм фикъһедән белеме яхшы булуы билгеле. Мәдрәсәсендә язылган бер «Фәраизе Сираҗия» ахырында мондый язу күренде: «Бу китап Казан вилайәтендә Ашыт авылында мелла Сәгыйдь бине Әхмәд мәдрәсәсендә Хәмид бине Сәгыйдь тарафыннан 1194/1780 елда язып тәмамланды». 1226/1811 елда Нигъмәтулла бине Рәхмәтулла ән-Наласавый илә берлектә ишан Дөһбәйди Мөхәммәд Түрәхан исемле кешегә ияреп хаҗ сәфәренә китсәләр дә, юл булмау сәбәпле, Кырым вилайәтеннән кире кайтып килгәннәр. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Ишнияз әфәндегә ияреп, «кыска төннәрдә ястү фарыз түгел» дисә дә, ахырда моннан тәүбә иткән!..» – дигән. Казан ислам йортымы, түгелме, дип, Ишнияз әфәнде илә бәхәсләшүе // [262] билгеле.

RUHIAT

Хатыны Гөлчәһрә бинте Салават бине Исмәгыйль бине Юныстан Габдессаттар, Габделгаффар, Габделвәли, Әхмәд, Җәмилә, Фатыйма исемле балалары булган. Габделвәли исемле угылы шәкерт чагында Бохарада вафат булган. Фатыйма элек Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавыйга никахланып, аерылышкан, соңрак Габделваһһаб бине Габдулла әл-Җәбәлигә кияүгә чыккан.

Остазлары: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Ибраһим бине Габдулла ән-Нократый әл-Барыши, Ишнияз бине Ширнияз әл-Хәрәзми һәм башкалар.

Шәкертләре: Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Җәбәли, Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри, Фәез бине Габделгазиз әл-Кенәри, Хәмид бине Ислам бине Нурмөхәммәд әл-Мәмдәли, Рәфыйк бине Морадым, Габделгафур бине Гаделшаһ әл-Балтачый һәм башкалар.

---

[65] Әмма метрикәдә язылганга күрә, 1247/1831 елның 2 июнендә (мөхәррәм башында) иде.

### 159. Фәхреддин бине Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд

Атасы вафат булганнан соң, Казан шәһәрендә икенче мәсҗидтә имам булып, 1247 елның мөхәррәм аенда/1831 елның июнь (июль) аенда вафат булган. Кабере Казан зиратында.

Хатыны Ибраһим әфәнде кызы Мәхбүбә булган. Әлеге хатын, Дауд бине Биккенә исемле кешедән аерылганнан соң, бу кешегә барды һәм Шиһабеддин исемле угылын дөньяга китерде. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Һәрникадәр икенче хатын алырга теләсә дә, Ибраһим әфәнде кызының: «Әгәр дә хатын алсаң, Бәшир байга шикаять итәрмен дә, сине имамлыктан алдырыр», – дип куркытуы сәбәпле, бу максатына ирешә алмады», – дигән. Моны ишеткән замандаш имам хатыннары: «Әгәр бездә дә Бәшир бай булса иде, муллаларыбызны эштән алдыру белән куркытып, өстебезгә хатын алдырмас идек!..» – дип ачынганнар. Ләкин бу заманда муллаларны куркыту өчен Бәшир байдан көчле һәм җиңел юл бар. Ул исә закон. Шулай ки, имамнар, вазыйфаларын үтәгәндә, хатын алыр өчен үзләренең баш мәхкәмәләреннән рөхсәт сорау тиеш. Рөхсәтсез хатын алганнарга мәгълүм җәза билгеләнә. Әлеге зат вафат булганда, яше алтмышка җиткән. Җеназасын Габденнасыйр ахун укыган. // [264]

RUHIAT

# АЛТЫНЧЫ КИСӘК

برنچی جلد ·                                                  آلتنچی جز

# آثار

ملکتمزده اولان اسلام عالملرینک ومشهور کیمسه‌لرینک ترجمه وطبقه‌لری، تاریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش کتابدر.

RUHIAT

آلتنچی جزء

صاحبی

رضاءالدین بن فخرالدین

اذا عرف الانسانُ اخبارَ من مضى * توهمتَه قد عاش من اوّل الدهر

فكن عالما اُخبارَ من عاش وانقضى * وكن ذانوال واغتنم آخر العمر

« اوفا »

۱۳۲۲ سنه

Дозволено цензурою. С.-Петербургъ, 5 Іюля 1905 г.

Типографія М.-Ф. Г. Каримова. Оренбургъ, 1904 г.

**160. Шәфи бине Гали бине Орыс бине Шыгай бине Янгураз бине Байгура**

Казан өязендә Мәмдәл авылында имам буларак вафат иткән. Диния Нәзарәтендә дә ике мәртәбә әгъза булды. 1209/1795 елның шәүвәл аенда Уфада вакытында «Мөхтаратен-нәуазил» һәм 1221/1806 ел эчендә «Фәтавый Бәззазия» китапларын күчереп тәмам иткән. Вафат елы мәгълүм булмады. Мөхәммәтшәриф исемле угылы Мәмдәлдә имам һәм ахун булып, 1255/1839 елда вафат булган. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни шәкертләреннән булган Габдессәлам мөфтинең 35 нче хатында исеме телгә алына. Ошбу Шәфи бине Галинең тәрҗемәи хәле беркадәр алдарак язылырга тиешле булган хәлдә, онытылып, бу урында бирелде.

**161. Бикчәнтәй бине Җәгъфәр бине Мәсалим**

Казан өязендәге Казанбаш авылында имам булып, 1233/1818 елда вафат булган. Диния Нәзарәтендә тоташтан өч нәүбәт әгъзалыкта булганлыгы мәгълүм. Уфада вакытында бер «Әхтәри» китабы сатып алып, 1211/1797 елда исемен язып куйган. Бу зат та, игътибарсызлыктан, кичегеп язылды.

**162. Габделваһаб бине Габделмәҗид**

Казан өязендә Түбән Аты авылында имам булып, 1246/1830 елда вафат иткән. Асыл нәселе Казан әһеленнән, имеш. Габделгаффар бине Сәгыйдьнең каенатасы. Диния Нәзарәтендә берникадәр вакыт әгъза буларак хезмәт иткәнлеге // [265] билгеле. Гатаулла исемле угылы Казанда яшәп вафат итте. Бу кеше дә, ялгышлык сәбәпле, беркадәр соңга калып язылды.

RUHIAT

**163. Госман бине Рәхмәтулла**

Түбән Сәрде авылында имам булып, 1246/1831 ел башында, рамазан башында 13 февральдә 71 яшендә вафат булган. Хиҗазга барып хаҗ кылган. Җеназасын Олуг Сәрдедә имам Гобәйдулла мулла Габдуш угылы укыган.

Шәкертләре: Хәбибулла бине Мортаза әз-Зипничәви һ.б.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Заманасында мәшһүр бер зат иде. Иши авылында Хаҗи Әрмәли һәм кызы Гайшә исемендә вәлиләр [изгеләр] кабере бар, дип, зиярәт итүне чыгарды. Бәлки, бу сүзен Шәрәфеддин бине Хисамеддин әл-Мөслими китабына ышанып әйткәндер. Яисә «тавыннан чыккан чишмә белән дәлилләгән булыр, чөнки гавам халкы күп вакытта изгеләр кабере булган җирдән чишмә чыга дип гөман итәләр» дигән. Без дибез ки, «вәли» сүзе Аллаһының дусты дигәнне аңлата, моны белү җиңел бер эш түгелдер. Каберләргә йөреп, гомер уздыруга вә кабер сакчыларына акча сарыф итүгә караганда, мәктәпләргә йөрү вә гыйлем юлына байлык фида итү хәерлерәк икәнлеге турында ислам шәригатендә йөзләр һәм меңнәрчә дәлилләнгән хәлдә, ни чарадыр ки, халкыбызда гыйлем агачы чәчәк атмаганлыктан – моны белүчеләр аз. Әһле исламның кабер белән кабак[66] юлына тоткан акчалары илә дөнья зурлыгы мәктәпләр, гыйлемханә һәм мәгариф йортлары төзү мөмкин булыр иде. Бер затның «Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәллам гомере буенча инсаннарны тәүхид-бердәмлеккә (Аллага ышануга) чакырды, мәҗүсилекнең хәтта тамырына кадәр суы-

[66] Аракы сатыла торган кибет. Төрки сүз булса да, «Камусе төрки»гә [Төрки теле сүзлегенә] кертелмәгән.

рып ташлауга иреште, фәкать үзеннән беркадәр соңрак килгән дәвамчылары аның шул гайрәтенең нәтиҗәсен юкка чыгардылар. Чөнки төрле исем вә төрле сыйфатлар илә мәҗүсилекне кире ислам шәригатенә куштылар!..» дигән сүз астында вәлиләр зиратларына, изгеләр чишмәсенә һ.б. шундый шәригатьтә әмер кылынмаган җирләрдә дин исеменнән йөрү дә керә һәм аңлана!..» // [266]

### 164. Габделләтыйф бине Әдһәм бине Әбүбәкер бине Мүкәй

Төп чыгышлары Казан өязендә Пүкәл исемле авылдан. Иң элек буларак Әбүбәкер Ур (Орск) өязендә башкорт халкы арасында булган Йулык авылына имам булган. Габделләтыйф, ошбу авылда дөньяга килеп, гыйлем иясе булып, имам вә мөдәррис дәрәҗәсендә 1247/1831 ел ваба эпидемиясендә вафат булды. Ун ел дәрес әйтеп, «Иннәл-кирам ликалиләтил-әгъмар» (затлы-данлыклылар кыска гомерле булалар) әйтемендәгечә, яшьли вафат булган. Моның вафаты илә Урал тауларының мәшрикъ тарафында гыйлем шәүкәте сүнгән, дип сөйлиләр.

Габделләтыйф хәзрәт заманасында булган галимнәрнең бөекләреннән вә кагыйдәсе илә укыткан фикер ияләреннән булган. Тугры галим һәм тугры зиһенле, мөлаем, матур язулы булган кебек, гомумән, шәкертләре дә мәгълүматлы булыр иде, диләр.

Үзе дә яшь бер мөдәррис булган хәлдә, уку өчен ерак вилайәтләрдән килгән вә күп галимнәрдән гыйлем алган пишкадәм затлар буларак, зур кызыксыну белән һәм яратып белем алганнар.

Иң элек атасы хозурында укып, аннан соң олуг шәехләр хозурында аерым әдип вә оста сүзләләр белән әңгәмәләшкән.

Остазлары: Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади һ.б.

Шәкертләре: Мифтахеддин бине Зәйнелгабидин, Корбангали бине Юлдаш әл-Акъяри, Габделхәким бине Корбангали әл-Чардаклый, Габделкадыйр бине Каһарман әс-Сафакүли, Габделләтыйф бине Габделкәрим әл-Йулыкый, Әшрәф бине Сәйфеддин әл-Кичүчатый һ.б.

Балалары: Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдшәриф, Мөхәммәдвәли, Фатыйма, Шәрифә, Гафифә, Камилә. Фатыйма Мифтахеддин бине Зәйнелгабидин никахында, Гафифә Мөхәммәдсаф бине Сәйфелмөлек исемле зат никахында булганнар.

«Шәрхе Габдулла» китабын күчереп // [267] тәмам иткәч, болай дип язып куйган: «Габделләтыйф бине Әдһәм бине Әбүбәкер әл-Болгарый, Саба авылында. Остазым – Сәйфеддин бине Әбүбәкер, 1218/1803 ел». «Тәфсире шәех Әбү Сәгыйдь әл-Хәнәфи» тәфсирен күчереп тәмам иткәч язган сүзләре болар: «...Габделләтыйф бине Әдһәм бине Әбүбәкер кулы белән ...Орнашбаш авылында, 1808 елда, 1 рәҗәбтә». Китапханәсендә булган китапларының хисабы хакында дәфтәрендә үз каләме илә болар язылган: «Сарфһауаи», «Шәрхе Габдулла», «Зәнҗани», «Гауамил», «Әнмүзәҗ», «Исагуҗи», «Ногман», «Бәрдәгый», «Хөсәения», «Гали әл-Фәрди», «Ташкөпре», «Муса әл-Бәрәкәти», «Хәмзә», «Менла Җами», «Габдеррахман», «Мәүләви тәкаммилә», «Мирсәед», «Тәлхыйс», «Хатаи», «Тәһзиб», «Мирза Заһид», «Чәгъмәйни», «Шәрхе Гомәр ән-Нәсәфи», «Менла Әхмәд», «Җамигыйр-рөмуз», «Чәләби галә шәрхел-викайә», «Шәрхе холәсател-Кәйдани лит-Тәфтазани», «Шәрхе холәсател лил-Каһестани», «Фәзаилес-салауат», «Кавагыйде Коръән», «Бостанел-фәкыйһ», «Мәҗалисеш-шөһүр», «Нисабел-ихтисаб», «Мирсәед әл-фәраиз», «Шәрхе Әмалый», «Фосүле гашәрә», «Тәүзих», «Гыйсамеддин», «Ибне Хәҗәр», «Ысулел-хәдис», «Тәлвих», «Мәүләви хашияте тәүзих», «Бәһҗәтен-нәзар, шәрхе тәүзихел-фикер», «Шәрхел-вика-

RUHIAT

йә», «Фәтави һиндия», «Мелла Җәлял», «Шәрхе ахунд Фәйзи галә Карабагый», «Шәрхел-мәвакыйф», «Мәүләви Габделхәким, хашиятес-сәйд», «Хадими», «Кифайәтиш-шәгъби», «Халисәтел-хәкаик», «Гайнел-гыйлем», «...Тәүзихел-әсрар», «Әл-ишбаһ вән-нәзир», «Ибне Мөлек», «Гыйздийә», «Тәһафәт», «...Җанибел-гарби», «Мизанел-гамәл», «Тәртибел-голум», «Тәфсир Әбүс-Согуд», «Тәфсире игъраб», «Табакате Хәнәфийә», «Мөхәммәд Садыйк», «Хашияте шәрхеш-шәмсийә», «Мәтне тәлхыйс», «Сөбател-гаҗизин», «Әхлакы гыйздийә», «Ифтитах», «Китабел-мәүҗиз», «Нәвои».

Габделләтыйф хәзрәт тарафыннан төзелгән вә үз каләме белән язылган, якынча 200 кәгазьдән гыйбарәт булган бер җыентыгы хәзер күз уңыбызда. Бу җыентыкта кайбер фарсыча һәм төркичә шигырьләр булып, // [268] Габдеррахман бине Габдеррәхим әл-Утыз Имәнинең ике рисалә-китабы һ.б. кыска-кыска язмалар бар. Җөмләдән, имам Суютиның кабер сораулары хакындагы китабын, Җәлаледдин әд-Дәванинең Сәгъдеддин әл-Истирабадига язган китабы, Котбеддин әр-Разый һ.б. бар. «1804 елда Саба авылында Габделләтыйф бине Әдһәм бине Әбүбәкер, Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый мәдрәсәсендә... Габдеррәхим бине Госман әл-Болгарый әсәреннән мулла Габдеррахман бине Габдуш әс-Сабавый өчен күчереп язылды». Моннан башка бүтән кульъязмалары да бар. // [270]

Бер кульъязмасында Габдеррәшид бине Иманколый әт-Ташкичүи, хаҗи Вәлид Хәсәншәехи әл-Казаный, Сәйфеддин бине Әбүбәкер әс-Сабавый, Габид бине Габделгазиз әл-Орнашбаши, Нигъмәтулла ән-Наласауый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф һ.б. затлардан гыйлем алганлыгы теркәлгән. // [271]

Хаҗи Бәгъдади тарафыннан 1232/1817 елда бирелгән иҗазәтнамәсе, шәһадәтнамәсе дә бар. // [272]

RUHIAT

### 165. Зәйнелгабидин бине Габдулла бине Ярмөхәммәд әл-Йулыкый

Йулык авылында ишанлык итеп, 63 яшендә вакытта 1247/1831 елда рабигыль-әүвәл/октябрь аенда вабадан вафат. Асылы Ханкирмәннән (Касыймнан) булып, Бохара, Кабул тарафларында сәяхәт иткән. Фәезхан бине Хозырхан хозурында гыйлем алып, ишанлыкка рөхсәт алган. Габделләтыйф бине Әдһәм белән дуслык һәм ихтирам эчендә гомер кичергән вә аның вафатыннан соң озакламый дөнья куйган.

Угыллары: Нәҗмеддин, Фәхреддин, Мифтахеддин. Мифтахеддин Габдеррәшид исемле авылда имам булып, 45 нче яшендә 1265/1849 елда вафат булган. Аның Салих исемле угылы калган.

### 166. Мөхсин бине Биккол бине Ибраһим әш-Шашый

Асылы Царевококшай өязе Янык Шашы авылыннан. Атасы Биккол Казан өязендәге Ашыт авылында имам булган.

Мөхсин бине Биккол ахун Фәтхулла бине әл-Хәсән әл-Орый хозурында белем алгач, Бохарага барып, Кәрминәдә казый булган. 1247/1831 елда ваба эпидемиясендә вафат булган. Бохарада ихтирам һәм абруй казанган Казан татарларының сирәкләреннән.

Шәкертләре: Хөснеддин бине Бәшир әт-Түнтәри, Фәхреддин бине Бикмөхәммәд әл-Иши, Фәхреддин бине Әбү Йәзид әл-Әтнәви һ.б.

**167. Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади**

«Хаҗи Бәгъдади» исеме белән мәмләкәтебездә мәшһүр һәм исеме бүгенгегә кадәр данлыклы булган Корьәнхафиз. // [273].

Бәгъдад шәһәрендә 1169/1756 елда дөньяга килеп, шунда беркадәр гыйлем эстәгән. 33 яшендә вакытында, 1202/1788 елда, сәяхәт нияте белән Бәгъдадтан чыгып, Һиндстан, Хорасан мәмләкәтләрендә йөреп, Бохарага барган. Аннан, Җаек елгасын кичеп, Оренбург шәһәренә килгән. Сәгыйдь бистәсе-Каргалыга килеп, ике манаралы җамигъ мәчетендә имам булып ике ел торгач, кайбер көнче бәндәләрнең тырышлыклары сәбәпле, шпионлык яласы ягылып, 40 көн кулга алынып торган. Хыянәтсезлеге мәгълүм булгач, әүвәлге хәлендә калуы яки китәргә ихтыярлы булганлыгы белдерелгәч, Бохара тарафларына юл тоткан. Кабул шәһәренә барып, кайбер хөрмәтле затлар белән күрешкәннән соң, яңадан Каргалыга килеп, шул ук ике манаралы мәчеткә рәсми имам булган. Бар күңелен биреп, хәтереннән Корьәннән дәрес әйтеп, 1247/1831 ел, рабигыль-әүвәл/октябрь аенда вафат булган. 84 яшьтә булган, диләр.

Мәүледе рәсүлулла хакында төрки телдәге тезмә бер китап язып, ахырында «Сәргезәштэ хаҗи»[67] башы астында үзенең тәрҗемәи хәлен язган.

Әлеге китапның башы болай:

Аллаһ адын зикер идәрем әүвәлән,
Ваҗиб улдыр, җөмлә эшдә һәр калә.
Аллаһ адкы улса һәр эшең уңы,
Һәргиз әбтәр улмайа аның соңы.

«Сәргезәштә» бүлегендә ошбу юллар бар:
Биң дә ике йөздә ике тарихың
Унбише иде әшһәре зөлхиҗҗәнең.
Әйләдем «Бисмиллаһ» тәкрар йад.

Тәрәки әүтан әйләдем хәрәме шад.
Баса килдем йөрүбән дәмбәдәм,
Таки Русия торабына кадәм.
Нәһре Йайыкда уар икән бер хисар. // [274]

Сөйләнер «Орски» аңа иштиһар,
Тормамагы анда чөн җәзем әйләдем.
Ул заманда вирделәр бәңа хәбәр:
«Бу якында карьяи Каргалы уар,

Биңдән артык вар мөселман ханәсе
Һәб кара мөселман кәшәнәсе.
Йиде мәсҗид, һәрбересе бимәнар,
Киме таштан, агачдан өстевар.

[67] Хаҗиның тәрҗемәи хәле (башыннан кичергәннәре).



RUHIAT

*зикер идәрем* – әйтәм
*важиб* – бурыч
*һәргиз* – һәрвакыт
*әбтәр улмайа* – начар, ким булмый
*биң* – мең
*әшһәре зөлхиҗҗә* – зөлхиҗҗә ае
*тәрәки әутан әйләдем* – ватаннан киттем
*дәмбәдәм* – туктаусыз
*таки* – кадәр
*торабына* – туфрагына
*кадәм* – аяк
*нәһре* – елга
*хисар* – ныгытма, җир, урын
*иштиһар* – мәшһүр
*тормамагы* – торуны
*чөн* – чөнки
*җәзем әйләдем* – карар иттем
*ханә* – йорт
*бимәнар* – манаралы
*өстевар* – күбесе

Үз каләме белән 1234/1819 елда Габденнасыйр бине мулла Сәйфулла исемле затка язган иҗазәтнамәсе дә күрелде.

Шәкертләре: Хәбибулла бине Рахманколый вә аның туганы ахун Габденнасыйр бине Рахманколый әл-Биги, Фазыл бине Ибраһим әл-Кимеви, Рәхмәтулла бине Гобәйдулла әл-Кизләви, Таһир бине Сөбхан әл-Мокраи, Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәти, Бәдреддин бине Сәйфелмөлек әс-Сәгыйди, Габделгаффар бине Габделхәмид әт-Түнтәри, Хөсәен бине Мөхәммәд әл-Кирмәни, Мөхәммәд бине Хәмид әл-Казаный, Мөхәммәдсафый бине Габденнасыйр әл-Адай, хаҗи Гали бине Әбүбәкер әл-Хаҗитархани, Габделләтыйф бине Әдһәм әл-Йулыкый, Габденнасыйр бине Сәйфулла, Гобәйдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви, Мөхәммәдәмин бине Мөстәкыйм әс-Сапайи һ.б. Бәйрәкәвигә булган иҗазәтнамәсен 1232/1817 елда язган. Каргалыдан хатын алып, балалары булган. Кабере Каргалыда.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Гәрчә гарәп теле гыйлемнәрендә камил һәм оста булмаса да, Коръән уку гыйлемендә камил остаз иде. Тавышы яхшы вә көйләре хуш иде, заманында булган Коръән уку осталарының шәехе иде, изге һәм намуслы иде. Күңеле дөрес һәм иманы сәламәт иде. Хаҗ вә җәнабы рәсүле әкрам хәзрәтләрен зиярәт иткән иде. Сәгыйдь бистәсеннән 1236/1821 елда Бохарада булган Хөсәен бине Мөхәммәд әл-Кирмәнигә иҗазәтнамә җибәргән. Бохараның мәшһүр Коръән уку осталары булган Габделбакый илә Хафиз Гошур бу затка шәкерт булып, кыйраәтләрен (Коръән укуларын) төзәткәннәр иде. Һәрбер шәһәрдә, аеруча безнең Болгар вә Казан җирендә вә аларга караган авылларда булган Коръән уку остазлары турыдан-туры яки аның шәкертләренә шәкерт булганнар», – дип язган.

### 168. Зәйнеддин бине Һашим бине Теләкәй бине Байкара бине Нурдәүләт бине Толъяр

Уфа ягыннан Үзен елгасындагы Иделбай авылында имам вә мөдәррис булып, 1247/1831 елда яшьли вафат булган. Башкорт таифәсеннән. Остазы – Сәгъди бине Максуд әл-Атауый, хатыны да шул остазның кызы Фәрхәназ. Зәйнеддин вафат булгач, ошбу хатыны бертуган Динмөхәммәд бине Һашимга, ә ул вафат булгач, Батыршаһ бине Хөррәмшаһ исемле мөәззингә никахланган, Зәйнеддин хәзрәтне Гайнан бине Вилдан әл-Атауый «дөньядан өстен, Аллага якын вә суфый иде» дип мактый. // [276]

**169. Мәгаз бине Бикмөхәммәд әл-Карамалый**

Эстәрлетамак өязе Карамалы авылыннан. Оренбург янындагы Ик суы буенда булган Яңа Гомәр авылында шәехлек-ишанлык итеп, 1247/1831 ел, 4 җөмадиелахирда/10 ноябрьдә вафат булган вә әлеге авылда җирләнгән. Ошбу авыл халкы бер вакыйга сәбәпле башка урынга күчеп киткәч, анда рус халкы җирләшеп, авыл корганнар һәм шул сәбәпле Мәгаз хәзрәтнең кабере билгесез булып калган. Авыл халкы күчкәннән соң, мәчетләре кырык елдан артык урынында торып, ахырында Ик Тамагы исемле авылга күчерелеп салынган, диләр.

Эстәрлетамак ягындагы Тукай авылында Мәсгуд бине Зәйнелгабидин хозурында белем алып, Каргалыда Вәлид ишан бине Мөхәммәделәминнән гыйлем эстәп, суфыйлыкка рөхсәт алган. Соңра Бохарага, аннан соң Кабулга барып, шәех Фәезхан бине Хозырхан белән аралашкан. Ватанга кайткач, Ур (Орск) шәһәрендә Дауд ахун исемле зат заманында мәншүр-указсыз буларак имамлык иткән. Аннан соң, Яңа Гомәр авылына барып, вафат булган. Күчереп язган бер «Шәрхе Габдулла» китабы ахырында болай дигән: «Хуҗасы һәм иясе Мәгаз мулла Бикмөхәммәд угылы, язылды 1196/1782 елда Тукай авылында, мулла Мәсгуд хәзрәт мулла Зәйнелгабидин угылы мәдрәсәсендә».

Шәкертләре: Габделхаликъ бине Габдулла бине Таһир бине Әмәт, Габделләтыйф бине Әдһәм әл-Йулыкый, Сәгъдеддин әт-Ташлый һ.б.

Хатыннары: Хакимә бинте Габдеррәфи бине Бикмөхәммәд әл-Белагурый, Шәмсениса Габдеррәфигъ кызы, Шәһрибану бинте Бәйрәмгали әл-Гомәри.

Балалары: Мөхәммәделбакый, Гайшә, Фатыйма, Разия, Мөхәммәдгарифлар.

Мәгаз хәзрәтнең тәрҗемәи хәлен белүчеләр «галим, күп фәннәр белүче бер зат иде» диләр.

RUHIAT

**170. Шәмседдин бине Габдеррәшид бине Госман бине Габделкадыйр**

1242/1832 елда Мисырда Каһирә шәһәрендә вафат. // [277] Асыл ватаны – Кышкар авылы. Бохарада укыган. Бу якларга кайткач, Ташкичү авылында олуг бер шөһрәт белән дәрес әйткән. Аннан хаҗ нияте белән сәфәр итеп, Каһирәдә Ибраһим паша (1265/1849 елда вафат) белән аралашкан. Мисырда Каһирә шәһәренең дарелфөнүнендә фарсы теле мөгаллиме булып, хаҗга барганчы вафат булган.

Остазлары: Габдессәлам бине Габдеррахман әл-Курсавый, Гатаулла бине Һади әл-Бохарый һ.б. Шәйхе Әбү Салих әл-Хәлеҗи әт-Төрекмәни. Галим, зирәк, җиңел табигатьле, яхшы аралашучан, мәзәк иясе бер зат вә беркадәр исрафчыл булган. Шул сәбәпле күп кешеләрнең малын әрәм иткән. Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый тарафдарларыннан булып, аның хакында фикере яхшы вә аның тарафын куәтләр иде, диләр. Вафат булгач, бу мәмләкәттә (Ташкичүдә) ике кызы һәм Мисырда Гали исемле бер угылы калган. Ата-анадан мәхрүм бер ятим бала булган хәлдә, Ташкичү авылында Әбү Йәзид бине Ибраһим бине Әбәк бине Туйхуҗа исемле дәүләтле бер зат тәрбиясендә укыган һәм гыйлем эстәгән. Хәтта әлеге зат моның Бохарадан кайтуына гаять камил сурәттә мәдрәсәләр төзеп, хәзерләп торган.

## 171. Искәндәр бине Гали бине Ает (Гаед) бине Хөсәен бине Хәсән бине Туйкилде бине Илтимер бине Биктимер бине Аксәед бине Имин бине Байтөгәл бине Алдыргыш бине Әлкәш би бине Өс би (Әлкес би)

Бөгелмә өязендә олуг мөдәррисләр, шәехләр вә бүгенгә кадәр дәвам итмәктә булган мәдрәсәләр белән шөһрәт казанган Бәйрәкә авылында Мөхәммәдкол бине Табай вафат булгач имам вә мөдәррис булып, 1248 елда мөхәррәм ахыры яки сәфәр ае башында (1832 ел, 17 июньдә) 75 яшендә вафат булган. Кабере Бәйрәкәдә. Бу зат беркадәр вакыт Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим // [178] белән бер мәчеттә имамлык итеп, аннан соң өченче мәчет төзелү илә Мөхәммәдшәриф анда күчә, вә бу зат үзе генә кала. Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим, Искәндәр бине Гали, Мостафа бине Әхмәр исемле өч затның мәдрәсәләре бер урында, фәкать үзләренең хөҗрә-бүлмәләре аерым-аерым биналарда булган, вә шул хәлдә шәкертләр укытканнар. Алар вафат булгач, бу мәдрәсәләрнең барчасы өченче мәчет имамы вә Мөхәммәдшәриф бине Ибраһимның улы булган Гобәйдулла бине Ибраһим тәрбиясенә калган. Ошбу мәдрәсәләр, шул көннән бу заманга кадәр гыйлем эстәүче шәкертләр өчен бер сыену урыны булып, бер-бер артлы алмашынып, олуг һәм файдалы мөдәррисләр укытканнар.

Балалары: Мөхәммәд, Әхмәд, Мөхеддин. Кызлары да булган, берсе Кәрәкәшле авылында Шәрәфеддин бине Яркәй никахында, берсе Урыссу авылында Бакый мулла исемле затта, Вәсилә исемле бер кызы Бәйрәкәдә Гобәйдулла бине Ибраһим никахында булган. Бәйрәкәдә исеме бу көнгә кадәр мәгълүм Исхак бай ошбу затның бертуганы булып, хәтта имам вә мөдәррис булуы да шул Исхак тырышлыгы белән, дип сөйлиләр. Мәсгудь әфәнде: «Искәндәр хәзрәтенең остазлары безгә мәгълүм түгел. Фәкать сәяхәтче бер адәм булып, күп урыннарда йөргән. Урта дәрәҗәдә гыйлеме булып, сөйләме ачык, шәкертләр өчен дәресләре файдалы булган», – ди.

Искәндәр илә Исхакның тагын Фәйзулла исемендә бертуган кардәшләре булган. «Иң элек Фәйзулла вә аннан соң Исхак, ә аннан соң Искәндәр вафат булды. Араларында бары икешәр ел вакыт үтте» диләр.

## 172. Мостафа бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмәтәй бине Таутик әл-Мөндеши

Казан өязендә Мөндеш авылында имам вә мөдәррис булып, 1248/1833 елда изге рамазан/февраль аенда 70 яшендә // [279] вакытында вафат иткән. Бохара, Кабул вә Һиндстанның мәшһүр шәһәрләрендә озак вакыт сәяхәт итеп, өч мәртәбә хаҗ кылган.

Балалары: Габдулла, Габдеррахман.

Кабер ташына ошбу рәвештә гыйбрәтле сүзләр язылган:

> Саныма бакдым хаҗи Мостайның кабер ташыйа,
> Сәнең гыйбрәттер, дукунур һәр кешенең башына.

> *дукунур* – төшәр

Олуг галим бер имам һәм камил остаз, дәүләтле һәм юмарт, диндар, пакь шәех иде.

Габдулла исемле угылы Бохарада укыган вә беркадәр еллар Мәккә һәм Мәдинәдә дәрвиш булган. 1266/1850 елда Җиддә шәһәрендә вафат булган. Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәринең шәкерте.

RUHIAT

**173. Габид бине Дәүки бине Заһид əд-Динеси**

Бөгелмә өязендә Динес авылында имам булган. 1248/1833 елда вафат.

Остазлары: Габдеррәшид бине Йосыф әл-Ашытый һ.б.

Муса исемле бер фазыйль угылы калган. Үзенең күчереп язган «Бәйзави тәфсире» китабы бу көндә безнең кулыбызда. Язуы бик үк матур булмыйча, хаталары булса да, басма китаплар алырга кодрәтебез юк һәм мондый газиз әсәрләрне күрергә һәртөрле сәбәпләрдән мәхрүм бер вакытыбызда сөекле әтиемнең ярдәме белән бу нөсхәне кулга төшерүгә ирештек һәм файдаландык. Җәнабы Аллаһ гафу кылсын! Әлеге нөсхә 616 кәгазьдә булып, ахырында мондый язма бар: «...бу тәфсир 1794 елда Болгар төбәгенең Габид бине Тәүки кулы белән күчерелде. // [280] Болгар һәм Уфа иленең Бөгелмә өязендәге Динес авылында күчереп тәмам ителде. 1794/1208 елда 14 май, җүзәнең 14 нче көнендә тәмам булды».

**174. Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ бине Габдулла бине Богдан**

Асыллары Бөре өязендәге Богдан авылыннан. Гаделшаһ бине Габдулла Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып, 80 яшенә ирешеп, 1227/1812 елда дөнья куйган. Кабере мәгълүм. Балыклы Күл авылында мәшһүр ахун Хөснеддин бине Шәмседдин, Минзәлә өязендә Вәрәш Мөслим авылында Шәмгун мулла моның мәдрәсәсендә укыганнар. Шәмгун мулла исә, 90 яшьләренә ирешеп, 1860 елда вафат булган. Гаделшаһ хәзрәте галим, укыту һәм галәм хосусларында оста һәм булдыклы бер зат булган, диләр. Күчереп язган бер «Мотаувәл» китабы ахырында болай дип теркәгән: «Бу нөсхә Гаделшаһ бине Габдулла кулы белән 1175–1177/1762–1764 елларда күчереп язылды. Боларны язганда Гаделшаһ хәзрәтнең бер иске җыентыгы янныбызда булып, ком арасында энҗе эзләгән бер кеше кебек, язуларын тикшереп чыктык. Монда үз каләме белән язылган ике васыятьнамәсе бар. Боларның берсе башыннан бер бит яки күбрәк төшкән булып, икенчесе тулы. Булган хәлләренчә һәр икесен бу урында күчерәбез. «...Вә урланудан яхшы саклап тотарга. Сораучы кеше мәнфәгать алыр өчен биреп һәм аннан кайтарып алырга. Вә барчасын бер урында һәм бер кеше кулында калдырмаска. Угылым Дәүләтшаһны мөтәвәлли кылдым вә ул нөсхәләрне яхшы саклар өчен. Үзем ун сумга алган тимерле күк сандыгымны да вәкыф иттем. Фани дөньядан мәңгелек йортка угылым Дәүләтшаһ та күчсә, үз угылым булганга, мәдрәсәгә хәле җитәрлек булса, аның // [281] кулында булыр.

Әгәр дә угыллары ике яки күбрәк булып, һәрбере мәдрәсә тотып, мөэмин вә мөселманнарга мәнфәгать бирүче булсалар, ул вакыт үз хәлләренә монасыйб булган нөсхәләрне нәүбәттә алып файдаланырлар. Әмма варисларым үз варисларына васыять итмәсеннәр, бәлки урынына куйсыннар. Үз балаларымнан соң оныкларым бу рәвештә мөтәвәлли булып гамәл кыйлсыннар. Әгәр нәселемнән мөтәвәлли булып, үзе файдаланырлык кеше булмаса, мәнфәгать күрерлек галимгә биреп файдаланырлар һәм соңыннан кире кайтарып алыр. Бер-берсеннән аерылмыйча, барчасы бер урында булсыннар. Кайчан әҗәл җиле исеп, минем газиз гомеремне кисеп, фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчсәм, варисларыма васыятем: безнең мирасыбыздан дирһәм һәм динар калды, дип, арагызда низаг булмасын. Чөнки дирһәм, динар туплау минем гадәтем булмады. Хак Тәгалә хәзрәтеннән мал һәм хезмәтчегә гаҗиз булмауны теләдем, әлхәмделиллаһи, Хак Тәгалә гаҗиз итмәде. Моннан соң да өметем шулдыр, сезләр дә шулай булыгыз. Янә вафатым соңында акча вә гайре затлардан 30 сум хәергә таратып һәм 70 сум фидия бирегез. Якын авылларга хәбәр итегез һәм шулардан мин мескен өчен бәхиллек

RUHIAT

үтенегез. Һәүл намазымны укырга үтенеп вә фидиям биреләчәк галимгә намазым, рузәм, важиб корбаннарым, зәкятем, гошерем өчен хәер-дога кылдырыгыз. Шулай ук гайбәт вә фахиш сүзләрем өчен, гаиләм, угыл һәм кызларым хакында булган кимчелекләрем өчен, күз гөнаһларым өчен ярлыкау сорагыз. Болар минем гариб, зәгыйфьлекләремнән булган гөнаһларым, инде пошаманга калдык. Ләкин вакыт үтте, кайтачак түгел. Әмма сез гафил булмагыз. Яшьлек вакыты – шайтанныкы, имеш. Аз гомеребезне күп дип санадык, әмма күп түгел икән, җил кебек үтте дә китте. Фидиямне кабул итүчеләр фәкыйрьләр, изгеләр, намаз әһелләре булсын. Нәфесле, ач күзләр булмасын. Мин гаҗиз, гарибне искә алынган гөнаһлардан коткарыр өчен һәм аларның да гөнаһларын Хак Тәгалә гафу итеп, җәннәткә күндерсен. Безнең гөнаһларыбыз алар өстенә куелмасын. Каберемнең дүрт // [282] почмагында дүрт могтәбәр галим утырып, бере «Сүрәи Йасин» вә бере «Сүрәи Дохан», вә бере «Сүрәи Әлиф, Ләм, Мим», бере «Сүрәи Мөлек» укысыннар. Аларга берәр сумлык әйберләр бирегез. Мең тәһлил унике кешедән әйттереп, аларга утызар тиен бирегез.

Туганнарым, якыннарым вә карендәшләрем, дусларым каберемне белеп, минем өчен Коръән укып, дога кылулары өчен һәм хайваннардан саклау өчен каберем тирәли кирпеч йә таштан бер бина кордырыгыз. Әгәр дә берәр кеше миннән рәнҗү күргәнен сөйләсә яки әйберен алып, онытып кайтармый калган булсам, һәрничек булса да ризаландырыгыз. Җомга, гаед, Кадер кичәләрендә минем өчен садака бирегез. Нәфел намазлар, Коръән укып багышлагыз, мин исә вакытымда сезнең хәсрәтләрегезне җыйдым. Балигъ булган угылларым! Яшь калган балаларыма шәфкатьле булыгыз, укырга тырышып, изге юлга күндерегез, үзегез дә изгеләр сүзен, картлар нәсыйхәтләрен тотыгыз. Аларга инкяр күзе белән карап, тел озайтмагыз! Минем җиремдә аталык итегез, балигъ булмаган балаларымны аермагыз. Дөньяда йөкче булуны гадәт итмәгез, бу исә атабыздан васыять ителеп калган. Без дә тәҗрибә иттек, пошаманлык җыйдык. Сез тәҗрибә дә итмәгез, чөнки муафыйк булмаган эшкә тәҗрибә кирәк түгел. Фәкыйрь Гаделшаһ бине Габдулла язды. 14 рәҗәб /10 апрель, 1203/1788 ел». Моннан соң икенче каләмнәр белән «Мәүлана дамелла Гаделшаһ хәзрәтләренең сәламәт заманында үзе язган әлеге васыятьнамәнең хаклыгын раслап, мин, ахун Габделхаликъ Габбас угылы һәм мин фәкыйрь дамелла – Зөлкарнәйн» дип язылган.

Икенчесе: «Бисмилләһи-рахмәни-рәхим. Мин Эстәрлетамак өязенең асыл ватаным Бүре Казган булып, унике ел микъдары Эстәрлебаш илендә булган мөэмин вә мөселманнарның җамигъ мәчетләрендә имамлык итеп, хәлебез кадәр вәгазь, нәсыйхәт кылып, Аллаһ ризасы өчен мөселман балалары // [283] укытканда 1217/1803 елда атабыз Адәм галәйһиссәлам яратылудан 7311 елда гөнаһлы, җәфаланучы, зәгыйфь, хурлыклы Гаделшаһ үткән гомеребезне хәтеребезгә алып күздән кичердек. Үткән 70 елга ирешеп, барчасы файдасыз үтеп, фани булган. Тормыш сәхифәләребезне бозык хыяллар белән тутыруыбыздан күп пошаман булдык.

Гомердән бәрәкәт, тәннән сәламәтлек, кулдан мал китте, һичберсен кайтарып алу мөмкин түгел. Әмма Аллага шөкерләр булсын, бәндәсенә мәрхәмәт итеп, 37 бала дөньяга китерде. Болардан 18 угыл, 17 кыз, икесе үле булды. 18 угылдан 5 есе исән булып, үз каршыбызда балигъ булды. Рәсүлуллаһ сөннәте буенча йортлы, гаиләле иттек вә бу юлда кирәкле малларны сарыф кылдык, калган ике яшь угылларым Мөхәммәдхәсән илә Мөхәммәдгалигә, алар микъдарынча, малмөлкәтле итәргә ниятләсәм дә, тутыру насыйп булмады. Олы углым Дәүләтшага 362 сумлык, Габдессаттарга 290 сумлык, Фәррахшадка 203 сумлык мал сарыф итүемнән варисларыма мал калмаган. Аз булса да, алданып калмасыннар өчен,

кулда барны үз кулым илә бүлеп бирдердем. Гәрчә тигезлек булмаса да, үз кулым белән сәламәт вакытымда бирү изге шәригатькә муафыйк. Өч остазбикәләрем өчесе өч өйдә торып тереклек иттеләр. Казаннары, кашык-аяк кеби нәрсәләре һәрберендә бар. Углым Шәрифтән калган маллары анасы вә кече хатыным Шәфигагә, мин үз өлешемне төшердем. Углым Дәүләтшаһны васый (васыятьне тормышка ашыручы) итеп билгеләдем. Ни рәвештә язган булсам, һич үзгәртмичә үтисең. Үзем ничек тиешле икәнен белеп эшләдем, эшем мәңгелек булсын. Кече угылым Мөхәммәдгалигә әйбер чыгарылмады, аңа укырга куштым. Малга алданып, укудан мәхрүм булмасын. Ошбу васыять һәм багышлау язмасы 1803 елда башланып, 1806 елда тәмам булды. Июнь башында. Гаделшаһ бине Габдулла».

Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ «Дәүләтшаһ ишан» исеме белән мәшһүр // [284] зат. Шул хәлендә Казан өязендә Кышкар исемле авылда вә аннан соң 19 еллар Курсада имамлык һәм мөдәррислек илә мәшгуль булып, «бу Казан йортында байларның зәкятләрен күп ашадым, инде үзем игенчелек итеп, кул кәсебем белән тормыш итсәм иде» дип, Оренбург өязендә булган Чебенле авылына күчкән һәм анда 1248/1832 елда 22 рәҗәбтә/3 декабрьдә 75 яшендә вафат булган. Кабере шул авылда.

Остазлары: Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни һ.б.

Шәкертләре: Ибраһим бине Габденнасыйр әс-Сәгыйди, Салих бине Сәйфулла әл-Чыршыуый, Нигъмәтулла бине Габдеррәхим әл-Пинзәви һ.б.

Бохарага баргач, шәех Әбү Салих әл-Хәлеҗи әт-Төрекмәни хозурында гыйлем эстәп, ишанлыкка рөхсәт алган һәм, бу якларга кайткач, мөридләр тәрбияләү белән мәшгуль булган. Һибәтулла бине Сәедбаттал илә Нигъмәтулла бине Габдеррахим исемле затлар шәехлектә үзенә дәвамчы булганнар.

Хатыны Казан өязендә Мәмәш авылында Госман бине Габдулла кызы Шәмсия булган.

Угыллары: Могътәмидшаһ, Мөхәммәдсадыйк, Габдулла, Гобәйдулла, Әхмәдшаһ, Габдеррәхман, Габделгалләм. Кызлары: Салиха, Ләтыйфа, Газизә һ.б.

Габдулла, дәүләт хезмәтендә буларак, 25 еллап кантон булган. Габделгалләм, 1245/1830 елда дөньяга килеп, бу көндә Иләк шәһәрендә имам вә ахун. Әхмәдшаһ Бохарада гыйлем алган вакытта вафат булган, диләр. Салиха Калкаш авылында Мифтахеддин бине Каибкол исемле бер мөхтәрәм затта, Ләтыйфа Куганакта Тәмурбәк ахун бине Вилданда, Газизә Зыябаш авылында Габдессәлам ахунда вә бер кызы Нигъмәтулла бине Габдеррәхим әл-Пинзәви никахында булганнар. Угылы Габелгалләм хәзрәт хәбәренә күрә, Дәүләтшаһ ишан хәзрәтләре Бохара шәһәренә әүвәл мәртәбә укыр өчен вә болар белән бәрабәр газиз һәм сирәк китаплары, // [285] олуг затлардан килгән хисапсыз хатлар – барчасы 1879 елда Иләк шәһәрендә булган янгын вакытында янып, юкка чыкканнар.

Вафат булгач, Һибәтулла бине Сәедбаттал исемле дәвамчысы «Мәҗмәгыльәдәб» исемле татарча шигъри китабында гүзәл сурәттә мәрсиясен язган. Гүзәл бер касыйдә.

Иске вә тузган бер кулъязма җыентык эчендә Дәүләтшаһ ишан исеменә килгән хатлардан кайберләренең күчермәләре бар. Шулардан без дә бу урында бер микъдарын күчердек. Очып югалган яки өзелеп төшкән сүзләр урынына нокталар гына куеп китәргә мәҗбүр булдык. Бу хатлар асыл нөсхәләрдән күчерелгән нөсхәләрдән күчерелде.

RUHIAT

Ишан хәзрәтенең (Төрекмәни ишан булса кирәк) 1796 ел, 3 июньдә мулла Дәүләтшага тапшырылган хатыннан нөсхә[68].

Ошбу хатларның ахырында язучының исеме мәгълүм булмаган кебек, кайда һәм кайчан язылулары да мәгълүм түгел. Күчерелгән нөсхә гаять дәрәҗәдә бозылган кебек, язуы да хаталы иде. Бөтенләй дөнья йөзеннән юкка чыкмыйча, начар сурәттә булса да нөсхәләр калсын, шаять, бер дәртле кеше чыгып төзәтер, дип яздык. Аннан соң фарсы телен яхшы белүче Лотфулла әфәнде әл-Исхакый ярдәме белән тагын берникадәр дөресләүгә ирештек.

Үзенең Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый хакында кыска бер язмасы күрелгән булса да, кызганычка каршы, күчереп алу насыйп булмады. Бу язмасында Әбеннасыйрны яхшы сурәттә мактаган вә дошманнарның хаксыз гайбәт вә яла ягуларын сөйләгән. Моның исә Әбеннасыйрның Бохарада булган вакыйгасыннан соң шәйхе Ниязколый әт-Төрекмәни ишарәсенә күрә язылган дип уйлаучылар бар. Чөнки шәех Төрекмәни үзе, ноктасына кадәр, Әбеннасыйрның золым күрүенә шөбһәсе булмаган.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим вә фазыйль иде. Тәфсир вә хәдис, шулай ук фикъһ, ысул, гарәп теленнән гыйлемле иде. Фәлсәфә белән мәшгуль булып, кәлям фәненә бирелмәгән иде. Гаять шәргый, гадел, суфый, диндар, игътибарлы иде. Дин юлында Хак юлын сөйләүче булып, Аллаһы // [291] Тәгалә юлында һичкемнең шелтәсеннән курыкмас иде. Вакытын китап уку вә башка файдалы эшләргә багышлый иде. Ишан Ниязколый әт-Төрекмәни хезмәтенә кереп, ишанлык һәм мөрид тәрбияләү илә мәшгуль иде. Дөнья әһелләренең шәригатькә хилаф гамәлләренә ризалык күрсәтмәде вә шул сәбәптән аларга юлдаш була алмады. Остазы булган Әбү Салих әл-Хәлеҗи әт-Төрекмәни тарафыннан олуг мактауларга иреште, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүшине гыйлемле санамас иде», – дигән.

RUHIAT

### 175. Габделваһаб бине Габдеррәшид бине Ишкуат

Богыруслан өязендә Бәкер авылында имам вә мөдәррис булып, 45 яшьләрендә вакытында 1248/1833 елда вафат булган. Кәшшаф исемле бер угылы вә ике кызы калган. Остазы Саба авылында Сәйфеддин бине Әбүбәкер әш-Шыңарый. «Гыйлем алганда Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйның шәкерте Габбас бине Мөхәммәделәмин илә күп бәхәсләре булыр иде, дәресләрне тәмам итеп төп ватаннарына кайткач та камил дуслык эчендә яшәделәр, вафат булган вакытында угылын шул Габбас мәдрәсәсенә җибәрергә васыять итте», – диләр.

Остазлары турында язган бер хезмәтен күргәнебез булды. Кыскача эчтәлеге ошбу: «Бу фәкыйрьнең остазы Сәйфеддин әс-Сабауый. Вә аның остазы Мөхәммәд Гатаулла әл-Бохарый. Вә аның остазы үзенең атасы Мөхәммәдһади, аның остазы Мәүләви Фәйзи. Аның остазы Мәүлана Шәриф. Аның остазы Йосыф әл-Карабагый. Аның остазы Мәүлана Мирзаҗан. Аның остазы Мәүлана Хуҗа Җәмал. Аның остазы Җәлаледдин әд-Дәвәни. Язылды 1820 елда».

Кәшшаф исемле угылы бүген дә шул Бәкер авылында // [292] булып, оныгы Мөхәммәдзакир бине Кәшшаф Тройски шәһәрендә ахун Хаҗиәхмәд вә шәйхе Зәйнулла әл-Халиди хәзрәтләреннән суфыйчылык һ.б. гыйлемнәрне өйрәнеп, бүген Алма-Ата шәһәрендә дәрес әйтмәктә вә шәехлек итмәктә. Кайбер басылып чыккан әсәрләре дә бар.

---

[68] Ризаэддин Фәхреддин бу урында ишан Төрекмәни һәм аның мөридләреннән 1797, 1805, 1808 елларда Дәүләтшага күндерелгән фарсы телендәге барлыгы 7 хат текстын күчереп бастырган. – *Төз.*

### 176. Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүуаб бине Габделгани әл-Мәрҗани

87 яшендә вакытында, 1279/1833 елда Хөсна авылында вафат булган. Олуг Яке вә Хөсна авылларында имам булып, 1225/1810 елда имамлыктан чыгып, сәүдә кәсебенә керешкән.

Остазлары: Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый һ.б.

Балалары: Бәһаведдин, Гыйззеддин, Сираҗеддин, Ләтыйфа.

### 177. Мөхәммәделәмин бине Сәйфулла бине Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай

Казан өязендә Наласа авылында имам вә мөдәррис булып, 1242/1826 елда хаҗ сәфәренә чыгып киткән вә, Мисырның Каһирә каласына барып, Ибраһим паша илә күрешкән һәм кабул кылынган. Шәмседдин бине Габдеррәшид вафат булгач, аның урынына фарсы теле мөгаллимлегенә билгеләнгән һәм хаҗ кылганчы, 1249/1833 елда вафат булган. Кабере шунда. Бу мәмләкәтнең сирәк галимнәреннән.

Остазлары: Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши һ.б. Бохарага баргач, Әбеннасыйрга теләктәш булган вә, аның фикерләрен фәһемләп, аның тоткан юлының хакыйкатен аңлаган. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим вә фазыйль булып, гыйлем иясе иде; дин гыйлеме китапларын укып күп файда алган иде, фәлсәфә һәм гыйльме тәүхид буенча әсәрләр иҗат иткән иде. // [293] Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый хакында яхшы фикердә булып, үз әсәрләрен дә аңа нисбәтле рәвештә иҗат итәр иде. Әсәрләре һәрникадәр тәгәлсезлекләрдән азат булмаса да, күбрәк урыннарында тугры вә хуш сөйләгән», – дигән.

Мин алган хатлардан Кыйвамеддин әл-Болгарый исемле затныкы дип хисапланган «Мәгадыйнел-мәкасыйд» исемле китап Мөхәммәделәмин әсәре икәнлегенә инандым. Әлеге хатларның берсе Габделхак әфәнде бине Зыяэддин бине Таҗеддин әл-Иштирәкинеке. // [294] «Әлеге һәм кичке намаз хакында бу ике әсәр авторы, минем уема күрә, Наласада булган Мөхәммәделәмин бине Сәйфулладыр, һәм моны «Мөстәфадел-әхбар...»ның 238 битендә булган бәйаннар да раслый».

Икенчесе фазыйль Галимҗан әфәнде якыннарыннан Шәһәр бине Шәрәф әл-Аксуый хатларыдыр ки. Ул: «Ошбу көннәрдә бер кульязма җыентыкны күздән кичердек. Бу рисаләнең өслүбе һәм язылышы «Мәгадыйнел-мәкасыйд» әсәренә тәңгәл, хәтта берничә җирләрдә тәмам кабатлана. Шуңа күрә бу әсәр Мөхәммәделәмин ән-Наласауый иҗаты булуын җәнабыгызга белдердек», – дип яза. // [295]

Бу әсәр Газзали вә Курсавый әсәрләре кебек гүзәл вә ләззәтле өслүбтә язылган.

RUHIAT

## 178. Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза әл-Чокалый

Казан өязендә Ашыт авылында имам вә мөдәррис булып, 1249/1833 җөмади-ел-ахирә/октябрь аенда 75 яшендә вафат булган.

Остазлары: Габдеррәшид бине Йосыф әл-Ашытый, Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Сәгыйдь бине Ибраһим әл-Барышый ән-Нократый, Хәбибулла бине әл-Хөсәен әл-Орый, Габделмәҗид бине Яхъя әл-Борнагыйлар.

Шәкертләре: Исхак бине Сәгыйдь әл-Казаный, Фазыл бине Нигъмәтулла бине Бәшир әл-Буавый, Сәгыйдь бине Хәмит әл-Бәшир әл-Буавый, Сәгыйдь бине Хәмит әл-Бәрәскәви, Габделләтыйф бине Яһүдә әт-Тилчәли, Сәйфулла бине Бәшир әл-Чокалый, Зәйнелгабидин бине Яхъя әс-Суыксуый, Фәтхулла бине Вәлид әз-Задури, Баһаведдин бине Сөбхан әл-Мәрҗани, Хәмәди бине Сәйфелмөлек әл-Чокалый, Вәлид бине Сәйфелмөлек әз-Задури һ.б.

Балалары: Хәбибә, Габделмөлек, Габделбасыйр, Габдеррәкыйб, Хөбәйбә, Гайшә һ.б. Хатыны Мәхбүбә бинте Туктамыш бине Габделкадыйр бине Идрис бине Юныс, һәм үзеннән соң 1258/1842 ел, зөлкагдә/декабрь аенда вафат булган. Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Гаять тәкъва вә диндар, сафлык һәм изгелек яклы, суфый // [296] иде. Иманы дөрес, гамәлендә мәзһәбләрне берләштерер, шәригатькә нык ябышкан, тормыш итүендә тәкәллефсез, хак сөйләүче, Хәбибулла ишан бине әл-Хөсәеннән ишанлыкка шәһадәтнамәсе булса да, яшерүе сәбәпле, вафатына кадәр һичкемгә мәгълүм булмаган», – дигән. // [297]

## 179. Габид бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Кенәри

RUHIAT

Казан өязендә Кенәр авылында имам вә мөдәррис булган. Аннан әүвәл Арбаш, Кариле, Орнашбаш авылларында да дәрес әйтү илә мәшгуль булган. Хаҗ сәфәреннән кайтуында Кара диңгездә 1249/1833 елда вафат булган[69]. Кабере Трабзон шәһәрендә.

Остазлары: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви һ.б.

Шәкертләре: Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәнгәри, Әбүбәкер бине Җәгъфәр әл-Әгерҗеви, Габденнасыйр бине Габдеррәхим әт-Тайсуганый, Фәхреддин бине Габдеррахман әл-Бәхтиярый, Хисамеддин бине Сәйфеддин әл-Олывый, Сәгыйдь бине Хәмид әл-Бәрәскәви, Габделләтыйф бине Әдһәм әл-Йулыкый, Габделҗәлил бине Гаделшаһ әл-Богадышый һ.б.

Арбаш авылында булган вакытында мәдрәсәсендә Мөхәммәдрәхим бине Габдүк исемле шәкерте 1213/1798 елда «Хәялый хашиясе»нә булган «Мулла Касыйм шәрхе» китабын күчереп тәмам иткән. Үзе нечкә күңелле, оялчан бер кеше булып, Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый белән кайбер әңгәмәләре булганлыгы сөйләнә. Урынына Мөхәммәдсадыйк исемле угылы имам булган. Бәхтияр авылында имам булган Фәхреддин бине Габдеррахман исемле зат имзасы белән ошбу рәвешле язу күргәнебез булды: «Орнашбаш авылының мулласы Габид Габделгазиз угылы 1831 ел, 10 август хаҗ сәфәренә юнәлде вә кулында булган кенәгәләрен без, Бәхтияр авылында указлы имам Фәхреддин Габдеррахман угылына тапшырды».

[69] Габдессәлам мөфтинең 49 нчы хаты.

## 180. Сафкол бине Котый бине Килмәк

Казан өязендә Йуртыш авылыннан. Олуг Мәңгәр авылында имам булып, // [298] 78 яшендә 1250/1835 елда вафат булган. Бабасы, милади XVI гасыр ахырында Кырым мәмләкәтеннән әсир буларак килгәнлеге сәбәпле, Килмәк исеме белән танылган.

Хатыннары: Зөбәйдә бинте Габдессәлам бине Исмәгыйль һәм Сәлимҗәүһәр Котый кызы булганнар. Олы угылы Садыйк Фәез бине Габделгазиз хозурында гыйлем алып, Казан өязендә Хөсна авылында имам булган вә 1268/1859 елда зөлхиҗҗә/август аенда вафат иткән. Икенче угылы Мөхәммәд тә Мәңгәр авылында имамлык итеп, 80 яшендә вафат булган.

Сафкол бине Котый 1170/1757 елда дөньяга килеп, Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Ибраһим бине Хуҗаш, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый хозурларында гыйлем эстәп, бер-ике нәүбәт Диния Нәзарәтендә дә әгъзалык хезмәтен үтәгәнлеге мәгълүм. Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Бер-ике нәүбәт хезмәт иткәннән соң, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим соравы буенча, тагын бер нәүбәт әлеге вазыйфасында дәвам иткән. Угылы Мөхәммәд «икенче нәүбәт калуыбызда, атабыз илә Оренбургтан Уфа шәһәренә күчүебездә мин 6–7 яшемдә идем, гафләт илә Идел елгасының икенче тарафында калдым, мине кире кайтып алдылар» дип сөйләде. Яшь вакытыбызда күп мәртәбә күрмеш идек. Олы гәүдәле, зур сакаллы бер зат иде, һәрникадәр галим булмаса да, диндар вә изге булып, кимчелекләрен таныр вә хаталары өчен үкенер иде. Кыска төннәрдә ястү вә витыр намазларын укуны куәтләгән тезмә әсәре бар. Мөхәммәд исемле угылы 1292/1875 елда рамазан/октябрь аенда вафат булды. Нурмөхәммәд исемле угылын Мәңгәр халкы үтергәнлеккә үз хәленә лаек сурәттә бер мәрсия бар иде», – дигән.

RUHIAT

***Мөляхәзә***

Җәмгыяте шәргыя мәхкәмәсе [Диния Нәзарәте] башлап Оренбург шәһәрендә ачылуын вә соңрак, 1208/1793 елда, Уфа шәһәренә күчүен фазыйль Мәрҗани берничә әсәрендә язса да, безгә күрә бу факт расланмады. Башлап мәхкәмә ачылган вакытта булган документ кәгазе бүген дә исән // [299] булып, анда исә Уфада нигезләнгәнлеге язылган. Ошбу урында Мөхәммәд бине Сафкол хәбәренә килгәндә, 6–7 яшендә булган берәүнең мәхкәмәнең күчүе хакындагы хәбәрен раслау беркадәр кыен. Атасы илә Оренбург шәһәреннән кунак вә сәфәрдә йөреп килгән булсалар гаҗәп түгел.

## 181. Ибраһим бине Габдеррәшид бине Ибраһим бине Габдеррәхим әт-Тарауый

Атасы Габдеррәшид Сибириядә Тара шәһәрендә булган таш мәчетне Сәед исемле бер сәүдәгәр белән бергәләп төзеткәннәр. Әлеге мәчет төзелешенә Табул вилайәт хакимияте тарафыннан 1794 ел, 19 августта № 20898 белән рөхсәт бирелгән. Атадан угылларга кала килгән риваятьләргә күрә, җамигъ мәчете төзүгә рөхсәт булгач, Тара шәһәрендә вә әтрафында булган галимнәр вә сәүдәгәрләр, нигез салынганда катнашып, зур бер җыен вә бәйрәм иткәннәр.

Бу зат – Ибраһим – Тарада имам булып, атасы төзеткән мәчеттә мөтәвәлли дә булган. 1250/1834 елда Мөхәммәд исемле угылы илә берлектә хаҗ сәфәренә юнәлеп, ошбу сәфәрдән кайтып килгәндә, үзенә 45 вә угылы Мөхәммәдкә

17 яшь вакытларында, һәр икесе вафат булып, Бәйрут шәһәре каберлегендә җирләнгәннәр. Диндар вә гаять тәкъва бер зат булган кебек, зур мал илә сәүдә кәсебендә дә булган. Сәүдә белән мәшгуль вакытларында да кайбер гыйлем ияләре мәҗлесенә йөреп, атнасына ике мәртәбә «Мәснәви» китабыннан дәрес укыган, диләр. Ул күчереп тәмам иткән «Мөхтасарел-викайә» шәрхе «Җамигыр-рөмуз» нөсхәсен күргәнебез булды. Язуы һәрникадәр яхшы вә кагыйдәчә булмаса да, хуш һәм дөрес. Петербургтагы Азия китапханәсендә № 121 булган «Һәдиятессагълүк» китабы ошбу зат каләме илә язылган дип уйланыла. Ахырда // [300] булган тарихы болай: «Бу нөсхә Болгар вилайәтендә Каргалы авылында Габдеррәшид бине Габделкәрим мәдрәсәсендә Ибраһим бине мулла Габдеррәшид кулы белән күчереп язылды, 1202/1788 ел».

Әбү Йәзид һәм Гомәр исемле угыллары вә берничә кызлары калган. Оныгы Габдеррәшид бине Гомәр Тарада имам вә ахун булып, 1309/1892 ел, 19 зөлхиҗҗәдән/15 июльдән башлап 1311/1894 ел, 7 зөлкагдәгә/12 майга кадәр Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәтендә әгъза булган, аннан үз ихтыяры белән бу вазыйфаны куйган.

### 182. Габдеррәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым

Бөгелмә өязендә Шушма елгасы башында Тимәш авылында мөдәррис булып, 1251/1835 ел, 5 рабигыль-ахирда/31 июльдә җомга көн вафат булып, җеназасын шул авылда имам вә мөхтәсиб булган Сәфәргали бине Габдеррахман укыган. 80 яшьтә булган.

Хатыннары: Хәмидә Габдерразак кызы, Бәдигыльҗәмал, Фәтхия бинте Рәхманкол бине Габдерразак.

Балалары: Габденнасыйр, Сахибҗәмал, Сахибкәмал, Бибиҗәмал, Бәдигыльҗәмал, Хәбибкәмал, Әхмәтҗан, Шәйхесәгъди, Җәмаледдин, Җәлаледдин. Сөйләүләренә караганда, Габденнасыйрның нәселе Бохара тарафында. Сахибҗәмал Чиләбе өязендә Күбәкәй авылында Мөхәммәд исемле кешедә, Сахибкәмал да Чиләбе ягында Зариф хаҗи исемле затта, Бибиҗәмал Бөгелмә өязендә Куакбаш авылында Гыймадеддин бине Котлыгбай исемле имамда, Бәдигыльҗәмал Утыз Имән авылында Әхмәтҗан бине Фәзлулла исемле кешедә, Хәбибкәмал Сарыбиккол авылында Әхмәтҗан бине Шәмседдин исемле затта кияүдә. Әхмәтҗан исемле угылы, язуга маһир булып, 1264–1265/1848–1849 елларда Тимәштә вафат. Угыллары исә бу көндә Уфа янындагы Үршәк елгасы буенда Мерәс авылында яшиләр. Җәмаледдин // [301] исемле угылы да шул Мерәстә яшәп, 1307/1890 елда вафат булды. Нәселе күп һәм таралган.

Аны һәм Гыймадеддин бине Котлыгбайны шәкертлек көннәремдә күргән идем. Әхмәдҗан бине Шәмседдин, беркадәр шагыйрь булган кебек, гүзәл яза иде. Бер вакыйга сәбәпле, тоткын буларак Себергә сөрелеп, Тара шәһәре янында гомер кичереп вафат булган. Балалары һәм нәселе бүген дә күп булса кирәк. Шәех Зәйнулла әл-Халиди хәзрәтләре Вологда шәһәренә җибәрелгән вакытта, Бөгелмә төрмәсендә очрашып күрешүләрен сөйлиләр. Габдеррәхим хәзрәт дәвамчыларыннан иң элек буларак суфыйлыкка бирелгән зат, бәлки, ошбудыр.

Габдеррәхим хәзрәт, Чистай өязендә Утыз Имән авылында дөньяга килеп, беркадәр затлар хозурында гыйлем эстәгәч, Хәмидә Габдерразак вә Бәдигыльҗәмал исемле хатыннары вә Габденнасыйр исемле угылы белән Бохара тарафына сәфәр кылган. Ошбу сәфәрендә хатыны Хәмидә Бәлх вилайәтендә Каурамич исемле бер урында вафат булган. Аннан Бохара вә Сәмәрканд вилайәтләрендә йөреп, Әфган мәмләкәтендә бераз сәяхәт иткәч, Бохарага килеп, Хаҗи Бәгъдади Вәлиэддин би-

не Хәсәннән соң «Мәсҗиде Мәгак»тә имам булган. Ничәдер еллар торгач, бу якларга кайткан вә Утыз Имән авылында Фәтхия Рахманкол кызына никахланган. Башта Чистай өязендә Ислай авылында вә аннан соң Бөгелмә өязендә Сарыбиккол авылында вә иң соңгысы Тимәш авылында шәкертләр җыеп, дәрес укыту белән мәшгуль булган. Мәншүр-указ алмаган вә имамлык кылмаган.

Бохарадан кайтканда, Эстәрлетамак өязе Мерәс авылында башкортлар түрәсе Локман кантон ибне Госман бине Ибраһимнның югалган Габдеррәхим исемле угылы буларак, һәр ике тараф ризалыгы илә хөкүмәт дәфтәрләренә язылган. Ошбу сәбәптән, мишәр буларак дөньяга килгән хәлдә, саф башкорт буларак дөньядан киткән. Балалары да башкортларның җир вә туфракларына катнашканнар.

Остазлары: Габделкаюм бине Габделкәрим бине Аллаһыяр[70] бине Аллаһколы, Аттанияз бине Мескин әл-Хәрәзми һ.б.

Шәкертләре: Мөхәммәдъяр бине Габдулла әл-Ахундый, Габденнасыйр бине Солтангали әл-Кырмыскалый һ.б.

Әсәрләре: «Шәрхе әбйате Морадел-гарифин», «Шәрхе Сөбател-гаҗизин», «Кәшфел-лөгать». Болардан башка гарәпчә, фарсыча, төрекчә тезмә һәм чәчмә әсәрләре бар. «Морадел-гарифин» әсәренә булган шәрехен «Төхфәтет-талибин» дип исемләп, Габделмоталлаб әл-Болгарый исемле затка бүләк итүе шул китабында бәйан ителгән.

Укытуы: укыткан китаплары «Мөхтәсарел-викайә», «Гайнел-гыйлем», «Әлфикъһел-әкбәр», «Тарикаи Мөхәммәдия», «Хәләби, шәрхел-мөннийәт», «Мәсләкел-мөттәкыйн», «Морадел-гарифин», «Сөбател-гаҗизин», «Бидайәтел-һидайәт», «Ысуле әрбәгыйн», «Ихъяил-голум», «Тәгарреф», «Кауагыйдел-гакаид» һ.б. Кич һәм көндезендә, сәфәрдә һәм йөрмәгәндә хөрмәтләп файдаланган китабы «Ихъяил-голум» илә Әбүбәкер Мөхәммәд бине Әбү Исхак Ибраһим бине Ягъкуб әл-Бохарыйның «Тәгарреф»е вә шәйхе Әбелбәрәкәт Әхмәд бине Габделәхәд әс-Сәһәрәндигә нисбәт ителгән «Мәктүбат» җилд-томнары булган. Бу китаплар шулкадәр күңеленә урнашкан ки, хәтта иҗат иткән әсәрләрендә булган гыйбарәләр боларга ияреп язылган.

Китаплар редакцияләү, хаталарын төзәтүгә биргән әһәмияте бик зур булган. Төзәтмә керткән китапларыннан шактый нөсхәләр күргәннән соң, «Истанбул вә Казан матбага-басмаханәләрендә моның кеби мөсаххих булып мөселман әсәрләре төзәтелеп, нәшер ителсә иде!» дип кызыгып куйдык. Фикердәш вә шәкертләренең язулары һәм дөрес, һәм гүзәл булып, болар мәртәбәсендә язуга игътибар иткән халык бу көнебезгә кадәр бу мәмләкәттә күренгәне юк. Габдеррәхим хәзрәтнең үзенең һәм оста язган шәкертләренең һәртөрле төзек вә гүзәл язылган әсәрләрен бер җиргә җыеп сакларга кирәк булса да, ни чара ки, әһәмият бирелмәгән, бу кадәр дикъкатькә юл булмаган. Башка иске вә газиз әсәрләребез кеби, болардан калган әсәрләр дә, озак та үтмичә, утларда янып, юешләрдә череп, балалар кулында ертылып, өзелеп вәйран булып беткән булсалар кирәк.

Үзе күчереп язып тәмам иткән вә зур бер игътибар белән төзәтелгән «Җәмигыр-рөмуз» нөсхәсе бу көндә Куакбаш авылында Гыймадеддин бине Котлыгбай нәселе кулында. Бу нөсхә 229 кәгазьдә вә һәр битендә 35 юл язылган. Язуы вак һәм кыйтгасы да нечкә, кечкенә. Ахырында болай язылган: «Бу нөсхә – Шәмседдин әл-Бохарыйның «Җәмигыр-рөмуз» исемле китабы, Габдеррәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым әл-Болгарый кулы белән Бохара шәрифтә 1208/1794 ел, 4 шәгъбан/7 март көнендә өйлә вакытында күчереп язып тәмам булды». // [311]

[70] Суфый Аллаһыяр дип танылган шагыйрь булса кирәк. 1130/1718 елда вафат булган.

Сәмәрканд шәһәрендә «Мәсҗиде Хуҗа Әхрар»да булган вә хәзрәти Госманга (аңа Аллаһның ризалыгы булсын) нисбәт ителгән Коръәнне төзәтеп яңартуы хакында «Ахырзаман» исемле төрки һәм шигъри китабында болай дип язылган:

Укыр Мусхәфе бер кичә Госман
Өенең сүрахендин төште дошман.
Урар хәнҗәр илә, бакмас үзенә,
Агар каны ушал Мусхәф йөзенә.
Рәсүлулланы төшендә күрмеш иде,
«Бүген безә килерсең» димеш иде.
Сәяхәттә бу мескин йөрдекемдә,
Сәмәркандтә ничә көн тордыгымда
Күребмән Мусхәфе, бер җайда тормыш
Вәрәкъләре тузып, бәнде өзелмеш.
Гаҗәеп хаты уардыр, һичкем ирсә
Укый белмәс, алып багын күрерсә.
Кылыплар пост аһудан вәрәкъләр
Җәлийи хаттыр, уникедер сәтырлар.
Олугдыр катъгы тулы дүрт карыштан,
Дәхи гарзын кылыбтыр өч карыштан,
Юанлыгы улыр ике карыштик.
Агырлыгы улыбтыр пәнҗ сирдик.
Булашмыш каныйга берничә әурак
Хисап итсәк, чыгар уннан зиядәрәк.
Тузып китмеш вәрәкъләрне йыйгыбмән,
Ике такта арасына куебмән.
Дәхи мөхкәм җеп илә таза багълап,
Куебмән такъаэгә хуп агырлап.
Сәмәрканд шәһәренә уарсаң, күрерсең,
Бинаи «Хуҗа Әхрар»дан сорасың.
Улыр хишттән кыйлан бер ак мәдарис,
Бинасы мәрфугъ имәстер, ирер пис.
Эчендә вакыфханә хөҗрәи уар,
Табарсың шунда керсәң, әй талибдар.

*Мусхәф* – Коръән
*сүрах* – тишек, мич тишеге
*ушал* – шул
*күребмән* – күрдем
*вәрәкъ* – бит
*бәнд* – төбе, теккән урыны
*хат* – язу
*пост аһу* – газәл, кыр кәҗәсе тиресе
*җәлийи хат* – гарәп язуының бер төре
*сәтыр* – юл
*дәхи* – тагын
*гарзы* – иңе
*пәнҗ* – биш
*булашмыш каныйга* – канга буялган
*әурак* – битләр
*зиядә* – артык
*йыйгыбмән* – җыйдым
*мөхкәм* – чыдам, нык
*хишт* – кирпеч
*мәдарис* – мәдрәсәләр
*мәрфугъ* – яхшы
*пис* – пычрак
*талибдар* – эзләүче, шәкерт

Искәрмә: Габдеррәхим хәзрәт язган ошбу Мусхәф Шәриф бу көндә Петербург шәһәрендә гомуми көтепханәнең кулъязма китаплар шөгъбәсендә. Сәмәрканд шәһәреннән Төркестан генерал-губернаторы фон Кауфман 1869 ел, 24 ок-

RUHIAT

тябрь 182 нумеры белән мәгариф министрына җибәргән. Хәзер көтепханәдә камил хөрмәт белән һәм һәрбер килүчегә күрсәтелеп торыла.

Габдеррәхим хәзрәт тарафыннан тезмә илә биш-ун юл эчендә язылган һәм дә хәзрәти Госман Коръәне булуы җиңел бер суръттә күрсәтелгән бу әсәр хакында рус язучыларыннан А.Ф.Шибунин җәнаплары шактый зур бер хезмәт язып, Петербург шәһәрендә 1891 елда, Академия // [313] наук басмаханәсендә бастырган иде. 65 биттән гыйбарәт булган бу хезмәттә беркадәр мәгълүмат бирелгән.

Бу нөсхә хәзрәти Госман Коръәне булып-булмавы хакында Шибунин җәнаплары, муллаларча түгел, бәлки тикшеренүчеләр һәм Шәрекъне өйрәнүчеләр гадәтенчә, киң вә тирәнтен тикшергән һәм, моның нәтиҗәсе буларак, хәзрәти Госман Коръәне түгел, шулай булса да, һиҗри I гасырда язылган бер әсәр дигән фикергә килгән. Моннан элегрәк фазыйль Мәрҗани дә, куфи язуының[71] борынгы рәвеше илә язылуына нигезләнеп, ошбу фикергә килгән булган һәм дә хәзрәти Госман Коръәне түгеллеген рәсүме Коръән (Коръән язулары) фәнендә шөһрәт казанган галимнәрдән Хафиз Әбү Габид Касыйм бине Сәлям әл-Бәгъдади (222/837 елда вафат) хәзрәтләреннән дәлил итеп китергән.

Хәзрәти Госман үзе, һәрникадәр язу белүче сахабалардан булса да, үз кулы илә Коръәни Шәриф язганлыгы исбатланмаган. Аңа Мусхәф Шәриф нисбәт ителүе – дүрт нөсхә Коръән яздырып, Мәккә, Басра, Куфә, Шам тарафларына берәр нөсхәсен җибәрүе җәһәтеннәндер. Ошбу нөсхәләрдән бере 552/1157 ел, рамазан/октябрь аенда Әндәлес вилайәте Куртуба (Кордова) шәһәре җамигъ мәчетендә булуы, «Имам» дип танылган Мәдинә нөсхәсе 735/1335 елда Мәдинәдә булганлыгы мәгълүм[72].

Ошбу пергаментка язылган нөсхәнең беркадәр сүзләре һәм хәрефләре соңрак икенче каләм вә башка кара илә яңартылуы вә Петербурга килүенә // [314] кадәр берничә кәгазьләре югалып юкка чыгуы Шибунин җәнаплары тарафыннан хәбәр бирелгән. // [316]

Габдеррәхим хәзрәт, сүз сөйләргә гаять тә кыю булып, хәтер вә нәзакәт саклау яки эчендәгесен яшерү һәм ялагайлану юлына кермәгән. Кулында чукмары вә авызында да чукмарыннан куәтле теле булып, ни дөнья һәм ни дин турында бәхәскә кергәндә җиңелмәгән. Замандаш шәехләрен инкяр итеп, аларның гамәлләрен вә беркадәр гадәтләрен тәнкыйть итеп, кайбер нәрсәләр язган. Шәкертләре, дәвамчылары исә, гомумән, авылларда мөселман балаларын укыту сәбәпле, алар булган һәр авылда ислам дине куәтле. Хәтта бүген дә иң игътибарсыз хисапланган гади халкына кадәр, нинди җирдә вә нинди хезмәтләрдә булсалар да, фарыз намазлары вакытында укыганнары, догалары күп мәхәллә имамнарына караганда дөрес укулары мәгълүм. Хәтта: «Әгәр дә шәкертләре Габдеррәхим хәзрәт дәрәҗәсендә тырышып һәм халык сүзен күтәреп гайрәт иткән булсалар, никадәр җирләрдә уку-язу белмәгән һәм мөселманлыкны дөресләп аңламаган бер мөселман калмас иде», – диючеләр бар. Моның хакында фазыйль Мәрҗани: «Укуга һәвәсле вә күп сәяхәт итүче иде, хач шәкелендә булган нәрсәләрне, хәтта тәрәзә агачларына кадәр инкяр итәр иде. Гарәп, фарсы вә төрки телләрендә әсәрләре күп булса да, хаталары вә ялгышлары да бар. Шәкерте булган Мөхәммәдъяр бине Габдулла әл-Ахундый әсәренә каршы бер әсәр язган. «Сөбател-гаҗизин» китабына язган шәрехе, кайбер хаталарын исәпкә алмаганда, яхшы бәйан ителгән», – ди. // 317

---

[71] К у ф и я з у ы – гарәп язуының борынгы төре. – *Төз.*
[72] Бу көндә бер нөсхә Госман Коръәне Мисырда да бар, диләр.

### 183. Мостафа бине Муса бине Иманкол бине Иманай бине Котлыг бине Үзбәк бине Буҗак бине Әлкәй әл-Казаный

Мостафа, хафиз буларак мәшһүр бер зат, Казанда имам булып, башлап хаҗга барган. Моннан әүвәл Казан имамнарыннан Хиҗазга китүче булмаган. Ашытбаш, Шушмабаш авылларында имам булганнан соң Казанга күчеп, 1251 елның зөлкагдә ахырында/1836 елның 6 мартында 67 яшендә вафат булган. Бохарага барып укыган. Кабулга сәфәр итеп, шәех Фәезхан бине Хозырхан белән күрешкән. 1232–1249/1817–1833 елларда хаҗ сәфәренә киткәч, мәхәллә халкының ризалыгы белән үз урынына Мөндеш авылының Сәйфулла Мортаза угылы исемле затны билгеләп китсә дә, Нурмөхәммәд мөхтәсиб ибне Ибраһим, шул ел 8 гыйнварда Диния Нәзарәтенә гариза биреп, мәхәллә хезмәте итүдән Мортаза угылын тыйдырды һәм Нәзарәт тарафыннан үзе билгеләнде.

Хатыны – Сәгыйдә бинте Габдүш бине Габдессәлам бине Исмәгыйль әл-Кавалый. Баласы булмаган вә нәселе дә калмаган.

Шәкертләре: Шәриф бине Сөләйман әл-Хәерби, Нурмөхәммәд бине Бикбау бине Бикбулат, Габделхаликъ бине Арыслан әл-Казаный һ.б. // 319

Мин күргән иске язулар арасында язуы беркадәр дөрес булган язу – ошбу Мостафа Хафиз язуы.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Карый вә хафиз, кыска сүзле, // 320 гайбәттән азат, нечкә күңелле, нәсех вә тәгъликъ язулары белән яхшы дәрәҗәдә язар иде. Ләкин гыйлем вә дәрес илә шөһрәтле булмады. Вафаты соңында Габдессәлам мөфти Нурмөхәммәд мөхтәсибкә «Хаҗи Мостафа әфәнденең вафатын аңлап бик кайгырдык, голәманың аксакал тәкъва затлары бетте. Аһ, хәсрәт!» рәвешендәрәк хат язып үкенечен белдергән», – дигән.

RUHIAT

### 184. Юныс бине Ибраһим

Чиләбе өязендә Какчыр авылында имам вә мөдәррис булып, 77 яшендә вакытында 1251 рамазан аенда (1836 ел, 1 гыйнварда) вафат булган.

Остазы Оры авылында Хәбибулла бине Хөсәен булган. 40 ел дәрес әйтү белән мәшгуль булган хәленчә, 10 ел дәрес әйткән, диләр. Кардәшләренә дип Тройски шәһәренә килгәч, әҗәле җитеп, шунда вафат иткән. Кабере Тройски зиратында.

### 185. Исхак бине Сәгыйдь бине Йортбагыш бине Колмөхәммәд бине Ишмөхәммәд әл-Лажый

Төп чыгышлары Бәрәңге ягында Лаж авылыннан булып, үзе Казан өязендә Кенәр авылыннан. Бохарадан кайтып, Сәрде авылында вә 1233/1818 елда Чистайда һәм 1247/1831 елда Казан шәһәрендә имам вә мөдәррис булып, 1251/1836 елда вафат булган.

Остазлары: Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Ашытый, Габид бине Габделгазиз әл-Орнашбашый һ.б.

Шәкертләре: Фәхреддин бине Садыйк әс-Сөни, Муса бине Габид әд-Динеси, Хәсән бине Хәмид әл-Курсавый, Хәмидулла бине Шәммас әд-Динеси, Гаедмөхәммәд бине Җәнәй әт-Тубылый һ.б.

Балалары Сәлахеддин, Әхмәд, Хәсән булып, кызлары Фәхреддин бине Садыйк әс-Сөни, Әхмәдҗан бине Габделҗәббар әл-Көекли, Мөхәммәдкәрим бине Габдеррәхим әт-Тәкәнеши исемле кешеләрдә никахлы булганнар.

Заманында гыйлем вә камиллеге белән мәшһүр бер зат.

### 186. Габденнасыйр бине Рәхманколый бине Мөхәммәдкол бине Габдеррахман бине Габделкәрим бине Бикхафиз әл-Биги

Тау ягындагы Биги авылыннан. Әнисе Җәмилә бинте Сөбхан бине Йосыф бине Арыслан. Казан шәһәрендә имам вә ахун вакытында 1251/1836 елның зөлхиҗҗә/апрель аенда кинәттән вафат булып, Казан зиратында җирләнгән.

Хатыны – Нәүбәһар бинте Котлыгъәхмәд бине Заһид бине Габделмәннан әд-Дусмәти. Фәйзеррахман исемле угылы 1292/1875 елда вафат булган. Фатыйма исемле кызы фазыйль Мәрҗани никахында булып, 1268/1859 елда вафат.

Остазлары: Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

Шәкертләре: Хәбибулла бине Рәхманкол әл-Биги (үз карендәше), Миңлебай бине Локман әл-Чагадайи, Габделкәрим бине Габдеррәфыйгъ әс-Сәгыйди һ.б. Башта Сәгыйдь бистәсендә (Оренбург Каргалысында) имам булып, аннан соң Казанга күчкән. // 324

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Хуш кыяфәтле, хуш йөзле, Коръән укуы гүзәл, тавышы бик килешле булып, Коръәнне моңлы вә тәэсирле укуы белән үзен һәм башкаларны елатыр иде. Җөрьәт, ныклык һәм куәт, гайрәт, тәкъвалык һәм суфыйлык белән мәшһүр иде. Фикъһ мәсьәләләре белән мәшһүр иде. Ләкин хотбәләрендә ялгыш гыйбарәләр беленә иде. Сәгыйдь бистәсендә гыйлем алуда сабакташы булу мөнәсәбәте белән мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим илә мәхәббәт һәм дуслыкта булып, мөфти Әхмәд исемле угылын моның хозурына укырга җибәргән иде. Ләкин аралары бозылып, дошманлык пәйда булды. Хәтта ахунлык вазыйфасыннан азат ителсә дә, вафаты сәбәпле, указы алынмый калды. Вафат иткәндә яше 63 иде», – дигән.

RUHIAT

### 187. Мостафа бине Әхмәр бине Мансур

Бөгелмәдән төн тарафта Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1251 ел, зөлхиҗҗәдә (1836 ел, 14 март) 60 яшендә вакытта вафат булган. Кабере Бәйрәкәдә. Мансур исемле бабасы Казан артындагы Балыклы авылыннан Бәйрәкәгә күчеп килгән. Атасы Әхмәрнең 1158/1745, 1159/1746, 1176/1763 елларда нәхүдән «Әл-мисбах», сарыфтан // [325] «Әфгаль», фарсы әдәбиятыннан «Гөлстан» исемле китапларны күчергәнлеге билгеле. Кайбер урыннарында «Габделкәрим бине Балтай бине Бабашәех әл-Каргалый (Адай авылында туган) әл-Казаныйдан, ягъни ишан Мөхәммәдһади әл-Бохарый мәхдүменнән ишетелгән иде» дип язган. Мәсгудь әфәнде: «Әхмәр бине Мансурның язулары уртача булса да, зур камиллеккә ия булганлыгын белдерә торган кайбер дәлилләр бар», – ди.

Мостафа бине Әхмәр, бу җирлектә булган остазлары хозурында гыйлем алгач, Бохарага барып, рәсми дәресләр белән мәшгуль булган вә, беркадәр еллар торгач, бу мәмләкәткә кайтып, Уфа илә Бөгелмә арасында зур почта юлы өстендә булган Япрук авылына имам булган. Ул авылда 9 ел торганнан соң, мәхәллә халкы илә дуслыгы киткәнгә, Бәйрәкә авылында булган баҗасы Фәйзулла бай бине Гали күрсәтүе һәм тырышлыгы илә Бәйрәкәдә икенче мәчет хозурына күчкән һәм дәрес әйтү илә дә мәшгуль булган. Хатыны Маһруй исемле булган.

Балалары: Мөхәммәдшәриф, Мөхәммәдзариф. Мөхәммәдзариф Бәйрәкәдә гомер кичереп, 1283/1866 елда рамазан/февраль аенда вафат булган. Сәлахеддин бине Габделвахид: «Мостафа хәзрәт галим, дәрәҗәле, тәкъва адәм иде», – ди, вә Мәсгудь әфәнде дә: «Гыйлем вә мәгърифәт өлкәсендә урта дәрәҗәдә бер зат булган дип уйланыла», – дип белдерәләр.

**188. Фәез бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Кенәри**

Казан өязендә Кышкар авылында имам вә мөдәррис булып, 1252/1836 ел, 4 сәфәрдә/21 майда вафат булган. Бохара вә Кабул тарафларына сәяхәт итеп, гыйлем алган вә газиз һәм сирәк очрый торган китаплар алып кайткан.

Остазлары: Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви, Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Сәгыйдь бине Әхмәд әш-Шырданый, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Гатаулла бине Һади әл-Бохарый, Фәезхан бине Хозырхан әл-Кабули һ.б. // [326]

Шәкертләре: үзенең угылы Гатаулла, Садыйк бине Сафкол, Әүхәди бине Искәндәр әл-Казый һ.б.

Балалары: Закир, Лотфулла, Гобәйдулла. Соңгысы Сими (Семипулат) шәһәрендә Икенче Таш җамигь мәчетендә имам булып, 1319/1901 ел шәгъбанында/ноябрендә 75 яшендә вафат булды. Габдулла исемле бер угылы бу көндә шунда имам булды.

**[188а]. Әхтәм бине Әхмәр[73]**

Бөгелмә өязендә Тимеркә авылында дөньяга килеп, Сарлы авылында имам булып, мәдрәсәләр төзетеп, күп шәкерт туплаган. 1252/1836 ел, 6 сәфәрдә/ 23 майда 73 яшендә вафат булган.

Шәкертләре: Хәбибрахман бине Мәхмүд әл-Әлмәти, Мөхәммәдкәрим бине Исхак әл-Мечтәйи һ.б. Әдип, оста сүзле, мәзәкчән бер кеше иде, диләр. Кайбер көлкеләре бүгенгә кадәр халык хәтерендә. // [327]

RUHIAT

**189. Йосыф бине Иманкол**

Алабуга өязендә Илмәт авылында имам булып, 1252/1836 ел, 25 // [328] ноябрьдә 77 яшендә вафат булган. Асылы Чистай янындагы Киекле авылыннан. Бу мәмләкәттә укыгач, Бохарага барып гыйлем эстәгән вә Кабул шәһәренә сәфәр итеп, Фәезхан бине Хозырхан хезмәтенә кереп, ишанлыкка рөхсәт алган. Галим, гакыллы, мөхтәрәм бер зат иде, диләр. Вәлид ишан бине Мөхәммәделәмин кордашларыннан булып, аның илә күрешүе һәм махсус аның янына йөреп, файдалар алуын сөйлиләр. Үз каләме язылып тәмам булган бер «Шәрхе Әмалый» нөсхәсе ахырында мондый язма күрелде: «1197/1783 елның рабигыль-әүвәл/февраль аенда Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабауый мәдрәсәсендә Йосыф Садыйк бине мулла Иманколый әл-Киекли әл-Болгарый кулы белән күчереп тәмамланды». Язуы матур һәм дөрес. Мөхәммәдгата исемле бер угылы Илмәт авылында мөәззин булып, 1314/1897 елда 97 яшендә исән-сау иде.

[73] Бу зат №108 белән югарыда язылган иде. Вафат елы мәгълүм булмагач, ошбу урында вафат елын күрсәтеп, тагын язу зарур күрелде.

### 190. Мөхәммәд бине Хәмид бине Мортаза

Казанда имам булып, 1252/1836 елда мөхәррәм ахырында/6 майда вафат булган. Бохарада хәлифә Ниязколый белән күрешеп кайткан иде. Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Гәрчә гыйлем вә диянәт илә мәшһүр булса да, байларга дустанә булмаганлыктан вә каты һәм ачы сүзлегеннән игътибары булмады. Диния Нәзарәтенә имтихан тоту өчен баргач, мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен кайбер сүзләр сорагач: «Миннән мондый юк-бар нәрсәләр сорап гомер уздырма, минем монда булуымнан файдаланып, үзеңә кирәкләрне ишетеп, файда алырга тырыш!» – дип, имамлык вазыйфасын бирдермәскә ниятләсә дә, кайберәүләрнең шәфәгатьләре белән имтиханы кабул ителгән», – ди. // [329]

### 191. Габбас бине Габдеррәфигъ бине Юныс бине Муса бине Кучкар

Хвалынь өязендә Муса авылында имам вә мөдәррис булып, 1252/1837 ел, зөлхиҗҗә/март аенда 49 яшендә вакытында вафат булган.

Остазлары: үз авылында Сөләйман исемле бер зат, Казан вилайәте Өлге авылында Шәмседдин исемле бер зат, Оренбург Каргалысында Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

Шәкертләре: Габденнасыйр бине Габдессәлам әз-Зимничәви, Хәбибулла бине Хансөяр әз-Зимничәви, Хәбибулла бине Исмәгыйль әл-Әҗеви, Гыйсмәтулла бине Сәйфулла әл-Манчалый һ.б.

Балалары: Фәхреддин, Фәхриҗамал, Мөхәммәдҗан, Мөхибҗамал, Хөсниҗамал. Бу көндә Мөхәммәдҗан исемле угылы үз җирендә имам. Оренбург өязендә Рәдүт авылында булган Шаһиәхмәд бине Йосыф әт-Тәүкилидән ишанлыкка рөхсәт алган иде, диләр. Сарыф һәм нәхү гыйлемнәрендә зур осталык кәсеп итеп шөһрәт казанган. Үзеннән соң булган янгыннарда барлык китаплары янып, һичбер әсәре калмаган.

### 192. Шаһиәхмәд бине Рәфыйк бине Габделмөэмин бине Хөсәен әс-Симәки

Төп чыгышы Вятка губернасы Салавыч авылыннан. Атасы Рәфыйк бине Габделмөэмин Минзәлә өязенә күчеп килгән. Шаһиәхмәд хәзрәт әүвәлдә Такта Алачык, аннан соң Симәк авылларында имам вә мөдәррис булып, 1253/1837 ел, мөхәррәм/8 апрель, чәршәмбе көн, 50 яшендә вафат булган. Ялгыз Нуреддин // [330] исемле бер угылы калган. Кабере Симәктә.

Остазлары: Вәлид бине Габдеррәшид әл-Мөслими, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый.

Шәкертләре: Габделфәттах бине Габделваһаб әл-Мөслими, Габделгалим бине Йәһүдә әл-Бикбауый, Мөхәммәдкәрим бине Исхак әл-Мечтәйи, Сәгъдеддин бине Габделҗәмил әл-Митрәйи, Габделгазиз бине Хәбибулла әл-Урманайи, Габделгалим бине Таһир әл-Миякәви, Гайнелкамал бине Габделвахид әл-Карани, Насреддин бине Габделхәким әл-Борайи, Габдулла бине Габделгафур әл-Чакмакый, Фазлулла бине Фәйзулла әт-Тактауый, Галәveддин бине Мөхсин әл-Каеный, Әхмәд бине Габделкадыйр әт-Тактауый, Ягъкуб бине Госман әл-Әмирхани һ.б.

Бохарага барып, күренекле затлардан гыйлем алган вә, бу мәмләкәткә кайткач, Габдеррәшид бине Атнакол бине Тимер бине Кунгыр бине Мөти бине Янурыс исемле һимматле сәүдәгәрнең тырышлыгы белән Минзәлә өязендә Такта Алачык авылына имам вә мөдәррис булган. Хозурына төркем-төркем шәкертләр килүен күргәч, моның сәбәбе мәдрәсәсе бай тәрбиясендә булып вә мөселман авылларының үзәге булганга дип уйлап, «монда кем булса да дәрес әйтергә мөмкин, хәлбуки минем морадым надан халык арасында дин вә шәригать тарату иде, монда торып хезмәт итмәк минем хезмәтемнән хисапланмас. Шуның өчен миңа башка бер гаять наданлыкта калган вә фәкыйрь мөселманнарны күрсәтегез, мин исә алар арасына барачакмын» дигәч, беренче дәрәҗәдә зәгыйфь булган Симәк авылы күрсәтелгән. Шуңа күрә әлеге авылга барып, иң әүвәл иман вә ислам динен өйрәтә башлаган һәм дәресен дәвам иткән. Шул заманның гыйлемгә сусаган егетләре, аны Симәктән дә эзләп табып, янына тупланган һәм гадәттән тыш бер гайрәт вә куәт белән гыйлем өйрәнгәннәр. Халыкны хак юлга күндерүдәге тырышлыгы, Аллаһы Тәгалә бәндәләренә булган шәфкать вә гүзәл нәсыйхәте, гыйлем тарату юлында булган изге нияте, мәйданга куйган хезмәте нәтиҗәсендә Симәк авылы, әүвәлге мескенлегеннән чыгып, бер [331] «гыйлем йорты» исеменә лаек урынга әверелгән. Уфа, Самара, Вятка губерналарында булган галим вә шәехләрнең гыйлем ала башлаулары ошбу затка бәйле.

Заманында гыйлем вә дәрес әйтү куәте илә шөһрәт чыгарган бөек остазлардан Хәбибулла ишан ибне әл-Хөсәен һәм моның карендәше Фәтхулла ахун, Габдеррәхим бине Госман әл-Утыз Имәни, Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәңгәри, Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри һәм аның карендәше Фәез әл-Кышкарый һ.б. бу мәмләкәттә кыска төннәрдә ястү намазы фарыз түгеллеген үзләренә мәсләк тотып, һичкемнән хәвефләнми белдерүләрен күрү белән Шаһиәхмәд хәзрәт боларга дошман сыйфаты илә түгел, бәлки инсафлы бер дус галим буларак каршы чыккан вә «Гомадәтет-тәдкыйкать вә зөбдәтет-тәхкыйкать» исемле китабын язган. Ш.Мәрҗанинең «Назурател-хак» китабында бу әсәрдән кайбер нәрсәләр файдаланылган. Үз каләме илә язылган нөсхәсе угылы Нуреддин ахун кулында икән, диләр. // [332]

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Күп фәннәрне өйрәнеп, гарәп теле гыйлемнәрендә белеме камил иде, зиһене үткен булу белән әтрафларында булган галимнәрнең мәшһүрләреннән иде. Яхшы исеме һәм макталуы һаман телләрдә йөри. Гүзәл әсәрләре бар», – дигән.

### 193. Рауил бине Габделвахид бине Сәлим бине Ишмөхәммәд әл-Караный

Минзәлә өязендә Байбулат авылында вә аннан соң Бәләбәй өязендә Бикмәт авылында имамлык итеп, 46 яшендә вакытында 1252/1836 елда вафат булган.

Остазы Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки булган. Бу көндә Сәлахеддин исемле бер угылы бар, диләр. Зирәк вә хәтере куәтле булганлыктан, 500 дән артык хәдис шәрифне яттан белгән, дип сөйлиләр. Гүзәл аваз илә Коръән укыр, укуы да хуш вә дөрес булган. Төрки телдә берникадәр бәетләр (шигырьләр) вә касыйдәләр сөйләгәнлеге, әгәр дә гомере озын булса, гыйлем мәйданында булып, мәшһүр затлардан булган Гайнелкамал бине Габделвахидның бертуганы вә Низамеддин бине Сираҗеддин әл-Илһаминың ике туганы. Кабере Бикмәт авылында булса кирәк. // [333]

**194. Габделлəтыйф бине Чураш бине Чүəкəй бине Күгеш бине Күчмəн**

Ерак бабасы Чүəкəй Эстəрлетамак өязендə Муса авылыннан. Атасы Чураш бине Чүəкəй, Кариледə Габдессəлам бине Хəсəн хозурында гыйлем алган. Бер «Каһестани» китабын күчереп язып, ахырында «Кариле авылында мулла Габдессəлам бине Хəсəн мəдрəсəсендə 1178/1764 елда» дигəн сүзлəрне теркəгəн. Аннан Богыруслан өязендə Колшəриф авылында имам булып, вафат иткəн. Габделлəтыйф үзе Мөэмин авылында имам булган. 72 яшенə җитеп, 1253/1837 елда вафат булган. Атасы Чураш Кариле авылында укыган вакытта алган хатыныннан шул Кариле авылында 1181/1767 елда дөньяга килгəн.

Хатыны – Шəмсекамəр бинте Корбангали бине Мөэмин. Шəмсекамəрнең анасы Хəмидə Сəлим кызы булып, Хəмидəнең анасы Зөбəйдə бинте Габдеррахман бине Туймөхəммəд əт-Тайсуганый. Габделлəтыйфның угылы Мөхəммəдсəлим исемендə иде.

Остазлары: Габид бине Габделгазиз əл-Кенəри, Сəфəр бине Исмəгыйль əт-Талкышый, Габдеррəшид бине Габделкəрим əс-Сəгыйди, Нигъмəтулла бине Рəхмəтулла əн-Наласауый һ.б. Күчереп язып тəмам иткəн «Гакаид шəрхе» китабы ахырында болай дип язып куйган: «Габделлəтыйф бине Чураш кулы белəн 1794 елның рамазан аенда». Ошбу китапның бер тарафына болай язган: «Габделлəтыйф бине Чураш бине Чүəкəй бине Күгеш бине Күчмəн ... бине Шыгали бине Шыгаман əт-Тимъйани, Бөгелчəн җиренең». Тагын «Кара Кəмал» китабы читендə болай дип язган: «Мин, Габделлəтыйф Чураш угылы, гыйлем эстəү нияте илə Кинəле буе Колшəриф авылыннан 1789 ел, мартның 2 нче көнендə чыктым. Габдеррəшид агайга утырып, Урыс Суы авылына бардым. Аннан [334] җəяүлəп барып, Бөгелмə шəһəреннəн ике елга паспорт алдым. Янсыбы авылының Нəзир агай йөклəре илə киттем. Бу сəфəрдə Кариледə Габид хəзрəтлəрендə гыйлем алдык, ике ел тулып өченчегə чыккач, Габделгазый агай барып алды. Ул вакытта Кариледəн Саснага Сəфəр хəзрəт мəдрəсəсенə күчкəн идек. Аннан соң өйдə бер җəй тордык. Кыш көне җиткəч, Тимершəех авылының Хəсəн агай илə янə Карилегə кайтам. Анда барып, бер ел тордым. Икенче ел тулганчы, кыш башында Карilенең Галикəй агайны яллап, Ибраһим мулла илə бергə кайттым. Ул кыш һəм җəй дə өйдə торып, көз көне Таҗеддин агайны яллап, Каргалының хаҗи Габдеррəшид хəзрəт мəдрəсəсенə барып, ул кышны анда белем алдык. Аннан яз көне өйгə кайттык. Бу вакыт тарих 1795 ел, 2 июнь иде. Җəйне өйдə тордым. Кыш көне Габделгазый агай Урыс Суына илтте. Аннан Бəйрəкəнең Габдекəй дигəн кешене яллап, янə Карилегə барып, Габид хəзрəттəн бер ел гыйлем алдык. Икенче ел җəендə Арбашка күчтек вə җəйне анда тордык. Кышны Наласага, Нигъмəтулла хəзрəт хозурына барып дəрес алдык. Яз көне җиткəч, оренбурчылар илə Хəсəншəех авылының Хəлил исемле берəүне яллап, өйгə кайттык. Бу вакыт тарих 1797 иде».

Габделлəтыйф хəзрəт вəгазь вə нəсыйхəт сөйлəргə оста, үзе тəкъва вə суфый, холкы гүзəл, сөннəт илə гамəл итүчəн бер зат иде, дилəр.

### 195. Шәмседдин бине Миңле бине Габдулла әл-Җәбәли

Асылы Тау ягында Балтай исемле авылдан. Бохарада «Эрек»тә яшәде вә 1253/1837 елда хаж сәфәренә китеп вафат булган. // [335]

Шәкертләре: Габделвахид бине Колый әл-Буавый, Фәхреддин бине Мостафа ән-Норлатый һ.б.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Тәкъва вә диндар кеше булса да, гыйлеме ныклы түгел иде. Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйга каршы бер китап язса да, гаять тә зәгыйфь вә кәгазьгә язарлык булмаган нәрсәләр белдерде», – дигән. Остазларыннан берсенә Әбеннасыйр әл-Курсавый хакында язган бер хатын күргәнебез булды.

### 196. Рәхмәтулла бине Габдүш бине Ишмән

Минзәлә өязендә Такта Алачык авылында шәехлек итеп, 1253/1838 елда 18 рабигыль-әүвәлдә/май аенда вафат булган. Кабере мәгълүм һәм вафат тарихы ташында язылган. Фәезхан әл-Кабулиның мәшһүр дәвамчыларыннан булып, мөрид тәрбияләү белән шөгыльләнгән.

### 197. Яхъя бине Сәфәр бине Арслан

Казан өязендә Шекә авылында имамлык вә шәехлек итеп, 1253/1838 елның зөлкагдәдә/февралендә 80 яшендә вафат булган. Асылы Бирәзә авылыннан. Яхъя ишан исеме белән мәшһүр булган зат шушы. Мөридләренең күбесе мишәр халкы булыр иде, диләр. Инсар өязендә Иса авылында ахун вә мөхтәсиб Исхак бине Габдеррәшид исемле кешенең 1829 ел, 27 майда язган бер хатын күргән идек. Эчтәлеге мондый: «Безем өязебездә Ендовище авылында // [336] ахун Әхмәд бине Исмәгыйль Аликов Яхъя ишанның шәкерте. Безнең өязебездә мөселман авыллары барлыгы 20 авыл булып, һәммәсе казанлы Яхъя ишан мөридләре. Әхмәд ахун ни әйтсә, барлык өяз халкы шуны әйтә».

Бу шәхес турында фазыйль Мәрҗани: «Гади халык арасында җен йомшарту илә мәшһүр булып, бу көнгә кадәр халык, куәтле җил яки тавыш булганда, «Шекә пәриләре» дип сөйли. Кайбер чордашлары бу эшләрне буш нәрсәләр диярләр, кайберләре гади халык мәхәббәтен җәлеп итәр өчен корылган хәйлә вә тозак иде дип уйларлар; Муса бине Габдеррәшид әт-Түнтәри үзенә ихласлы мөрид булганлыктан, җен йомшартуына ышаныр иде. Намазларны тугрылык белән кыйлуыннан бик озын укылган намазларны «Яхъя ишан намазы» диләр. Аллаһка өндәү хакында бер тезмә әсәре һәм «Касыйдәи бөрдә»гә бер тәхмисе (бишәр юллы шигъри әсәр) дә бар», – дигән.

### 198. Таҗеддин бине Ялчыгол бине Мәмәткол бине Янтимер бине Җәянчура бине Котлыгбулат

1182/1768 елда дөньяга килеп, Мәлем авылында имамлык иткән. Минзәлә өязендә Имәнлебаш авылына кунакка баргач, 1254/1838 ел, 14 рабигыль-ахир/ 26 июньдә 71 яшендә вафат булган.

Остазы: Габденнасыйр бине Торымтай һ.б.

Бу җирлектә укыганнан соң, Дагыстан вилайәтендә сәяхәт иткән вә кайбер шәхесләр хозурында да гыйлем алган. Вафат булганда Бәһаведдин, Җәлаледдин исемле угыллары калган. Үзенең күчереп язып, тәмам иткән китаплары һәм ахырында язып куйганнары болар:

1) «Һидайәтел-хикмәт». Ахырында «бу фәннән Дагыстан вилайәтендә Әл-Җаксай шәһәрендә Җомгакилде әфәнде мәдрәсәсендә дәрес алдым. Һәм бу нөсхә 1243/1828 елда Таҗеддин бине Яхшыколый әл-Болгарый әл-Иштәки кулы белән рамазан аенда күчерелде» // [337] дип язылган.

2) «Каһестани». Ахырында «Таҗеддин бине мулла Яхшыколый әл-Болгарый әл-Иштәки кулы белән 1247/1832 елда Минзәлә өязенең Мәлем авылында язылды» диелгән.

«Рисаләи Газизә» китабының башында, өченче битендә, ошбу сүзләре бар: «Сөбател-гаҗизин» китабын шәрехләүгә ниятләдем, һиҗри 1211/1797 ел, Елкы елында тәмам иттем, вә бу шәрехкә «Рисаләи Газизә» дип исем бирдем». Моннан башка Һәфтияк шәрифкә тәфсир дә язган. Фикеребезчә, әсәрләре башлангыч дәверендә язылган һәм дә үз тарафыннан төзәтелмичә калып, караламалардан яки ташландык кәгазьләрдән туплап бастырылган. Бу зат хакында хаҗи Мөхәммәдсәлим Ишмөхәммәд угылы Өмидбай: // [338] «Башкортлардан Әй дәрьясында ватан тоткан Таҗеддин хәзрәт Ялчыгол угылы атасы Ялчыгол илә хаҗ шәрифкә ниятләп сәфәр иттеләр. Хаҗитарханнан кичеп, Дагыстанга вә аннан Диярбәкергә барганнар. Анда Таҗеддин хәзрәтне уку өчен куеп, атасы Хиҗазга юлланган. Таҗеддин ошбу шәһәрдә 14 ел торганнан соң, Ялчыгол да хаждан килгән, һәм икесе бергә Истанбулга килеп 2 ел торганнар. Аннан кәрван илә Мәскәүгә килеп, 6 айга калганнар. Аннан Мәкәрҗәгә килеп 3 атна вә Казанга килеп 2 ай торганнар. Аннан 40 сум илә ат яллап, Тройски шәһәренә сәфәр иткәннәр. Атасы Ялчыгол, әҗәл нәүбәте ирешеп, Сөн авылында вафат булган. Бу вакытта яше 65 булып, 1200/1786 ел булган», – ди. Фазыйль Мәрҗани: «Таҗеддин хәзрәт гаять язуга мөкиббән вә сәяхәтче һәм җәяү йөрүче бер зат иде. «Кяфия» касыйдәсенә, «Тәгаллемес-саләт», «Шөрутес-саләт» китапларына шәрехләр язды. Язуы яхшы вә камил һәм гүзәл рәвештә. «Кяфия», «Фәваиде зыяийә», «Гыйсам җөмләсе»н бер җирдә туплап, бер китап язган. «Кяфия»не кызыл кара илә, «Фәваиде зыяийә» өстенә кызыл кара илә сызык тарткан, «Гыйсам»ны шул хәленчә язган. Атасы Ялчыгол Кече Сөн авылының тавында җирләнгән», – дигән.

RUHIAT

**199. Вәис бине Хуҗаколый бине Йәмәк**

Пермь губернасында Саз авылында имам, мөхтәсиб булып гомер уздырган вә 1254/1838 елда вафат булган.

Остазлары: Вәлид бине Габдеррәхим әл-Кайпаный һ.б.

Низамеддин исемле угылы мәшһүр затлардан.

Асыллары Тау ягында бер авылдан булып, Пугачев вакыйгасыннан соң Пермь тарафына күчкәннәр. Хуҗаколый бине Йәмәк тә шул ук Саз авылында имам булган. // [340]

RUHIAT

## ҖИДЕНЧЕ КИСӘК

برنچی جلد

بدنچی جزء

# آثار

مملکتمزده اولان اسلام عالملرینك ومشهور کیمسه‌لرینك ترجمه وطبقه‌لری، تاریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش کتابدر.

RUHIAT

بدنچی جزء

صاحبی

رضاءالدین بن فخرالدین

« اوفا »

لیس بانسانٍ ولا عاقلٍ من لایعی التاریخَ فی صدره
ومن دری اخبار من قبله اضاف اعماراً الی عمره

Дозволено цензурою С.-Петербургъ 10 Августа 1904 г.
Оренбургъ, типографія М.-Ф. Г. Каримова, 1904 г.

## 200. Габдессәлам бине Габдеррәхим бине Габдеррахман бине Мөхәммәд

Русия дәүләтендә Идарәи шәргыяи Оренбургның [Диния Нәзарәтендә] икенче мөфтие. 1255/1840 ел, 7 зөлхиҗҗәдә/30 гыйнварда вафат булып, 10 зөлхиҗҗә/2 февраль көнне җирләнгән. Бу вакытта яше милади еллар хисабы белән 67, һиҗри еллар буенча якынча 70 булган.

Җеназасында, ошбу көннәрдә Уфа шәһәрендә зур базарларда булганча, җәмәгать гаять күп булган вә җеназа намазын Балыклы Күл авылында мәшһүр мөдәррис вә ахун Хөснеддин бине Шәмседдин бине Җәгъфәр әл-Ыжданый укыган. Фәкать вафат вакыты Уфа шәһәрендәге мөселман мәхәлләсенең махсус метрикә дәфтәренә язылмаган кебек, Балыклы Күл дәфтәренә дә язылмый калган. Җеназасын Хөснеддин ахун укуы, ул вакытта Уфа шәһәрендә рәсми имам булган затның өйдә булмавы сәбәпле, мөфтинең үз васыяте буенча яки шул көндә Уфа шәһәрендә беренче дәрәҗәдә булган мирзаларның мәслихәтләре белән булган.

Диния Нәзарәтенең 100 еллык бәйрәме-юбилее уңае белән 1891 елда русча нәшер ителгән җыентыкның 42 нче битендә мөфтинең вафаты 1839 елда дип ялгыш күрсәтелгән. Чөнки берникадәр иске китаплар читендә язылган сүзләр һәммәсе без язган рәвештә. Моннан башка Нәзарәтнең журналлары әлеге сүзнең ялгыш икәнлеген // [341] исбат итәләр.

### *Кабере*

Мөфти хәзрәтләренең кабере каберлекнең төнге кояш баеш тарафында, иң читтә. Элек таштан ихаталап алынганлыгының калдыклары бар. Фәкать кабер ташы тоз сыман уалучан булганлыктан, тиз вакыт эчендә бозылган булса кирәк. Бу көндә таш ихата эчендә, гади рәвештә агачтан ясалган вә яшел төскә буялган рәшәткәле. Хатыны Мәрфуга Габдеррахман кызы да янында. Һәр икесенең баш очларында таш булса да, эшлексез таш булганлыктан, ярылып, бозылып беткәннәр. Язу сакланырлык булмаганлыктан, язулары да булмаган кебек. Мин исә җәй көннәре, каберлеккә барганда, һәрчак бу кабер хозурына барып, сәлам бирәм, «догаи истигъфар» уку гадәтендәмен. // [342] Кызганыч ки, өстендә исеме вә вафат тарихы язылган таш юк һәм бу хакта тырышучы да күренми. Шуңа күрә мөфти хәзрәтләренең кабере беркадәр еллардан соң тәмам онытылып бетәргә мөмкин. // [343]

### *Мирасы, калган малы*

Вафат булган көнендә барлык малы, хисапланып, 4849 мең сум 34 тиен булган. Балигъ булган варислары да 1100 сум бурыч белән икърар иткәннәр. Оренбург губерна идарәсе кушуына күрә, ошбу малны бүлү өчен шул вакыт Нәзарәт әгъзаларыннан булган Габделҗәббар Рәхманколый угылы илә Бәләбәй өязендә Кыргыз Миякә авылында ахун Габделгалим Таһир угылына Нәзарәт указ биргән. Әхмәди исемле угылы бу вакыт Бохарада булганга, аның урынына тәрҗемәче Салих мирза бине Хан мирза Мәмлиевне урынбасар итеп билгеләгәннәр. Фәкать ошбу мал-мөлкәт дәфтәрендә мөфти хәзрәтләренең китаплары хисабы һәм исемнәре, шулай ук кайсы китап кайсы варис өлешенә туры килүе мәгълүм түгел.

RUHIAT

### *Асылы вә туу вакыты*

Мөфти хәзрәтләре 1188/1774 елда ата вә бабасының асыл ватаннары – Бөгелмә өязендә Габдрахман исемле авылда дөньяга килгән. Әлеге авыл исә Зәй елгасының сул тарафында вә почта юлы өстендә, Әлмәт илә Карабаш мәнзәлләре-стансалары арасында. Үзе типтәрләрдән булып, Габдрахман авылы да моның ерак бабасы исеме белән аталган.

### *Җитлегү чоры*

Бөгелмә өязендә беркадәр урыннарда гыйлем алып, аннан соң Казан шәһәренә барып, Ибраһим әфәнде Хуҗаш хозурында укыды. Ибраһим әфәнде исә Габдрахман авылы янында булган Шәрләмә авылыннан булганлыктан, ихтимал, нәсел карендәшлекләре яки башка бер мөнәсәбәтләре булгандыр. Казан шәһәрендә күпмедер вакыт торгач, ни сәбәптәндер Сәгыйдь бистәсенә (Каргалыга) күчкән вә анда Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни хозурында гыйлем алган.

Бохара, Хива, Ташкент вилайәтләреннән килеп-китеп йөргән илчеләргә // [344] һәм, гомумән, Азия мөселманнарына Русия дәүләте тарафыннан Оренбург шәһәрендә төзелгән Беренче җамигъ мәчетенә имам хаҗәт булганда ошбу зат имам вә хатыйб, аннары ахун да булган. Оренбургка килеп үз эшен күркәм башкарудан тыш, сөйләргә оста, дустанә булганлыктан, мөселманнарның, аеруча байларның күңелләрен җәлеп иткән.

### *Рәсми тәрҗемәи хәле*

Формуляр кәгазенә күрә, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим 1826 елда, 53 яшендә вә угыллары Габдеррәүф 20 яшендә, Әхмәди 11 яшендә, Гыйнәятулла 1 яшендә, барчасы үзе илә бергә булганнар. 1799 елда, 17 октябрьдә Оренбург шәһәрендә Таш мәчеткә имам вә 1805 елда, 14 августта ахун һәм мөдәррис булган. 1806 ел, 16 августта Русия дәүләте өчен кылган хезмәтләренә бүләк буларак, елына 150 сум вазыйфа билгеләнгән. 1814 елда алтын медаль бүләк ителеп, әүвәлгесенә янәдән 80 сум арттырылып, еллык вазыйфасы 230 сум булган. 1817 елда казнага җан бәрабәреннән биреләчәк һәртөрле түләүләрдән азат ителеп, сентябрь аеннан әүвәлге вазыйфасына 70 сум өстәлеп, еллыгы 300 сум булган. Оренбургта генерал-губернатор Эссен тарафыннан булган үтенеченә күрә, 1820 елда 100 сум бүләк итеп бирелгән. Кыргыз Урдасының эшләрен тикшерү өчен оештырылган җәмгыятькә 1823 ел, 14 октябрендә әгъза буларак, Ширгазый хан бине Айчуак бине Нургали хан бине Әбелхәер хан хозурында булган. Хан янында булган хезмәтләре мәгъкуль күрелеп, дәүләт // [345] тарафыннан 1824 ел, 28 апрельдә 500 сумлык алтын сәгать бүләк ителгән. Император Александр Беренче указы илә 1825 ел, 30 сентябрьдә Диния Нәзарәтенә мөфти итеп билгеләнгән. Үзенә йорт сатып алыр өчен 1826 ел, 7 майда казнадан 4 мең сум акча бүләк ителгән. Аннан соң алган медальләре һәм акчалары вә башка вакыйгалары да булса кирәк. Фәкать без соңгы формулярын күрә алмадык.

### *Хатыннары*

Бер хатыны – Зәй елгасында вә Габдрахман авылына ике чакрым ераклыкта булган Тайсуган авылында мәшһүр галимнәрдән Габдеррахман бине Туймөхәммәд кызы Мәрфуга. Бу хатын исә, Уфага килүләреннән соң, кайсы елдадыр, мөфти хәзрәтләренең үзеннән алдарак вафат булган. Мөфти хәзрәт вафат булганда хатыны Фәрхибану Рәхмәтулла кызы булган.

RUHIAT

## *Балалары*

Мөфти хәзрәте вафат булган чагында исән-сау булган балалары: Габдеррәүф, Әхмәди, Гыйнәятулла, Бибибәдәрсафа, Бибимаһиҗиһан, Бибисәрвиҗиһан, Бибифәхриҗиһан. Болардан башка Әнүәрхан исемле кызы булып, Бохарадан килеп йөргән кәрван башы хаҗи Нәзарбай бине Ишмөхәммәд исемле затка бирелгәнлеген сөйләсәләр дә, Алла белә, бәлки, үзеннән элек вафат булгандыр.

Бибисәрвиҗиһан Минзәлә өязе Мечтәй авылында башкортлар кантоны булган Шәйхелислам бине Мөхәммәдрәхим Солтанов никахында булган. Аның исә Нәфисә, Шәйхеззаман, Әмиртимер, Мәрьям исемле балалары булган. Нәфисә Уфа шәһәрендә шул вакытта Нәзарәттә тәрҗемәче булган Мирзасалих бине Ханмирза Мәмлиев угылы Рәхмәтулла мирзага никахланган вә 34 яшендә 1281/1866 елда, шәүвәлдә/4 мартта вафат иткән. Кабере мөфти Габдессәлам кабереннән төньякта вә якынча 25 аршын ераклыкта. Вафат елы илә яше вә ничә баласы калганлыгы ташында язылган булса да, ташы сынып төшкән һәм тиз көннән бу кабер онытылачак. // 326 Нәфисәдән башкалары исән-саулар.

Бибифәхриҗиһан Казанда мәшһүр сәүдәгәр Исхак бине Мостафа бине Мортаза бине Дауд бине Йосыф бине Мөхәммәд бине Апак никахында булып, Шәйхегаттар, Бәхтегәрәй, Маһиҗиһан, Хөсниҗиһан исемле балалары булган. Болардан Бәхтегәрәй 1297/1880 елда Казанда вафат.

Габдеррәүф, атасы мөфти булганда Оренбург шәһәрендә Беренче Таш җамигъта имам булып, «Әфәнде хәзрәт» исеме белән танылган һәм аннан соң ахунлык дәрәҗәсе бирелгән. Хәрби мәктәптә (кадетский корпуста) укыган мөселман шәкертләренә дин мөгаллимлеге хезмәтендә булып, еллык 500 сум вазыйфа алган. 1830 ел, 17 июньдә булган Министрлар җәмгыятенең карары вә императорның раславы белән Гыйнәятулла исемле туганы илә берлектә тарханлыкка ирешкән иде. 1259/1843 елда имам вә ахунлыгыннан азат булгач та, зур түрәләрнең яклавы сәбәпле, мөгаллимлегендә даими буларак вазыйфасын алып торган вә соңыннан, бу хезмәтеннән үз ихтыяры илә китеп, пенсия алган. 76 яшьне узып, 1298/1881 елда, 15 рабигыль-әүвәлдә/15 февральдә вафат булган. Кабере Оренбург зиратында. Укытуы вә шәкертләр тәрбияләве нинди тәртип белән булуы хакында мәгълүмат табылмады. Һәрникадәр Бохара вә Кабул тарафларына бармаса да, үз тырышлыгы аркасында фарсы телен өйрәнгән вә яхшы сөйләшкән. Хатыны әстерханлы вә Җиһангир хан казые Җабир ахун кызы булган. Аларның Хәбибулла исемле бер угыллары булган. Ул исә, шул ук җамигъ шәрифтә имам булып, беркадәр еллар торып вафат иткән. «Гүзәл гыйлеме вә дәрес камиллеге бар иде, бәлки, мөфти хәзрәтләренең исемен хәер-дога илә искә алуга да сәбәп булыр иде, фәкать гомере кыска булды» диләр. Диния Нәзарәтендә булган имтихан дәфтәренә язган гыйбарәсе будыр: «1861 ел, 11 ноябрьдә мин, Оренбургта // 347 яшәүче тархан Мирхәбибуллаҗан ибне өлкән ахун мулла Габдеррәүф Габдессәламев, Уфа каласында зур дәүләт хезмәтендәге мөфти хәзрәтләренә килеп мәгълүм булдым. Шул шәһәрнең җамигъ мәчетенә имам булу өчен. Шәһәребездә җан хисабы 200 дән артык, хатыным юк. Укыган дәресләрем – «Мөхтәсар», «Шәрхе викайә», «Фәраиз». Остазым – дамелла Габдулла әл-Мәчкәрәви».

Әхмәди Оренбург губерна идарәсе тарафыннан 1834 елның декабрь аенда Уфа шәһәрендә булган Таш мәчеткә имам вә өлкән ахун дәрәҗәсенә расланган. Озын вә төрле маҗаралар соңында, Габделвахид мөфти ибне Сөләйман вакытында, 1843 елның июнь аенда, Нәзарәт тарафыннан вазыйфасыннан азат ителгән. Аллаһы Тәгалә гафу кылсын, гадәтләре гүзәл түгел иде, диләр. Казанда Габденнасыйр ахун ибне Рәхманколый, Исхак бине Сәгыйдь хозурында, Мәчкәрәдә Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши мәдрәсәсендә гыйлем алгач, ошбу мәчеткә имам булган һәм аннан соң, Бохарага сәфәр итеп, Күгелташ мәдрәсәсендә тор-

ган. Мөфти вафат булган елны кайтып, үз хезмәтенә керешкән. Шәрәфеддин әл-Эстәрли кызы Бибигабидә исемле хатыныннан Мәһди атлы бер угылы булган. Әлеге хатыны исә атасы белән берлектә Нәзарәт хозурында дәгъвалар йөртеп, 1843 ел, 21 мартта аерылышканнар. Мәһди исә, әстерханлы Җабир ахунның Зөһрә исемле тол кызын никахлап, Эстәрлетамак шәһәрендә яшәгән вә 1295/1878 елда вафат булган.

Әхмәдинең Мәһдидән башка Хәйдәр исемле бер угылы булган, диләр. Әхмәди вазыйфасыннан азат ителгәч, Уфадан китеп, Мечтәй авылында җизнәсе хозурында торган һәм шунда вафат булган, диләр.

Габдеррәүф, Әхмәди, Сәрвиҗиһан, Фәхриҗиһаннарның аналары Мәрфуга Габдеррахман кызы булган. Башка балалары хакында мәгълүматым юк.

### *Туганнары*

Алар – Габделмөэмин, Мәхбүбҗамал, Мәхбүбҗиһан. Габделмөэмин Эстәрлебаш авылында торып дөнья куйган. Габдеррәкыйп исемле угылы Казанда Барудия мәхәлләсендә имам вә Габделхәким исемле икенче угылы Габдрахман авылында имам булганнар. Һәр икесенең балалары һәм нәселләре күп. // 348

Мәхбүбҗамал Оренбург өязендә мәшһүр кантон Габдулла бине Дәүләтшаһ бине Гаделшаһка никахланган. Аның да нәселе бар.

Мәхбүбҗиһан Оренбургта Хәмзә исемле берәүнең никахында булып вафат. Балалары һәм оныклары бар, диләр.

### *Башка әхвале*

RUHIAT

Габдессәлам мөфтинең тырышлыгы вә гайрәте нәтиҗәсендә Мөэмин бине Таһир бине Нәзир бине Туктамыш бине Хуҗасәед исемендәге казанлы бер сәүдәгәр Уфа шәһәрендә Беренче Таш мәчетне төзетте. Моннан элек бу шәһәрдә мәчет булганлыгы мәгълүм түгел. Бу мәчетнең тыштан кергәч икенче ишек өстендә ташка ошбу сүзләр язылган: «Бу мәчетне мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим тырышлыгы белән Мирза Мөэмин бай бине Таһир әл-Казаный төзетте... Мәчет 1246/1830 ел, 12 рамазан/ 7 мартта ачылды.

Гаҗәп гали мәкам улмыш, мөбарәк әйләгел, йа Рабб!
Гыйбадәт әйләп эчендә, кабул син әйләгел, йа Рабб!
Кыйлып тәүфыйкымы һәмраһ, һидайәт берлә син, йа Рабб!
Ки җәннәт эчрә дидарың мөяссәр әйләгел, йа Рабб!
(Гаҗәп олуг урын булган, мөбарәк кыл, йа Раббым!
Гыйбадәт кылып эчендә, кабул ит син, йа Раббым!
Кылып тәүфыйкымны юлдаш, һидайәт берлә син, йа Раббым!
Җәннәт эчендә күрешүне насыйп кыл син, йа Раббым!)

Мөфти булгач, Бөгелмә өязендә Ык суы буенда булган Урсай авылында кода буларак туй мәҗлесенә барган. Риваятьләргә караганда, мөфти хәзрәтнең каршысына, авыл башына, шәкертләр чыгарылган, алар, чана артына басып, хөрмәт һәм мактау шигырьләре укыганнар. Мөфти хәзрәтләре чанасыннан төшкәндә, әтрафтан җыелган галимнәр вә бөек затлар каршы алып күрешкәннәр.

Йортка кергәч, әүвәлдән хәзерләнгән мәҗлестәге ике тарафның үтенүләре буенча, мөфти хәзрәт никах хотбәсе укыган. Ни сәбәптәндер хотбәне күңелдән түгел, бәлки дәфтәрдән карап укыган һәм үз кулы белән метрикә дәфтәренә ошбу рәвештә теркәп куйган: «Бөгелмә өязе Урсай авылында башкортлардан 12 нче кантон башлыгы Шаһингәрәй Күрмәкәй угылы господин Нугайбәкевнең үз кызы Газизә Мәфтуха туташ гыйззәтле майор кенәз Әсфәндияр Мостафа улы

господин Максудовка никахландырылды. 1835 ел, 11 февральдә». (Бу урында үзләре төркичә язып имза салганнар, вә алардан соң ике-өч морза русча шаһитлар сыйфатында кул куйганнар.) Мәһәр 11 мең сум ошбу никах мәҗлесендә тулаем бирелеп, господин Шаһингәрәй Күрмәкәй угылы, үз кулы белән кабул итеп, кызына бирү өчен алды. Падишаһ әгъзам император фәрманы белән, никахланган мөселманнардан 30 ар тиен мәчет төзү өчен бирелергә дигән боерыкка нигезләнеп, господин Шаһингәрәй Нугайбәкев үз дәрәҗәсенә лаек 30 сум кәгазь акча бирде. Мөфти Габдессәлам мулла Габдеррәхим угылы һәр ике якның үтенечләре илә никах хотбәсен укып, ошбу дәфтәргә үз кулым белән язып, мөһерем бастым». Мөһере исә рәсми мөһер булып, сургыч белән басылган. // [350]

Монда телгә алынган Нугайбәкев илә Максудов фамилияләре бер заманнарда шөһрәтле фамилияләр иделәр. Әсфәндияр мирза исә мөфти Сәлимгәрәй мирза бине Шаһингәрәй Тәфтилев анасы булган Зөләйхабикә илә бертуган булган. Бәләбәй өязендә Килем авылында торган. Хатыны Мәфтуха Шаһингәрәй кызы, Әсфәндияр мирза вафат булгач, 30 ел тол булып торып, аннан соң Гәрди кантон Сыртланов белән никахланган вә аннан да тол калып, 1310/1893 елда вафат булды. Кабере Килем авылында. Кабер ташына яздыру өчен исемен вә елларын яздырып йөргән булсалар да, караламасы калмаган вә ни рәвешле язып биргәнлегемне һич белмим. Фикеремчә, бу хатынның нәселе юк. Безнең зур шөһрәтле мирзаларыбыз, дөнья кадәр милекләргә вә Ротшильдлар дәрәҗәсендә байлыкларга ия булган хәлдә, үзләренең ата-бабалары, кабилә вә нәселләре хакында китапчык рәвешендә бернәрсә язып бастыра алмаганнар.

Уфа шәһәрендә ул вакытта рәсми имам булмаганлыктан, җомга һәм гаетләрне һәм башка мәхәллә хезмәтләрен мөфти хәзрәт үзе башкарган вә кайбер вакытларда Нәзарәт әгъзаларына тапшырган.

Уфа шәһәренә беренче килгән вакытымда (1891 ел, 17 февраль) Габдессәлам мөфтине күреп белүчеләрдән Терегулов фамилиясеннән бары Гаделшаһ угылы Вәлиулланы күрдем. Аннан: «Габдессәлам мөфти әхваленнән хәтерегездә берәр нәрсә юкмы? Сөйләсәгез иде?!» – дип соравыма: «Җомга намазында мөнбәрдә хотбә укыганы бүгенге кеби күз уңымда. Зур бәдәнле, олы йөзле, зур сакаллы, ачык йөзле иде. Тавышы гаять гүзәл вә әсәрле булганлыктан, халык тәмам ләззәт илә тыңлап утырыр иде. Ак вә зур сакалыннан кайбер хотбәләрне укыган чагында күз яше агып, тамчылап торыр һәм кайчакларда үзен-үзе тыя алмый елар иде. Үзе елаган кебек, җәмәгать тә елар иде», – дип сөйләде. Ошбу Вәлиулланың кабере Уфа зиратында. // [351]

Уфада Беренче Таш мәчеттә мөәззин булган Хәйреддин бине Һашим мөфтине күргән булса да, язарга лаеклы хәбәрләре юк иде. Бу мөәззин дә 80 яшендә 1316/1898 ел, җөмадиел-ахирдә/октябрьдә вафат булды. Хәзерге мөфти хәзрәтләре бервакыт: «Мөәззин бабай, ничә мөфтине кабергә куйдың?» – дигәч, «Сезне куйсам, дүрт мөфти була», – дип көлдергән иде.

Бу зат хакында фазыйль Мәрҗани: «Мөхәммәджан мөфти вафат булгач, Казан халкының үтенечләренә күрә, Казан губернаторы әлеге вазыйфа өчен ахун Габдессаттар бине Сәгыйдьне яраклы табып, хәтта хөкүмәткә тәкъдим итсә дә, Габдессәлам хәзрәт, мәгърифәте вә алар илә бердәм булуы аркасында, Оренбург губернаторы соравы белән мөфти итеп билгеләнде. Сәгыйдь бине Әхмәдкә көндәшлектән казанлы Ибраһим бине Хуҗаш та Габдессәламне яклады. Габдессәлам мөфти тәкәллефле, ачык йөзле иде», – дигән.

RUHIAT

## *Йорты*

Мөфти хәзрәтләренең йорты Беренче Таш мәчетнең мәшрикъ тарафында, Воскресенский илә Бельский урамнары арасында булган. Үзеннән соң бу йорт Тәфтилевләргә сатылган вә, аркылыга, икегә бүленеп, кыйбла ягында булган өлешенә мөфти Сәлимгәрәй өй төзегән. Төньякта булган өлеше һәм иске өйләр ятимханә ителгәннәр. Ошбу ятимханәнең ике читендә булган иске өйләр Габдессәлам мөфти тарафыннан төзетелеп, мәчет янында булганында үзе яшәгән һәм көнчыгыш яктагысында Нәзарәт арендалап торган, диләр. Моннан башка мәчетнең көнбатыш ягында тагын берникадәр урыны булса да, үзенең сарай кызларыннан булган Мәрьям исемле бер хезмәтчесенә бүләк иткән. Хәзер бу урында гүзәл бер бакчалык. Мәрьям бервакыт Уфа шәһәрендә // [352] танылган бер хатын булып, Уфага килгән кантоннар һәм башка чиновниклар, имтиханга килгән шәкертләр, Нәзарәткә хезмәт белән килгән хәзрәтләр вә ахуннар, җир сатарга килгән башкортлар – һәммәсе моның өенә төшкәннәр. Моннан күп еллар элек вафат булган.

## *Хатлары*

Һәрникадәр әһәмиятле булмасалар да, шул замандагы галимнәр вә, гомумән, милләтебезнең әхлак вә гадәтләрен тасвир итүгә, гыйлем вә мәгърифәтләренең, гайрәт вә фикерләренең дәрәҗәсен бераз булса да аңлауга ярдәм итәр дип уйлаганга, мөфти хәзрәтенең китапханәбезгә тупланган хатлары монда күчерелә. Ошбу хатларның аерым бер өлеше нәкъ үзендәгечә күчерелеп, башкалары бераз төзәтмәләр белән язылды. Гыйлем вә камиллектә мөфти хәзрәтләренең ни дәрәҗәдә булганлыгын белергә теләүчеләр өчен үзендәгечә үк, үзгәрешсез бирелгән хатлары беркадәр үрнәк булыр. Мөфтинең бездә булган хатлары рәсми һәм ярым рәсми булганнарын беренче бүлек, ә хосусыйларын икенче бүлектә бирдек.

RUHIAT

### *Беренче бүлек*[74]

// [353] *Икенче хат.*

«Әй безнең диндәшебез вә газиз карендәшебез! Без, Аллаһның зәгыйфь колы, Ходай Тәгаләнең тәкъдире белән, падишаһ император әгъзам хәзрәтләренең фәрманы илә 1825 елда 30 сентябрьдә мөфтилек дәрәҗәсенә билгеләндек. Ләкин яшәвебез һәм вазыйфабыз Уфа шәһәрендә булып, фарыз булган биш вакыт намазны җәмәгать илә башкаруыбыз өчен бу шәһәрдә мәчет юклыгыннан җәмәгать намазы сәбабыннан мәхрүм булып, гыйбадәтләребез кимчелекле. Барлык укымышлы вә голәманың рәисе мөфти булган шәһәрдә мәчет юклыгы бик тә гаҗәп, гаҗәпләрнең гаҗәебе вә гарьлек. Һәм дә бу шәһәргә һәрчак вә һәрвакыт голәмаларның күп килүләре һәм йорт илә торучы сәүдәгәр һәм мещан, мирза вә солдат, ягъни гаскәриләр күп булудан гаять зарурлык вә хаҗәт күрәбез. Безнең тырышлык илә бу шәһәрдә таш вә кирпечтән бер җамигъ мәчет төзелеп, янында имам вә мөәззиннәр, имтиханга килүчеләр вә галимнәр өчен өйләр төзелеп һәм бездән хәерле ядкәр калса иде, дип телибез.

---

[74] Ризаэддин Фәхреддин хатларның I бүлегендә барлыгы 11 хат текстын урнаштырган. Алар татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә 1826–1837 елларда язылганнар. Күпчелеге мөселманнарга мөрәҗәгатьләр, фәтвалар булган бу хатларның эчтәлекләре шәригать мәсьәләләренә (никахлар, исламда хатын-кыз һ.б.) багышланган. Шулай ук мөселманнарда табибчылык, хөкүмәт канун-тәртипләренә буйсыну кирәклеге, Оренбург губернаторының чәчү һәм урып-җыю мәсьәләләренә караган фәрманына бәйле, император Беренче Николайның 1836 елда Казанда булуына кагылышлы хатлар урын алган. Арадан татар тарихы өчен әһәмиятлерәк дип табылган 2 хатны тәкъдим итү белән чикләнергә булдык. – *Төз.*

һәркайсыбыз кодрәтегезгә лаек вә вөжданыгызга муафыйк бер җамигъ мәчет белән әйтелгән биналарны төзетү өчен Аллаһы Тәгаләгә ихласлы булып, акча // [354] биргәнлегегезне моның белән бергә җибәрелгән дәфтәргә үз кулыгыз белән язсагыз, изге саваплар вә җәннәткә керәчәгегез шөбһәсез. 1827 ел, 24 сентябрь». // [375]

*Унынчы хат.*

«Оренбург губернасында һәрбер өяз калаларында булган төрмәләрдә тоткынлыкта булган мөселманнарга үгет вә нәсыйхәт итү өчен ошбу муллалар билгеләнә:

1) Оренбург шәһәрендә шаһанә мәчетендә имам вә өлкән мөхтәсиб һәм мөдәррис, мулла Габдеррәүф Габдессәлам мөфти угылы;

2) Уфа шәһәренә Уразбакты авылында ахун Габделгалләм Йосыф угылы;

3) Бәләбәй шәһәренә Тукай авылында имам вә мөдәррис Габделхаликъ Китап угылы;

4) Бөгелмә шәһәренә Габдеррахман авылында имам вә мөхтәсиб Габдеррәкыйб Габделмөэмин угылы;

5) Богырослан шәһәренә Гали авылында имам Котлыәхмәд Морад угылы;

6) Бозаулык шәһәренә Җаек авылында имам Иманкол Ходайвирде угылы;

7) Минзәлә шәһәренә Буеч авылында ахун Мөхәммәдлатыйф Йәһүдә угылы;

8) Бирски шәһәренә Әҗәк авылында ахун Әхмәдшаһ Атйытар угылы;

9) Чиләбе шәһәренә Үркәй авылында ахун Мөхәммәдвәли Ярмөхәммәд угылы;

10) Тройски шәһәренә имам вә мөхтәсиб Мөхәммәдзариф Габделҗәмил угылы;

11) Верхурал шәһәренә Козгын Әхмәр авылында имам Габделгаффар Сәедкол угылы;

12) Эстәрлетамак шәһәренә ахун Шәрәфеддин Зәйнеддин угылы;

13) Уральски шәһәренә ахун ярдәмчесе Габделхаликъ Хәлил угылы».

RUHIAT

### *Икенче бүлек*

Габдессәлам мөфтинең хосусый булган хатларыннан үз кулы белән Казан шәһәрендә мәшһүр Ибраһим әфәнде ибне Хуҗаш угылы Нурмөхәммәд мөхтәсибкә // [376] язган 146 хаты хәзерге вакытта күз алдыбызда. Боларны копия рәвешендә күчерү файдасызга китап озайтуга сәбәп булачагыннан, вә моннан башка ул хатларда булган озын гыйбарәләр, Казан байларына булган сәламнәр бу заманда телеграмма яки газета мәкаләсе рәвешендә хат язышуны гадәт иткән халыкларның күңелләренә хуш күренмәячәгеннән, югарыда әйткәнебезчә, копия рәвешендә күчерүдән тыелдык. Бәлки һәр хаттагы файдасы ихтимал булган гыйбарәләр кыскача бирелеп, хатларның язылу вакытлары да күчерелде[75]. // [377]

*Дүртенче хат.*

«Военный губернаторның чакыруы буенча Оренбургка килеп, күп шөкраналар кылдык. Үргәнечтән өч йөз дөя микъдары кәрван килеп, 13 июнь Меновныйга керде. Йөкләрен кәрвансарайга салдылар. Казакълар да яхшы ук килә башладылар. Бохарага җибәрелгән чабарлар да кайтты. Бохарадан кәрван хәзер-

[75] Бу 2 нче бүлектә исә Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан, үзе әйткәнчә, кыскартылып, барлыгы 78 хат урын алган. Хатлар 1826–1836 елларда язылганнар. Аларда сүз, нигездә, шәригать мәсьәләләре, дөнья хәлләре, Уфада мәчет төзүгә нисбәтле аерым имамнар, казыйлар турында, император Николай Беренченең Казанга килүе һ.б. турында бара. Алар арасыннан кызыклырак дип табылган дүрт хатны күчерү белән чикләнергә булдык. – *Төз.*

ләнеп чыга икән. Бохарада Әмир Хәйдәр хан вафат булгач, Әмир Хөсәен исемле угылы, хан булып 80 көн торып, вафат булган. Аннан соң Әмир Гомәр исемле туганы хан булып берничә көн торгач, Баһадирхан исемле туганы, башка шәһәрдән гаскәр җыеп килеп, Сәмәрканд һәм башка калаларны алган вә, Бохарага килеп, 50 көн буе камап торган. Шул вакыт Гомәр хан Бохараны ташлап, качып чыгып киткән. 27 нче рамазан, Кадер кичәсендә, таң алдыннан Баһадирхан шәһәргә кереп, хан булган вә, Гомәр хан тарафдарларын үтереп, башка голәма вә укымышлыларга мәрхәмәтләр күрсәткән. 1827 ел, 15 июнь. Оренбург». // [386]

*Утызынчы хат.*

«Тыйб [медицина] китабын кулыбызга алып куйдык. Исеме «Китабе канун», кәгазь хисабы [битләре] 300 дән артыграк, зур кулда [форматта] басылган[76].

«60 сум кәгазь акчадан кимгә бирми» дип язгансыз. «Канун» – шәйхе Әбүгали ибне Сина хезмәте булса кирәк. Ул булса, гарәп телендә булыр, ул китаптан күчерелгән кайбер сүзләрне күргәнебез бар. Бу якларда күп гамәлдә булган китап түгел, аңа һәвәс итеп алучы тиз чыкмас. Иясе үзе надан булса, аннан файда да ала алмас. Әгәр дә 50 сум кәгазь акчага бирсә, алып җибәрегез, акчасын тапшырырбыз. Күңелегезгә ошаса, 10–15 сум артык биреп булса да алырсыз. Тагын Истанбулда басылган сүзлек китаплары табылмасмы? ...Сорашыгыз әле? Улыбыз «Әнмүзәҗ»не чыгамы? Хаҗәт китаплары булса, язып җибәрер. 1832 ел, 12 май». // [378]

*Утыз дүртенче хат.*

«Тыйб китабының 1 һәм 2 нче томнары бергә төпләнгән булса кирәк. Чөнки бездә булган томының беренче битенең саны 278. Әгәр дә табылса, яхшы булыр иде. «Бистәдә бер табиблык итүче бар, шуннан сорармын» дип, мулла Йосыф әйткән иде. Бервакыт «басма бер тарих китабым бар» дип сөйләгән идегез. Шуны карап торыр өчен безгә җибәрсәгез, яхшы булыр иде. Граф безгә бер төрки телдәге тарих китабы җибәргән. Казанда басылган булса кирәк. «Шәҗәрәи төрк» Әбелгазый Мөхәммәд Баһадир хан бине Гарәб Мөхәммәд хан әсәре» дип язылган. 1832 ел, 14 июль». // [403]

## *Мөфти хәзрәтләренә язылган хатлар*

[Бу бүлектә Габдессәлам мөфтигә язылган 4 хат бирелгән. Алар 1827–1834 елларда язылганнар. Хатлар Кузнецк өязеннән, Мәскәүдән, Тәтеш өязеннән һәм Пермь губернасыннан. Аларда никах мәсьәләләре һәм кайбер имамнардан зарланган шикайәтләр язылган. – *Төз.* // [409]

## *Китапханәсе*

Габдессәлам мөфти китап җыярга һәвәсле булганлыгы билгеле булса да, Диния Нәзарәтендә барлыгы 10 китабы, вәкыф буларак, һаман саклана. Алар түбәндәгеләр:

1. «Тәфсире Бәйзави».

1175/1762 елда Сәгыйдь бистәсендә (Оренбург Каргалысында) Мәхмүд бине Максуд исемле зат кулы белән язылган. Язуы матур түгел, гомумән, бозык. Ялгыш, хәтта беркадәр тупас хаталары бар. 388 кәгазьдә, бер томлы. «Фәтех» сүрәсе тәмам булмыйча, бетми калган. Мөфти, 1251/1835 елда вәкыф итеп, үз кулы белән язган вә мөһерен баскан.

---

[76] Моңарчы «Канун» китабы бары Румия (Рим) шәһәрендә, дүрт томлы булып 1593 елда бер генә мәртәбә басылган. Мөфти хәзрәт кулына кергән нөсхә ошбу басма булыр.

2. «Тәфсир».

Ошбу әсәр «Йасин» сүрәсеннән башланып, «Саффат»тан 14 юл язылган. «Фәтех» сүрәсенә кергән вә ахырга кадәр барган. Исеме һәм тәфсирчесе мәгълүм булмаса да, шигый галимнәреннән беренең әсәре икәнлеге мәгълүм. Тәфсирне һәрникадәр аю, төлке хикәяләре, бозык җәгърафия вә хыялый гыйльме хәйванат (зоология) белән тутырмаса да, мәзһәб тәгассыбен (фанатизмын) күбрәк язган. Аллаһы Тәгалә игътибар бирмәсен! Бу нөсхәнең язуы бозык вә гаять ялгыш. Мөфти тарафыннан 1254/1838 елда вәкыф ителгән.

3. «Шәрхи әлмәнзумәти лилвәзни».

Чит мәмләкәттән килгән иске язу булып, гүзәл бер әсәр. Язуы гадәти, фәкать дөрес.

4. «Мөхтәсар Кәрамвәри».

Бозык язулы, әһәмиятсез бер китап. 1131/1719 елда күчереп язылган вә мөфти тарафыннан 1254/1838 елда вәкыф ителгән. Бу нөсхәнең бер тарафында «Габделҗәлил бине Ишмөхәммәд милке, исеме «Кәрамвәри», авторы Ибне Һибәтулла. Габбас бине Рәхимколый 1789 елда күчерде» дигән бер язу бар. // [410]

5. Каһестаниның «Шәрхел-мөхтәсар» китабы.

1838 елда вәкыф ителгән. Язуы ярыйсы һәм дөрес.

6. «Тәбәйинел-хакаикъ лил-имам әл-Зәйләгый».

Нурмөхәммәд мөхтәсиб бине Ибраһим әфәнде әл-Казаный тарафыннан мөфтигә бирелгән вә мөфти тарафыннан 1253/1837 елда вәкыф ителгән. Ике томда язылып, һәр икесе Хозыр бине Габдулла әс-Сәгътый әл-Малики кулы белән күчерелгән. 1 нче томы 968/1561 елда вә икенче томы 969/1562 елда тәмам булган. Язуы дөрес булса да, мәгъриби төре илә язылганлыктан, язу серләрен белмичә торып, укылышы беркадәр авыр. Бу китап Ибраһим әфәнде кулында да булган, 231 битендә моңа ишарә бар.

7. «Тәүзыйх вә тәнкыйх».

Язуы матур вә дөрес. Яшел кәгазьдә язылган. Язучының исеме вә күчерелү вакыты күрсәтелмәгән. Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни хозурында, Каргалыда язылгандыр дип уйлыйм.

8. «Әл-әнүәр».

Шафигыйлар фикъһы булган бу әсәр, 379 кәгазьдә Сәлман бине Касыйм исемле зат тарафыннан язылып, 987/1579 елда тәмам булган. Язуы матур һәм дөрес. Бу китапны исә мөфти кемнәндер 1254/1838 елда сатып алган. Аннары улы Әхмәди 1841 елда мөфти Габделвахид бине Сөләйманга 20 сум хак бәрабәренә сатып биргән. Аннан соң мөфтинең угылы ахун Шәрәфеддин бине Габделвахид бине Сөләйман тарафыннан Нәзарәткә вәкыф ителгән.

Ошбу китапларның һәрберсендә мөфти хәзрәтләренең язуы булса да, сатып алганлыгы яки вәкыф итүе турында гына. Китапның эчендә, хашияләрендә һичбер язуы күрелмәде, китапның кайбер хаталы сүзләрен төзәткәнлеге дә беленмәде. «Юкса китап җыярга хирыс булып, аларны укуга ул дәрәҗәдә хирыс булмаганмы?» дигән бернәрсә уйлап куйдым. Иске мөдәррисләр гадәтенчә, кайбер урыннарына «мөһим» дигән кебек ишарәтләр куелырга тиеш иде.

Мөфти хәзрәтнең каләме килешле, язуы дөрес, фәкать гарәп телендә гыйбарәләр илә язганнары яман сурәттә ялгыш. Белгәнебез кадәр мөфти хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлен яздык, мәгълүматыбыз исә ошбу кадәр. // [412]

RUHIAT

## СИГЕЗЕНЧЕ КИСӘК

برنچی جلد

سکزنچی جزء

# آثار

بزنمزده اولان اسلام عالملرینك ومشهور کیمسه‌لرینك ترجمه وطبقه‌لری.
تاریخ ولادت ووفاتلری، وباشقه احواللری حقنده یازلمش کتابدر.

RUHIAT

سکزنچی جزء

صاحبی
رضاء الدین بن فخرالدین
« اوفا »

والناس لاتبقى سوى * آثارهم والعين تفقد
اوما سمعتَ بمن مضى * هذا يذم وذاك يحمد

Дозволено цензурою С.-Петербургъ, 11 Октября 1904 г.
Типографія М.-Ф. Г. КАРИМОВА, Оренбургъ.

**201. Фәйзулла бине Госман**

Безнең Болгар вилайәтеннән булган хәлдә, Дагыстан вилайәтенә сәфәр иткән вә анда чәчән һәм Дагыстан халыкларына әмир сыйфатында булган шәех Мансур әфәнде белән аралашкан һәм кайбер вакыйгаларында берлектә булган. Шәех Мансур әсир булганнан соңмы[77] яки аннан элегрәкме Истанбулга китте вә аннан Мисырга, әл-Каһирәгә сәфәр кылды, Мисырда булган вакытыннан файдаланып, олуг галим Сәедмөхәммәд бине Мөхәммәд бине Мөхәммәд Әбелфәез Мортаза әл-Хөсәени әз-Зөбәйди әл-Хәнәфи (аңа Алланың рәхмәте булсын) хәзрәтләреннән гыйлем алган. Фәкать бу мәмләкәткә кайтмаган дип уйланыла.

Әгәр дә, кайтып, Сәед хәзрәтләре кеби чын бер галимнән[78] өйрәнгән заттан белем алу мөмкин булса, халкыбыз вә милләтебез дә никадәр бәхетле булыр иде.

Төркия дәүләте тарафыннан Дагыстан вә чәчән халыкларына җибәрелгән иде. Үлгән елы хәзер безгә мәгълүм булмады. Тәфсыйльле әхвале рус тарихларында бар. // [413]

Бу кеше фазыйль Мәрҗанигә мәгълүм булса, «Мөстәфадел-әхбар...»ның икенче кисәгендә, һич югы, кыскача булса да искә алыныр дигән уй белән әлеге әсәрне тикшердем. Хатыннар да хисапка кергән хәлдә әлеге китапта якынча 1200 кешенең исеме бар икән. Болар арасында «Фәез» кисәге белән тугыз исем булып, Фәйзулла бине Госман исеме алар арасында юк. Шулай ук «Вафиятел-әслаф...»та Сәед Мортаза тәрҗемәсендә дә мондый бер исем искә алынмаган. «Гаҗаибел-әсәр фит-тәраҗим вәл-әхбар» исемле китабында Габдеррахман әл-Җәбәрти[79] һәм кулыбызда булган башка беркадәр затлар ошбу Әбелфәез Зөбәйди тәрҗемәи хәлен сөйләгән урыннарда аңа кагылышлы бер нәрсә язылмаган. Шуңа күрә бу затның мәмләкәтебезнең кайсы өязенә нисбәтле, кавем вә кабиләсе ни җирдә вә кемнәр булган, туу тарихы вә вафаты безгә караңгы калды. Әгәр Сәед хәзрәтләре моның торган урынының исемен вә тарих фәнендә искә алыныргa лаек булган ишеткән сүзләрен, остаз вә шәехләренең нинди затлар икәнлеген язган булса, безгә «Ихъя шәрхе»ннән кыйммәтле бер ядкәре // [414] булыр. Фәкать безнең кавемебезнең бәхетсезлеге хәтта бер гыйлем гашыйгы вә язу машинасының да кулын хәрәкәт иттермәгән.

**202. Сәйфеддин бине Хәлил бине Дөрәс баба**

Асыллары Казан өязендәге Наласа авылыннан. Атасы Хәлил берничә авылда имамлык вә укыту хезмәтендә булып, Торналы авылында вафат булган. Сәйфеддин 1189 елның 1 мөхәррәмендә/1775 елның 21 февралендә, пәнҗешәмбе көн дөньяга килгән, вафат елы билгесез. Бу мәмләкәт галимнәреннән файда күргәннән соң, Бохара тарафына киткән, Сәмәрканд вә Нәсеф шәһәрләрендә дә берара торган. Язып тәмам иткән китапларының ахырларында үз каләме белән ошбу эчтәлекле язулары бар.

---

[77] Имам Мансур вә Мансур Гази дип танылган зат шушы. Анафа шәһәрендә сугышкан вакытта Русия гаскәре тарафыннан әсир алынып, Петербург шәһәренә җибәрелгән вә аннан Соловецкий исемле монастырьга ябылган, әлеге монастырьда 1199/1785 елда вафат булган.

[78] Әлеге зат 1145/1732 елда Һиндстанда дөньяга килгән. Гыйлем алу юлында күп сәфәр иткән вә, беркадәр хаҗ кылып, кадер-хөрмәт казанган. 1067 елның сәфәр аенда/1656 елның ноябрендә Мисырга, Каһирәгә барган һәм, анда урнашып, гыйлем тарату илә шөгыльләнгән. Остазлары вә шәкертләре кемлеген бер Аллаһы белер. 1205 елның шәгъбан аенда/1791 елның апрелендә якшәмбе көн вафат булган.

[79] Шәех Габдеррахман әл-Җәбәрти Сәед Мортаза хәзрәтләренең шәкерте булганга, тәрҗемәи хәлен гаять тәфсыйльләп язган (2 кисәк, 196–210 б.).

1) «Бу шәриф нөсхәне зәгыйфь, мескен Сәйфеддин бине Хәлил 1217/1802 елда тәмамлады».

2) «Китап 1223 елның җөмадиел-ахирендә/1808 елның июлендә җомга көн Нәсеф шәһәрендә Сәйфеддин бине Хәлил әл-Болгарый тарафыннан язып тәмам ителде».

3) «Каршы шәһәрендә 1225 елның 3 рәҗәбендә/... Сәйфеддин бине Хәлил кулы белән күчерелде».

4) «13 зөлхиҗҗәдә, 1224 елда/1810 елның 7 гыйнварында язып тәмам ителде».

Хатыннары: Фатыйма, Сәгыйдә. Фатыйманы 1223/1808 елда Сәмәркандтә вә Сәгыйдәне, бу мәмләкәткә кайтып, Ямаширмә авылында ярәшкәннән соң, 1227/1812 елда никахлаган. Бу соңгы хатыны – хаҗи Габдүш бине Габдессәлам әл-Кавалый әл-Мәмдәли кызыдыр. Беренче хатыныннан Шәмсениса Том вилайәтендә (Сибириядә) Каинский тарафында үз шәкерте Габделгазиз исемле кешегә никахланып, Мәгъсүм исемле угылы дөньяга килгән. Рабига да Тахта шәһәренә йөрүче мәшһүр сәүдәгәр Габделгазиз исемле казанлының Гобәйдулла исемле угылына никахландырылды. // [415]

Ошбу Сәйфеддин, әлеге Ямаширмә авылында озак вакытлар имамлык вә сабыйлар укыту хезмәтендә булып, хаҗ кылу максаты илә Хиҗаз тарафына сәфәр иткән. Хаҗ гамәлләрен тәмам итеп кайтып килгәндә, кораблары, Истанбул шәһәренә якын бер җирдә казага очрап диңгезгә баткач, бөтен иптәшләре илә шәһид булганнар. Рабига исемле кызы тарафыннан Уфа вә Казан шәһәрләрендә нәселе бар.

RUHIAT

### 203. Нуреддин бине Мөхәммәд бине Төхфәтулла бине Зәбир әл-Мамалавый

1256/1840 елда Бохара шәһәрендә вафат булган.

Остазлары: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши, Салих бине Надирмөхәммәд әл-Хөҗәнди, Мөхәммәд бине Гата әл-Бохарый вә гайреләр. Дөрес, галим кеше булган, фәкать яшьлегендә вафат булуы сөйләнә. Моның хакында фазыйль Мәрҗани: «Галим вә фазыйль иде, карашы дөрес вә сүзе тугры иде, хакыйкать эзләүче галимнәрнең китапларын карап файда алган иде, вафат булгач, үзенең шәехе казый Шәриф әл-Бохарый: «Бу зат башыннан аягына кадәр гыйлемнән гыйбарәт иде», – дип мактап алды», – дигән.

### 204. Нигъмәтулла бине Максуд

Бөре өязе Күккуян авылында имам булып, 86 яшендә 1840 елның 9 июнендә вафат булган. Кабере шул ук авылда. Остазы – Сәгыйдь бистәсендә Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни.

Остазы илә кайбер язышкан хатлары, якыннары илә беркадәр фикер алышулары булганы билгеле. Үз каләменнән булган кайбер хатлары бу җирдә китерелә.

*Беренче хаты.*

10 нчы кантонлы башкорт, типтәр, мишәр халыкларының // [416] агасы Нигъмәтулла бине Мөхәммәдшәриф Киеков хәзрәтләренә, балаларына саф күңелдән чакыруларыбызны җибәрәбез. Әмма шуннан соң хәзрәтләрегезгә язабыз, безгә Духовное собрание тарафыннан указ бирелде, хәзрәтләрегез карамагында булган Дәүләтбай бине Йосыф аганың хатыны Фәрхисорур бинте Әрдәшир ага илә

араларында булган аерылышу хакында ислах итәргә яки хөкем кылырга боерып. Ләкин әлеге кешенең безнең чакыруыбызга күрә килеп җавап бирүе шөбһәле күрелә. Бу вакытта халык кемдә хәйлә күп, кемдә ялган сүз күп, шул затны акыл иясе, зиһен әһеле дип гөман итәләр. // [417] Шул җәһәттән хәзрәтегезгә язабыз, ул кеше якыныгыз булганга, шул хакта чарасын күреп, безгә юлыктырсагыз иде. Ул кешенең үзенә аңлатып, соңра хәлне безгә язарсыз. Бәләбәй өязендә Чакмагыш авылында ахун Хәбибулла бине Габделваһаб тарафыннан вәкаләт, үз тарафымнан нигезлелек яздым. Күккуян авылында мәчет хозурында Нигъмәтулла бине Максуд. 17 гыйнвар, 1830 ел. // [418]

*Икенче хаты.*

[Бөре өязе Янтоз авылында типтәр Тимеркәй Биктимер угылы илә хатыны Ләйлибәдәр Габделҗәлил кызы арасындагы дәгъваларны тикшерү хакында 1832 елның 20 ноябрендә язылган.]

*Өченче хаты.*

[Бөре өязе Талпазы авылында яңа ай күрү хакында 1834 елның 16 февралендә язылган.] // [422]

### 205. Нигъмәтулла бине Хәбибулла бине Габделмән бине Акхуҗа

Чыгышлары Тау ягы мирзаларыннан булуы билгеле. Ошбу зат, Чистай өязе Кыр Бикүле авылында имам булып, 77 яшендә 1256 елның рамазан ае башында/1840 елның октябрь ахырында вафат булган. Хатыны Вятка губернасы Малмыж өязендәге Ильяс авылыннан Бәшир кызы Шәмсеҗиһан булган.

RUHIAT

Балалары: Мәсгудь, Морадулла, Шаһиморад, Җәлаледдин һәм башкалар.

Унсигез яшьләренә ирешкәннән башлап укырга ният иткән вә, бу ниятен җиренә җиткермәк өчен, асыл ватаныннан җәяүләп чыгып киткән вә Казан тарафына сәфәр иткән. Мәчкәрә, Сәрде, Мәмсә авылларында 18 ел тоташтан укып, шул заманга күрә гыйлем туплап, асыл ватаннарына кайтып килгән. Мәдрәсәдә вакытында гаять фәкыйрь булып, киштәләрдә калган икмәк кисәкләрен табып алып, йомшартып вә казаннарда калган касмакларны кырып алып ашар вә шуның белән көн кичерер булган. Кыр Бикүле авылында // [423] азмы-күпме торганнан соң, 1804 елның 6 июлендә 9391 нче номерлы указ алган. Әлеге указ Казан шәһәрендә вилайәт мәхкәмәсеннән бирелеп, эчтәлеге болай: «Казан губернский правлениясеннән Чистапул өязе татар Нигъмәтулла Хәбибулла угылына бирелде. Бу кеше хакында Оренбургский мухамеданский закон собраниясеннән хәбәр ителгәнгә күрә, имам, мөдәррис вә мөхтәсиб вазыйфасына лаек икән. Шуңа күрә Габдрахман авылына (Степное Белое озеро) әлеге урынга билгеләнә».

Язуы дөрес вә гүзәл һәм дә замандашлары тарафыннан гыйлем иясе дип танылса да, укыту белән шөгыльләнмәгән һәм мәдрәсә тотмаган. Садә вә тәкәллефсез бер шәхес булган кебек, зур бәдәнле һәм гадәттән тыш куәтле вә гайрәтле булуы да билгеле. Авылына кайтып тереклек итә башлагач, дүрт потлы капчыклар белән орлыкларын кырларга күтәреп барып, чәчеп кайта торган булган. Мәдрәсәдәге фәкыйрьлегенә капма-каршы буларак, дөньяга чыккач, бәхтияр булып бөек хәзинәләргә, муллыкка ирешкән. (Гадәттә мәдрәсәдә фәкыйрьлек илә укыган иҗтиһадлы шәкертләр, дөньяга чыккач, бәхетле, бай булалар.) Утыз-кырык баш аты, җиде-сигез йөз кадәр сарык хайваны булып, ашлыгы да дүрт-биш йөз арбадан аз булмас иде, диләр.

Балаларын дин белерлек кадәр укыткан, хәтта Габдеррәхим бине Госман әт-Тимәши шәкерте булган угылы Җәлаледдин, голәма җәмәгатьчелегеннән саналса да, мәхәллә имамы булырга ризалык күрсәтмәгән. Бу турыда: «Мин, шәригатьтә галим вә байлыгым да камил булганым хәлдә, халыктан өмет итәр идем, алардан аласым киләдер, бирсәләр, рәхәтләнеп алыр идем, инде минем балаларым, әгәр дә имам булсалар, хәтта сорап алуга кадәр батырчылык итәрләр, ихтимал, тиеш булмаган садакаларны тиеш күрсәтүдән курыкмаслар, кем белә, бәлки, «садакаларыгызны бездән, имамнардан башкага бирмәгез, чөнки алар мәхәллә имамнарының хакыдыр» дип, шәригатькә яла ягудан да тартынмаслар; боларның мондый бозык гамәлләренә сәбәп булудан куркамын, инде аларга гыйлем // [424] өйрәттердем, гыйлемнәре илә гамәл итсеннәр, адәмнәрдән көтеп тормыйча, үз кәсепләре вә кул көчләре илә ризыклансыннар, кешеләрдән алу зәгыйфь вә куәтсезләр өчен гаеп булмаса да, әгъзасы сәламәт бер мөселманга зур гаеп!» – дип, сәбәбен күрсәткән. Ләкин ни сәбәпледер кызларын мәхәллә имамнарына биргән. «Бу мәмләкәт җирләре гошер түгел, фитыр садакасы фәкыйрьләргә мәҗбүри түгел, байлыгы булган имамнарның садака алулары дөрес түгел» кебек сүзләре халык арасында таралганга, тирә-яктагы муллалар аңа нәфрәтле булган, вә бу сәбәптән алар илә аралаша алмаган.

Бервакыт, башында колакчын, аягында оек илә чабата, өстендә дә ак тула чикмән булган хәлдә, Казанда мәшһүр вә бөек ислам мәдрәсәләреннән берсенең җәмәгать сәкесенә кереп утырган икән. Шәкертләр исә, моны надан, гади кеше дип уйлап, янында төрле-төрле сүзләр сөйлиләр вә мәсхәрә итеп көләләр икән. Ул да, арада бер абруйлы дип саналган хәлфәгә мөрәҗәгать итеп: «Дәресең нинди китапта?» – дип сорагач, хәлфә дә, күкрәген киереп, борынын бераз югары күтәреп: «Хикмәт!» – дигән. Бу да аңа каршы: «Укымасаң «Хикмәт», табылмасмы дип уйладык икмәк!» – дигән вә моның файдасы вә нәтиҗәсе нәрсәдән гыйбарәт булачагын сораган. Сүз сүзне тартып, мәдрәсәнең иң оста бәхәсләшүчеләрен, ягъни иң каты кычкыручыларын җиңеп чыккан вә шул хәлдә безнең мышмым бабай мәдрәсәдән чыгып киткән икән.

**206. Таҗеддин бине Габдеррәшид бине Мортаза әл-Иштирәки**

Малмыж өязендә Сасна авылында имам вә мөдәррис булып, 74 яшенә ирешеп, 1256 елның 8 рамазанында/1841 елның 12 апрелендә, дүшәмбе көн кичендә вафат булган. Кабере Саснада билгеле. Тууы 1181 елның 26 шәгъбан/1768 елның 5 гыйнварында, дүшәмбе көн сәхәр вакытында булган. // [425]

Башта үзенең асыл ватаны булган Бөгелмә өязе Яңа Иштирәк авылында имам булып, атасы Габдеррәшид хәзрәт исән вакытта Сасна авылына күчкән. Сәфәр бине Исмәгыйль әт-Талкыши үз авылы Талкышка кайтып киткәннән соң, Сасна байларыннан Муса бине Ягъкуб һәм башкаларның тырышлыгы белән Сәфәр хәзрәт урынына килгән. Саснага иң әүвәл килеп яши башлавы 1209 елның 10 рабигыль-әүвәлендә/1794 елның 30 сентябрендә, якшәмбе көн булган.

Таҗеддин хәзрәт Саснада 29 ел торганнан соң, Яңа Иштирәк халкы моның урынына имам буларак бертуган карендәше Хафиза бинте Габдеррәшид кызы Бәдрелҗамалның ире Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдәмин әл-Бәйрәкәви исемле кешене имам итеп билгеләгәннәр. Рәсми кәгазьләрнең төп нөсхәсе мондый: «1823 ел, 31 август. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Яңа Иштирәк авылының авыл җәмәгатьләре 7 нче ревизиядә язылган ясаклы вә типтәрләр – һәммәсе 198 җан булып, барыбыз бертавыштан ошбу довереииене бирдек, элгәре безнең авылыбызда указлы мулла Таҗеддин мулла Габдеррәшид бар иде, ләкин әлеге

кеше күп еллардан бирле Уржум өязе (Малмыж түгелме? Яки ул вакыт бу җирләр Уржум өязендә исәпләнгәннәрме?) Сасна авылында җәмәгате илә йорт итеп торадыр. Без ничә ел шул мулланы көттек, ләкин һаман кайтканы юк. Шуның өчен хәзер без үз авылыбызда торучы торговый татар Мөхәммәдкәрим Мөхәммәдәмин угылын үзебезнең мәсҗидебезгә имамлык һәм мөдәррис вә мөхтәсиблек өчен сайладык. (Бу җирдә кырык бер кеше тамга салган вә өч кеше кул куйган, боларның исемнәре исә күчерелмәде.) Югарыда язылган картлар вә выборник үтенүе буенча, Бөгелмә өязендә Иштирәк Бәкер авылында имам Зәйнелгабидин мелла Әбүбәкер угылы яздым».

Яңа Иштирәк авылы Бөгелмә өязендәге мәшһүр Шушма елгасының уң ягында, бу көндә шактый зур бер авыл. Ун чакрым ераклыкта әлеге елганың түбән агымындагы Иске Иштирәк авылыннан күчеп // [426] утырулары билгеле. Иске Иштирәккә исә Казан шәһәре Русия тарафыннан басып алынган көндә Казан ягыннан күчеп вә качып килгән типтәрләр нигез салган икән.

Иштирәк Бәкер авылы исә Иске Иштирәк каршында, Шушма елгасының уң тарафында өченче бер авыл. Мәшһүр Пугачевның бер төркем гаскәре бу авылларны уравы вә биек тауларының өстендә чатырларын корып ятулары безнең сабый чакларыбызда картлар вә карчыклар тарафыннан сөйләнә, вә без дә, күктән килгән вәхи тыңлаган кебек, ләззәт вә игътибар илә тыңлый идек. Соңрак заманнарда бу өч авыл янындагы бер чишмә буенда Гали Кәрәмулла хәзрәт әфәндебезнең кабере бар икән, дигән бер сүз таралып, шактый шөһрәт тапса да, Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте белән аз вакыт эчендә онытылды, һәм мөселманнар да зур бер фетнәдән котылды.

Сөйләгәннәргә күрә, үзе Саснадан мәҗбүри рәвештә кайтырга туры килмәсен өчен, әлеге Мөхәммәдәмин угылын Таҗеддин хәзрәт авыл халкыннан үтенеп куйдырткан икән. Саснада яхшы гына мәдрәсәләр булганга вә шөһрәтле байларның үтенеченә күрә килгәнгә, шулай ук Казан шәһәренә вә каенатасы һәм остазы Ибраһим әфәндегә якын булганга, үз тормышы өчен һәр җәһәттән мәслихәт күрелгән.

RUHIAT

Җир-су вә һәммә мәшәкатьләре Иштирәк авылында булганга, һәр ел, аз дигәндә бер мәртәбә, Сасна авылыннан кайтып килергә мәҗбүр була, хәтта кайвакытларда кыш көннәре, салкын бураннарда да сәфәр иткән икән. Юлы безнең Кичүчат авылы аша үткәнгә һәм дә шәкерте булу мөнәсәбәте белән бабабыз Сәйфеддин бине Сөбханкол йортына туктала торган булган.

Остазлары: Казан өязендә Чаллы башы авылында Габделмәҗид бине Әбүбәкер, Габделхаликъ бине Әгъзам әт-Тенеки, Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казаный, Ишмөхәммәд бине Заһид әл-Көбәки әл-Уфавый һәм башкалар.

Шәкертләре: Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри, үзенең угылы Зыяэддин, // [427] Сәйфеддин бине Сөбханкол әл-Кичүчатый, Гайса бине Габделмәҗид әл-Камывый, Ягъкуб бине Габдеррафикъ әл-Мирасый, Мөхәммәдшәриф бине Мостафа әл-Кабили, Ибраһим бине Мөхәммәд әл-Бәрсуаный, Фазлулла бине Мөхәммәдәмин әл-Бәрсуаный, Габделхәким бине Габделкәрим әл-Петряксый, Мөхәммәдзакир бине Габделваһаб әс-Саснавый һәм башкалар.

Хатыны Казан шәһәрендә Ибраһим әфәнде кызы Мәүдүдә булып, 73 яшендә өченче рабигыль-әүвәл, шимбә көнендә ире белән бер елда вафат булган, кабере исә иренеке янында. Башка хатыны булмаган.

Балалары: Мәфтуха, Мәүсуфә, Дилшад, Мәүһубә, Зыяэддин. Таҗеддин хәзрәт бу мәмләкәт галимнәре арасында иң мәшһүрләреннән вә нәсел-нәсәпләре дә гаять таралган вә күп булганга, болар хакында беркадәр тәфсилләп язу тиеш күрелде.

Таҗеддин хәзрәтнең беренче баласы Мәфтуха 1215 елның 14 шәгъбан кичәсендә/1800 елның 19 декабрендә дөньяга килеп, 1264 елның 15 рамазанында, якшәмбе көн/1848 елның 3 августында вафат булган. Ире исә атасының шәкертләреннән Уфа янындагы Бәрсуан авылыннан Ибраһим бине Мөхәммәд әл-Бәрсуаный булган. Казаннан 135 чакрым төньякта, Нөнәгәр авылында имам буларак вафат итте.

Боларның балалары: Зәкия, Сабира, Гарифә, Зыяия, Әсгадеддин, Фатыйма. Зәкия Казаннан 100 чакрым ераклыктагы Арбаш авылында имам Һибәтулла никахында булган. Әлеге имам исә 1313/1896 елда вафат булды. Сабира Казаннан 70 чакрымда урнашкан Күлтәс авылында Нурмөхәммәд исемле бер имам никахында булган. Бу Нурмөхәммәд якынча 1305/1888 елда вафат. Гарифә, Казаннан 100 чакрымда урнашкан Кенә авылы имамы Шәрәфеддин никахында булган хәлдә, 25 яшендә 1276 елның зөлкагдәсендә вафат булган. Зыяия Кошкәтбаш имамы Габдессаттар никахында булган. Әсгадеддин, Габдессаттар вафатыннан соң, Көшкәтбашта имам булган. Түнтәрдә мәшһүр шәех Мөхәммәдгали бине Сәйфулла шәкертләреннән.

Бохара шәһәренә сәяхәт // [428] итеп кайтканда, Идел өстендә пароходта, хәтерләвемә күрә, 1318/1900 елда вафат булып, Казан каберлегендә җирләнгән. Фатыйма Казан өязендәге Носы авылында Габдулла бине Мозаффар әл-Утарый исемле бер имам никахында булган.

Таҗеддин хәзрәтнең икенче баласы Мәүсуфә 1212 елның 15 рамазанда/1798 елның 20 февралендә дөньяга килеп, 1280/1863 елда Әй буенда Кабил авылында икенче ире Мөхәммәдшәриф бине Мостафа никахында вафат булган. Элек Казаннан 100 чакрымдагы Хәсәншәех имамы Габденнасыйр бине Габдеррәхим бине Мөслим бине Әлмөхәммәд әш-Шыңкарыйга никахланган булган. Бу әүвәлге иреннән балалары: Мөхәммәдшакир, Мөхәммәдфатыйх, Фәридә. Мөхәммәдшакир Капал тарафында казакъ арасында йөргәндә, 1277/1860 елда вафат булган. Балалары вә нәсәбе шунда калган. (Мөхәммәдфатыйхның тәрҗемәи хәле бирелер.)

Фәридә, анасы белән бергә анасының икенче ире Мөхәммәдшәриф бине Мостафа өендә тәрбияләнеп балигъ булгач, шул яктагы Кыйгы авылында имам Әхмәдшаһ бине Габделгафур бине Җәгъфәргә никахланган.

Таҗеддин хәзрәтнең өченче баласы Дилшад 1221 елның рабигыль-әүвәлендә/1806 елның маенда дөньяга килеп, 1308 елның зөлхиҗҗәсендә/1891 елның июлендә Тройски шәһәрендә вафат булган. Казаннан 80 чакрымдагы Сабабаш авылы имамы Мостафа бине Габделкәримдә кияүдә булган. Ире вафат булгач, балалары илә Тройски шәһәренә күчеп киткән.

Таҗеддин хәзрәтнең дүртенче баласы Мәүһубә 1223 елның рабигыль-әүвәлендә/1808 елның апрелендә дөньяга килеп, 1306 елның җөмадиел-әүвәлендә/1889 елның гыйнварында вафат иткән. Ире Фазлулла бине Мөхәммәдәмин әл-Бәрсуаный булган. Ул исә Таҗеддин хәзрәтнең шәкертләреннән булып, Гарәбстанга сәяхәт иткән вә хаҗ кылган. Башта Мөэмин бай тырышлыгы белән Оры авылында Фәтхулла ахун бине Әлхөсәен янында иптәш имам булган, соңра, туганының улы Ибраһим бине Мөхәммәд әл-Бәрсуаный вафатыннан соң, Вятка вилайәте Малмыж өязе[80] // [429] вә Малмыждан ун чакрымдагы Нөнәгәр авылына имам булып күчкән. Тавышы гүзәл вә укуы дөрес булып, рузә вә ифтарны хисап белән үти иде, диләр. 1284 елның 11 зөлхиҗҗәсендә/1868 елның 23 мартында вафат булган.

[80] «Мөстәфадел-әхбар...»да ялгыш Мамадыш өязе Мәңгәр авылы дип язылган (2 нче кисәк, 194–195 б.).

RUHIAT

Таҗеддин хәзрәтнең бишенче баласы турында киләчәктә үзенә тиешле урында язылыр.

Таҗеддин хәзрәтнең гыйлем алган вакытта язган китапларының исемнәре вә тарихлары: 1) «Сарфы Бидан» вә «Шәрхе Габдулла». 1195 елның 17 зөлкагдәсендә/1781 елның 24 октябрендә, Болгар вилайәте Карча Елга авылында мулла Мохтар бине Мөхәммәдшәриф мәдрәсәсендә. 2) «Шәрхе Әнмүзәҗ». 1199 елның 8 шәгъбанында/1785 елның 5 июнендә. 3) «Шәрхе шәрхел-исагуҗи Ногман». 1199 елның 2 зөлхиҗҗәсендә/1785 елның 25 сентябрендә, Утар авылында Ибраһим әфәнде бине Хуҗаш әш-Шәрләмәви мәдрәсәсендә. 4) «Мишкятел-әнвәр». 1200 елның 8 мөхәррәмендә/1785 елның 31 октябрендә, Чаллы башы авылында Габделмәҗид бине Әбүбәкер мәдрәсәсендә. 5) «Шәрхел-исагуҗи». 1202 елның 18 шәүвәлендә/1788 елның 11 июлендә, Казан вилайәте Тенке авылында Габделхаликъ бине Әгъзам мәдрәсәсендә. 6) «Шәрхе Шәмсия». 1203/1788 елда Тенеки авылында Габделхаликъ бине Әгъзам мәдрәсәсендә. 7) «Рамазан шәрхе – шәрхел-гакаиден-Нәсәфия». Утар авылында Ибраһим әфәнде Хуҗаш әш-Шәрләмәви мәдрәсәсендә. 8) «Шәрхе хикмәтел-һидайә». Утар авылында Ибраһим әфәнде әш-Шәрләмәви мәдрәсәсендә. 9) «Шәрхел-гакаидел-Гыйздийә лимелла Җәлял». 1203 елның 4 мөхәррәмендә/1788 елның 24 сентябрендә, Утар авылында Ибраһим әфәнде мәдрәсәсендә. 10) «Мотаувәл». 1204/1790 елда. 11) «Шәрхеш-Шатыйбый». 1207 елның 8 шәгъбанында/1793 елның 10 мартында хаҗи Ишмөхәммәд бине Заһид мәдрәсәсендә. 12) «Шәмсия хашиясе Гыйсамеддин». 13) «Мирсәед». 1213/1798 елда. 14) «Гакаиде Нәсәфи хашиясе Хәййали». 15) «Хәййали шәрхе мелла Касыйм». 16) «Җәлял хашиясе мәүляна шәриф». 17) «Мелла Җәлял хашиясе». 18) «Шәрхе рисаләи исбател-ваҗиб». 19) Моның хашиясе «Мелла Хәнәфи». 20) «Хашияте мотаувәл». 21) «Шәрхе мелла Җами галәл-Кафия». 22) «Хашияте Гыйсам галәл-Җами». // [430] 23) «Гыйсмәтулла». 24) «Тәүзыйх». 25) «Тәлүих галәт-тәүзыйх». 26) Шәмседдин әл-Каһестани галәл-фикъһел-Кәйдани. 27) «Әл-хиснел-хассин». 28) «Шәрхе рисаләти фил-әдәб ли-Әхмәд әлмөштәһир Биташкүпризадә». 1213 елда. 29) Моның хашиясе «Ли-Муса бине Әхмәд әл-Бәркәти». 30) «Рисаләте Гыйздийә фил-адаб». 31) Моның хашиясе «Лимир Әбелфәтех». 32) «Мирза Заһид галә шәрхел-мәвакыйф». 33) «Шәрхе кадим галәт-тәҗрид лил-мохаккак әт-Туси». 34) «Һидая». 35) «Хутәбүл-әрбәгыйн». 36) «Касыйдәи бөрдә». 37) «Шәҗәрәтен-нәби Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәллам». 38) «Гайнел-гыйлем». 1830 елда. 39) «Шәвәкилел-хур шәрхи һәвакилен-нур». 1838 елда. 40) «Фөтухатеш-Шам ли Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Гомәр әл-Вакыйди». 1840 елда, 72 яшендә язылуы ахырда бәйан ителгән.

«Һидая» нөсхәсенең әүвәл тарафына болай язган: «Бу «Һидая» китабын мин фәкыйрь Таҗеддин язып, мелла Зыяэддингә тапшырдым 1833 ел, 20 июль. Истәлек өчен фәкыйрь Таҗеддин мелла Габдеррәшид угылы». Бу китаплар бер җирдә җыелсалар, зур бер печән кибәне кадәр булуы шөбһәсез. Бу көндә боларны язу түгел, исемнәрен укырга да ялкауланмаган аз булыр.

RUHIAT

## *Таҗеддин хәзрәтнең хатлары*

*Беренче хаты.*

[Шигъри шәкелдә 1822 елның 1 февралендә Муса бай бине Ягъкуб бине Исмәгыйль әс-Саснавыйга язылган 42 юллы тезмә хат.] //

*Икенче хаты.*

[Хаҗи Бәгъдадый хозурында Коръән күчереп язучы угылы Зыяэддингә 1825 елның 18 августында язылган. Фарсы телендә.] //

*Өченче хаты.*

[Мулла Сәйфулла хәзрәтләренә 1828 елның 16 сентябрендә язылган.]

Бу хат Саснадан Бохарага киткән Сәйфулла бине Йосыф исемле кешегә Бохарага җибәрелгән. Моның атасы Йосыф мулла, хокуксыз мулла исемендә булып, абруйлы бер зат булган вә, Таҗеддин әл-Иштирәки Саснага килгәч, аның ярдәмчеләреннән булып, хезмәтләрен үтәгән. Сасналың мәшһүр адәмнәреннән булган Муса бай бине Ягъкуб бине Исмәгыйльнең бабасы Исмәгыйль Йосыф мулла илә бертуган. Боларның кабиләләре Караҗыен дип танылган. Сәйфулла исә Чистайда мөдәррис вә шәех Мөхәммәдзакир хәзрәтнең атасы Габделваһаб бине Габделкәримнең әнисе ягыннан абыйсы булган.

*Дүртенче хаты.*

Газиз мөкәррәм мулла Нурмөхәммәднең гали хәзрәтләренә күп догалар. Рамазан шәрифенең 15 нче көнендә Вятка каласына чыгып, Вяткага барып, гаедтән бер көн алда кайттык. Духовное собраниедән ике авыл, ягъни Саснадан алган приговорны вә һәм Иштирәктән алган кәгазьләрне сораганнар икән, анда калган иде, шуны җибәрмәгәннәр. Аннан башка хокук бирмиләр икән. Җибәргәннәрне сорасагыз, белер идегез. Ягъни моннан соң узган көннәрдә язган вакытта күп-күп // [434] хафалыклар күреп, җыйнаксыз сүзләр язылгандыр. Таркау хәтерле булмагыз.

Үз гәүдәбезне күтәрергә дәрман булып, кеше өстенә асылмасак иде. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызның ашау-эчүләрен үзенә салса иде.

Һәмишә догалар җибәрүче Таҗеддин бине мелла Габдеррәшид әл-Иштирәки. 1829 елның 22 апрелендә.

*Бишенче хаты.*

Газиз мөкәррәм мулла Нурмөхәммәднең гали хәзрәтләренә догалар. Фәкыйрьләр хәер-догаларыгызда исән-саулар, Аллаһыга шөкер. Мөфти хәзрәтләренә вә һәм Шәкүр казый илә Әмин казыйга хат яздым. Сезгә бик мәшәкать булмаса, почта илә җибәрсәгез, бу сүзне яздым, мелла Зыяэддин иманасы кай җирдә түләнә, дип. Безгә хокук бирү Сезнең җавабыгызга бәйле икән, диләр. Шәригатьне һәм канунны һәммәдән артык беләсез, фәкыйрьләргә иганәт максаты белән тиешле җавап бирелерме? Яки фәкыйрьләргә хезмәтегезгә барырга ишарә кылырсызмы? Земский кешесенә бер тәңкә биргән идек, тагын бер гөрәнкә чәй бирдек, «мулла булма» дип подписка алып китте, күңелебез җәрәхәтләнде. 400 сум акча бетереп, һаман эшнең ахыры күренми. Кыш барганымда мулла Нурмөхәммәдкә серемне сөйләп карыйм дип бардым, ләкин һичбер сүз әйтергә кыя алмадым. Үзебез барыйк дисәк, кодрәт юк, барча эшебез юлда ятып калды. Миһер-

банлык килеп, мулла Зыяэддинне кардәш яки угылы күреп ярдәм итмәсәгез, ихтыяҗ булдырып, мәнфәгать өмет итәр җай калмады. Кайбер кешеләр әйтәләр, мулла үз губерна кешесе булсын, дип, фәрман бар икән, дип. Бу тәкъдирдә иманабызны күчерер өчен йөрү кирәк буладыр. Ничек кенә булса да, Сездән башка кемгә еларга мөмкин?! Ят кешеләрнең һәркайсына ыспай мөгамәлә тиеш, авыл халкының игътибарлары юк. Хәзер рамазан шәриф вакыты, рамазан беткәч, әллә юл бетәрме? Кар китеп, кара җир булгач, һәркая барырга мөмкин булыр кебек. Мулла Нурмөхәммәд, кардәшлек итеп, мулла Зыяэддинне 100 сум акчага бурычка иганәт итәрсез. //

[435] Аллаһы Тәгалә гомер бирсә, әлбәттә, түләрләр. Җиңеллек күреп язмыйбыз, 100 тиен сорар кешебез юклыгыннан, барлык ихтыяҗыбызны Сезгә юлладык вә һәм гаеп кылмагыз. Аллаһы рәхмәте белән Сезгә, алачак бар кеше кебек, ихтыяҗыбызны юлладык. Вәссәлам. 1829 елның 4 марты.

*Алтынчы хаты.*

[Угылы Зыяэддингә 1831 елның 6 мартында язылган.]

*Җиденче хаты.*

[Угылы мелла Зыяэддингә һәм мелла Гобәйдуллага язылган, вакыты мәгълүм түгел.]

*Сигезенче хаты.* [1832 елның 9 маенда, тугызынчы хаты 1833 елның 25 августында, унынчы хаты 1834 елның 14 сентябрендә, унберенче хаты 1834 елның 26 декабрендә, уникенче хаты 1836 елның 28 июнендә, унөченче хаты 1836 елның 29 октябрендә, ундүртенче хаты 1837 елның 22 декабрендә «мелла Нурмөхәммәд тархан мөхтәсибел-ислам хәзрәтләренә» язылган. Унөченче хатта угылы мелла Зыяэддингә Норма авылыннан «Габид агайның» кызын ярәшүләре турында сүз бара.] // [439]

*Унбишенче хат.*

Газиз мөкәррәм мулла Нурмөхәммәднең гали хәзрәтләренә догалар... Юл хатыбызны алып, Әлмәт Мулла авылында Хәбибрахман муллага тапшырырбыз, дигәннәр иде. Ул муллага бик гозер итеп: «Сезгә китерсәләр, мулла Нурмөхәммәдкә тапшырырбыз», – дигән идем. Алар: «Бистәнең Миңлебай исемле кешенең угылы безнең авылыбызда ята, аның илә булса да яки гайре кеше // [440] илә булса да мулла Нурмөхәммәд хәзрәткә тапшырырбыз», – дип әйткәннәр иде. Инде ничек булганын белмибез. Әгәр дә Сезгә килгән булса, бу баручы Ибраһим Мөхәммәдрәхим угылы илә җибәрерсез. Мәүдүдә, хатны укыгач, үзләрен чакырмагансыз, дип, бик үпкәләп яздырды. Мулла мәхдүм тархан хәзрәт! Дәүләтебез бик мул, ун көн киленбикә илә бергә килеп торыгыз, шәһәр тупаслыгыннан саф булыр өчен. Хат башына язылачак гәпләр[81] үз алдына язылды. Гозерле тоталар.

Догада булучы фәкыйрь Таҗеддин мулла Габдеррәшид угылы әл-Иштирәки. 1838 ел, 20 апрель.

[81] «Гәп» төрки сүзебезме, юкса фарсыдан алынган «гөфтегү»ме? Әдипләребез тикшерсеннәр.

Бу хатта телгә алынган Хәбибрахман мелла Бөгелмә өязендә Зәй елгасы буенда вә зур юл өстендә почта вә телеграфлы Әлмәт авылының имамы иде[82]. Миңлебайның тәрҗемәсе «Мөстәфадел-әхбар...»да бирелә (2 том, 341 б.).

*Уналтынчы хаты.*

[Шигъри шәкелдә «мулла Габбас»ка язылган. Вакыты мәгълүм түгел.]

*Таҗеддин хәзрәтнең кайбер язмалары:*

[443] «2) Минем әткәм ягыннан бабам Янгилде абыз, аның угылы Җанъегет абыз Сембер урынын руска кальга корырга биргән, үзенең агач җире икән. Моның өчен падишаһ хәзрәтләре күп рус крестьяны биргән. Җанъегет угылы Сүкә, Сүкә угылы Метри, Метри угылы Шәфи.

3) 1294 елның 20 зөлхиҗҗәсендә/1877 елның 14 декабрендә, җомга көн дамелла Габдеррахман хәзрәт мәдрәсәсеннән чыгып киттем».

Биредә китерелгән хатларыннан башка, мәгълүм булган дәрес китаплары, шәрех вә хашияләренең читләренә язылганнар аның әсәрләренә туры килә. Бохарага барып дәрәҗә алып кайтмаган булса да, замандашы Фәтхулла ахун бине Әлхөсәен кебек шөһрәт ияләреннән түбән дәрәҗәдә булмавы мәгълүм. Үзенә Бохарадан Сәйфулла бине Йосыф әс-Саснавый тарафыннан язылган хатларыннан нөсхәләр күренсә дә, мосье Вамбери сүзләренә муафыйк рәвештә, бу хатлар бары юмалау вә икейөзлеләнүдән гыйбарәт булганга, күчерү кирәк күрелмәде.

### 207. Ишмөхәммәд бине Заһид бине Бикмөхәммәд бине Әлмөхәммәд бине Өлеш бине Колыш бине Теләш бине Кызылбай бине Урманчы бине Чытырман бине Аяз бине Бишмәт

RUHIAT

Бәләбәй өязендә Күбәк авылында имам вә мөдәррис булып, 100 яшендә 1256 елның зөлхиҗҗәсендә/1841 елда вафат булган. Бу шәҗәрә, нәсел-нәсәбенең кулында булган берничә нөсхәсеннән күчереп, бу җирдә язылды.

Кабере // [449] өстендә булган ташы югалганга, яңадан икенче таш куелып, болай язылган: «Хаҗи ахун Ишмөхәммәд Заидов, вафат булды 95 яшендә[83], 1 февраль, 1841 елда, яздым мин Габделлатыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел, 3 сентябрьдә». Күбәк авылы Бәләбәйдән – 80, Уфадан 110 чакрым ераклыкта.

Бу гасырда вә бу якларда мәшһүр галимнәрдән булган Әмирхан ахун бине Абзай исемле кешенең кабере дә Ишмөхәммәд хаҗи кабере илә күрше. Әлеге Әмирхан ахун исә 1227/1812 елда 73 яшендә вафат булган. Күбәк авылыннан күчеп, Таулар авылында торган вә соңрак кире Күбәккә кайткан. Моның исә Габдеррәфигъ исемле угылы, башкортлар кантоны буларак, 34 яшендә атасы илә бер елда вафат иткән. Язуга маһир булган Габделгани исемле икенче угылы Таулар авылында ахун булган. Боларның нәсел-нәсәпләре, бу көндә «Әмирханов» дип шөһрәт казанып, дворян сыйныфына керәләр. Әмирхан ахунның тәрҗемәи хәле бу җирдә өстәмә буларак язылды. Ишмөхәммәд хаҗиның хатыны Фатыйма бинте Гомәр иде.

Балалары: Мөхәммәдлатыйф, Габделлатыйф, Габделҗәббар, Маһитаб һәм башкалар. Бер кызы Әмирхан ахун угылы Габделгани ахун никахында вә икенче

[82] Хатыны Сыйддика исемле иде. Тәрҗемәи хәле «Мәшһүр хатыннар»да бирелә.
[83] Бу исә Шәмсия [Кояш] ел хисабы илә, Камәрия [Ай] илә 100 яшь ахыры була.

кызы Маһитаб, Шаһкол (Шакул) фамилиясеннән бер затка никахланып, Мәликә исемле кызны дөньяга китергән. Мәликә исә кенәз Сәлимгәрәй Әлмаксудыйга кияүгә бирелгән. Мөхәммәдлатыйф исемле угылы Күбәк авылында имам вә ахун булган.

Шәкертләре: Таһир бине Сөбхан әл-Адайи, Габделлатыйф бине Сөбхан әл-Кырчый, Хәбибулла бине Габделваһаб әл-Чакмагышый, Таҗеддин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки, Тавабил бине Сабак әл-Йөгәмеши, Нурмөхәммәд бине Ибраһим әл-Казаный һәм башкалар.

Ишмөхәммәд хәзрәтләре яшь вакытында укый-яза белгәннәрдән булмый, // [450] авыллардагы гади халык балалары илә берлектә вакытында эшләп, вакытында рәхәт чигеп, көн уздыра торган булган. Җырларга маһирлыгы сәбәбеннән, һәртөрле мәҗлесләргә чакырылып, төрле кешеләрнең кәефләрен күтәрә торган булган. Кыска вакыт эчендә скрипка уйнарга өйрәнеп, үзе кебекләр арасында кызыгырлык бу ике һөнәрне бергә туплаган. Көн-төн уен-көлке, исраф вә мал туздыру даирәсендә йөргән бу егетнең киләчәктә шөһрәтле вә вәкарьле бер остаз булачагы күз алдына да китерелмәгән булса кирәк. Шушы хәлендә яшәгәндә өйләнгән вә 22 яшендә, көннәрнең берендә, авылдан югалган. Җәяүләп йөреп, шушы чыгып китүеннән Хиҗазга барып хаҗ кылган, сигез елын Каһирәдә үткәреп, калганнарын сәфәрдә уздырып вә башка шәһәрләрдә кичереп, егерме биш ел гомерен уздырып, Күбәк авылына кайтып килгән. Бу вакытта яшьләре дә 47 булган икән. Фәкать бу юлы «скрипкачы Ишмөхәммәд» түгел, бәлки галим вә фазыйль Ишмөхәммәд хәзрәт буларак мәйданга чыккан. Кайтканнан соң, Фатыйма исемле хатынны алып, ахыр гомеренә кадәр бергә гомер сөргәннәр. Моның яшь вакытында булган хәлләрен вә нинди фикерләрдә булуын, хатынын вә һәммә якыннарын ташлап китүенә төп сәбәп нәрсә булуын аңлау – зур бер гыйбрәт вә тәрбия гыйлеме кагыйдәләренә күрә беленергә тиешле бер дәрес булса да, ни чара ки, боларны белгән кеше белән очрашу насыйп булмады. Нигездә мондый нәрсәләргә вә рух гыйлеме [психология] мәсьәләләренә игътибар иткән вә күңел биргән бездә юк хөкемендә. Зур шәхесләрнең көн кичерүләрен белү, аларның гадәт вә холыкларын аңлау бала вә шәкертләрне тәрбия итүдә беренче ишек булса да, безнең халкыбыз карашында әһәмиятсез бер нәрсә. Ишмөхәммәд хәзрәтнең бер сәяхәтнамәсе булуы сөйләнсә дә, бу көндә җиһанда булуы шөбһәле.

RUHIAT

Оренбург вилайәтендәге «Археология җәмгыяте» тарихының 1902 елда басылган китабында әйтелгәнгә күрә, императрица Екатерина Икенче // [451] Уфа, Сембер вилайәтләрен идарә итүче генерал-поручик Иван Варфоломеевич Якобига 1782 елда, указ язып, Уфа, Тобол вилайәтләрендә булган чикләрдә җамигъ мәчетләре салырга боерган булган. Шундый эчтәлектәге указ 1783 елның 2 маенда әлеге вилайәтләрне идарә иткән генерал-поручик Аким Иванович Апухтинга да кабатланган. Шуңа күрә Петропавел, Тройски, Верхнеурал һәм Оренбург шәһәрләрендә дүрт мәчет салынган. Оренбургта Меновныйдагы мәчетнең салынуына Кече Урданың Нургали хан килү якынлыгы сәбәп булган. Ошбу мәчетнең имамына елга 150 сум, ике мөәззин булып, һәрберенә елга 20 сум, ике биш вакытлы имамнарның һәрберенә елга 60 сум, мөдәррисенә елга 60 сум хезмәт хакы билгеләнгән булган. Иң беренче буларак генерал-губернатор 1789 елның 17 сентябрендә әлеге мәчет хозурында мөдәррис булу өчен Бәләбәй өязе Күбәк

авылының типтәр[84] таифәсеннән хаҗи Мөхәммәд Заһид угылын, имамлыкка Думай авылының Әбү Йәзид Уразман угылын, мөәззинлек өчен Сәгыйдь бистәсенең Габдеррахман Габделгазиз угылын билгеләгән. Шулай ук төрле хезмәтләр өчен кирәк булачак кешеләрне билгеләү вазыйфасын хаҗи Мөхәммәд Заһид угылына тапшырган. Моннан соң, 1790 елда, әлеге мәчет хозурында мөдәррислек өчен Бөгелмә өязе Баулы авылыннан мишәр Мөслим Мансур угылы билгеләнгән.

Моннан аңлашылганга күрә, Оренбург шәһәрендәге Меновный базары мәчете төзелүе 1203–1204/1789 елда, Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәте ачылганга кадәр 1–2 ай алдан булып, бер елдан артык хезмәт күрсәтмәгән булса кирәк.

Оренбург вә Казан шәһәрләрендә боларга караган төрле авылларда кыйраәт гыйлеме // [452] укытканга, аның хозурында күп кешеләр укыган. Коръән уку гыйлемендә остаз булган кебек, тавышы чиктән тыш гүзәл, башкаруы дөрес, язуы тиңдәшсез яхшы булганга, бу мәмләкәт олуглары хозурында мәртәбәсе югары булган. Бу уңайдан үзенә дә дөнья буйсынган, диләр. Байлыгы күп булып, дөнья байлыгыннан файдаланыр өчен үз авылына кайтып урнашкан, тегермән вә кярханәләр [остаханә, фабрика] салып, күп урман вә җирләргә ия булган. Фәкать ахыр гомеренә эшләре начарланып, җир вә урманнары читләргә киткән, байлыгы да бетеп китеп, хәле түбән тәгәрәгән.

Хиҗазда кайбер шәехләргә ышаныч китереп, суфыйлыкта рөхсәте булса да, мөрид тәрбияләргә вакыты җитешмәгән вә яки аңа теләге булмаган. Сөйләгәннәргә караганда, бу мәмләкәткә иң элек кергән «Әл-миркате шәрхел-мишкят» нөсхәсен Ишмөхәммәд хәзрәт Хиҗаздан китергән булган икән. Алты кисәкле гүзәл каләм илә язылган әлеге әсәр, мөфти Сәлимгәрәй бине Шаһингәрәй Тәүкили тарафыннан сатып алынып, Килем авылындагы мөселман мәдрәсәсе шәкертләре файда алсын өчен вәкыф ителгән. Ләкин 1314 елның 22 зөлхиҗҗәсендә/1897 елның 12 маенда, дүшәмбе көн булган янгында янып юкка чыгуы сөйләнә.

Үзенең файдаланган «Фәтавый» китабы бу көндә Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәте шкафында саклана. Бер китабының читенә үз каләме белән: «1823 елның 13 гыйнварында казага калган намазларымны янәдән каза кылырга башладым, мин фәкыйрь хаҗи Мөхәммәд, гәрчә сәфәр йөргәндә үтәгән булсам да», – дип язылган. Асыл исеме Ишмөхәммәд булган хәлдә, күпчелек язуында бары Мөхәммәд дип кенә язылганы күрелде. Бәлки, моның берәр сәбәбе дә бардыр.

### 208. Мөхәммәдшаһ бине Мирас

Тройски шәһәрендә имам булып, // [453] Хиҗаз тарафына киткән вә 1256 елның ахырында/1841 ел башында Мәдинәи мөнәүвәрәдә вафат булган. Бу кешене мактап зурлаганны шәех Зәйнулла әл-Халиди хәзрәтләре тарафыннан кабат ишеттем.

[84] Казан шәһәре Русия дәүләтенә кушылгач, «типтәр» дип мәшһүр булган халыклар. Болар бу көндә Самара, Оренбург, Уфа вилайәтләрендә ике миллионнан артык хисапланалар.

RUHIAT

## 209. Дәүләтбакый бине Галиеләсгар

Сибириянең танылган галимнәреннән булып, Бохарадан Тара шәһәренә кайтып килгән вакытта Кара Үткәлдән чыгып сигез йә ун чакрым килгәч вафат итеп, бер су янында күмелгән, вә кабере мәгълүм икән. Бу исә 1256/1840 елдан соң иде, диләр. Асылы Оренбург ягындагы Иманкол авылыннан булып, атлы гаскәрдә хезмәт иткәндә, бер сәбәп илә Бохарага юлланган вә, анда тырышып гыйлем туплап, Тара бистәсенә килеп, имам вә мөдәррис булган. Азмы-күпме шул шәһәрдә укыту белән шөгыльләнгәндә, рамазан аеның рузәсе хакында һәм гомумән айларның башы вә күренми торган чаклары турындагы шөбһәләрне ача алмаганга, гыйльме нөҗүм [астрономия] укыр өчен кабат Бохарага юнәлгән. Бу вакыт урынында туганы Фәйзулла бине Галиәсгар Тарада калган. Голуме гаклия вә голуме нәкълиядә белем җыйганнан соң, Ташкент юлы белән кайтып килгәндә, югарыда әйтелгән урында вафат булган. Китаплары вә гыйльме һәйәткә [астрономиягә] кагылышлы әсбаплары варисларына калган. «Вәсига күрсийүһү әссәмават вәл-арз» дип язылган түгәрәк бөриз [чукмар] коралы, Тараның мәшһүр байларыннан хаҗи Насреддин бине Нияз тарафыннан сатып алынып, Тобол шәһәрендәге музейга һәдия ителгән. Бу көндә камил тәрбия кылынып саклана вә «мине зиярәт итәчәк бер мөселман дөньяга һаман килмәдеме?» дип сөйләп тора, диләр. Ташкенттагы Хәйдәр әт-Таравыйга язган бер хаты ошбудыр: // [454] «Әүвәлге Әсәдулла агалар берлә язган хатыбызда бу кышны монда үткәреп, киләчәк мәкәрҗәчеләр илә бергә, Аллаһы Тәгалә боерса, кайтырбыз» дип язган идек. Инде, Аллаһы боерса, тизрәк кайтырга уйлап, мәслихәт итеп торабыз. Насыйп булса, моннан бүлмәбезне сатып, Ташкентка барсак кирәк. Шаять, бу кәрваннан калып, үзебезнең ага вә энеләрдән иртәрәк чыга торганнарыгыз булса, хуп булыр иде. Һәрхәлдә, моннан Ташкентка барып торсак иде. Әгәр сезгә җитешә алсак, сезнең белән кайтырга булыр иде. Җитешә алмасак, янә карарбыз. Бохараның һавасы килешмәгәннәнме, нидәндер, килгәнебездән бирле табигатебез авыр булып, тәмам тырышлык куя алмыйбыз. Үзебез дигәннән, мелла Зәйнелбәшәрдән соң бераз ютәл булыбрак йөрибез, суык үтте бугай. Бүлмәбезне алучы күп, әгәр хәзер сатар булсак. Инша Аллаһ, мелла Зәйнелбәшәр алса, кыйммәте арзан булыр. // [455]... Үзебезнең мөфти угылы бүлмәсендә бер кәттә хәлфәсен күрдем. Нәзер, нияз вә шөһрәт ияседер.

Фәкыйрь Дәүләтбакый бине Әсгар. 1255 ел, 28 җөмадиел-ахир». // [456]

## 210. Габденнасыйр бине Сабит бине Сәфәргали әл-Эчкени әл-Әлмәни

Асыллары Шадрин өязендә Тәрсүк авылыннан. Бу зат үзе Чиләбе өязе Әлмән авылында дөньяга килеп, 95 яшьләренә җиткәндә 1257 елның сәфәр/1841 елның март (апрель) аенда вафат булган. Остазы Бөре өязендә Яугилде авылында Габденнасыйр исемле бер зат булган.

Шәкертләре: Мөхәммәдзариф бине Габделҗәлил һәм башкалар.

Балалары: Габделкәрим, Насреддин, Габделәхәд, Хисамеддин.

Язган нөсхәләре күп булып, тәмам мәртәбәгә ия булган. Кирәк җирләренә аңлатмалар язылган ике җилд «Гыйная»се илә ике җилд «Тәфсире казый Бәйзавый» нөсхәләре ошбу көндә исән сакланалар, диләр. Әлеге «Гыйная» нөсхәсенең бер читенә үзе каләме белән: «Моның белән барлык язган китабым 223 җилд булды; 20 яшемнән китап яза башлаган идем, хәзер 95 яшемә ирештем, һич

күзлек кимәдем, чыра яндырып яздым, хәзер гәрчә шәм дигән бер нәрсә чыкса да, берәр кич яндырырлык шәм алырга да акчам юк, инде картайдым, бәлки, моннан соң язарга куәтем дә җитешмәс!..» дип язылганы билгеле.

И с к ә р м ә. Чыра яндырып, 200 җилд китап язган иҗтиһадлы бабаларның балалары ошбу мәдәният дәверендә Сибирия юлын салучы мөһәндисләр [инженерлар], бөтен дөньяны китап вә гыйлем илә тутырган остазлар булырга тиешле заманда, ни чара, адәм кыяфәтендәге вәхши хайваннар булып калдылар. Инде бездә һиммәт сүнде. Иҗтиһадның исеме дә калмады, гомерләр пыран-заран килде. Бу сүзем үз кавем вә кабиләмә караган Урал мөселманнарына кагыла. Шуның өчен ошбу юлларымны укыганда, Казан ягындагы вә Казан шәһәрендәге мөселманнарның хәтере рәнҗемәсен! Чөнки алар заманага муафыйк тәрәккый иткәнгә, // [457] бу исәпкә кермиләр! Аларда булган алтын күзлекләр, энҗе калфаклар, кәкре таяклар, бәһале сәгатьләр, велосипед һәм дачалар хәтта французлардан аерылмый, диләр. Кайбер яшь байлар вә модный сакал ияләре хәтта кафе-шантаннарда булган матур күзләр тарафыннан: «Шул дәрәҗәдә мөкәммәл образованныйдыр ки, татар булырга кызганыч!» – рәвешендә макталулары җиһанга таралган, имеш. Менә тәрәккый шулай була!.. Русия мәнфәгатен Төркестанга, Бохара вә Ташкент малларын Русиягә күчереп, Кызылком сахрасыннан кәрван йөрткән ак бүрекле, тирән кесәле карт бабаларның балалары болай тизлек белән шаккатырырлык мәдәният кәсеп итүләре, әлбәттә, гаҗәпләнүгә лаеклы булса кирәк!

### 211. Габделҗәлил бине Микәй бине Капкын бине Чапкын

RUHIAT

Оренбург ягындагы Рәдүд авылында имам вә ахун булып, 110 яшендә 1257 елның 9 рабигыль-әүвәлендә/1841 елның 2 маенда, шимбә көн вафат булган. Асылы Сембер губернасында Ендовище исемле авылдан. Нигъмәтшаһ, Газыймшаһ исемле угыллары булып, бу көндә вафатлар. Чын исеме Габделкәрим булган хәлдә, Рәдүдкә килгәннән соң, исемен Габделҗәлилгә алыштырган.

### 212. Хөснеддин бине Бәшир әт-Түнтәри

Чын исеме Арыслан булган хәлдә, Хөснеддин дип мәшһүр булган. Бохарадан кайтканда Еланлыклы дигән урында 1257/1841 елда вафат булган.

Остазлары: Салих бине Надирмөхәммәд әл-Хөҗәнди, Мөхсин бине Биккол әш-Шашый.

Шәкертләре: Фәварис бине Габделҗәлил әт-Тимерҗани, Шаһиәхмәд әл-Кариле // [458] һәм башкалар. Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Диндар, изге, галим, язуга маһир иде, ләкин җиңел гакыллы, үз-үзен мактаучы вә үзенә яхшы карашлы, иптәшләрен ким итүче. Яман сүзле, бозык сөйләмле, мөнәсәбәте булса-булмаса да, дәрес вакытында һәр белгәнен сөйләүче вә, шуңа өстәп, гайбәтләр катнаштыручы иде, хатын алмады, кәнизәк тотмады; аз йоклаучы вә күп елаучы юмарт бер зат иде; Бохарага барган казанлылардан фәкать Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавый, Мөхсин бине Биккол әш-Шашый, Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүши, Баһаветдин бине Сөбхан әл-Мәрҗани гыйлем иясе булып, алардан башкалары гыйлемсез кайттылар, дип әйтә иде», – дигән. Бохарадан Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәригә язган озын бер хатын күргәнебез булды.

## 213. Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви

Үргәнеч мәмләкәтендә вә Яңа Үргәнеч шәһәренә 4 чакрымда булган Чекә атлы урында ишанлык итеп, 1257/1841 елда вафат булган. (Кайбер кешеләр сөйләвенә караганда, 1258/1842 елда вафат булган.) Асылы типтәр таифәсеннән булып, ни вакыттадыр Бохарага сәфәр иткән. Хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни белән аралашкан. Бу мәмләкәткә кайткач, Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында, имам вә мөдәррис булып, шәкертләр укыткан вә тәрбияләгән. Шул чорда Бәйрәкәнең мәшһүр байларыннан Исхак бине Гали бине Ает (Гаед) бине Хөсәен бине Хәсән бине Туйгилде бине Илтимер бине Биктимер бине Аксәед бине Имин бине Байтөгәл бине Алдыргыш бине Әлкешби исемле кешенең Шәмсекамәр исемле кызын никахлаган. Күпмедер вакыт торганнан соң, үз теләге беләнме, шәехе ишарәсенә күрәме, балаларын Бәйрәкәдә калдырып, 1230/1815 елда Бохарага шәех Төрекмәни хозурына киткән вә аннан югарыда аталган Үргәнечтә, Чекәдә торган.

Монда калган балалары: Әбүнәгыйм, Таҗенниса, Мәрьям. // [459] Әбүнәгыйм фәкыйрь вә мескенлек белән Бәйрәкәдә тереклек итеп, 60 яшендә 1298 елның җөмадиел-әүвәле ахырында (1881 елның 17 апрелендә) вафат булган. Мөхәммәдгалим, Мөхәммәдшәриф, Бибигазизә, Фатыйма исемле балалары калган. Бу көндә Мөхәммәдгалим вафат булып, нәселе калмаган. Мөхәммәтшәриф тә вафат булып, Гарифә исемле бер кызы калган. Газизә Кәрәкәшле авылында Әхмәд исемле кешедә, вә Фатыйма Бәйрәкәдә Габделгали исемле кешедә никахта булганнар. Болар һәммәсе гавам таифәсенә карыйлар. Әбүнәгыйм өчен галим атасыннан гыйлем өлкәсендә калган мирас Әбүһашимнан үзенең угылы Әбүгалигә калган мирас күләмендә иде. Шулай булса да күңелле саф бер зат иде, диләр. Атасы хөрмәтендә һәркем каршында абруе булыр вә, кая барса да, ишекләр ачык торган.

Яшь чагында мөхтәрәм атам йортында еш күрә идем, фәкать ишеткән сүзләрем хәтеремдә түгел. Гадәттән тыш озын буйлы, зур гәүдәле булып, никадәр бөгелеп утырса да, мәҗлестә булган иң зур адәмнәрдән чирек аршын микъдарында артып тора иде. Бик кечкенә аты булып вә моңа кечкенә арбасын җигеп йөри, арбасына утыргач, бөтен мәйданын биләп, һичбер урын калмый иде. Башында тупый бүрек, өстендә сары туладан чикмән, аягында читек белән чабата була иде.

Таҗенниса Бәйрәкә имамнарыннан «хаҗи хәзрәт» дип танылган Мөхәммәд бине Мәүлекәйгә никах ителгән, 1834 елның 29 декабрендә вафат булган. Әлеге имам исә якынча 95 яшьләрендә, 1300 ел ахырында (1883 елда) вафат булган. Гыйлем куәте аз вә гыйлемгә мәхәббәте дә чикләнгән булганга, Мөхәммәдшәриф хәзрәттән калган газиз китапларны таратып бетерде, диләр. Бер «Шәрхе әлхиснел-хассин» читенә болай дип язган: «Бәйрәкә авылында әүвәлге мәсҗиде җамигъ хозурында имам, мулла Мөхәммәд Мәүлекәй угылы ошбу китапны хатыным Бибимәрьям ишан дамелла Мөхәммәдшәриф кызының хозурында вә аның ризалыгы вә вәкаләте илә өч тәңкә хак илә 3 нче мәхәлләдә имам вә ишан дамелла Габделгали мәхдүм бине Гобәйдулла хәзрәтләренә // [460] саттым вә хакымны тәмам алдым. 1784 ел, 19 май». Мәсгудь әфәнде бу китапны Мөхәммәдшәриф хәзрәтнең үз каләме илә язылганын бәйан итә. Таҗеннисадан Мөхәммәдхафиз, Мөхәммәдлатыйф, Маһитаб исемле балалары булып, бу көндә һәммәсе вафатлар, нәселләре калган.

RUHIAT

Бибимәрьям, Таҗенниса вафат булганнан соң, 1250/1835 елда җизнәсе имам Мөхәммәд бине Мәүлекәйгә никах ителгән. Мөхәммәдсадыйк, Мөхәммәдзакир, Бибисәидә исемле балалары булган. Мөхәммәдсадыйк илә Мөхәммәдзакир үзләре исән булып, балалары да күп, диләр. Мөхәммәдшәриф хәзрәтнең Бәйрәкәдәге нәсел-нәсәбе шушы ике кеше вә аларның балаларыннан гыйбарәт икән.

Үргәнечкә баргач, Мөхәммәдшәриф хәзрәт өйләнеп, балалары булуы сөйләнә. Күчеп киткәннән соң, урынына үз тарафдарларыннан Гобәйдулла бине Ибраһим исемле зат калган.

Шәкертләре: Габделҗәлил бине Үтәкол әл-Үтәки, Исламкол бине Фулад әс-Сәйрани, Мөхәммәдвафа бине Гобәйд әл-Бигәши, Хәсән бине Зәбир әл-Килеми, Гыйләҗеддин әт-Тәкәи, Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдәмин әл-Бәйрәкәви әл-Иштирәки, Гобәйдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви һәм башкалар.

### *Хатлары*

*Беренче хаты.*

[«Мөхәммәдшәриф бине Ибраһимнан баҗа ахун Габдессәламгә». Гарәп телендә, вакыты мәгълүм түгел.] // [461]

Мәсгудь әфәнде хәбәренә күрә, ошбу хат Мөхәммәдшәриф хәзрәт тарафыннан Бәйрәкәдә вакытында Оренбург шәһәрендә имам вә ахун Габдессәлам бине Габдеррәхимгә (Габдессәлам мөфтигә) язылган. «Баҗа» дип әйтүе ни җәһәттәндер? Ихтимал, Тайсуганлы Габдеррәхим бине Туймөхәммәднең үзе яки хатыны илә Исхак бай арасында берәр төрле туганлык мөнәсәбәте бардыр.

*Икенче хаты.*

«Мөхәммәдшәрифтән туганым дамелла Нигъмәтуллага. Аллаһыга шөкер, бу замангача сәламәтмен. Мелла Габделбакый хәзрәт тә исән-сау. Үзебезнең туганыбыз да Ык суы буенда Япрук дигән авылга имам булды. Сезне бик сагындык. Дамелла Шәрәфеддинне бик күрәсебез килә, Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсен. Дамелла Шәрәфеддингә күп дога вә сәламнәребезне күндерсәләр иде. Дамелла Дәүләтшаһ килеп китте вә сәламегезне һәм сәламәтлегегезне белеп хушландык. Үзебез әүвәлге кеби, муллалар укытып вакыт кичерәбез».

### *Мөхәммәдшәриф хәзрәт балаларының хатлары*

*Беренче хат.*

«...Мәгълүмдер ки, атабыз Бәйрәкә авылында Исхак бай дигән кешенең кызын алып, беркадәр вакыт әлеге бай мәдрәсәсендә мөдәррислек итеп йөргәндә, хатыны дөньядан киткән. Әлеге Исхак бай исә икенче кызын бирергә булгач, атабыз, кабул итмичә, һәммә китап, мал вә башка нәрсәләрен бер угыл вә кызына ташлап, үзе Бохараи шәрифкә килгән. Берничә еллар укыганнан соң, Хәрәзмгә килеп, Үргәнеч ягындагы бер мәсҗидкә имам булган вә шул мәхәлләдән өйләнгән. Биредә 30 елдан артык дин гыйлеме укытып, Аллаколый хан заманында вафат булган. Вафат вакытында өч угылы вә бер кызы, хатыны калган. Бу вакыт атабызга 56 яшь булган». // [463]

Бу хатны төп нөсхәсеннән Мәсгудь әфәнде күчереп җибәрде. Читенә: «Бу хатта язучының исеме дә, тарихы да куелмаган. Фәкать каләме яхшы вә язуы дөрес», – дигән. Фикеребезчә, хат Мөхәммәдшәрифнең үз угылы Мөхәммәдзакир әфәнде тарафыннан язылгандыр.



RUHIAT

*Икенче хат.*

«...Атабыз үлгәннән соң, өч угыл вә бер кыз калдык. Угылларының исемнәре: Мөхәммәдбакыр, без Мөхәммәдзакир, Дәүләтҗан, кыз карендәшебез Бибизәйнәб. Агабыз Мөхәммәдбакырдан Нәфисә, Падишаһ исемле ике кызы калды. Нәфисәдән бер угыл вә бер кыз бар – исәннәр. Бибизәйнәбтән Аллаһыяр, Хәсән, Сәедхан исемле угыллары, Бибизәрнәб, Бибимәрьям исемле кызлары бар. Аллаһыярдан башкалары исәннәр. Аллаһыярдан өч угыл калды. Вә без Мөхәммәдзакирдан Мөхәммәдсәгыйд, Мөхәммәдсалих, Мөхәммәдгазиз исемле угылларыбыз вә ике кызыбыз бар.

Энебез Дәүләтҗан 17 яшендә дөньядан сәфәр кылды. Аннан бер угыл калды. // [464] Бу хатны әтием авызыннан мин, Мөхәммәдгазиз бине Мөхәммәдзакир әл-Үргәнчи, 1317 елның рамазан аенда/1900 елның гыйнварында яздым».

***Бу кеше хакында безгә махсус булган хатлар***

«Мөхәммәдшәриф хәзрәтнең Ибраһимнан югары бабаларының исемнәре монда мәгълүм түгел. Кавем вә кабиләсенең дә кайдан икәнлеге беленмәде. Бер «Сөбател-гаҗизин» китабы бу көндә Күгәрчен авылында мирза Заһид бине Мөхәммәдлатыйф бине Мөхәммәд бине Мәүлекәй кулында саклана икән. Мәсгудь бине Габделгали бине Гобәйдулла әл-Бәйрәкәви. 4 гыйнвар, 1904 ел». // [465]

«Мөхәммәдшәриф ишан бине Ибраһим әл-Бикчурый әл-Бәйрәкәви әл-Үргәнчи. Тууы Ык буенда мәшһүр Бәйрәкә авылында булган. Атасы ягыннан Бикчура ханга мөнәсәбәтле икән. Оренбурглы Мирсалих Бикчурин да Бәйрәкәдән булып, ул да Бикчура ханга мөнәсәбәтле».

RUHIAT

«Мөхәммәдшәриф ишан вафатында угылы Мөхәммәдзакир унбер яшендә калган, әнисе Үргәнечтән. Балигълыкка ирешеп гыйлем алганнан соң, Арал диңгезе белән Амударья // [466] арасында Караком диелгән җирдә каракалпак кабиләсендә Котлыхуҗа ишаннан тарикатькә өйрәнеп, бик мәшһүр булган». // [467]

Мөхәммәдшәриф хәзрәтнең әсәрләре: 1) «Ястү намазы хакында»; 2) «Ястү хакында»; 3) «Чалма койрыгы хакында»; // [468] 4) «...Хатыннарның туйларга, мәҗлесләргә йөрүләре дөрес булу-булмау хакында».

Мөхәммәдшәриф хәзрәтләре галим, фазыйль, тәкъва, гакыллы, гарәби гыйлеме зарарсыз, китап вә сөннәт гыйлемнәреннән хәбәрдар, Әбеннасыйр кебек бер зат иде. Фәкать тәкъвалыгы өстенрәк булганга, халыктан читләшүне ихтыяр күрде, байларның ахмаклыгына вә галим кыяфәтендә булган затларның шапырынуларына риза булмады, йортын ташлап китте. Юкса, ватанында торып, гыйлем таратыр иде, үз милләте, дине өчен бик зур файдалы хезмәт иткән булыр иде, диләр. // [469]

**214. Габелхәлим бине Зәйнелгабидин**

1231 ел ахырында/1816 елда Шәңгәлчедә вә аннан соң Мортышбаш авылында имам булып, 1258 ел рәҗәбендә/1842 елның июлендә (августында) вафат булган. Нәселе калмаган. Минзәлә өязендәге мөдәррисләрнең мәшһүрләреннән булган.

Остазлары: Габдессәлам бине Хәсән әл-Кариле, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни, Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый, Әбеннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим әл-Курсавый.

Шәкертләре: Мөхәммәдкәрим бине Исхак әл-Мәчтәйи, Габдеррәхим бине Салих әл-Караный, Габдеррәкыйб бине Исмәгыйль әл-Кодашый һәм башкалар.

Күбрәк дәресе «Мелла Җами» илә «Тәлхыйс» китапларыннан булуы сөйләнә. Шәкертләре арасында галим вә абруйлы затлар чыгуыннан дәресенең дә файдалы булуы аңлашыла. Солтанбәк ахун бине Сагындык хәбәренә күрә, анасының атасы булган Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый мәдрәсәсендә укыган вакытында Әбеннасыйр әл-Курсавыйны күреп, гыйлемгә зур ихтыяҗлы булганга, һичбер рөхсәт сорамый, Әбеннасыйр хозурына киткән. Риваятьләргә күрә, мәктәбендә булган шәкертләре арасында аларның берсе мисалында йөргән вә һичбер тәкәллеф-фәләне булмаган икән. Хәтта йокысы килгән вакытларында, кайберәүләрнең яннарына барып: «Иптәш! Урыныңа ятып торыймчы!..» – дип әйтә торган булган. Өстендә ак тула чикмән, башында гадәти киндердән чалма булып, күрше авылларга күп вакытта чабата киеп йөргән икән. Хәлбуки шәкертләре, моннан файда күргән гыйлемнәре аркасында, яхшы атлар вә яхшы арбаларда йөриләр, гүзәл йортларда торалар, купшы киемнәр кияләр иде, диләр. Мәдрәсәсендә вафат булган // [470] бер шәкертенең атасы, Мортышбаш авылыннан үтеп барганда, каберлегенә кереп, Коръәни Шәриф укып киткән, моны ишеткәч: «Угылына өеннән укыса да барыр иде, бу авылга килгәч, минем белән күрешергә кирәк иде», – дигән.

Дәрес биреп утырган вакытта бер мөсафир кереп күрешеп, 20 тиен садака биреп чыгып киткәч, акчаны, кулына тотып, шәкертләргә күрсәткән дә: «Шушы нәрсәдә минем һич мәхәббәтем юк, туфрак илә икесе бәрабәр!» – дигән. Аңа каршы бер шәкерте: «Алай булса, хәзрәт, аны безгә бир!» – дигән. Хәзрәт: «Үземә кирәк, аннан башка чәй бирмиләр!» – дип җавап биргән.

Яңгырга бик мохтаҗ бервакытта якындагы Карамалы авылына җәяүләп барган, барып керүе белән җылы вә мөлаем яңгыр явып, бөтен дөньяны яшәртеп, игеннәргә җан кертеп киткән. Һәркем Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә шөкерләр әйтеп сөенгән. Мәхәлләнең имамы Әшрәф бине Сәйфеддин (минем дәү абыем) моның кергән йортына барып күрешкән вә: «Мөбарәк килдегез, хәзрәт! Аллаһы Тәгалә безгә яңгыр бирде, бәлки, Сезнең бәрәкәтегездәдер дип шатланабыз!..» – дигән. Моңа каршы: «Сез уйламый әйтәсез! Безнең мортышлылар исә, Аллаһы Тәгалә безгә Хәлим карт шомлыгыннан яңгырны бирми торган икән, дип әйтерләр дигән уй күңелемә килде!..» – дигән. Бу сүзе күңеленең саф вә Аллаһы Тәгаләдән оялучы бер кеше булуына дәлил булыр. «Сезнең фатыйхагызда болай булды, Сез дога иттерсәгез, шулай булыр!..» – дип, үзлегеннән хөкем иткәннәргә каршы елмаепкөлеп вә гаять кәефе килеп рәхәтләнеп утыручылар илә дөнья тулган. Атасы Зәйнелгабидин дә, мәшһүр галимнәрдән булган хәлдә, тоз вә дегет сәүдәсе илә базарларда йөри торган булган. 1225/1810 елда вафат булуы сөйләнә.

### 215. Әмин бине Дәмин бине Мөхәммәдкол бине Бимәт бине Әҗи

Тау ягында Танай авылында имам булып, 1258/1842 елда // [471] вафат булган.

Угыллары: Мөхәммәдшаһ, Мостафа, Хәйдәр.

Диния Нәзарәтендә әгъза булып торган. 1826 елда ясалган формулярында «яше 34 тә дип язылган. Мөхәммәдҗан мөфти вафат булгач, мөфти вазыйфаларын башкарып торган. Габдессәлам мөфти килгәч, аның соравына күрә, тагын урынында калган. Хезмәт вакыты тәмам булгач, Казан шәһәрендә Барудия мәхәлләсенә имамлык өчен чакырсалар да, мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим-

нең каршы килүе сәбәпле, бу нияте тормышка ашмаган. Исәк авылында Әхмәд бине Бәхтияр исемле имамның Хөсни дигән кызын никах итеп, Хәбибулла бине Рахманкол вә Габделҗәббар казый бине Мөстәкыйм белән баҗа булган. Ягымлы, нәзакәтле, русчаны вә Русия тәртипләрен белүдә үзе кебекләрдән өстен булуы сөйләнә.

### 216. Һибәтулла бине Динмөхәммәд бине Бикмөхәммәд

Малмыж өязендә Салавыч авылында имам вә мөдәррис булып, 73 яшендә 1258/1842 елда вафат булган. Чыгышы Бөгелмә өязендә Динес авылыннан. Бохарага барып укыган, Кабул шәһәренә барып, Фәезхан бине Хозырханнан суфыйлык гыйлеме алып, бу якларга кайткач та суфыйлык белән шөгыльләнгән.

Остазлары: Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытый. Габделхаликъ бине Әгъзам әт-Тенеки һәм башкалар.

Шәкертләре: Ногман әл-Кырганый, Әхмәд бине Нигъмәтулла әт-Таузарый һәм башкалар.

Балалары: Гобәйдулла, Мифтахеддин, Минһаҗеддин, Сахибҗамал, Фатыйма, Хәдичә, Сара. Гобәйдулла атасы хозурында гыйлем алып, Сасна авылына имам булып, бераздан вафат булган. Галим вә тәкъва бер зат иде, фәкать гомере кыска булды, дип искә алалар. Мифтахеддин, атасы вафатыннан соң аның урынына имам булып калса да, алты елдан соң үзе дә вафат булды. Сахибҗамал Таузар имамы Нигъмәтулла никахында, Сара Бәләбәй өязендә Кырган авылының Ногман исемле имам никахында вафат булган[85]. // [473]

RUHIAT

### 217. Мөхәммәд бине Касыйм бине Диуан әш-Ширвани

1258/1842 елда Бохарада вафат булган. Асылы Ширван шәһәреннән булган хәлдә, бервакыт Казан шәһәрендә Коръән уку серләрен өйрәткән. Фазыйль, укуы хуш бер зат иде, диләр.

### 218. Габдулла бине Габделгафур

Әстерхан шәһәрендә имам вә өлкән казый дәрәҗәсендә булып, 1258/1842 ел ахырында вафат булган.

### 219. Габденнасыйр бине Гаед бине Рахманколый бине Исай бине Битә бине Боерган

Спас өязе Баллы Күл авылында имам булып, 1259/1843 елда вафат булган.

Остазы: Хәбибулла ишан бине әл-Хөсәен.

Уфада Диния Нәзарәтендә әгъза булып сайланып, ничә нәүбәттер шунда булды. 1239/1824 елда Уфа шәһәрендә туган угылына Казыйзадә дип исем кушып, әйткәнем гафу ителсен, һәм ләззәтсез, һәм мәгънәсез гамәлен мәйданга күрсәткән. Диния Нәзарәте кәгазьләре арасында 1815, 1817, 1821, 1822, 1824 еллар белән имзалары күренде. [Биредә Габденнасыйрның Әхмәд Хөсәен угылы белән Зә-

---

[85] Бу Сөләйман әфәнде әс-Саснавый вә Габделхак әфәнде әс-Саснавый хатларыннан алынды.

бәйдә Галиәкбәр арасындагы талак мәсьәләләрен караган хөкемнамәсе китерелә. Татар телендә, 1821 елның 21 августы һәм 13 декабренә карый] // [475]

**220. Сәгъди бине Максуд бине Әлмөхәммәд бине Исмәгыйль**

Златоуст өязендә Туймы авылында имам вә мөдәррис булып, 1259/1843 елда 84 яшендә вафат булган.

Остазлары: Сәйфелмөлек бине Мортаза бине Сәлим, Габденнасыйр бине Тумтай әл-Ирсайи, Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни булып, шәехләре // [476] Вәлид бине Мөхәммәделәмин әс-Сәгыйди, Котлыгәхмәд бине Заһид әд-Дусмәти.

Шәкертләре: Зәйнеддин бине Һашим әл-Иделбайи, Морадым бине Йосыф, Габделгаффар әл-Кыйгувый, Колмөхәммәд әт-Тугызлый, Мөхәммәдҗан бине Мәхмүд әл-Атавый, Ибраһим бине Мөхәммәдрәхим әл-Иделбайи, Шәрәфеддин әл-Юкәви, Сәедбаттал әл-Мөслими һәм башкалар. Вилдан исемле фазыйль бер угылы калды. Йомшак сүзле, мөлаем мәҗлесле, күркәм холыклы, аз йокылы, күп гыйбадәтле, дөрес гыйлемле, вәгъдәсенә тугры, сүзендә рас, кешегә сөйләгән нәсыйхәтләре илә үзе дә гамәл кылучы бер зат иде, диләр.

**221. Габделхаликъ бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд әл-Курсавый**

Әбеннасыйр Габденнасыйр әл-Курсавыйның бертуган абыйсы. 1259/1843 елда вафат булып, Курса зиратында // [477] күмелгән. Газизә исемле кызы Хәсән бине Хәмид әл-Курсавый никахында булган. Шәехе Әбү Салих Ниязколый бине Шаһнияз әт-Төрекмәни.

Шәкертләре: Хәсән бине Хәмид әл-Курсавый, Хәсән бине Сәлим әл-Әлдермеши һәм башкалар.

Бу мәмләкәт галимнәреннән беркадәр укыганнан соң, Бохарага барып, шәех Төрекмәни белән аралашкан. Тарикатьтә рөхсәт булганнан соң, Әбеннасыйр Габденнасыйр вә Габделкәрим исемле туганнары илә хаҗ сәфәренә киткән. Беркадәр Каһирәдә калып, голәмасыннан кыйраәт гыйлемен вә тәҗвид укыган. Бу якларга кайткач, Курса мәсҗиденә имам вә Әбеннасыйр мәдрәсәләренә мөдәррис булган. Кыйраәт гыйлеменнән остазы Диярбәкер мөфтие Әбүссөгуд әфәнде булып, башка фәннәрдән остазы туганы Әбеннасыйр булган.

Бу кеше хакында фазыйль Мәрҗани: «Изге, диндар, тәкъва иде, туганнары Әбеннасыйр – Искедарда, Габделкәрим – Каһирәдә, Габдеррәшид Бохарада вә үзе Курсада җирләнеп, бу дүрт кабернең бер-беренә ераклыгы Габбас Ибне Габделмоталлаб хатыны Өммелфазыл[86] угыллары каберләренең бер-беренә булган ераклыкларына охшады», – дигән. Вафатыннан соң, шәкерте вә кияве Хәсән бине Хәмид урынында имам вә тарикатендә дәвамчысы булган. // [479]

**222. Насреддин бине Зәйнеш әл-Калмыкый**

Бөре өязендә Калмык авылында шәехлек итеп, 1259 елның 10 рамазанында/1843 елның 22 сентябрендә вафат булган. 1206/1792 елда дөньяга килгән. Ис-

[86] «Мәшһүр хатыннар» китабында тәрҗемәи хәле бирелә. 71–76 б.

RUHIAT

ке Тазлар авылында Фәхреддин бине... мәдрәсәсендә укыганнан соң, Җәгъфәр ишан бине Габди тәрбиясендә ишанлыкка рөхсәт алган.

Дәвамчылары: Фәхреддин бине Мостафа әл-Әгерҗеви, Габделгафур ән-Наҗарый, Әрмәншаһ бине Әхмәди бине Габдеррәшид әс-Солтанай һәм башкалар.

Хатыннары: Гөлҗамал бинте Габдеррәхим, Гөлҗиһан бинте Биктимер, Зәйнәб бинте Габделҗәббар әл-Максуди. Баласы булмаган, нәселе дә калмаган.

Шәехе Җәгъфәр ишан хакында халык ике төркем булып, берсе шелтәләп, икенчесе мактаган кебек, моның хакында да ике төрле фикердә булганнар. Хәтта берара Бөре өязендәге галимнәр Диния Нәзарәте рәисе мөфти Габделвахид бине Сөләйманга шикаять тә язганнар.

Кабер ташында «Һуәл-хәййу әлләзи лә йәмут. Тарих 1259 да рамазан әл-мөбарәк 10 нчы көнендә әш-шәех мәүляна Насреддин мелла Зәйнеш угылы 53 яшендә рихләт итте» дип язылуы сөйләнә. // [480]

RUHIAT

## Беренче җилднең хатимәсе [ахыр сүзе]

Ошбу сигезенче кисәктә «Асар»ның беренче җилде [томы] тәмам булды. Тугызынчы кисәк илә икенче җилд башланыр. Безнең мәмләкәтебез вә хосусан безнең арабызда тарих вә тәрҗемәи хәл китапларын язу мөшкел икәнлеген, вә моның да беркадәр сәбәпләрен «Асар»ның беренче кисәгендә керештә сөйләгән идек, хәзер исә боларны бу җирдә кабат язуның хаҗәте юк. Авырлык белән язылган бу әсәргә кушар өчен беркадәр мәгълүмат язып күндергәч һәм дә язганнарыбызны укыган гайрәтле туганнарга җан вә күңелдән рәхмәт әйтү ләззәтле бер вазыйфабыздыр.

Фәкать язылган нәрсәләрдән бөтен халыкның риза булачагы мөмкин эшләрдән түгел. Дөньяның иң даһи язучылары язган нәрсәләре белән бер төркем халыкларны риза итә алсалар да, гомуми риза итә алмаулары мәгълүм. Хәл болай булганда, безнең кебек зәгыйфь каләм тотучылар язган нәрсәләре илә халыкны риза итү фикерендә булсалар, бер буш хыял белән алданган булырлар.

Нигездә без замандашларыбызга укыттырачак нәрсәләр язу максаты белән түгел, бәлки йөз вә мең, бәлки, миллион еллар соңында киләчәк буыннарга ядкәр калдыру нияте белән бу китапны язарга уйладык. Бу теләк эчендә булган ләззәтләрне үзләре тәҗрибә итмәгән затлар, ихтимал ки, кирәк дәрәҗәдә белмәсләр, әмма мин үзем моны исә бөтен дөньяга хуҗа булуга да фида итмәм.

*Ризаэддин Фәхреддин* // [481]

## Гомуми бер җавап

«Асар» кисәкләрен укучылар тарафыннан безгә бик күп хатлар язылып, кайбер искәрмәләребез тәнкыйть ителә, вә кайбер нәрсәләр турында тәфсыйльле хосусый җаваплар бирү сорала. Әгәр мөмкинлек булса, әлеге кешеләрнең хезмәтләрен үземә ярдәм сынап, аерым-аерым рәхмәтләр, кулымнан килгән кадәр ачык вә озын җаваплар күндерер идем, фәкать болай итәргә бу көнгәчә ирешә алмадым. Шуңа күрә бу юлы шушы гомуми бер җавап белән канәгатьләнергә мәҗбүр булдым.

Бер китап яки рисаләнең могтәбәр булуына әдәп вә фазыл әһеле тарафыннан тәнкыйть ителүе кадәр дөрес дәлил була алмас. Чөнки тәнкыйть өчен тәнкыйть ителәчәк әсәрне дикъкать белән уку, мөхәррирнең [авторның] мәсләге илә хаклык өчен таныш булу вә язылачак нәрсәләрнең дөрес булуы өчен күп кенә әсәрләргә мөрәҗәгать итү зарур була. Әһәмияте булмаган әсәрләр хакында мондый мәшәкатьләр гадәт ителмәс. Басылган әсәрләрне әһәмият бирмичә генә мактау яки гаепләү җиңел булган хәлдә, шартларын туры китереп тикшерү, тәнкыйть итү авыр бер эш икәнлеге һәркемгә мәгълүмдер.

Шул сәбәпле каләм хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өчен язган нәрсәләренең ысул вә кагыйдәсе өчен тәнкыйди тикшерелүен күрү кадәр ләззәтле башка нәрсә

булмас. Җыеп кына әйткәндә, каләм иясе булган адәм, үз эшендә никадәр кодрәтле булса да, хаклы тәнкыйтьне танырга тиеш. // [482] Матбугат дөньясында, әдипләр галәмендә тугры сүзгә хак бирү мөкатдәс бер вазыйфадыр.

Тәнкыйди тикшерү кагыйдәсе язу, «Адабе моназара» («Бәхәс әдәпләре») рисаләсе төзеләчәк булганга, бу җирдә аның буенча бәхәс ачуның кирәге юк, фәкать кайбер сәбәпләр ошбу җөмләне бу җирдә язарга безне мәҗбүр итә: «Шиксезлек һәм дәлиллек җәһәтенчә катгый булмаган бер дәлил илә чын күңелдән ышанулар нык булмас дәгъвасы кебек бер кешенең сүзе, кирәк Газзали, кирәк Ибне Рөшд кебек могтәбәр булсыннар, ялгызларның сүзләре илә тикшерелмәс. Инде Казан ягындагы шөһрәтле мөдәррисләрнең эндәшмәүләре белән тәнкыйть итү ни җирдә калды?! Дин өлкәсендә дәшмәүнең дәлил булуы бары шәригать сахибенә хас!»

Гыйлем ләззәтен белгән вә хакыйкать эзләү мәсләгендә булган кеше // [483] өчен хурлау, яла ягу капкаларын ачарга тузан кадәр дә ихтыяҗ юк. Чөнки инсаф даирәсе шулкадәр киң, һәрбер фикерне аңлату вә нинди генә булса да максатлары булу мөшкел булмас.

Бер дикъкать ителсен! Аллаһы Тәгалә, үзенең газиз бәндәләрен иң тәкәббер вә инсафсыз бер дошманына илче итеп җибәргәндә: «Барыгыз һәм дә йомшак вә гүзәл сөйләгез, шаять, инсафка килер, гыйбрәт алыр», – дип нәсыйхәт биргән.

Начар сүзләр вә шикаятьнамәләр һәрникадәр бер төркем ахмакларның бер сәгатьлек кәефләренә ярдәм бирсә дә, гакыл әһелләрен һичбер канәгатьләндермәс. Ошбу хикмәт өчендер ки аңлы затлар һәр белгәнен язмаслар вә күңелләренә килгән һәрнәрсәне мәйданга чыгармаслар. Юкса шәхсияткә тыкшынырга, көлеп, мәсхәрә итеп язарга кемнең кулыннан килмәс?..

Кабахәтлек һәм орышу-шелтәләшү мәсләгендә дәвам итүчеләргә каршы күркәм холык һәм инсанлыкның шушындый әдәп вә тәрбия әһелләре артыннан китүнең рәвешен күрсәтә алсам, үземне бәхетле санар идем. Фазыйләт белән өстен булуны теләгәннәрдән әдәп белән өстен булу – иң сөйгән бер максатымдыр.

Ризаэддин Фәхреддин.

Уфа. 20 рабигыль-ахир, 1322 (21 июнь, 1904)

RUHIAT

## Шәхесләр күрсәткече

Арыслан бине Туйчы бине Тәмә бине Иртуган – 74

Ахунд Хуҗа бине Маһим Хуҗа – 40

әл-Ашытый Мөхәммәдрәхим бине Йосыф бине Габделкәрим бине Арыслан бине Әбкә – 114

Әбелмәних бине Әбелфәез бине Габдессәлам бине Урай – 134

Әбелхәер Мөхәммәд бине Айрыш бине Ача бине Айчуак бине Бүләкәй бине Үсәк бине Әбү Сәгыйдь Җанбик хан – 39

Әбүбәкер бине Ибраһим бине Йосыф бине Ишбулад бине Ишморад – 64

әл-Әгерҗеви Җәгъфәр бине Әднакол – 124

әл-Әлмәни әл-Эчкени Габденнасыйр бине Сабит бине Сәфәргали – 210

әл-Әлмәни әл-Эчкени Фазыл бине Ибраһим бине Котлыгъәхмәд – 123

Әлмөхәммәд бине Сүкәй бине Айтуган бине Шаһйосыф бине Шәмәк – 34

Әмин бине Дәмин бине Мөхәммәдкол бине Бимәт бине Әҗи – 215

Әмир бине Нурмөхәммәд – 47

Әмирхан бине Кучкар бине Ягъкуб – 140

әл-Әндәлеси Әбү Хамид – 3

Әхмәд бине Хәсән бине Колмәмәт (Колмөхәммәд) – 96

Әхмәд бине Шәмседдин – 15

Әхмәджан бине Әмирхан бине Кучкар бине Ягъкуб – 100

Әхмәд Шиһабеддин бине Мөхәммәд бине Габдулла (Ибне Гарәбшаһ) – 22

Әхтәм бине Әхмәр – 108, [188а]

әл-Барышый Сәгыйдь бине Ибраһим бине Габдулла бине Габделгафур – 101

Баһадиршаһ бине Сәйяркол бине Габдеррәшид бине Ишбулад – 83

әл-Бәгъдади Әхмәд бине Фәзлан бине әл-Габбас бине Рәшид бине Хәммад – 1

әл-Бәгъдади Вәлиэддин бине Хәсән – 167

әл-Бәйрәкәви Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим – 213

әл-Бәрәскәви Бикчәнтәй бине Ибраһим – 76

әл-Биги Габденнасыйр бине Рәхманколый бине Мөхәммәдкол бине Габдеррахман бине Габделкәрим бине Бикхафиз – 186

Бикчәнтәй бине Җәгъфәр бине Мәсалим – 161

Биниәмин бине Йәһүд бине Балтач – 127

әл-Бирәзәви әл-Казаный Хәмзә бине Мөхәммәд бине Хәсән бине Җиһанмөхәммәд – 144

әл-Болгарый Ибраһим Борһанеддин бине Хәзир – 9

Болгарый Мөхәммәд – 13

әл-Болгарый Рамазан бине... – 99

әл-Болгарый Садир Әбү Мөхәммәд бине Галәведдин – 11

әл-Болгарый Хамид бине Идрис – 2

әл-Болгарый Хәсән бине Гомәр – 7

әл-Болгарый Ягъкуб бине Ногман – 4

Борһанеддин бине Шәриф бине Сөләйман – 145

әл-Борындыкый Мансур бине Габдеррахман бине Әнәс – 30

әл-Борындыкый Хөсәен бине Габдеррахман бине Әнәс – 55

әл-Бөрҗани Байым бине Динпакь – 109

RUHIAT

Вәис бине Хуҗаколый бине Йәмәк – 199
Вәлид бине Максуд бине Афак бине Дустмөхәммәд бине Байгура бине Тукгура бине Чукгура – 63
Вәлид бине Мөхәммәделәмин бине Сөләйман бине Бикмөхәммәд бине Азай – 81
Вәлид бине Сәгыйдь бине Фулад бине Әмин – 85
Вәли хан бине Аблай хан – 53
Габбас бине Габдеррәфигъ бине Юныс бине Муса бине Кучкар – 191
Габделвәһаб бине Габделмәҗид – 162
Габделвәһаб бине Габдеррәшид бине Ишкуат – 175
Габделҗәлил бине Габдеррәшид бине Мөэмин бине Мөслим – 129
Габделҗәлил бине Микәй бине Капкын бине Чапкын – 211
Габделҗәлил бине Мирсәлим бине Мәкаш бине Чунбай мирза бине Әлмөхәммәд мирза – 86
Габделҗәббар бине Габдеррахман бине Морадым бине Җиһанмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Ярмөхәммәд бине Нәзар бине Юныс бине Иванай – 151
Габделҗәлил бине Әбулай бине Йосыф бине Алтынбай бине Камыш би бине Урак би – 148.
Габделкәрим бине Балтай бине Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд – 41
Габделкәрим бине Хәлил – 93
Габделләтыйф бине Әдһәм бине Әбүбәкер бине Мүкәй – 164
Габделләтыйф бине Габдессәлам бине Уразмөхәммәд – 51
Габделләтыйф бине Чураш бине Чүәкәй бине Күгеш бине Күчмән – 194
Габделкадыйр бине Сөләйман бине Мостафа бине Юныс – 128
Габделмәннан бине Габдеррахман бине Туймөхәммәд – 48
Габделмөҗиб бине Габдулла бине Мөслим – 112
Габделхәлим бине Зәйнелгабидин – 214
Габденнасыйр бине Гаед бине Рахманколый бине Исай бине Битә бине Боерган – 219
Габденнасыйр бине Торымтай – 92
Габдерраззак бине Ишмөхәммәд бине Тәйми – 42
Габдеррахман бине Туймөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Янбулат бине Ягъкуб бине Симән бине Илаз бине Габдулла бине Бикчура хан – 43
Габдеррәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым – 182
Габдеррәшид бине Йосыф бине Кадермөхәммәд бине Бикмөхәммәд бине Тәтеш – 44
Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд – 65
Габдеррәшид бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Мәмат (Мөхәммәд) бине Нурмөхәммәд бине Бисуфый бине Муса бине Мәмәт бине Хәмадиш бине Үдәмиш бине Хөсәен бине Җәгъфәр – 73
Габдеррәшид бине Мөхәммәд бине Габдулла бине Колмөхәммәд бине Акмөхәммәд бине Үтәш суфый бине Урманче – 154
Габдессаттар бине Сәгыйдь – 155
Габдессәлам бине Габдеррәхим бине Габдеррахман бине Мөхәммәд – 200
Габдессәлам бине Мортаза бине Максуд бине Габдеррәхим – 138
Габдессәлам бине Хәсән – 46
Габдессәлам бине Хәсән бине Кадермәт (Кадермөхәммәд) бине Теләнче бине Байгилде бине Туеш – 57

RUHIAT

Габдессәлам бине Уразмөхәммәд (Урай) бине Колмөхәммәд бине Колчура бине Колаб – 37

Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай бине Мәмәт (Мөхәммәд) бине Акман бине Илкәй бине Дулаҗан бине Әюб шәех бине Хуҗа шәех бине Юллык шәех – 87

Габделхәмид бине Үтәгән бине Ярмөхәммәд бине Котлыгмөхәммәд бине Мөхсин – 84

Габдулла бине Габделгафур – 218

Габдулла бине Мөслим бине Гали бине Әлмөхәммәд бине Чуенчал мирза бине Дәвеш мирза – 67

Габдүш бине Габдессәлам бине Исмәгыйль бине Нурмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Рысмөхәммәд баба – 110

Гарнати Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Габдеррәхим бине Сөләйман – 5

Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим – 126

Госман бине Рәхмәтулла – 163

Әд-Дагыстаный Мөхәммәд бине Гали (Казакай ахун) – 68

Дәүләтбакый бине Галиеләсгар – 209

Дәүләтшаһ бине Гаделшаһ бине Габдулла бине Богдан – 174

әд-Динеси Габид бине Дәүки бине Заһид – 173

әл-Җәбәли Әбүбәкер бине Йосыф бине Ильяс – 157

әл-Җәбәли Шәмседдин бине Миңле бине Габдулла – 195

Җәгъфәр бине Габди бине Исхак бине Котлыгмөхәммәд бине Нәриман – 132

Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт бине Әлмәт бине Алыш – 69

Җәгъфәр бине Имай – 82

әл-Җәнди Әхмәд бине Мәхмүд – 10

Заһиди Мохтар Әберриҗа Нәҗмеддин бине Мәхмүд бине Мөхәммәд – 6

Зәйнеддин бине Һашмм бине Теләкәй бине Байкара бине Нурдәүләт бине Толъяр – 168

Ибне Батутта – *кара:* әт-Тәнҗи Мөхәммәд

Ибне Бәззаз – *кара:* Мөхәммәд Хафизеддин

Ибне Гарәбшаһ – *кара:* Әхмәд Шиһабеддин – 22

Ибне Фәзлан – *кара:* әл-Бәгъдади Әхмәд – 1

Ибраһим бине Габдулла бине Габделгафур – 52

Ибраһим бине Мөхәммәдтүләк бине Бикмөхәммәд – 35

Ибраһим бине Хуҗаш – 139

Иванай бине Усай – 26

Искәндәр бине Гали бине Ает (Гаед) бине Хөсәен бине Хәсән бине Туйкилде бине Илтимер бине Биктимер бине Аксәед бине Имин бине Байтөгәл бине Алдыргыш бине Әлкәш би бине Өс би (Әлкес би) – 171

Исмәгыйль бине Бикмөхәммәд – 45

Исмәгыйль бине Габид бине Габдулла бине Мөслим бине Бикбулат бине Ишкенә бине Ишбулат бине Шаһфулад – 147

Исхак бине Габделкәрим бине Балтай – 77

Ишбулат мелла – 36

Ишемхуҗа бине Дәүләтбирде – 153

Ишмөхәммәд бине Заһид бине Бикмөхәммәд бине Әлмөхәммәд бине Өлеш бине Колыш бине Теләш бине Кызылбай бине Урманчы бине Чытырман бине Аяз бине Бишмәт – 207

RUHIAT

Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд (Тәмәт) бине Нияки бине Төнләче бине Сабырхуҗа бине Йәмаш бине Бәраш бине Байтөгәл бине Габдерраззак бине Сардак бине Йәмин – 31
Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд – 60
әл-Иштирәки Таҗеддин бине Габдеррәшид бине Мортаза – 206
Йосыф бине Иманкол – 189
Йосыф Җәмаледдин бине әл-Хәсән бине Мәхмүд – 19
әл-Йулыкый Зәйнелгабидин бине Габдулла бине Ярмөхәммәд – 165
әл-Казаный Габделвәли бине Сәгыйдь бине Әхмәд бине Мөхәммәд – 102
әл-Казаный Касыйм бине Ибраһим – 23
әл-Казаный Мостафа бине Муса бине Иманкол бине Иманай бине Котлыг бине Үзбәк бине Буҗак бине Әлкәй – 183
әл-Калмыкый Насреддин бине Зәйнеш – 222
әл-Карамалый Мәгаз бине Бикмөхәммәд – 169
әл-Караный Рауил бине Габделвахид бине Сәлим бине Ишмөхәммәд – 193
әл-Кенәри Габид бине Габделгазиз бине Гайсә – 179
әл-Кенәри Фәез бине Габделгазиз бине Гайсә – 188
әл-Кили Салих бине Сәгыйдь бине әл-Хәсән – 136
әл-Кирмәни Габдеррахман бине Мөхәммәдшәриф – 143
Котлыәхмәд бине Заһид бине Габделмәннан – 152
әл-Курсавый Габделхаликъ бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд – 221
әл-Курсавый Габденнасыйр Әбеннасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк – 98
әл-Курсавый Габдессәлам бине Габдеррахман бине Габделгазиз бине Рәфыйк – 120
әл-Курсавый Рәфыйк бине Таиб – 32
әл-Лажый Исхак бине Сәгыйдь бине Йортбагыш бине Колмөхәммәд бине Ишмөхәммәд – 185
әл-Мамалавый Нуреддин бине Мөхәммәд бине Төхфәтулла бине Зәбир – 203
әл-Мәргыйнани Гыйсамеддин бине Габделмөлек – 21
әл-Мәрҗани Габделкәрим бине Габдеттәүуаб бине Габделгани бине Габделкоддус – 59
әл-Мәрҗани Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүуаб бине Габделгани – 176
Мәсгудь бине Бинейәмин – 72
Мәүлед бине Мостафа бине Юныс – 119
Мәхмүд бине Мөхәммәделәмин бине Ярмөхәммәд бине Мамыш (Мамәш) – 97
Миңлеакай бине Хаҗиморад бине Дуенкилде – 71
Морадбакый бине Ишали бине Ишмөхәммәд бине Йосыф бине Сөләйман – 104
Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд – 70
Мортаза бине Гали бине Йосыф – 38
Мостафа бине Биктимер бине Дәүләтъяр – 142
Мостафа бине Әхмәр бине Мансур – 187
әл-Мөндеши Мостафа бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мәмәтәй бине Таутик – 172
Мөхәммәд бине Хәмид бине Мортаза – 190
Мөхәммәделәмин бине Сәйфулла бине Габделхәмид бине Динмөхәммәд бине Шыгай – 177

RUHIAT

Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Габдеррахман – 133
Мөхәммәдкол бине Табай – 54
Мөхәммәд бине Хафизеддин бине Мөхәммәд бине Шиһабеддин Йосыф (Ибне Бәззаз) – 20
Мөхәммәдхәнәфия бине Салих бине Сөлүк бине Бикчура бине Бикәй бине Җанъегет бине Җаник бине Балтач бине Ябынчы – 146
Мөхәммәдшаһ бине Мирас – 208
Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман бине Чикә бине Бимәк суфый – 50
Мөхәммәдъяр бине Габдулла бине Мөслим – 111
Мөхсин бине Сәфәр бине Юныс бине Иванай – 56
Нәриман бине Сөләйман бине Мостафа – 131
Нигъмәтулла бине Максуд – 204
Нигъмәтулла бине Рәхмәтулла бине Иманкол бине Рахманкол – 105
Нигъмәтулла бине Хәбибулла бине Габделмән бине Аккуҗа – 205
Нургали хан бине Әбелхәер хан бине Ага – 61
Рәхмәтулла бине Габдүш бине Ишмән – 196
Сабанчы бине Богай – 75
әс-Сарайи Ибраһим Минһаҗеддин бине Сөләйман – 14
Сафкол бине Котый бине Килмәк – 180
әс-Сәгыйди Габдеррәшид бине Габделкәрим – 107
Сәгъди бине Максуд бине Әлмөхәммәд бине Исмәгыйль – 220
Сәгыйдь бине Әхмәд бине Хөсәен – 158
Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали – 135
Сәйфелмөлек бине Мортаза бине Сәлим бине Исмәнән – 79
Сәйфеддин бине Хәлил бине Дөрәс баба – 202
Сәлим бине Габдеррәхим – 89
Сәлим бине Рәхимкол бине Урман бине Капкай бине Юлай бине Колай бине Сөләйман бине Тимери бине Рәми бине Ихсан – 117
Сәлимҗан бине Дустмөхәммәд – 49
әс-Симети Мортаза бине Котлыгыш – 29
Сөбханкол бине Бикмөхәммәд бине Юлдаш бине Ишкәй бине Түмкәй бине Янгилде бине Кайбула бине Кормыш – 90
Сөләйман бине Мостафа бине Юныс (Сүнәй) бине Ишали бине Ишанмыш бине Ханмирза бине Хантимер бине Каракай – 95
Таҗеддин бине Ялчыгол бине Мәмәткол бине Янтимер бине Җәянчура бине Котлыгбулат – 198
әт-Тарауый Ибраһим бине Габдеррәшид бине Ибраһим бине Габдеррәхим – 181
Таиб бине Уразай бине Имкәй бине Бимкәй – 115
әт-Талкышый Әмирхан бине Габделмәннан бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт бине Әхмәд бине Җәлмәт бине Гәрәй – 149
әт-Талкышый Сәфәр бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт (Кадермөхәммәд) бине Әхмәд бине Җәлмәт бине Гәрәй – 121
әт-Тәнҗи Мөхәммәд Әбү Габдулла бине Габдулла бине Мөхәммәд бине Ибраһим (Ибне Батутта) – 16
әт-Тәхтани Мөхәммәд Котбеддин бине Мөхәммәд әр-Рази әш-Шафигый – 12
әт-Тенеки Габделхаликъ бине Әгъзам бине Габдеррахман – 78

RUHIAT

әт-Түнтәри Муса бине Габдеррәшид бине Үтәгән бине Ярмөхәммәд бине Котлыгмөхәммәд бине Мөхсин – 106
әт-Түнтәри Хөснеддин бине Бәшир – 212
әл-Утарый Нигъмәтулла бине Гомәр – 113
Үзбәк бине Сөбханкол бине Мостафа – 122
Үтәгән бине Уразмәт – 88
Фазыл бине Сәйфулла бине Хәбибулла – 94
Фазлулла бине Габделмәннан бине Габдеррахман – 66
Фәйзулла бине Габбас бине Мөэмин бине Мөслим – 125
Фәйзулла бине Госман – 201
Фәхреддин бине Габдеррәшид бине Гаед – 80
Фәхреддин бине Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәд – 159
Фәхреддин бине Сөбханкол бине Бикмөхәммәд – 118
Хәбибулла бине Әлхөсәен бине Габделкәрим – 116
Хәмзә бине Ишкуат бине Баеш – 150
Хәмид бине Ислам бине Нурмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Рысмөхәммәд – 141
Хәмид бине Мортаза бине Нурмөхәммәд – 91
Хисамеддин бине Шәрәфеддин – 24
Хөҗәнди Мәсгудь Кәмаледдин – 17
Хөсәен бәк бине Измир бәк – 8
Хөсәен бине Габделкәрим бине Ярмөхәммәд бине Янсарый бине Байсарый – 58
Хуҗашөкүр бине Гаузбай – 27
Һибәтулла бине Динмөхәммәд бине Бикмөхәммәд – 216
Шаһиәхмәд бине Рәфыйк бине Габделмөэмин бине Хөсәен әс-Симәки – 192
әш-Шашый Мөхсин бине Биккол бине Ибраһим – 166
Шәмседдин бине Габдеррәшид бине Гаед – 62
Шәмседдин бине Габдеррәшид бине Госман бине Габделкадыйр – 170
Шәмседдин бине Дәванай бине Мәмбәт суфый бине Сөләйман бине Колмөхәммәд бине Кадербирде бине Бикмәт абыз – 130
Шәфи бине Гали бине Орыс бине Шыгай бине Янгураз бине Байчура – 160
әш-Шәфигый әт-Тәфтазани Мәсгудь Сәгъдеддин бине Гомәр – 18
әш-Ширвани Мөхәммәд бине Касыйм бине Диуан – 217
әш-Ширвани Мөхәммәд бине Муса әл-Каддәкый – 28
әш-Шыңарый Сәйфеддин бине Әбүбәкер бине Сәлим – 137
әл-Шырданый Габделгаффар бине Сәгыйдь – 156
әл-Чалпыуый Габделкәрим бине Габдулла бине Солтан – 103
әл-Чокалый Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза – 178
Юныс бине Ибраһим – 184
Юныс бине Иванай бине Усай – 33
Янсарый бине Хафиз бине Байсарый бине Килдеш бине Килуаз – 25
Яхъя бине Сәфәр бине Арыслан – 197

RUHIAT

## Географик атамалар күрсәткече

Агыйдел елгасы – 117
Адай (авыл, Малмыж өязендә) – 31, 84, 140, 187
Аерыкүл (авыл) – 119
Азалак (Минзәлә өязендә) – 57
Азау (Азов) диңгезе – 29, 145
Азия – 181, 200
Акбаш (Уфа өязендә) – 95
Акмәт Әхмәт (авыл, Спасс ягында) – 73
Аклуш (Уса өязендә) – 127
Акъегет (авыл) – 139
Алабуга – 126, 189
Алма-Ата – 175
Алты Ата (авыл) – 122
Амасия (шәһәр) – 137
Амударья елгасы – 213
Анатолия – 139
Анафа (шәһәр) – 111, 112, 118
Арал диңгезе – 213
Арбаш (авыл) – 179,194, 206
Арыслан (авыл) – 98, 117, 132
Аты (Түбән Аты) – 162
Атҗитәр – 133
Африка – 16
Ахун (авыл) – 139, 112, 62, 86
Ашыт – 158, 114, 166, 178
Ашытбаш (авыл) – 183
Ачулы (авыл) – 112
Әдернә – 22
Әҗәк (авыл) – 200
Әй елгасы – 198, 206
Әлдермеш – 91
Әлҗаксай (шәһәр, Дагыстанда) – 198
Әлкәй (авыл) – 118
Әлмән (Чиләбе өязендә) – 123, 75, 210
Әлмәт – 43, 60, 206
Әндәлес (Андалузия) – 3, 5, 16, 182
Әстерхан (Хаҗитархан) – 20, 21, 22, 29, 71, 133, 139, 98, 198, 200, 218
Әфганстан – 182
Әхмәт Абыз (авыл) – 43
Байбулай (авыл, Минзәлә өязендә) – 193
Байым (авыл) – 109
Бакырчы – 139
Баллы Күл – 219
Балтай – 195
Балтач (Уса ягындагы авыл) – 65
Балыклы (Казан өязендә) – 187
Балыклы Күл (авыл) – 174, 200
Барыш (Тау ягында авыл) – 52
Басра – 182, 45
Баулы – 207
Бәгъдад – 1, 4, 6, 25, 29, 167
Бәйрәкә – 54, 118, 171, 187, 194, 213
Бәйрут – 181

Бәкер – 175
Бәләбәй – 123, 193, 200
Бәлх – 41, 182
Бәрәскә – 114, 74, 76
Бәрәңге (авыл) – 185
Бәрсуан (Уфа янында) – 206
Бәхтияр (авыл) – 179
Бигәш – 154
Биги (авыл) – 186
Бизнә – 38, 139
Бикбау (авыл, Минзәлә өязендә) – 57
Бикмәт (авыл, Бәләбәй өязендә) – 193
Иске Бикмәт (авыл, Бөре өязендә) – 82, 128
Биләр – 31, 139
Бинарис (шәһәр) – 45
Бирәзә – 144, 197
Битрәндә (шәһәр) – 24
Биш Курай (Уфа өязендәге авыл) – 63
Бишмунча – 154
Богады – 146
Богдан (авыл, Бөре өязендә) – 174
Богырослан (шәһәр) – 175, 194, 200
Бозаулык (шәһәр) – 200
Болгар – 1, 3, 4, 5, 7, 22, 28, 31, 35, 76, 81, 98, 99, 139, 167, 173, 181, 201
Борындык – 30, 55
Бохара – 7, 8, 30, 41, 45, 67, 81, 89, 94, 98, 99, 102, 111, 114, 116, 118, 120, 123, 132, 133, 137, 139, 144, 147, 149, 155, 156, 157, 164, 166, 167, 169, 170, 172, 174, 182, 183, 185, 187, 188, 189, 190, 192, 195, 200, 202, 203, 206, 209, 212, 213, 216, 217, 221
Бөгелмә – 60, 117, 171, 173, 182, 187, 188а, 194, 200
Бөгелчән җире – 194
Бөре (шәһәр) – 174, 200
Бөстам – 29
Бубый – 93, 128
Буеч (авыл, Минзәлә өязендә) – 200
Буклавыч (авыл) – 76
Бүкәй иле – 133
Бүре Казган (авыл, Эстәрлетамак өязендә) – 174
Вәрәш Мөслим (авыл, Минзәлә өязендә) – 174
Верхурал (шәһәр) – 67, 68, 86, 200, 207
Вологда – 182
Вятка (шәһәр, губерна үзәге) – 192, 206
Габдрахман – 200, 90
Габдрахман (Степное Белое озеро) – 205
Габдеррәшид (авыл) – 165
Газмин (шәһәр) – 6
Гали (авыл, Богырослан өязендә) – 104, 200
Гарәбстан – 206
Гарәфә – 29
Гәйнә иле – 124
Гыйрак – 16, 29, 133
Дагыстан – 29, 31, 67, 68, 114, 123, 139, 140, 198, 201
Дамган (шәһәр) – 29
Дәшти Кыпчак (Алтын Урда) – 17, 67
Димәшкъ – 22,107
Динес (авыл) – 173, 216

RUHIAT

Диҗлә (елгасы) – 29
Диярбәкер (шәһәр) – 29,139,198
Дөбъяз – 110
Дусмәт (авыл, Оренбург ягында) – 152
Европа – 16,29
Еланлыклы – 212
Ендовище (авыл, Сергач өязендә) – 197, 211
Җаек (авыл) – 200
Җаек елгасы – 43, 167
Җәйхун (елга) – 29
Җиддә – 172
Зәй елгасы – 43, 57, 117, 200
Золотой (пристань, Саратов ягында) – 110
Зыябаш (авыл) – 157, 174
Идел елгасы – 8, 12, 22, 27, 110, 180, 206
Иделбай (авыл, Уфа өязендә) – 168
Ик елгасы (Оренбург губернасы) – 169
Иләк (шәһәр, Оренбург губернасы) – 174
Ильяс (авыл, Малмыж өязендә) – 205
Исәнтимер – 126
Ислай (авыл, Чистай өязендә) – 182
Илмәт (авыл, Алабуга өязендә) – 126, 189
Иманкол – 209
Имән Кискә – 139
Имәнлебаш (авыл, Минзәлә өязендә) – 198
Инсар (шәһәр, өяз үзәге) – 197
Ирсай (Бәләбәй ягындагы авыл) – 92
Иса (авыл, Инсар өязендә) – 197
Иске Әлмәт (авыл, Минзәлә өязендә) – 43, 46
Искәндәрия (Александрия) – 29, 105, 106
Иске Иштирәк (авыл) – 50, 206
Иске Кенәр – 136
Иске Кишет – 101
Иске Мастак (Саратов губернасы Хвалын өязендә) – 96
Иске Сәлман – 126
Иске Тазлар – 222
Иске Уфа – 61
Истанбул – 29, 45, 98, 110, 111, 113, 118, 123, 134, 182, 198, 200, 201, 202
Исфаһан – 29
Иштирәк Бәкер – 206
Йәмән – 16, 28
Йөзкәй Тәкермән (авыл, Минзәлә өязендә) – 43
Йөргән (авыл) – 117
Йулык (авыл) – 67, 112, 117, 164, 165
Йуртыш – 141, 180
Кабил (Әй буендагы авыл) – 206
Кабул – 81, 111, 113, 116, 132, 133, 137, 144, 164, 167, 169, 172, 183, 188, 189
Кавал – 110, 48
Кавказ – 133
Каҗмакты (авыл, Уса ягында) – 83, 148
Казаклар (Казан өязендәге авыл) – 52, 58
Казаклар Орысы (Царевококшай округы) – 98
Казан – 23, 26, 28, 36, 43, 44, 57, 62, 64, 68, 69, 77, 83, 86, 87, 91, 94, 97, 98, 113, 126, 132, 133, 136, 139, 140, 144, 151, 155, 156, 157, 158, 159, 160, 161, 162, 166, 167, 172, 174, 177, 178, 179, 180, 182, 183, 185, 186, 187, 188, 190, 191, 197, 198, 200, 202, 205, 206, 207, 210, 215, 217

RUHIAT

Казакъстан – 39, 68
Казанбаш (авыл, Казан өязендә) – 161
Казан ханлыгы – 33, 35
Казарма (авыл, Уфа ягында) – 95, 128
Каинский (Сибириядә) – 202
Кайбыч – 80
Какчырлы (авыл, Чиләбе өязендә) – 184
Калкаш (авыл) – 174
Калмык (авыл, Бөре өязендә) – 222
Калтай (авыл, Уфа ягында) – 119
Калькутта – 22
Камы Исмәгыйль (авыл) – 73
Кандаһар (шәһәр) – 45
Копал – 206
Карагай (Җаек елгасы башындагы авыл) – 43
Кара диңгез – 16, 29, 133, 137, 179
Караком – 213
Карамалы – 214
Каран (авыл, Минзәлә өязендә) – 66, 193
Каратай (Бөгелмә өязендәге авыл) – 70
Каргалы (Сәгыйдь бистәсе) – 37, 41, 44, 45, 51, 60, 77, 81, 85, 96, 98, 107, 117, 118, 122, 123, 128, 133, 134, 142, 143, 167, 169, 186, 191, 200
Каргалы (авыл, Чистай өязендә) – 181
Каргалы елгасы – 68, 117
Кариле – 91, 179, 194
Кармасан елгасы – 95, 128
Кара Үткәл – 209
Каршин Шәриф (авыл) – 95, 128
Карча Елга – 206
Каспий диңгезе – 28
Касыйм (Ханкирмән) – 123, 164
Каурамич (Бәлх вилайәтендә) – 182
Каһирә – 16, 22, 81, 114, 170, 177, 201, 207, 221
Кәкре Елга (авыл, Мәллә елгасы башында) – 57
Кәлибула – 29
Кәрәкәшле – 213
Кәрминә (шәһәр) – 23
Кәшан (шәһәр) – 29
Кәче – 26
Кенә (авыл) – 206
Кенәр (авыл, Казан өязендә) – 179, 185
Кече Елга (авыл) – 139
Кече Урда – 207
Кече Сөн (авыл, Мамадыш өязендә) – 198
Киекле (авыл, Чистай өязендә) – 189
Киекле Бурмәт (Чирмешән елгасында) – 65, 90
Кизләү – 69, 94, 126
Килат (шәһәр) – 45
Килем (авыл, Бәләбәй өязендә) – 200
Кили – 136
Киме – 74
Кинәле елгасы – 43, 194
Кирмәншаһ (шәһәр) – 29
Кичү елгасы – 57, 90
Кичүчат – 90, 118, 132, 206

RUHIAT

Кишет – 62, 139, 158
Коддес (Иерусалим) – 45
Козгын Әхмәр (авыл, Верхурал өязендә) – 200
Колай – 133
Калтай (авыл) – 128
Колшәриф (авыл, Богырослан өязендә) – 194
Колшәриф (Зәй елгасы буендагы авыл) – 154
Копал шәһәре – 104
Кондыр (авыл) – 117
Кондырау (Сакмар буенда авыл) – 68
Коры Алачык (авыл) – 79
Кошман – 154
Көндәшле (авыл) – 47
Көек – 110
Көшкәтбаш – 206
Көрдестан – 29
Көтернаҗ (авыл) – 42
Куакбаш (авыл) – 182
Куганак (авыл) – 174
Кузнецк (шәһәр, өяз үзәге) – 200
Куртуба (Кордова) – 182
Курса – 32, 46, 94, 174, 221
Куфә (шәһәр) – 182
Күбәк (авыл) – 31, 207
Күбәкәй (авыл, Чиләбе өязендә) – 182
Күгәрчен – 213
Күкчә-Бирәзә (авыл) – 139
Күккуян (Бөре өязендәге авыл) – 204
Күк Каен (авыл) – 143
Күҗәкә (авыл) – 43
Күлтәс – 206
Кызлар – 46
Кызылҗар (Петропавел шәһәре) – 123
Кызыл Чапчак – 100
Кыйгый (казакъ) – 206
Кыр Бикүле – 204
Кырган (Бәләбәй өязендә) – 216
Кыргыз Миякә – 200
Кыргыз Урдасы – 200
Кырмыскалы (авыл) – 37, 63
Кырык Садак – 110
Кырым – 16, 20, 22, 137, 180
Кыска Елга (авыл, Бәләбәй ягында) – 90
Кытай – 16
Кышкар – 70, 101, 137, 170, 174, 188
Лаж (авыл, Бәрәңге ягында) – 185
Лейден – 22
Максабаш – 98
Малмыж – 98, 121
Мамадыш – 29
Мәвараэннәһер – 23
Мәдинә – 4, 29, 45, 81, 111, 118, 131, 134, 143, 172, 182
Мәзриб – 29
Мәкәрҗә – 111, 133, 137, 198, 155
Мәккә – 4, 29, 45, 110, 118, 134, 143, 172, 182

RUHIAT

Мәл (авыл, Гәйнә илендә) – 124
Мәлем – 46, 198
Мәмәк – 131
Мәмәш – 174
Мәмдәл – 110, 160
Мәмсә – 94, 106, 205
Мәңгәр (Олуг Мәңгәр) – 37, 110, 147, 180
Мәрвишаһҗиһан (шәһәр, Фарсы вилайәтендә) – 29
Мәрҗан – 59
Мәскәү – 117, 198, 200
Мәүсыйль (шәһәр) – 29
Мәчкәрә – 84, 98, 114, 200, 205
Мерәс (авыл, Эстәрлетамак өязендә) – 182
Мечтәй (авыл) – 200
Минзәлә – 117, 125, 174, 192, 193, 196, 198, 200
Минзәлә елгасы – 43
Минзәләбаш – 85
Мирас (авыл) – 132
Мисыр – 16, 29, 133, 140, 170, 177, 182, 201
Мишһәд – 29
Мортаза (авыл, Бөре төбәгендә) – 95
Мортышбаш – 154, 214
Мортыштамак – 43
Мостафа – 117
Мөндеш – 172, 183
Мөслим – 67, 125, 129, 138
Мөэмин (авыл) – 194
Муса (авыл, Хвалын өязендә) – 190, 194
Наласа – 87, 105, 177, 194, 202
Нәдер (Надир) – 57
Нәсеф (шәһәр, Урта Азия якларында) – 202
Нәсыйбин (шәһәр) – 29
Нижний Новгород – 95
Нил – 29
Нисабур (Нишапур) – 4, 29
Нократ авылы – 52
Норма – 103, 206
Носы – 206
Нөнәгәр – 206
Нөркәй – 85
Нугай (авыл) – 117
Олуг Яке – 176
Олы Кавал – 110
Оренбург – 1, 35, 43, 61, 77, 90, 95, 114, 117, 122, 123, 128, 133, 167, 174, 180, 186, 191, 200, 207
Оренбург вилайәте – 67, 164, 167, 169, 207, 213
Ор шәһәре (Орск) – 39
Орнашбаш – 151, 164, 179
Оры – 25, 33, 56, 58, 98, 133, 184, 206
Өлге – 191
Париж – 16
Пәчек – 139
Пермь – 132, 199, 200
Петербург – 97, 107, 133, 181, 182
Петропавел – 98, 207

Портнур – 44, 141
Пүкәл – 164
Рәдүд (авыл, Оренбург өязендә) – 191, 211
Рәшид (шәһәр) – 29
Рим – 200
Родос – 29
Рум иле – 20, 29
Русия – 8, 23, 39, 44, 53, 57, 58, 87, 133, 167, 200, 215
Саба (Олы Саба) – 65, 76, 87, 89, 118, 125, 127, 128, 137, 164, 175
Сабабаш – 98
Саз (авыл, Пермь губернасы) – 199
Сакмар елгасы – 37,68
Сакыз – 29
Салавыч (Иске Салавыч) – 84, 87, 192, 216
Самара – 1, 8, 192
Сарай (шәһәр) – 6, 10, 12, 14, 15–22
Сарайлы (авыл) – 117
Саратов – 110
Сарлы – 108, 188а
Сарыбиккол – 65, 182
Сасна – 100, 121, 140, 194, 206, 216
Сатыш – 65
Сәбезвар (шәһәр) – 29
Сәгыйдь – (*кара:* Каргалы)
Сәмән (авыл, Уфа янында) – 29
Сәмәркәнд – 8, 15, 18, 21, 22, 98, 182, 200, 202
Сәмнан (шәһәр) – 29
Сәрде – 185, 205
Сәрхәс (шәһәр) – 18
Сәфәр – 95, 128, 132
Себер – 123, 181, 182
Сембер – 73, 121, 122, 206
Сембер вилайәте – 207
Семипалат (Сими) – 42, 114, 139, 188
Сибирия – 25, 27, 209
Сивас (шәһәр) – 139
Симәк – 192
Симет – 29
Синоп (шәһәр) – 16
Сок елгасы – 57
Солтанай – 95, 119
Солтанкол авылы (Кинәле елгасы буенда) – 43
Сөрде – 110, 141
Сүрия – 133
Сугышлы – 90
Тайсуган – 43, 48, 66, 104, 200
Такталачык – 192, 196
Талкыш – 121, 206
Талпазы – 204
Танай – 215
Тара (шәһәр) – 123, 181, 182, 209
Таузар – 216
Таулар – 207
Тау ягы – 30, 57, 186, 195, 199, 204
Тахта (шәһәр) – 202

RUHIAT

Ташбилге – 24
Ташкент – 200, 209
Ташкичү – 37, 120, 170
Ташлыяр – 114
Тәбриз (шәһәр) – 17,19
Тәнҗә (шәһәр) – 16
Тәрсүк (Шадрин өязендә авыл) – 210
Тәтер суы – 117
Тәтеш – 200
Тенеки – 206
Тенеки Сабасы – 78
Тибет – 133
Тимәч – 153
Тимошка – 132
Тимәш – 82
Тимеркә – 108, 188а
Тимерче – 155
Тимершәех – 149
Тобол – 27, 98, 181, 209
Тобол вилайәте – 207
Том – 202
Торналы – 202
Төреш – 92
Төрек (авыл, Казан өязе) – 149
Төркестан – 8, 16, 182
Төркия – 90, 140
Трабзон (шәһәр) – 179
Туйгилде – 138
Тукай (Эстәрлетамак өязендә) – 169, 200
Тройски (шәһәр) – 67, 98, 123, 175, 184, 198, 200, 206, 207, 208
Тугыз (авыл) – 75
Туймы (Златоуст өязендәге авыл) – 220
Турай (Кодаш елгасы буендагы авыл) – 150
Тус – 29
Түбән Иши – 155
Түбән Мактама – 65
Түбән Сәрде (Олуг Сәрдә) – 163
Түбән Шәлчәле (Түбән Чыршылы) – 47, 90
Түнтәр – 42, 48, 106, 206
Уразбакты – 200
Урал (тау, вилайәт) – 12, 22, 57, 164, 210
Уральски – 200
Урбар (Арбор) авылы – 52, 88
Уржум – 206
Урсай – 200
Урта Азия – 33
Урта диңгез – 29
Үршәк елгасы – 119
Урыссу – 171, 194
Ус (Болгар дәүләтендә) – 73
Уса (шәһәр) – 132
Усы (Минзәлә өязендә) – 115
Утар – 113, 206
Утыз Имән – 182

RUHIAT

Уфа – 8, 29, 39, 47, 53, 61, 62, 64, 67, 76, 80, 85, 98, 119, 128, 132, 133, 139, 145, 160, 161, 168, 173, 180, 181, 182, 187, 192, 202, 200, 219
Уфа вилайәте – 46, 67, 207
Ушма авылы – 58, 98, 138, 140
Үзен елгасы – 168
Үрә – 158
Үргәнеч (Яңа Үргәнеч) – 60, 61, 200, 213
Үркәй – 200
Үрге Оры – 95, 111, 116
Үтәк (авыл, Эстәрлетамак ягында) – 101, 137, 140
Форат (Евфрат) елгасы – 29
Хаҗитархан – (*кара:* Әстерхан)
Хан түбә (Әстерхан янында) – 40
Хәйдәрабад – 45
Хәлеб (шәһәр) – 29
Хәрәзем – 1, 6, 20, 39, 45, 213
Хәрәмабад (Солтанай) (Уфа ягындагы авыл) – 133
Хәсәншәех – 52, 194, 206
Хвалын – 191
Хива – 29, 57, 98, 200
Хиҗаз – 134, 183, 198, 202, 207, 208
Хорасан – 1, 29, 167
Хөҗәнд – 17
Хөма (шәһәр) – 29
Хөсна – 176, 180
Һәмдан (шәһәр) – 29
Һәрат (шәһәр) – 45
Һиндстан – 16, 24, 167, 172
Чакмагыш – 123, 128, 204
Чакмак – 114
Чаллы башы – 206
Чалпы – 98, 103, 114, 119, 140
Чебенле – 174
Чекә (Үргәнеч мәмләкәтендә) – 213
Чиләбе – 67, 182, 184, 200
Чирмешән елгасы – 126
Чирүле Шонталы – 121
Чистай – 121, 182, 185, 189, 206
Чишмә (станция) – 8, 132
Чишмә Сарт – 131
Чуалкиб (авыл) – 131
Чупай – 50
Чутай Завод – 84
Чокалы – 135
Шам (Димәшкъ, Сүрия) – 16, 26, 29, 33, 45, 182
Шарлама (Шәрләмә) – 139, 200
Шәйморза – 122
Шәлчәле – 73
Шәмәк (Тау ягындагы авыл) – 34
Шәңгәлче – 140, 214
Ширван – 28, 217
Шекә – 197
Шөгер – 48, 90, 154
Шушма елгасы – 57, 182, 206
Шушмабаш – 183

RUHIAT

Шыгай – 46, 50, 145
Шыңар – 137
Шырдан – 73, 90, 158
Ык елгасы – 54, 200, 213
Эстәрлебаш – 55, 114, 133, 174, 200
Эстәрле – 72
Эстәрле елгасы – 117
Эстәрлетамак – 37, 117, 133, 169, 174, 182, 194, 200
Югары Курса – 98, 149
Юбраш – 140
Югары Сәрдә – 158
Ямаширмә – 110, 202
Янгул – 64, 139
Янсыбы – 194
Янтоз – 204
Янык Шашы – 166
Яңа Әлмәт – 69
Яңа Гомәр – 169
Яңа Иштирәк – 73, 206
Яңа Кәшер – 43
Яңа Тазлар – 84
Яңа Сала – 62
Яңа Чаллы – 23
Япрук – 187, 213
Яубаш – 143
Яугилде – 210
RUHIAT

# Асар

Книга о биографиях,
датах рождения и смерти,
о других событиях из жизни мусульманских ученых
нашего государства

Автор: **Ризаэддин бин Фахруддин**

Том первый

RUHIAT

Допущено цензурой: 20 сентября 1899 года, С.-Петербург

Казань
Типо-литография Императорского университета
Оренбург. 1901–1904 гг.

## *От составителей*

Переиздание первого тома четырехтомного биобиблиографического сочинения татарского ученого, общественного и религиозного деятеля Ризаэддина Фахреддинова «Асар», надеемся, станет заметным событием в истории культуры тюркских народов России. Первый том, изданный в 1900-1904 годах в восьми частях, уже давно стал библиографической редкостью. Арабографические татарские издания не только не доступны для широкого круга современных читателей, но и для большой аудитории культурологов, историков, филологов, специалистов социальных дисциплин, интересующихся социокультурным состоянием татарского общества второй половины XIX–начала XX веков.

«Асар» был переведен на татарский язык с соблюдением норм современного языка, при этом особенности авторского стиля сохранены. В подготовленном тексте есть отдельные сокращения, которые составители посчитали возможным допустить в этом варианте издания. Страницы подлинника приведены в тексте после двойной косой линии в квадратных скобках.

Список личных имён и географических названий даны в конце текста. В издание включено и второе короткое авторское предисловие, которое Р. Фахреддинов написал в 1929 году, когда он намеревался переиздать свой труд. К сожалению, этот план остался неосуществленным.

С целью доступности труда для более широкой аудитории российских и зарубежных специалистов основной текст первого тома был переведен и на русский язык.

Составители выражают свою благодарность Марселю Ахметзянову, Алсу Арслановой, Ильясу Мустакимову, Сирене Багавиевой, Лилие Байбулатовой, Ильшату Гимадиеву, оказавшим свою помощь в процессе подготовки книги.

RUHIAT

## Место «Асар» в истории нашей культуры

